Хәбир Ибраһим
Газиз ярым
Пьесалар
КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2006

УДК 821.512.145-2
ББК 84(2Рос=Тат)-6
И13

**Ибраһимов Х.К.**

Газиз ярым: Пьесалар / Хәбир Ибраһим. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. — 318 б.

ISBN5-298-03925-1

Язучының әлеге китабына инде дистә елдан артык театрларда уңышлы уйналып килгән сәхнә әсәрләре тупланды. Китапка шулай ук тамашачыларыбызның мәхәббәтен яуларга өлгергән «Ялгыз тәкәрлек» телефильмының пьеса варианты да кертелде.

ISBN 5-298-03925-1
© Татарстан китап нәшрияты, 2006
© Ибраһимов Х.К., 2006

## ГАЗИЗ ЯРЫМ

*Ике пәрдәле мелодрама*

КАТНАШАЛАР:

Фәүзия.
Фазыл — аның ире.
Извиль — аларның уллары, 22–24 яшьтә.
Галимхан — ток (ындыр) мөдире.
Мөршидә — аның хатыны, иреннән җиде яшькә олы.
Сәкинә — аларның кызлары, 18 яшьтә.
Саимә — өлкән яшьтәге хатын.
Юлаучы.

Вакыйга авылда бара.

### БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

#### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Кышкы декорация. Галимханнар өенең алгы ягы (уң як). Сул якта кышкы урам, карлы тыкрык. Җил сызгыра. Вакыт төнгә авышкан.
Галимхан кызмача, үз-үзен кая куярга белмичә, әле бәсле тәрәзәгә, әле тәбәнәк урындыкта бер ноктага төбәлеп утырган Мөршидәгә усал гына карап ала.

Галимхан *(тешләрен шыгырдатып)*. Нишләп син мине көннәр буенча берни дә эшләмичә, кул кушырып саклап утырасың, ә?! Йөреп, бер әйләнеп кайтыр идең?! Елга бер генә тапкыр булса да, бертуган апаңны менеп күрер идең! Ул бит әллә кая Камчаткада тормый, авылда, арткы урамда гына тора. Оят түгелме сиңа?! Көн-төн корбанын саклап утыручы убырлы карчыкка охшата башладым инде мин сине! Ә?!

Пауза.

Дәшмисең... Дәшмә, дәшмә! Үкенерсең әле бер! *(Мөршидәгә якыная.)* Их! Дөмеккере! *(Бар көченә артсыз урындыкның аягына тибә. Мөршидә очып төшә.)*

Мөршидә. Әс...тәгы... *(Тыныч кына күтәрелеп, янә утыра.)*

Галимхан *(шашып).* У-у... у-убырлы! *(Өстәлгә йодрыгы белән суга. Маңгаен бәрә. Бәрә торгач, аңын җуеп егыла.)*

Мөршидә *(хыялый).* Яшәгән, ди, булган, ди... чибәр бер егет. Тимердәй таза, корычтай нык булган, ди, ул...

Галимхан *(аңына килеп).* У-у! Баш!

Мөршидә. Ел үсәсен ай үскән, ай үсәсен көн үскән, ди.

Галимхан *(көзгегә каранып).* Шишка чыккан... үсеп китмәсә ярый инде...

Мөршидә. Бу асыл егетнең булган, ди, бер бик чибәр, бер бик сылу сөйгән кызы...

Галимхан *(сискәнеп).* Ә?!

Мөршидә. Ул кызның исеме Фәүзия атлы булган, ди.

Галимхан *(төшенмичә).* Кем дисең?

Мөршидә. Көннәрдән бер көнне шул сылу кызны һич көтмәгәндә генә Дию пәрие урлап алып китә. Асыл егет, Акбүз атына атланып, аны Дию кулыннан тартып алыр өчен, сөекле Фәүзиясен эзләргә чыгып китә...

Галимхан. Тукта! Син нәрсә, ычкындың мәллә?! Нинди егет? Нинди Фәүзия? Нинди Дию? Җитте! Акылдан шаштырасың бит инде син мине! *(Пауза.)* Ә-ә... Ике көн өйдә кунмаган идем, шуның үчен алырга җыенасың инде миннән, шулаймы?! Соң, син дә кунма, бар! Мин сиңа тулы ирек бирәм. Кызны туганнарыңа җибәрдең бит, шәһәрдә ял итеп кайтсын, дип. Син дә аның белән бар идең, бер җилләнеп кайтыр идең! Миннән рөхсәт!

Мөршидә. Көн барган, ди, бу, төн барган, ди. Нәкъ ике көн, ике төн дигәндә, Дию яшәгән Кара Сарайга килеп җиткән, ди...

Галимхан *(үчекләп)*. Ә шул Сарай төбендә бер убырлы карчык утыра, ди... урындыкка артын терәп... Һәм шул карчык әйткән, ди, моңа...

Мөршидә. Әгәр дә сөйгән ярыңны шушы зәһәр Дию кулыннан кире тартып алырга теләсәң...

Галимхан *(төкереп).* Тфү!

Мөршидә. Минем сүземне ишет... тыңла...

Галимхан *(чыгырыннан чыгып).* Ә ул аны тыңлап-нитеп тормаган, буган да аткан, шулаймы?! *(Мөршидәне буып ала.)*

Мөршидә *(тыпырчынып).* Дөрес итми-сең, е-гетем... Тыңлап бетер сүземне... Акылыңа кил... *(Буыла.)*

Галимхан. Сиңа... сиңа акылга килергә вакыт. Мондый юләр әкиятләреңне миңа сөләмә бүтән, яме! Юкса... *(Аракы эчеп куя.)* Йа Хода, кайчан син минем күз алдымнан юк булырсың икән, ә?! *(Тәрәзә каршына килә.)* Кайчан?!

Мөршидә. Тыңлыйсың килмәсә, сөйләмәм. Тик атап әйтәм, Галимхан, синең бу кыланышларың яхшылык белән бетмәячәк... *(Пауза.)* Төш күрдем...

Галимхан. Нинди төш?

Мөршидә. Әкияти төш...

Галимхан. Ух! Тагын!

Мөршидә. Кап-кара болытлар йөзеп йөри чалт аяз күгебездә... *(Көйләп.)*

> Кара болыт йөзәдер,
> Кара болыт астыннан
> Кара сыер киләдер,
> Мөгезе күккә terәлгән...
> Му-у-у!
> Җилене җиргә терәлгән...

Галимхан. Җитте! Ишетәсеңме?! Шаштырасың бит! Син үзең әкият, син үзең төш! *(Балта алып, Мөршидәгә яный.)* Үтерәм! Гомерең белән саубуллашыр вакытлар җитте! Җитте!

Мөршидә *(торып).* Бер имчәгеннән май килә...

Галимхан. Йә син чыгып китәсең, йә мин сине чабып үтерәм!

Мөршидә. ...бер имчәгеннән кан килә, бер...

Галимхан. Җитте!

Мөршидә. Шуны аша да, шуны эч...

Галимхан. Мә! Кадалып кит!

Балта белән кизәнә. Мөршидә иелеп кала. Йөгерә. Галимхан аны куып китә. Абына.

Мөршидә *(саташып).* Фәләнгә тимә... хатыныңа тимә...
Галимхан. Үтерәм!!! *(Сикереп тора.)*
Мөршидә. Кагылма!

Аяк киемсез чыгып йөгерә.

**ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Галимхан тиз генә урын-җирне рәтли. Берничә мендәрне юрган белән каплап куя. Читтән караганда, юрган астында кеше ята сыман. Болдырга чыгып баса. Бераздан Фәүзия белән бергә керә. Фәүзиянең кулында бипс.

Галимхан. Менә, Фәүзиякәй, хәлләр шундыйрак бит әле! Карчык чирләп китте. Мөршидәм авырый...
Фәүзия. Ни булган?
Галимхан. Шайтан белсен! *(Фәүзия Галимханга карап куя.)* Ә ни... Кыш көне ни булсын инде... Салкын тигән, температурасы югары. Өй-тышлы яланаяк йөреп, салкын тидерде.
Фәүзия. Белмим дә инде. Мин өйгә ашыга идем шул. Фазыл көтә... Иртәгә калага китә, аны юлга җыйныйсы бар.
Галимхан. Ә карчык нишләсен, үлсенме?!
Фәүзия. Ярый, кайда авыру?
Галимхан (*урынга күрсәтеп*). Ята әнә...

Фәүзия караватк каршына килеп утыра. Бипсны ача, дарулар чыгара.

Ач юрганын...
Фәүзия. Нишләп син аны юрган белән томаладың? Сулыш алалмаенча тончыгып үлсә?! *(Ача.)*
Галимхан *(шашып).* Ха-ха-ха!
Фәүзия *(торып)*. Бу нинди кәмит?! Кая хатының?
Галимхан. Температурасы төшсен дип, мин аны башы белән кар астына тыккан идем. (*Ишекне биклэп куя*.)
Фәүзия. Шаярма! Шаяра торган нәрсә түгел! *(Әйберләрен җыя башлый.)* Ач ишекне!
Галимхан. Йә, йә! Кычкырган, тавышланган бул инде, сылу кыз! Котлыйм сине! Дию пәриенең нәкъ авызына килеп кердең! Ха-ха!
Фәүзия *(катгый).* Ач! Ишек бикләп кенә теләгеңә ирешә алмассың! *(Ишеккә атлый.)* Ач!
Галимхан. «Чү, ашыкма, дустым, сабыр ит...» Асыл кошым, син минем кулда! Син көчлерәк тыпырчынган, көчлерәк тиргәнгән саен, мин үземдә чиксез рәхәтлек сизәм.
Фәүзия. Ут белән шаярганыңны аңлыйсыңмы, юкмы?! Шәһәр җире түгел бу, авыл бу! Сиңа кергәнемне Саимә апай күреп калды.
Галимхан. Күрсен. Син бит авыру янына кердең, синең бит эшең шул, син — фельдшер. Син менә минем яныма кердең, син менә мине тикшер, минем йөрәгем авырта, йөрәгем бик каты сызлый. Йөрәгем генә түгел, бөтен җаным сызлый минем. Мә, менә тотып кара йөрәгемне! Җаным сызлана, җаным! (*Фәүзиянең кулын күкрәгенә сала.)*
Фәүзия *(кулын тартып алып).* Ул хәзер Фазылга кереп әйтәчәк, ә Фазыл мине көтеп тора.
Галимхан. Әйтсен! Көтсен! Көтсен гомере буе! Мин көттем бит әле! Мә, мә, тыңла йөрәгемне! (*Күлмәк изүен ерта*.) Ал приборыңны! Ал... алмасаң, үзем алам кочагыма! (*Кочмакчы була*.)
Фәүзия. Җибәр! (*Этеп җибәрә.)*
Галимхан. Җитәр, дисең дә, җитәр, дисең. Ә үзең... үзең минем кочагымда эрергә генә торасың.

Фәүзия Галимханны каты итеп этеп җибәрә.

Тыңла әле! Тыңла әле бер мине дә!
Фәүзия (*чигенеп*). Юк...
Галимхан. Утыр! Тынычлан, матурым, тыңла!
Фәүзия. Юк. Мондый хәлемдә мин сине тыңлый алмыйм.
Галимхан (*урындыкка күрсәтеп*). Ә шулай да?!

Фәүзия урындык кырына чүгәли.

Тыңла... һәм аңла. Кеше көчләүче яман адәм түгел мин. Шүрәле дә, Дию пәрие дә түгел. Сине көч кулланып алырга да теләмим, мине шулкадәр акылсызга санама. Син мине аңларга тиеш, без дошманнар түгел. Без бит кайчандыр бер-беребезне яраткан, чын-чынлап сөйгән кешеләр. Хәтерлисеңдер бит?

Фәүзия. Аз гына. Беренче мәхәббәт кебегрәк нидер булды бугай.

Галимхан. Синең өчен «кебегрәк» кенә булса, минем өчен чын мәхәббәт булды ул, чын! Беренчесе вә соңгысы. Аңла. Синең кире авылга әйләнеп кайтканыңа да инде җиде ел булды. Инде менә җиде ел мин үземнең җаныма тынычлык таба алмыйм. Җаным әрни, йөрәгем сыкрый. Нигә? Нигә дип кенә кайттыгыз соң сез, ә?!

Фәүзия. Әни өчен.

Галимхан. Әниеңне җирләгәнгә дә ничә ел булды бит инде, нәрсә тота сезне, нигә хәзер китмисез?

Фәүзия. Кайтулар, китүләр язмыш кулында шул.

Галимхан. Юк, сез белеп кайткансыз, минем җанымны ашар өчен кайткансыз! Кайтмаган булсагыз, онытып та булыр идем мин сине. Миңа мең мәртәбә җиңелрәк булган булыр иде. Ие... Күңел газабыннан да авыр нәрсә юктыр бу дөньяда! Ә бит без синең белән кавышырга тиеш идек, бергә булырбыз, дип, сүзләр дә куешкан идек. Әниең дә минем өчен үлеп тора иде, кайчан кермә, һәрчак ачык чырай белән каршы ала иде. Авылда безне зурлап *(көйләп)*:

И турыгыз, турыгыз,
Турыгызга нурыгыз.
Нурыгызга күз чагыла,
Яшел пәрдә корыгыз, —

дип җыр да чыгара башлаганнар иде бит инде. Оныттыңмыни соң? *(Көрсенеп.)* Их, язмыш безне үзенең җылы кочагында җылытыр дип хыялланып йөргәндә, ул безгә кара пәрдә корды да куйды...

Фәүзия. Кем гаепле соң?

Галимхан. Кем?! *(Пауза.)* Син... син гаепле!

Фәүзия. Ә син?

Галимхан. Ә мин нәрсә?! Ие, мине утырттылар. Нәрсә өчен? Ниндидер бер мәхлукка суккан өчен! Юк өчен утырттылар. Юк өчен! Ә син мине ике ел да көтә алмадың! Атна саен диярлек хат юллап тордым, ә син бер-ике җавап хаты яздың да шуның белән туктадың. Шәһәргә китеп, кияүгә чыгарга ашкындың бит, бала табарга... Йә, кем гаепле булып чыга соң инде монда? Уйлап кара?!

Фәүзия (*килешеп*). Ярар, мин гаепле булып калыйм. Инде хәзер нишләргә кушасың? (*Тора*.)

Галимхан. Фазылны ташларга, минем белән тора башларга.

Фәүзия. Ансат кына, иеме?! Ә мин сине яратам микән соң? Нишләп син шул турыда берни сорамыйсың?

Галимхан. Сорап торасы юк. Болай да күренеп тора. Мине ятратканың йөзеңә чыккан бит. Әнә яшерә дә белмисең, күреп, сизеп торам. Син бит ул ярым-йорты, чирләшкә Фазылыңа аптыраганнан гына, чыгар кешең булмаганга гына чыктың. Эш белән бара дигән буласың, дәваланырга бармый микән әле ул, ә?! *(Фәүзиягә үрелә.)* Аңла, без бер-беребездән башка яши алмыйбыз, без бер-беребезгә кирәк. Фәүзия... җаным-бәгърем... *(Фәүзияне коча.)* Син минеке...

Фәүзия, Галимханның яңагына сугып, ишеккә атыла.

Их! Аңламасаң да аңламассың икән! Юк, юк бу дөньяда дөреслек! Юк!

Фәүзия. Бар, бар ул дөреслек! Башта айнырга, аннан соң гына эзләргә кирәк. *(Ишекне тарта. Ача алмый.)*

Галимхан. Бар?! Ә кая ул? Менә мин үземнән ун яшькә олы, пачти карчык кеше белән гомер итәм. Яратмаган, күралмаган кеше белән гомер итәргә мәҗбүрмен! Ә яраткан кешем башкада, башка белән тыныч кына гомер кичерә. Йә, шушы да булдымы дөреслек?!

Фәүзия. Миңа иремнән башка беркем дә кирәк түгел. Нинди генә булмасын, ул минем яраткан, бердәнбер газиз ирем.

Галимхан. Газиз ярым, име! Ха-ха! Алдашма, сиңа килешми алдашу! Яратмыйсың син аны, яратмыйсың! Төкер ireңә, төкер балаларыңа! Мин дә хатынны яратмыйм, мин аның үлгәнен генә көтәм. Кызны тапкан вакытта да чак кына үлмичә калды, чөнки картаеп тапты. Шул чакта ук мин аңа үлем теләгән идем, үлем! Хәзер дә телим! Мин синең белән бергә булуыбызны телим!

Җил искән, буран купкан тавышлар килә. Урам якта Фазыл күренә.

Фәүзия. Юкка өметләнәсең. Аңла, минем ирем бар, яраткан кешем, мин аңа бервакытта да хыянәт итмәячәкмен.

Галимхан Фәүзия каршына килә.

Ишеттеңме?!

Галимхан Фәүзияне коча. Фазыл ишек кага.

Җибәр, ач! Ишек кагалар! Фазыл бу...

Галимхан. Әһә! Инде җанкисәгең дә килеп җиттемени? Торсын, торсын әле әзрәк салкында, дөньяның ни икәнен белсен! Ә без синең белән әзрәк кенә күңел ачып алыйк! Йә, үзең чишенәсеңме?! (*Чишендерә.)*

Фәүзия. Оятсыз! Җирбит! Җи-бәр! (*Ычкынырга тели.*)

Галимхан Фәүзияне урынга ега. Фазыл тәрзәгә килә. Күреп ала.

Галимхан. Карышма, файдасы юк! Син барыбер минеке!

Фәүзиянең күкрәкләре ачылып китә. Фазыл тәрәзәдән очып төшә. Фәүзия күлмәк якасыннан булавка алып, Галимханга кадый. Галимхан читкә сикерә. Фәүзия, тунын эләктереп, ишекне тибеп ача да урамга йөгереп чыга. Каршына Фазыл килеп баса.

**ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Галимхан (*артыннан кычкырып калып*). Ха-ха! Анасын карарга кайткан, имеш! Юк! Син мине яратканга кайттың, яныңда гел мине күреп торыр өчен! Килмешәк ирең моны исеңдә калдырсын иде! Их, җылы иде кочакларың, үзең мине кочакладың... (*Аракы эчеп куя.*)

Фәүзия. Фазыл...

Фазыл. Фәүзия!

Фәүзия. Нишләп торасың? Әйдә, киттек! Ул бит исерек. Шашкан ул. Киттек! (*Фазылны тарта.)* Киттек!

Фазыл карыша. Фәүзия тун якасы белән ачылып киткән күкрәкләрен каплый.

Киттек... Мин сиңа барын да аңлатырмын, тик монда түгел, киттек!

Фазыл. Син... кайт... Фәүзия... Мин аның белән сөйләшеп алырга телим!

Фәүзия. Син миңа ышанмыйсыңмы?

Фазыл. Мин сиңа гомерем буе ышандым, Фәүзия. Тик мондый хәлләрне күргәч, миндә шик туды.

Фәүзия. Ә нәрсә күрдең соң син?

Фазыл. Барын да.

Фәүзия. Күргәч, нишләп соң ишекне ватып кермәдең, нишләп тордың?!

Фазыл (*башын аска иеп*). Син бик тә үзгәрдең, Фәүзия. Яратмыйсың син мине!

Фәүзия. Яратуның монда ни катнашы бар? Ул бит мине өенә алдап алып керде, көчли башлады. Ә син?!

Галимхан болдыр алдына чыгып баса. Бипсны идәнгә тондыра. Бипс чәчелә. Фәүзия җыя. Галимхан тәмәке кабыза.

Галимхан. Ишек ватып керер өчен аңа кыюлык та кирәк бит әле.

Фәүзия (*елап*). Дәшмәс идең! Мин сине аңладым, син безнең тормышны бозарга җыенасың. Тик берни дә барып чыкмас! Әгәр дә син чын ир икәнсең, әйт иремә хәзер үк, мин аны үзем алдап алып кердем, аның бер гаебе дә юк, дип әйт!

Галимхан. Хатын-кыз үзе теләмәсә, аны көчләп кенә алып кереп булмый. Син үзең арттан ияреп кердең, үзең шуны теләдең, теләп бирдең...

Фәүзия (*чиксез ачу белән*). Кабахәт!

Пауза.

Минем башка әйтер сүзем юк. Киттек, Фазыл!

Фазыл. Син кайта тор, минем монда кайбер нәрсәләрне ачыклыйсы, сөйләшәсе сүзләрем бар.

Фәүзия. Нәрсә сөйләшергә була аның белән?! Аның һәр сүзе ялган бит! Син шушы кешегә ышанасыңмы?!

Фазыл. Сиңа акланып тору килешми, Фәүзия.

Фәүзия. Кайтыйк, Фазыл, сөйләшик өйдә, тик монда түгел, бу әшәке кеше янында түгел!

Галимхан (*көлемсерәп*). Минем кочагымда ятканда, болай ук тупас сөйләшмәгән идең, сандугач сыман сайраган идең.

Фазыл. Соңрак кайтырмын. Минем әле күп нәрсәгә төшенәсем бар, бу хәлнең төбенә төшәсе бар.

Фәүзия (*горур*). Яхшы. Кайтмыйсың икән кайтма. Бөтенләйгә кайтма! Икегез алдында да акланып торасым килми, минем намусым чиста!

Фәүзия чыгып китә. Фазыл белән Галимхан бер-берсенә текәлешеп карап торалар.

Галимхан. Йә, нигә дәшмисең?! Нәрсә карап торасың?! Телмә җанны — суксаң сук!

Фазыл. Минем беркайчан да кешегә сукканым булмады. Сугып кына мәсьәләне хәл итеп булмый.

Галимхан. Ә мин сугар идем. Әгәр мин синең урында булсам, сугып кына калмас идем, минем сөекле хатыныма орынган адәмнең башын борып атар идем!

Фазыл. Бу дөньяга һәр кеше үзенчә карый. Син бер төрле, мин икенче...

Галимхан. Барысы да синең күз алдыңда булды бит! Нәрсә, ышанмыйсыңмы булганына?!

Фазыл. Юк. Син аны алдап алып кергәнсең.

Галимхан. Син тыныч кына басып карап тордыңмы? Нишләп соң син миңа сукмыйсың? Сугарга көчең җитмимени соң? Көчең җитмәсә, мә, балта ал! *(Балта бирә.)* Мә, чап, өз башымны! Куркасыңмы? Куркасың шул! Куркак җан бит син! Син көчкә каршы тора торган адәм түгел!

Фазыл. Мин явызлыкка яхшылык белән җавап бирергә өйрәнгән.

Галимхан. Яхшылык йодрык белән була ул, агай эне!

Фазыл. Йодрык белән генә кешене төзәтеп булмый, бәхетне дә көч белән генә алып булмый. Кеше бәхетсезлегеннән дә бәхет корып булмый, анысын да онытма.

Галимхан (*Фазылны якасыннан каптырып*). Әй, син, килмешәк! Син миңа ничек яшәргә кирәген өйрәтмә, яме, мин үзем дә яхшы беләм. Акыллы булып, минем алда фәлсәфә сатып торма! Мин сине барыбер юк итәчәкмен, Фәүзиягә өйләнәчәкмен! Ул инде риза... Ә син кем соң?! Килмешәк син! Юньле ир, хатыны авылына кайтып, хатыны өендә яшәми. Синең кебекләрне, синең белән яшәсәләр дә, хатыннар барыбер яратып яшәмиләр. Ни кыяфәтең, ни чыраең юк бит синең! Хатыннар алар менә минем кебек, сукса, суга, кыйнаса, кыйный ала, сөйсә, янып сөя ала торган ирләрне сөяләр. Аңладыңмы? Әйе, мин бәхетсез, ләкин барыгызга да үч итеп мин барыбер бәхетле булачакмын! Сиңа яшәргә көн бирмәячәкмен, Фәүзия минеке булачак! Ул миңа үзе шулай дип әйтте! Ишеттеңме?! *(Фазылны ычкындыра.)* Йә, нигә дәшмисең? Нигә сукмыйсың? Ни көтәсең?

Фазыл. Син әле генә үз-үзеңә суктың, үз-үзеңне хөкем иттең. *(Китә башлый.)*

Галимхан. Син кая? Синең өең ул якта түгел, теге якта түгелме соң? Саташтың мәллә?

Фазыл. Без барыбыз да саташкан, безнең буын саташкан буын. Хуш, бәхил бул!

Фазыл китә.

Галимхан *(тунын киеп)*. Әй! Фазыл! *(Фазылны күрми.)* Туктале! Фу! Шайтан! Җир йоттымыни?! Катырак әйтеп ташладым, ахрысы! *(Кул изи.)* Әй, чукынып китсен! Өенә әйләнгеч юл белән кайтадыр ла ул. Ну, теттем тетмәләрен! Шул кирәк аларга! Тукта, мине бүген Зоя көтеп тора бит... станцада... Ә нәрсә! Ат җигелгән... Утыр да кит!

Чыгып китә.

Читтәрәк Галимханның: «На, малкай, на!» — дип кычкырган тавышы ишетелә. Урамның аргы башында Фазыл күренеп ала да, күләгә булып, арткы планга иңә. Моңсу көй агыла. Көйне поезд тавышы басып китә. Кайтаваз булып кире кайта. Караңгылык.

**ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Бу вакыйгадан соң ел ярымнар вакыт узган. Фәүзияләр өе. Урып-җыю вакыты. Бер төрле генә мебель. Уңда — бакча ягына чыга торган веранда, ишек. Извиль комод шүрлеген актара, акчалар чыгарып, тиз генә чалбар кесәсенә салып куя. Ишектә аяк тавышлары. Извиль комод ишеген ябып куя да, кәнәфигә килеп утыра. Фәүзия керә. Кулында торт.

Фәүзия. Уф, тәмам арыдым! Шул дарулар артыннан йөреп көнем үтте дә китте бүген. Районнан попуткага утырып кайттым. Улым, утыр, торт алып кайттым, әйдә, чәй эчеп алыйк. *(Тортны өстәлгә куя.)*

Извиль. Мин торт яратмыйм.

Фәүзия. Нигә?

Извиль. Аристократлар азыгы ул торт.

Фәүзия. Аш җылытыргадыр, бәлкем. Калган аш бар.

Извиль. Калган ашыңны мәчеңә җылыт.

Фәүзия. Дорфа. Кемгә охшап шулай булып тугансыңдыр инде син?! Эшкә мендеңме?

Извиль. Нинди эшкә?

Фәүзия. Ындыр табагына.

Извиль. Эшләп кем баеган. Юләрләр эшләсен. Ә мин эштән туйдым.

Фәүзия. Анаң белән сөйләшкәндә, башыңны күтәреп сөйләшер идең.

Извиль. Күтәрер идем дә, күтәрелми. Шөрепләре бушаган.

Фәүзия. Карап-карап торам да мин сиңа, тагын бер карап куям. Нишләп син әниең белән шулай тупас сөйләшәсең, ни җитми сиңа? Ни кирәк?!

Извиль. Машина... һич югында, матай.

Фәүзия. Нинди матай?

Извиль. Алсаң, ниндие дә ярар.

Фәүзия. Алырбыз. Тик башта әниең белән кешечә сөйләшергә өйрән. *(Чәй ясый. Улына карап-карап тора да чәй эчә башлый.)* Җил куып йөргәнче, гармунда уйнарга өйрәнер идең. Әтиең алып биргән гармунда.

Извиль. Миңа матай кирәк.

Фәүзия. Ниемә ул? Кызлар артыннан куаргамы? Сәкинәңне утыртып йөрергәме?

Извиль *(ярсып)*. Әни, ярар инде сиңа, ә!

Фәүзия. Яшермә. Синең Галимхан абыең кызы белән йөргәнеңне бөтен авыл белә. Шуның белән йөрмәсәң, башка кызлар беткән димени бу төбәктә?! *(Пауза.)* Ярар. Бу турыда синең белән әле ныклап сөйләшәсе булачак. Синең өчен борчылам. Укуны бетергәнеңә инде ике ел булды, ни укырга теләмисең, ни юньләп эшләргә! *(Пауза.)* Ярар, күтәр башыңны, алырмын мин сиңа матай, алырмын.

Извиль *(гармун күреген тартып).*

Их! Па-па по-дарил,
Па-па подарил,
Па-па подарил мне куклу!
Па-па!

Фәүзия. Абау! Бигрәк ямьсез җыр җырлыйсың, татарча бер җыр да белмисеңмени?

Извиль *(гармунын читкә атып)*. Юк инде ул, юк. Кеше бәхете лотерея уены кебек, отса — ота, отмаса — юк. Кемдер ота, кемдер юк. Джунгли законы! Әнә Гайнаннар машина алганнар, ә безнең ниебез бар? Миңа әтидән нәрсә калды соң?!

Фәүзия. Әтиеңнән зур нәрсә калды, аның рухы калды.

Извиль. Нишлим мин аның рухы белән, аны тотып та, ашап та булмый.

Фәүзия. Бар булган акчабыз сеңелкәшеңне дәваларга китте. Оныттыңмыни атаң үлгәннән соң баланың ни хәлдә булганын?! Хәзер менә ул калада дәү әниең янында, аңа җибәреп торам, аның гына пенсия акчасы җитми.

Извиль. Шуңар күрә дә мин беләм бернәрсә дә булмаячагын. Башкаларның булыр. Ә минем булмас. Чөнки башкаларның әтиләре бар, ә минем — юк. *(Тора.)*

Фәүзия. Кимсетмә үзеңне. Аллага шөкер, начар яшәмибез. *(Тора.)* Син миңа бүген ял итәргә бирәсеңме, юкмы? Мин бик тә арыдым... *(Извиль ишеккә атлый.)* Син кая?

Извиль. Алам. Барыбер алам.

Фәүзия. Ал соң. Тик нәрсәң белән алырсың икән?

Извиль. Алам. Үз акчама алам.

Фәүзия. Ә кая соң ул синең үз акчаларың?

Извиль. Менә алар! *(Кесәсеннән акчалар чыгара.)*

Фәүзия. Ни бу?

Извиль. Акча.

Фәүзия. Каян алдың?

Извиль. Орынма. Минекеләр. Шулар өчен җәй буе бил бөктем.

Фәүзия. Мин синнән нинди акчалар дип сорамыйм, каян алдың дип сорыйм?

Извиль. Комодтан.
Фәүзия. Ах, оятсыз!
Извиль. Алдым. Алырга хакым бар.
Фәүзия. Бардыр, әйтмим. Тик син миңа әйт: мин сиңа нәрсә ашатырга да, нәрсә киендерергә тиеш? Кызга каян алып җибәрим, ике ай акча алалган юк. Син шул турыда уйладыңмы, юкмы?
Извиль. Уйладым.
Фәүзия. Уйласаң, каян алдың, шунда куй! *(Извиль акчаларны идәнгә чәчә.)* Хулиган!
Извиль. Әле генә белдеңме! *(Ишеккә атыла.)*
Фәүзия. Син кая?
Извиль. Китәм. Поезд таларга.
Фәүзия. Син акылыңдамы?
Извиль. Акыл сиңа җитми ул. Синең уеңда без түгел, ә...
Фәүзия. Җитәр! Югал хәзер үк күземнән!
Извиль. Рәхәтләнеп.

Чыгып китә.

Фәүзия. Нишләргә инде? Улым! Бернишләп тә булмый бу бала белән! *(Акчаларны җыйганда, фоторәсем табып ала.)* Бу кем тагын? Ә... Сәкинә! Галимхан кызы. Димәк, белмичә сөйләмиләр. Кызык. Галимхан моңа үзе ничек карый икән? *(Фотоны карый.)* Чибәр! Коеп куйган Галимхан! *(Ертып ата.)* Мә сиңа!

**БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Саимә керә.

Саимә. Исәнме, күрше!
Фәүзия. Исәнме, Саимә апай.
Саимә. Улың белән талашып алдым дисең инде алайса?!
Фәүзия. Каян белдең? Кем сөйләде? *(Акчаларны җыйнап, комодка сала.)*
Саимә. Идәндә яткан акчалар сөйләде.
Фәүзия. Кая чыгып чапты инде ул?
Саимә. Әллә эзләп кайтыргамы?
Фәүзия. Кирәкми. Әнисен яратса, кайтыр.
Саимә. Анысы да дөрес.
Фәүзия. Мин аның начар компаниягә эләгеп, начар юлга кереп китүеннән куркам. Тәмам юлдан ычкынып бара. Поезд таларга китәм дип әйтеп чыгып китте.
Саимә. Булмас. Поезд талый торган егет түгел лә ул. Ирең поездга тапталып үлгәннән бирле, шул поезд тәресе белән җенләнә инде ул. *(Утыра.)* Бик авыр кичерде атасының үлемен. Кызыңны инде әйтәсе дә юк. Кайчан үткәрдең әле ireңнең ел ашын?
Фәүзия. Гыйнварда.
Саимә. Әй, онытканмын да инде. Ялгышлык белән килеп керде инде ул поезд астына, ялгышлык белән.
Фәүзия. Мин алай уйламыйм. Килгән поездны гына күрер иде. Ул ике арада, ике поезд арасында калган. Поезд машинистлары шунда тагын бер кешене күреп калганнар, тик аның кем булуын гына ачыклый алмадылар.
Саимә. Берәрсен гаепле дип саныйсыңмы?
Фәүзия. Әйе. Үземне. Аның үлемендә бары тик мин генә гаепле.
Саимә. Үлгән кеше алдында барчабыз да үзен гаепле итеп сизә инде.
Фәүзия. Аның үлемендә тагын икенче кеше дә гаепле, ләкин ул үзенең гаебен танырга теләми.
Саимә. Кем ул?

Пауза.

Нишлисең инде! Үлгән артыннан үлеп булмый, диләрме әле! Ничек тә яшәргә кирәк. Бүген иртән, почтага төшеп, малаема посылка җибәрдем. Өч пачка цэйлүнский чәй, өч кила яхшы прәннек, бер пар оек... Ә киленгә шәл...

Фәүзия. Нинди шәл?

Саимә. Кибет шәле. Шулкадәр дә матур инде, мин сиңа әйтим, бөтен җире ялтырап тора! Бәясе дә очсыз гына...

Фәүзия. Малаең кайтып алам дигән иде түгелме соң?!

Саимә. Кайтыр, Аллаһы боерса, кайтыр! Себер яклары бик тә ерак бит. Әй, анда китеп тә! (*Чыраен сытып.)* Килен бик усал. Нишләп бу киленнәр шулай усал булалар икән?

Фәүзия *(түземлеген җуеп).* Саимә апай, син йомыш белән кердеңме соң?

Саимә. Әй! *(Исенә төшеп.)* Онытып та торам! Вәт тити баш, ә! Бүген почтадан кайтышлый ындыр табагына дип менгән идем. Пенсионерларга икмәк бирә башлаганнар. Анда, беләсеңме, кемне күрдем?! Галимханны! Фәүзиягә әйт, бүген төнлә җиде капчык бодай төшерәм, көтсен, каршы алсын, ди. Алай да, бигрәкләр дә уңган кеше булып чыкты инде бу Галимхан! Бәхете генә юк, хатыныннан уңмады. Теге төндә аягын өшеткәннән соң, бөтенләй рәте китте мескеннең. Бусы — бер. Тагын бер шатлыклы хәбәр бар синең өчен. Галимхан, Мөршидәсеннән аерылып, сиңа өйләнергә тели.

Фәүзия *(киная белән)*. Рәхмәт, шатландырдың.

Саимә. Юләр син. Шундый ирне кулдан ычкындыралар димени инде! Акчалы, абруйлы. Ялгызың гына яшәмәссең минем күк. Сиңа да бит тормышны алып барырга кирәк. Ә тормыш итү бик җиңел түгел хәзер, җиңел түгел. Яшьрәк булсам, үзем дә чыгар идем әле...

Фәүзия. Әле дә соң түгел.

Саимә. Көл инде, көл. Фазыл үлгәннән бирле, гел миңа кырын карый башладың. Ә бит без синең белән чыбык очы гына булса да туганнар. Әйе, хәбәрен җиткердем инде, синең Галимханнарга кереп киткәнеңне күргәч тә, Фазылга әйтмичә булдыра алмадым. Мин намуслы хатын, намусым чиста, саф минем.

Фәүзия. Телем кычытты, диген инде.

Саимә *(ишетмәгәнгә сабышып).* Уйла! Андый ирне ычкындырма. Малаең да Галимхан кызы белән йөри дип ишеттем, болай булгач, берьюлы ике туй ясаячаксыз инде! *(Кеткелдәп көлә.)*

Фәүзия. Саимә апай, нишләп һаман кеше тормышына тыгыласың, ә?!

Саимә. Йә, йә! Әйттем исә кайттым! Җиде капчык икмәкнең икесе миңа дип әйтте Галимхан. Өчне бирсә дә каршы килмәм. Биргәндә алырга кирәк. *(Машина килеп туктаганы ишетелә.)* Төште, Ходайның рәхмәте! *(Тора.)* Син аны яхшылап каршы ал инде, кешечә! Бераздан кереп чыгармын, хуш булып тор!

Бакча ягыннан чыгып китә.

Фәүзия. Нишләргә?

**АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ**

Галимхан керә.

Галимхан. Нишләп каршы алучы юк? *(Фәүзиягә.)* Саимә апай әйткәндер бит?

Фәүзия. Әйтте.

Галимхан. Әнә бар, чыгып кара! Шыгырдап торган җиде капчык бодай! Бел кадеремне!

Фәүзия. Рәхмәт. Мин синең урлап төшкән бодаеңа мохтаҗ түгелмен.

Галимхан. Урланган түгел, яздырып төшкән. Үз исемемә. Мин анда үзем хуҗа.

Фәүзия. Яздырып төшкәнсең икән, кире менгер йә әнә Саимә апайга бир.

Галимхан. Кызык. Яз көне фураж сорап теңкәмә тидең, ә хәзер төшереп биргән икмәктән дә йөз чөерәсеңме? Ни булды сиңа? Чыраең да болай вагон астыннан чыккан сыман түгел иде.

Фәүзия. Буялырга теләмим.

Галимхан. Кем буйый әле сине?! Минем үз гомеремдә беркемне дә буяганым булмады. Ташлале шул үпкәләвеңне!

Фәүзия ишеккә бара.

Кая?!

Фәүзия. Киттем. Икмәгеңне кире менгер, соң булмасын!

Чыгып китә.

Галимхан. Ни булган моңа? Болай ук киребеткән нәрсә түгел иде!

Бакча ягыннан Саимә керә.

Саимә. Киттемени?! Үләксә! Синең кебек ирләрне табарга кирәк әле аңа!

Галимхан *(өстәлгә күз ташлап).* Ичмасам, тамак асты да кытыклап тора.

Саимә. Минем буш кул белән йөргәнем юк. Мин изгелекне аңлый торган кеше.

Итәк астыннан бер шешә аракы чыгара. Галимхан көлә. Өстәл янына утыралар. Галимхан шешәне ачып, бер стакан аракы эчеп җибәрә.
Саимә дә йотып куя.

Саимә. Бик тә хөрмәт итәм мин сине, Галимхан. Белмим, бу Фәүзиягә ни җитми торгандыр инде?! Синнән дә йөз чөереп маташкач, белмим инде...

Галимхан. Акыллы хатын булсаң, әйт әле син миңа, бу Фәүзияне ничек итеп кулга төшерергә, ничек шуны үземә каратырга була? Аптырадым. Берничек тә барып чыкмый бит...

Саимә. Болай итеп кара. Балалар ягыннан килеп кара. Балаларының күңелен күрә алсаң, аның белән дә бик тиз якыная алырсың. Хатын-кыз шундый нәрсәгә үлә дә китә инде ул.

Галимхан. Акыллы киңәш. Тик ничек?

Саимә. Акчалы бит син. Бай.

Галимхан. Зарланган юк болай. Кыш саен Себердә эшләп кайтам. Быел машина алдым менә...

Саимә. Ә Фәүзиянең малае матай алалмыенча йөри... аптырап.

Галимхан. Матай! Алып бирәм мин аңа матай! Сүз дә юк!

Саимә. Кызы Сәрия Фазылның әнисендә яши, акчалары җитми. Аңа төртсәң дә була әзрәк.

Галимхан. Булды. Эшләрбез. Акча җибәрермен мин аларга. *(Эчә.)* Акыллы киңәш бирдең, рәхмәт. Ә хәзер мине тыңла...

Саимә. Тыңлыйм, тыңлап кына торам.

Галимхан. Берәр иреннән аерылган яисә уйнаштан бала тапкан балалы хатын-кыз юкмы синең тирәдә?

Саимә *(уйлап).* Бар. Минем туганнан туган сеңлем бар. Ул районда яши. Менә аның кызы Рамилә иреннән аерылып кайтты. Калада яшәгәннәр. Ире бик каты эчкән...

Галимхан. Бик яхшы. Ул Фазылның сөяркәсе булган дип фараз кылыйк. Малае Фазылдан булыр, ягъни Фазылныкы булыр.

Саимә. Әстәгы...

Галимхан. Шулай, Саимә апай, шулай. Фәүзия күз алдында Фазыл һаман да әүлия булып тора. Фазылны каралтырга, аның данын сатарга вакыт җитте. Болай ит син: хат оештыр. Шул хатыннан Фәүзия исеменә хат яздыр. Хатта Фазыл аның сөяркәсе булганын, Фазылдан баласы калганлыгы турында язсын. Булдыра алырсыңмы?!

Саимә. Тырышып карарга кирәк булыр инде.

Галимхан. Тырышып карарга гына түгел, булдырырга кирәк. *(Кесәсеннән акча чыгара.)* Мә! Менә шул хатынга бирерсең! Шулай, шулай, акчасыз хәзер берни дә эшләнми. Ал, тыгып куй!

Саимә *(акчаны итәк астына тыгып).* Анысы шулай, анысы шулай инде. Әгәр беленсә... соңыннан?

Галимхан. Соңыннан сер ачылса да ярый. Ул чакта Фәүзия инде минеке булыр! Ха-ха!

Саимә. Шулаен шулай да... Син өйләнгәнче, кызың Сәкинә чыгып куймасын дим әле мин Фәүзия малаена.

Галимхан. Әйе, ишеттем, беләм. Әлегә миннән килеп кыз сораучы юк. Сизеп торам, яшьләрнең кавышуына Фәүзия пыр тузып каршы булачак. Минем белән, бигрәк тә Мөршидә белән туганлашудан курка ул. Әгәр яшьләр өйләнешсәләр, мин каршы килмәячәкмен. Тик бездән соң, без Фәүзия белән кавышкач. Әгәр алар алдан өйләнсәләр, безнең берни дә барып чыкмаячак.

Саимә. Нигә?

Галимхан. Мөршидә бозарга мөмкин эшне, Мөршидә.

Саимә. Бигрәк мескен кеше инде ул синең Мөршидәң!

Галимхан. Таптың мескен кеше! Тыштан гына шундый мескен булып күренә ул, эчтән явыз, ай, явыз. Аздылар бу хатыннар! Беләсеңме кем аздырды аларны? Дәүләт аздырды, дәүләт. Мин Илбашы булсам, бу кадәр үк ирек бирмәс идем аларга!

Саимә. Элек хатын-кызлар башкачарак иде шул. Тыйнак, сабыр иделәр. Ир сүзеннән чыкмый торганнар иде. Менә минем апайның борчак хәтле генә, кечкенә буйлы ире (үлде инде, мәрхүм!) тетмәсен тетә иде колга кадәр озын апайның! Буе җитмәгәч, урындыкка менеп кыйный иде апаны.

Галимхан. Ничек түздең? Нишләп бәреп төшермәдең урындыгы-ние белән?!

Саимә. Бәреп төшерер идең дә бит, арага керергә ярамый.

Галимхан. Нигә кыйный иде соң ул аны?

Саимә. Көнләшеп. Үзе гомер буе йөрде. Апайдан көнләшеп туялмады. Иртән торгач, сорыйм инде апайдан. Нишләп, мин әйтәм, шундый зур гәүдәң белән шул бүтәкә иреңнән үзеңне кыйнатып торасың, дим. «Әй балакаем, ярамый бит, ир хакы бит, ир хакы...» — дия иде.

Галимхан. Менә монысын дөрес әйткән. Менә шул ир хакын онытып бара хәзерге хатыннар. Шуңар хатыннар баш булып йөри хәзер, шуңар күрә дә дөньяның рәте-чираты китте.

Саимә. Әйе шул, хатын-кыз тормышын әйтмә дә инде син. *(Эчеп куя.)* Мине сугыш ирсез калдырды. Апай кияүгә чыгып та бәхет күрмәде. Апайны кияүгә биргәндә (*көйләп*):

Караватта өч такта,
Минем апай бер якта.
Шул тактаны кызганып,
Саталар җиде ятка, —

дип җырлаганнары әле дә истә... *(Тора. Башы әйләнә.)* Ай... әллә күбрәк китте инде...

Галимхан. Утыр, торма!

Саимә *(бер ноктага төбәлеп).* Шушы Фазыл үлгәннән бирле җанымның тынычлыгы бетте. Кашын җыерып, килә дә баса, килә дә баса каршыма!

Галимхан. Кара аны! Кабер ташы күтәреп кайтып керә күрмәсен!

Саимә. Алла, диген! *(Карана.)* Тфү, тфү, китте... *(Утыра.)*

Галимхан. Ярар. Миңа китәргә кирәк.

Саимә. Кая?

Галимхан. Хатын-кыз ир-атны юньләп каршы алмаса, ул кая бара? *(Пауза.)* Ул икенче хатын янына бара.

Саимә. Кирәкми, йөрмә. Йөрмә дәрәҗәңне төшереп! Йөрмә шул бозык марҗаң янына! Бер Фәүзияне генә ничек тә күндерербез әле! Уф, башым... әйләнә...

Галимхан *(йодрыгы белән өстәлгә сугып).* Их, бар иде яшь чаклар! Ник кенә бу авылга әйләнеп кайтканмын?! Кайда гына булсам да хөрмәт итәләр иде үземне. Чөнки беркайчан да түбән төшмәдем, үз-үземне юкка рәнҗеттермәдем. Армиядә чагында миңа багышлап җыр да чыгарганнар иде әле! Грузин егетләре! Ничек әле ул?! Ә? Әйе! Асса *(көйләп):*

Галимджан, Галимджан,
Приходи на лавка.
Будем есть баклажан,
Разный, прочий травка.

Их! *(Биеп китә.)* Асса! Асса!

*Саимә дә кушыла, бииләр.*

Галимхан *(туктап).* Киттем, исән бул!

Саимә *(ябышып).* Юк, җибәрмим!

Галимхан. Бу дөнья бер Фәүзиягә генә килеп туелмәгән! Асса! *(Чыгып китә.)*

Саимә. Асса... Асса... *(Кәнәфигә ава.)*

**ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Машина кузгалып киткән тавыш ишетелә. Бакча ягыннан Извиль, Сәкинә керәләр.

Извиль. Сәкинә! Кер, тартынма! Мин сиңа әйттем бит, өйдә беркем дә юк, дип. Әнинең гадәтен яхшы беләм, берәр нәрсә булса, чыга да китә кая да булса.

Сәкинә *(туңып).* Салкынайтты! Каттым!

Извиль. Көзгә авышты, шуңар салкын. Утыр, җылынып алыйк.

Сәкинә. Әниең кайтып керсә?

Извиль. Кайтса кайтыр, ишек ачык. Качып йөри алмыйм. Бала-чага түгелмен. Ә бәлкем, җае чыгып, бүген барысын да хәл итәрбез?! *(Утыралар.)*

Сәкинә. Нигә дәшмисең?

Извиль. Дәшми утыруың рәхәт. Сүздән гауга чыга, ә гауга чыккач, үзең беләсең...
Сәкинә. Безнең киләчәк сине борчымыймы?
Извиль. Сөйләштек бит инде. Тиздән өйләнешәбез. Кияү белән кәләш без хәзер.
Сәкинә. Кем әйтте?
Извиль. Менә мин әйтәм.
Сәкинә. Бар да уенга охшаган. Безне беркем дә санга сукмый. Беркем дә безгә ризалыгын бирергә тормый. Анаң каршы, минеке дә каршы. Әтине аңламассың, аның акылы үзе белән!
Извиль. Ничек уйлыйсың, минем әти каршы булыр иде микән, әгәр исән булган булса? *(Пауза.)* Юк. Ул каршы килмәс иде. Ул миңа, яраткан кешеңә өйлән, улым, яраткан кешең белән генә бәхетле булып була, дия торган иде. Син борчылма, Сәкинә, каршы килмәсләр. Аларның бер-берләрен күралмаганга безнең ни гаебебез бар? Каршы төшсәләр, үзләренә үпкәләсеннәр!
Сәкинә. Фатихасыз гынамы?
Извиль. Ие. Ә нәрсә?
Сәкинә. Шәригатькә сыймас.
Извиль. Сыймаса сыйдырырбыз. Сыймый икән, дәү әни янына таярбыз. Сәрия дә шунда. Анда минем әтинең әнисе яши. Карт инде ул. Безне үзенә яшәргә чакырып хатлар язып тора. Кала янындагы поселок тибындагы бер авыл ул. Анда май заводы бар, шунда эшкә керермен. Сиңа укырга кирәк, шуннан калага йөреп укырсың. *(Пауза.)* Син миңа ышанасыңмы? *(Сәкинәне кочагына ала.)*
Сәкинә. Сиңа ышанырга да, сиңа сыенырга да була. Миңа аз сүзле егетләр ошый. Синнән башка миңа бу дөньяда беркем дә кирәк түгел. Мине беркем дә аңламый синнән башка. Шуңар күрә бер-беребезне беркайчан да юкка рәнҗетмик. Бердәнбер яраткан кешем син минем. Мин үз йөрәгемне кулыма алдым, телисең икән, син дә ал, теләмисең икән, кагылма — кире үз урынына куярмын.
Извиль. Сине рәнҗетсәң, җир йотар, Сәкинә. Син миңа ошыйсың, яратам мин сине. *(Онытылып кочаклашалар.)* Сәкинәм... *(Кулына гармун алып, тыныч кына уйный. Көй агыла.)*
Сәкинә. Извиль, уйнале без яраткан көйне?!
Извиль. Хәзер, матурым! *(Уйный.)*
Извиль
Сәкинә } *(икесе бергә җырлыйлар).*

Күзләремә бер каравың җитә,
Бөтен кайгылар да югала.
Әле дә ярый син бар бәхетемә,
Әле дә ярый син бар дөньяда...

Кыштырдаган тавыш ишетелә.

Сәкинә. Т-с-с! Өйдә кемдер бар!
Извиль. Кем булсын монда? *(Гармунын куя. Сәкинәне үбә.)*

Кәнәфидән Саимә күтәрелә.

Сәкинә. Әнә әниең өйдә икән бит! Йоклап кына яткан! Киттек, тизрәк, Извиль!

Бакча ягына йөгереп чыгып китә. Башындагы яулыгы төшеп кала.

Саимә *(торып)*. Кайда соң мин? Ә?! Мин кая? *(Карана.)* Берни дә аңламыйм... Исәнме соң мин? *(Үзен чеметеп карый.)* Исән икән... *(Извиль торып баса.)* Кит... (*Саташып.*) Фазыл, кит! Ни кирәк сиңа? Кит!
Извиль. Саимә апай, саташма, бу бит мин... Извиль...
Саимә *(йөзен каплап).* Кит, кит! Синең алда минем бер гаебем дә юк. Килмә яныма! Кит! *(Извиль Саимәгә якынлаша.)* Кит! Тфү, өрәк, тфү! *(Тәрәзәдән сикерә.)* Ай... бетте аягым! Аягым! Иблис тәресе... Ай...
Извиль. Әкәмәт! *(Карап тора.)* Сәкинә... Син кая? Тукта, кызык сөйлим үзеңә! *(Сәкинә артыннан йөгерә.)*

**СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Фәүзия керә. Арыган, талчыккан. Шулай да кәефе күтәренке. Шәл бөркәнгән, кәнәфигә сөялә.

Фәүзия. Нинди көн булды соң бу? Нинди көн һәм нинди төн килде? Фазыл... Без йөргән, без хозурланган урыннардан әйләнеп кайттым. Газапларга салдың да... китеп бардың... Юк, Фазыл, юк, син һаман да безнең арада... Бер тартылам сиңа, бер аерылам синнән... Үлемеңә ышанасым килми... Аңа ышану мөмкин дә түгел бит, Фазыл... Син күл буенда йөрергә ярата идең, ул ничектер шыксызланып, бушап калган... Фазыл... (*көйләп*):

Авыл күле тирән икән,
Буйлаганым булмады.
Бу хәсрәтләр килер диеп,
Уйлаганым булмады.
Ялгыз үрдәк оча күлдә,
Шаулый бөдрә тал.
Газиз ярым, назлы җырым
Булып мәңге кал.
Кадереңне белмәгәнмен,
Соңлап аңладым.
Хушлашмыйча китеп бардың,
Кайта алмадың.
Иртә торып сулар сибәм
Роза гөлемә.
И Ходаем, бир бәхетне
Килер көнемдә...

Тора. Идәндә Сәкинәнең баш яулыгын күреп ала. Күтәрә.

Бездә Сәкинә булган, улым тагын чыгып качкан... *(Елый.)* Тол хатынның күз яшьләрен берәү дә күрми дип сөйлиләр, шушыдыр инде... *(Тәрәзә каршына килә.)* Кая син, юньсез малай? Әниеңне кемгә алыштырдың? Нишләргә? Әллә соң язмышка буйсыныргамы? Бирегез берәрегез киңәш! Нигә... нигә барыгыз да мине ташладыгыз?!

Моңсу көй агыла.

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Фәүзияләр өе. Веранда ягы. Өстәлдә самавыр, чәй сервизы, ваза. Извиль урындыкта утыра. Гармун күреген тартып, яңа көй өйрәнә.
Сәкинә, диварга сөялгән хәлдә, уйга талган.

Извиль. Сәкинә! Безнең булачак туебызда җырларга мин бер яңа җыр иҗат итәргә булдым. Сүзләре тел очымда тора, тик менә көе генә авыр чыга...
Сәкинә. Ә мин туй буласына ышанмыйм.
Извиль. Юк сүз сөйләмә, ышанырга кирәк. Безнең хыяллар кайчан да булса бер тормышка ашарлар. Ә, менә... менә көе килеп чыкты *(көйләп)*:

Җилләр исә ярларга,
Дулкын бәрә кыяга.
Ак пароход күренсә,
Чынга аша хыял да...

Галимхан керә.

Галимхан *(кәефсез).* Ә-ә! Сез мондамыни, качкыннар?! *(Извильгә.)* Әниең кайда соң?
Извиль *(гармунын куеп).* Минем аны күргәнем юк. Кайда йөргәнен төгәл генә әйталмыйм.
Галимхан. Матай йөриме?
Извиль. Рәхмәт, йөри. Галимхан абый, акча алу белән үк мин синең белән исәп-хисап тотармын.

Галимхан. Йөрегез рәхәтләнеп. Исәп-хисап тотарга сораучы юк сездән. Бүләгем булсын! *(Пауза.)* Исәнме, кызым! Сине хәзер өйдә күреп тә булмый!

Сәкинә. Исәнме... Мин өйдә беркемгә дә кирәк түгел.

Галимхан *(кискен).* Карагыз әле, яшьләр! Мин сезнең белән сөйләшкән идем бит инде, башта мин өйләнәм, аннан соң гына сез өйләнешерсез, дип. Сез сүзегездә тормадыгыз. *(Пауза.)* Миннән бернәрсәне дә яшерә алмыйсыз. Әле генә авыл мулласын күрдем. Сез аңардан җомга көнне сезгә никах укытуны сорагансыз икән. Дөресме бу?

Извиль. Гафу ит, Галимхан абый, без сезнең әни белән тарткалашып торганыгызны көтеп тора алмыйбыз. Безнең үзебезнең планнарыбыз бар...

Сәкинә *(Галимханга).* Ә әнине кая куясың?

Галимхан. Беркая да куймыйм. Аерылам. Разводка бирдем. Шушы бер-ике көндә хәл ителер дип уйлыйм. Хәзер барысын да акча хәл итә.

Извиль. Юк, без көтә алмыйбыз...

Галимхан. Миңа каршы сөйләүчеләрне сөймим. Әгәр мин теләсәм, сез бөтенләйгә дә өйләнешә алмаячаксыз!

Извиль. Берни дә барып чыкмас. Без теләсә нинди киртәләрне дә җиңеп чыгарга әзер!

Галимхан. Әгәр дә мин бер серне ачсам! *(Пауза.)* Извиль! Син минем улым! *(Пауза.)* Сәкинә минем кызым. Ә бертуганнар үзара өйләнешә алмыйлар.

Сәкинә *(ышанып).* Ничек? Извиль синең улы-ың?!

Галимхан. Әйе. Ә нигә шаккатасың аңа! Фәүзия апаң минем беренче мәхәббәтем. Извиль шул мәхәббәтнең җимеше. Кхым!

Ачудан ярсыган Извиль сикереп тора. Аяк астында аунап яткан кисәү белән Галимханга томырмакчы була. Кизәнә, тик бакча ягына тондыра.

Извиль. Мин моңа ышанмыйм! Бу чеп-чи ялган!

Йөгереп чыгып китә.

Сәкинә. Әти! Нишләп син шундый явыз кеше, ә?! Син бит дөрес сөйләмисең? Син шаярдың гына, шулай бит?!

Галимхан *(көлеп җибәрә).* Ә дөреслек бармы соң бу дөньяда?!

Мотоцикл кузгалган тавыш ишетелә.

Сәкинә. Их, син, әти! Шулай шаяртырга ярый димени?! Шушы телеңне! Извиль! Тукта... акыллым... акрын...

Чыгып китә.

Галимхан. Ха-ха! Тәэсир итте! Ха-ха!

Ишектә аяк тавышлары.

**ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Галимхан арты белән борылып утыра. Фәүзия керә.

Фәүзия *(сискәнеп).* Йа Ходам! Кем син?

Галимхан. Кер, кер, курыкма, өеңдәге кебек бул! *(Фәүзиягә таба борыла.)* Инде кеше дә танымый башлагансың икән!

Фәүзия. Син ничек монда?

Галимхан. Сине көтәм.

Фәүзия. Нишләп өеңә кайтмыйсың?

Галимхан. Сүзем бар.

Фәүзия. Ни турында? *(Пауза.)* Кайт өеңә, хатының көтеп тора торгандыр!

Галимхан *(торып).* Кума! Бик тиз куасың! Мин сиңа бер дә ошамыйммыни соң? Ошыйммы мин сиңа, юкмы? Теге гыйнвар төнен тагын бер кат искә алыйк мәллә, ә?! *(Якынлаша.)* Ул төнне син шундый чибәр, шундый сылу идең бит. Тәнемне, канымны кыздырып тора идең! Ә син миннән көлдең ул төнне... Көл хәзер дә, нигә көлмисең, ә?! Көлә алмыйсың шул, чөнки язмыш синең үзеңнән көлде, елатып, кычкыртып көлде! Ха! *(Пауза.)* Хәзер син минем кулда. Яклар кешең дә, ирең дә юк. Сөекле ирең дә,

сөяркәң дә хәзер мин инде, мин! Мин, бер мин генә! Ишетәсеңме?! Кил, кил, иркәм, кил инде, кочакка кер инде! *(Фәүзиягә үрелә.)*

Фәүзия. Кит! *(Галимханның кочагыннан ычкынып, аның яңагына суга.)* Кит, дим... *(Елап, кулы белән йөзен каплый.)*

Галимхан. Юләр...

*Пауза.*

Мин сиңа суга аламмы соң?! Ни өчен күралмыйсың син мине, аңламыйм. Нишләп син һаман да минем турыда начар фикердә йөрисең?!

Фәүзия. Калдыр мине. Бир тынычлык.

Галимхан. Китәрмен. Тик сиңа әйтер сүзем бар. Яңакка тондырмаган булсаң, бәлкем, гомер сиңа әйтеп башкаралмаган булыр идем. Хәзер... хәзер миңа барыбер...

*Пауза.*

Мин Фазылның үлемен күрдем. Әйе, әйе, Фазыл поезд астына эләккәндә, мин дә аның белән янәшәдә булдым.

Фәүзия. Син?!

Галимхан. Мин... Ул үлгәннән соң, авыл халкы арасында, Фазыл үз үлеме белән үлмәде, аны үтерделәр, дигән хәбәр дә таралып өлгергән иде...

Фәүзия. Мин ышанам аңа.

Галимхан *(кычкырып).* Ялган! Чеп-чи ялган. Фазылның ничек үлгәнен бер мин генә беләм, мин генә! Бер мин генә күрдем!

Фәүзия. Поезд машинистлары күреп калган икенче кеше син булган, димәк?!

Галимхан. Мин.

Фәүзия. Димәк...

Галимхан. Юк, син уйлама, мин Фазылны үтермәдем. Син әле күп нәрсәне белмисең... Теге гыйнвар төнендә мин ат җигеп станцыга китеп бардым. Яшермим, инде хәзер әйтсәң дә ярыйдыр, минем анда кереп, кунып йөри торган бер хатыным бар...

Фәүзия. Беркөнне дә шуның янына чаптыңмы?

Галимхан. Бүлдермә. Ләкин ул хатын да, аның салып биргән көмешкәсе дә минем күңел сагышымны баса алмады. Күңелдә ниндидер үкенү хисе калган иде. Иртәнге якта ул тагы да көчәйде. Иртәнге бишләр, алтылар иде бугай. Таныш кеше очрамасмы дип, станцыга чыктым. Чыксам, вокзал каршында Фазыл басып тора. Поезд көтә. Аны күргәч, сөенеп киттем, сөйләшәсе, аңлашасы килде аның белән. Бер ялгансыз әйтәм, мин аңардан гафу үтенергә теләдем. Ә ул, мине күрүгә үк, нигәдер тимер юл ягына йөгерде. Бераз югалып та торды ул. Аннан поезд килеп туктады. Мин дә аның артыннан тамбурга сикереп мендем. Ә ул икенче якка сикерде. Мин дә аның артыннан калмадым, шул якка сикердем. Тимер юл буйлап чаба бу ачык вагон эзләп... «Тукта! Мин сиңа начарлык теләмим!» — дип тә кычкырып карыйм. Туктамый гына. Шулчак каршыга, икенче юлдан, «встречный» килеп чыкты. «Акрын! Поезд астына керәсең бит!» — дип кычкырам Фазылга... (*Пауза.*) Йөзен генә күреп калдым... Шашынган... әсәрләнгән... Поезд сөйрәп кенә алды үзен...

Фәүзия. Ә син?

Галимхан. Кире станцыга йөгердем.

Фәүзия. Качкансың! Ә нигә качтың? Нигә янына бармадың? Димәк, син үтергән аны?

Галимхан. Мин аны үтермәдем. Сиңа күпме әйтергә була. Мин аңа кагылмадым да... Курыктым мин. Утыртырлар дип курыктым. Утырып чыккан кеше бит мин. Фазыл белән безнең аралар бозылганын бөтен авыл халкы белеп тора.

Фәүзия. Әйт әле, син аның үлемендә үзеңне гаепле итеп санныйсыңмы?

Галимхан. Бу сорауны син миңа инде ничәнче кат бирәсең. Юк, мин аны үтермәдем. Ул үзе, ашкынып, поезд астына барып керде.

Фәүзия. Син, син гаепле! Әгәр дә син безнең тормышка кермәгән булсаң, Фазыл исән булыр иде. Бу фаҗига булмаган да булыр иде. Без, без гаепле, аңлыйсыңмы?! Без аны үлем чигенә китереп җиткердек! Син аңа яшәргә ирек бирмәдең, төрле ялалар яктың...

Галимхан. Аның үлемендә минем гаебем юк, кабатлап әйтәм, мин аны үтермәдем.

Фәүзия. Кешене яман сүз белән, кылган гамәлләрең белән дә юк итәргә, үтерергә була. *(Елый.)*

Галимхан. Елап кына үлгән кешене кайтарып булмый. Авыр туфрагы җиңел булсын инде. Әйбәт кеше иде. Мин бит аңа гомердә дә начарлык теләмәдем.

Фәүзия. Синме! Ә менә бу нәрсә?! *(Сумкасыннан хат кисәге тартып чыгара.)* Бу синең эшең! Бу хатны син оештырган!

Галимхан *(белмәмешкә сабышып).* Хат?! Нинди хат?

Фәүзия. Белмәгән булып кыланма. Фазыл турында теләсә ни яздырып, минем алда аны каралтмакчы булдыңмы?! Юк, барып чыкмас. Мин ялган белән дөреслекне генә аера алам әлегә.

Галимхан. Тикшердеңмени?

Фәүзия. Тикшермичә дә белдем. Саимә апаның кулын бик тиз таныйм мин.

Галимхан *(аптырап).* Ә нишләп ул язган соң аны?

Фәүзия. Менә анысын синнән сорарга кирәк. *(Пауза.)* Рамилә исемле хатын янына барган ул баруын. Бар бит дөньяда изге кешеләр, ул хатын иремә андый пычракны атарга яхшысынмаган. Аптырагач, акчасы да үземдә калыр дип, Саимә апа тоткан да үзе язган.

Галимхан *(башын аска иеп).* Димәк, барын да беләсең. Аңла, мин бит Фазылны карага буяр өчен яздыртмадым аны, синең белән якыная алырмын, бәлкем, дип яздырттым...

Фәүзия. Сине аңларлык түгел, Галимхан. Минемчә, син үз-үзеңне аңлап бетерә алмыйсың кебек.

Галимхан. Кичер, Фәүзия.

Фәүзия. Ходай кичерер, әгәр дә кичерә алса.

Галимхан. Шулай да син миңа соңгы сүзеңне әйтмәдең бит әле.

Фәүзия. Нәрсә?

Галимхан. Син миңа чыгасыңмы кияүгә, юкмы?!

Фәүзия. Иң элек хатыныңнан аерыл.

Галимхан *(яктырып).* Аерылам. Бүген үк. Миңа ул күптән хатын түгел бит инде. Тәк... болай... кәгазьдә генә. Аерылам, тик син генә риза бул! Нишлим мин ул әби белән? Яратмыйм мин аны, ратканым да булмады. Таныш булмаган кешеләр, безне бергә күрсәләр, әниең түгелме бу, дип сорыйлар... Яратмыйм! Сине генә яратам! Әлегә тиклем кылган бөтен гамәлләрем фәкать сине яраттыру өчен генә, сине үземнеке итәр өчен генә эшләнде. Валлаһи, бер ялгансыз әйтәм моны!

Тәрәзә шакыган тавыш ишетелә.

Фәүзия. Хатының янына кайтсаң, Галимхан, яхшырак булыр иде.

Галимхан. Нигә мин аның янына кайтырга тиеш?

Фәүзия. Хатыныңны яманлап утыру ирләр эше түгел.

Галимхан. Ә ничек яманламыйсың ди аны! Ул бит мине танымый да башлады. Акылы зәгыйфьләнде. Кайчан карама, дөньядан китеп утыра. Көзгә карап тик тора...

Фәүзия. Ә кичләрен... кичләрен килеп минем тәрәзәмә шакып йөри... *(Тәрәзә шакыйлар.)* Әнә! Килде!

Галимхан. Кем?

Фәүзия. Хатының, Мөршидә...

Галимхан *(сагаеп).* Тикшерә, димәк. Ә-ә! Чукынып китсен! Фәүзия! *(Фәүзиянең кулыннан тотып.)* Телисеңме, синең алдыңа тезләнәм, бул минеке! Мин синең бөтен теләкләреңне дә үтәячәк! Акча җитәрлек! Кызыңны үз карамагыма алам. Моннан китәрбез. Извиль белән Сәкинәне өйләндерербез. Туй чыгымнарын да үз өстемә алам... Фәүзия... *(Тезләнә.)*

Фәүзия. Минем яшьләргә өйләнергә рөхсәт биргәнем юк. Белмим, алырлар микән әле алар миннән рөхсәт?! Ә сине нигәдер кызганам, Галимхан. Тор, кирәкми... Мин сиңа әлегә берни дә әйтә алмыйм, вакыт күрсәтер...

Галимхан. Димәк, өмет бар, Фәүзия, шулаймы?! Уйла, Фәүзия, уйла. *(Тора.)* Мин көтәргә риза, разыймын!

Фәүзия, йомшап, башын Галимханның җилкәсенә сала. Галимхан аны кочагына ала.

**ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Мөршидә керә. Култык таягына таянган. Шактый картая төшкән.

Галимхан *(тупас).* Ни кирәк?

Мөршидә. И-хи-хи! Вакытсыз йөрим бугай, комачауладым, ахрысы! Кичерә күрерсез... Исәннәрмесез!

Галимхан. Исән әле, исән. Ни кирәк сиңа монда?

Мөршидә. Төш күрдем әле бүген. Гаҗәеп төш. Шуны сөйләргә дип керүем иде сезгә. Сездән башка мин аны тагын кемгә сөйлим инде...

Галимхан. Төш?! Нинди төш тагын? Син бит үзең төш, син үзең төш эчендә йөрисең. *(Фәүзиягә елыша.)*

Мөршидә. И-хи! Минем каршымда кочаклашып тормасагыз...

Галимхан. Ә кем соң син? Кешеме, өрәкме? Без сине чакырып китермәдек. Без өрәкләр белән дус түгел. Бар, кит, йөрмә монда! Кайт өйгә!

Фәүзия *(Галимханга кагылып).* Галимхан, булды, җитәр. Бар, үзең дә кит, хатыныңны да алып кит!

Галимхан *(ясалма).* Синең сүзең минем өчен закон, кадерлем. Кит-тем! Ә бу убырлы карчыкның мин кем икәнен белмим, белергә дә теләмим! У-у! Шайтан корты! Йөрисең шунда эч пошырып, кит, кагылма!

Мөршидәне төрткәләп чыгып китә.

Мөршидә. Шулай инде, сырхау, авыру кеше беркемгә дә кирәк түгел. Тиз онытты изгелекләремне, яхшылыкларымны. Ә хәзер әнә тыңларга да теләми. *(Фәүзиягә.)* Ә бәлкем, син тыңларсың? *(Пауза.)* Эчем тулы авыру, сагыш, каргыш... Ә син яшь, чибәр, ай-яй, бигрәк шома күренәсең. Яп-яшь кызлар кебек әле син, тфү, күз тимәсен! *(Такмаклап.)*

Төтәс, төтәс хатыннан,
Кыздан, кара күздән.
Зәңгәр күздән, яшел күздән,
Картлардан, яшьләрдән,
Ятлардан, дуслардан!
Тфү, тфү, бетсен-китсен,
Җитмеш агач башына.
Азганга, тузганга,
Тигәнәккә, туфракка,
Җилгә очкан яфракка,
Тфү, тфү, үтсен, китсен,
Тфү, тфү! Дөмексен!

Шаркылдап көлә. Төкерекләрен чәчә. Фәүзия читкә тайпыла.

Хәйләкәр, һай, хәйләкәр! Иремне башкача тартып алалмагач, инде нәселебез белән туганлашырга уйлагансың икән, ә?!

Фәүзия. Тел төбеңне аңламадым?

Мөршидә. Малаеңны, көчегеңне минем асыл кызыма өйләндерергә йөрисең икән. Ю-ук! Барып чыкмас! Алай гына минем Галимханымны тартып алалмассың! Юк! Калдыр, калдыр, Галимханымны калдыр!

Фәүзия. Аның миңа кирәге юк.

Мөршидә. Үтенеп сорыйм... Ул минем бердәнбер таянычым, терәгем. Нишләп ул мине шулкадәр күралмый, нишләп мине кешегә санамый, белмим инде, аңламыйм?! Нишләп соң мине беркем дә яратмый? Әгәр миңа кешечә карасалар, мин бу хәлгә төшәр идеммени! Мин дә бит кешедер, хайван түгел, адәмдер. Минем дә бит сезнең кебек яратырга, сөяргә, сөелергә хакым бардыр?! Үтенеп сорыйм!.. Калдыр Галимханны!..

Фәүзия. Миңа кирәк түгел синең ирең. Ул үзе килә, үзе йөри.

Мөршидә. Хатын-кыз теләмәсә, ир-ат йөрми ул. Син үзең шундый. Шома, сезнең гел шома килеп чыга инде. Мин оекчан килеш, аягымны өшетә-өшетә бозлы кардан йөгергәндә, сез минем җылы өемдә, җылы куышымда утыргансыз... шомарып...

Фәүзия. Җитте, мин арыдым. Минем акланасым да, аңлатасым да килми, калдыр мине...

Мөршидә *(көлеп).* Төште... Аллаһының каргышы төште! Сине дә ирсез калдырды! Хи-хи-хи!

Фәүзия. Җитәр! Акылыңа кил!

Мөршидә. Төш күрдем... Бер ташландык сарайда салам өстендә аунап ятамын икән... Ниндидер чиркангыч җәнлекләр, күселәр, йөгереп килеп, кулларымны, аякларымны иснәп китәләр... Ә мин менә шушы култык таягым белән шул әшәке затларны куам... *(Таягы белән селтәнә.)* Менә, менә шулай! Качалар күселәр, качалар... Ә мин һаман сугам, һаман куам... *(Фәүзиягә суга.)*

Фәүзия *(чигенеп).* Абау!

Мөршидә *(селтәнеп).* Менә шулай!

Фәүзия. Мөршидә апа! Акылыңа кил! *(Мөршидәнең таягын бәреп төшерә.)*

Мөршидә. Менә шулай! *(Фәүзиянең чәченә ябыша.)* Мә! Мә сиңа!

**ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Бакча ягыннан Извиль керә.

Фәүзия. Ай! Җибәр чәчемне!

Извиль араларына керә.

Мөршидә. Бет, үләт...

Извиль. Әй, син, җен карчыгы! Нишлисең? Җибәр әнине! *(Мөршидәне йолкып алып, ишек ягына ыргыта.)* Нишләп син әнине кыйныйсың, ә?!

Сәкинә күренә.

Сәкинә. Әни!

Мөршидә *(кызын күреп).* Ә-ә! Уйнашчылар, уйнашчылар, миннән хәер-фатиха юк сезгә, юк! Юк! Сөймим, күралмыйм берегезне дә!

Таягын каптырып чыгып китә.

Извиль. Әни... *(Фәүзияне кәнәфигә сала.)*

Фәүзия. Улым! *(Улының башыннан сыйпый, хәлсезләнеп ава.)*

Извиль. Борчылма, әни, ят. *(Сәкинә килә.)* Ни өчен анаң шулкадәр аңа үчләнгәндер, белмим?!

Сәкинә. Саташкан ул, саташкан.

Извиль. Әни белән мондый хәлдә сөйләшеп булмаячак. Йокласын, хәл алсын әзрәк. Әтәчләр кычкыра. Таң ата... төн узып бара... Сәкинә...

Сәкинә. Әү?!

Извиль. Без синең белән бүген йокламабыз, таң каршыларбыз. Болынга, урманнарга чыгарбыз, күп итеп кыр чәчәкләре җыйнап кайтырбыз. Әнигә бүләк итәрбез. Безнең әни кыр чәчәкләрен ярата, бигрәк тә ак чәчәкләрне...

Сәкинә. Минем әле бервакытта да таң каршылаганым булмады.

Извиль. Бүген каршыларбыз. Киттек!

Китәләр. Мотоцикл тавышы ишетелә.

**БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Галимхан керә. Кулында хат. Фәүзия аяк тавышын ишетеп уяна.

Фәүзия. Кем анда? Улым, синме?

Галимхан. Мин әле бу.

Фәүзия. Ә, син икән... *(Кире ята.)*

Галимхан. Хәлең ничек? Мөршидә кайтып сөйләде. Ачуым чыкты. Хәер, җәзасын каты алды, эт иткәнче кыйнадым үзен.

Фәүзия. Кирәкмәс иде. Сырхау кеше бит.

Галимхан. Сырхау кеше кеше кыйнап йөрми ул. Үзегезне генә калдырганга үкенеп бетә алмыйм. Мөгез чыгарачагын сизенгән идем бит юкса. Син әле шуны кызганып торган буласың...

Фәүзия. Исәндер бит?

Галимхан. Нәрсә булсын аңа, җен карчыгына?! *(Пауза.)* Ә, менә онытып та торам. Почта яшнигегездә хат ята иде, шуны алып кердем. Мә! *(Хатны бирә.)*

Фәүзия *(карап).* Кыздан. Фазылның анасыннан.

Галимхан. Ни язалар?

Фәүзия. Һаман шул. Хатның яртысын әнкәй, яртысын кыз яза. Кызым мине сагына, абыйсын да. Әнкәй безгә күченеп килегез дип яза. Анда күчеп киткәнче, Сәрияне авылга алып кайтырга кирәк инде.

Галимхан. Китәргә булдыңмыни?

Фәүзия. Китсәң дә ярый. Тол хатынга авыр авылда яшәүләре.

Галимхан. Китсәң, әйдә, бергә китик. Бер-беребезгә таяныч булыр идек.

Фәүзия. Миңа таянырга ярамый, мин аяктан егучы гына.

Галимхан. Миңа таянырсың.

Фәүзия. Куркам. Яратудан куркам, синнән куркам, үземнән дә... Көчсезлегемнән куркам. Юк. Без гомердә дә бергә була алмабыз, кирәкми, мин куркам...

Галимхан. Тагын кемнән куркасың?

Фәүзия. Хатыныңнан.

Галимхан. Мин аның янына бүтән кайтмаячакмын. Аерылыштык дип сана...

Фәүзия. Мин гаилә бозучы булып калырга теләмим.

Галимхан. Бозасы юк бит инде аны, бозылган ул.

Фәүзия. Юк, без синең белән бергә була алмыйбыз. Аның өчен көч кирәк. Минем яшәү канатларым инде күптән сындылар, моннан ел ярым элек... Фазыл үлгәннән бирле... Ә сынык канатлар белән, үзең беләсең, озак очып булмый.

Галимхан *(торып).* Синең соңгы сүзең шушымы? Мин сиңа кирәк түгелме?

Фәүзия. Мин... иремне яратам.

Галимхан. Ireңне?! Ничек? Ул бит үлгән, ул бит төтен, ул бер бушлык кына хәзер. Ә бушлыкны ничек итеп яратырга була, аңламыйм?!

Фәүзия. Минем өчен ул әле дә тере.

Галимхан. Сиңа күптән аны күңелеңнән чыгарып атарга вакыт иде инде.

Фәүзия. Бу сүзләрең белән син мине рәнҗетәсең.

Галимхан. Гафу ит, менә мин шундый инде. Тик мин — тере. Начармы, яманмы, мин — тере! Мин — бар, мин — үлмәгән, мин — яшим! Мин — тере!

Фәүзия. Ялгышасың, син минем өчен...

Галимхан. Әйтеп бетермәсәң дә була. Мин китәм. Мин синең тормышыңа керергә җыенмыйм. Тик шуны аңла, син мине һаман да явыз, яман кеше итеп күрергә тырыштың. Әйе, ireңнең үлемендә минем гаебем дә бардыр, анысын инкарь итмим. Тискәре гамәлләрем бар. Ләкин, кабатлап әйтәм, боларның барысы да сине ярату бәрабәренә эшләнде...

Фәүзия. Синең яратуың явызлык, яманлык илчесе генә булып калган.

Галимхан. Соңгы өметемне дә өздең, Фәүзия! Миңа хәзер ике генә юл кала. Ерак-ерак сәфәр йә үлем. Мин болай яши алмыйм мондый күңел газаплары белән... Күз алдымда һаман да ул тора... ул...

Фәүзия. Кем?

Галимхан. Әнә ул... Ул чакыра мине... Мин башымны салырга да әзер... поезд астына ташланырга...

Фәүзия. Шаштың мәллә?

Галимхан. Үләр вакытлар җитте. Бәлкем, үлгәч кадеремне белерләр...

Фәүзия. Син?!

Галимхан. Мине куркак дип уйлыйсыңмы? Мин үлемнән курыкмыйм, үлем миннән курыксын.

Фәүзия. Тынычлан. Өеңә кайт, бар.

Галимхан. Өйгә кереп, кирәк-яракларны алам да юлга чыгам, юлга... Мине юл дәшә... юл... Күңелемә бер дәва бар... ул да булса юл гына... Хуш...

Әсәрләнеп чыгып китә.

Фәүзия. Шашкан, акылдан шашкан. *(Хатны ача.)* Кызым яза... *(Укый.)* «Әни, кайчан монда күченеп киләсез, мин дә, дәү әни дә сезне бик сагындык. Әни, төш күп күрәм мин... Күптән түгел генә әтине күрдем... Ул бик үкенә, әнием... Ул: «Нишләп мин шундый булдым, нишләп сезне ташлап киттем икән?!» — дип әйтә... *(Елый.)* Сез җибәргән акчага дәү әни миңа җылы тун алды. Мин аны киеп карадым, ул шундый җылы... Кыш җиткәч, урамга киеп чыгам...» Тукта! Акча?! Кем җибәргән соң аңа аларны? *(Уйлана.)* Аңладым. Галимхан эше бу. Миңа ул бурычтан тиз генә котылырга кирәк. *(Тора.)* Миндә күпмедер акча бар бит әле... Җитәр микән?

Комод каршына килә. Куллары калтырый.
Караңгылык иңә. Моңсу көй агыла. Шул караңгылыкта якты нур балкып алган кебек була.

**АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ**

Юлаучы керә. Ул төс-кыяфәте белән Фазылга охшаган.

Фәүзия *(сискәнеп).* Сез кем?

Юлаучы. Гафу итегез, мин юлаучы булам. Локман атлы. Галим мин. Авыллар тарихын язам.

Фәүзия. Утырыгыз!

Юлаучы. Ярый, рәхмәт.

Фәүзия. Утырыгыз, бу бит таможня түгел.

Юлаучы. Рәхмәт, утырып торырга вакыт юк. Ә хуҗа өйдә юкмыни соң?

Фәүзия. Кем?

Юлаучы. Сезнең ирегез Фазылмы?

Фәүзия. Әйе... Фазыл... тик...

Юлаучы. Аңладым. Командировкада. Эш болай: мин бу тирәдә авыллар тарихын өйрәнәм. Ә үзем калада, Казанда яшим. Беркөнне кич поезд белән сезнең якларга кайтканда, станцаларны бутап, алдарак, кирәкмәгән урында төшеп калганмын. Кап-караңгы. Попутный юк. Үземә кирәкле станцыга кадәр җәяү атларга туры килде. Караңгыда таеп егылып, җитмәсә, акча янчыгымны да төшереп калдырганмын. Үз-үземне сүгә-сүгә әкрен генә алга атлыйм. Куркыныч. Шүрләтә. Ярты чакрым юл үткәнмендер, артымнан ат җиккән арбалы кеше килеп чыкты. Утыртты бу мине. Танышып киттек. Фазыл исемле. Сезнең ирегез була инде ул... Әйбәт, киң күңелле кеше. Сөйләшеп бардык...

Фәүзия. Ничек? Туктагыз әле!

Юлаучы. Ул мине кирәкле станцага шулкадәр тиз китереп җиткерде, мин хәтта сизми дә калдым. Рәхмәт инде аңа. Акча югалтканымны белгәч, ул миңа акча да бирде. Бурычымны нинди адрес белән кайтарыйм, сезне каян табыйм дип сорагач, ул авылыгызның адресын бирде, сезнең исемегезне әйтте... Сез Фәүзияме?

Фәүзия. Әйе.

Юлаучы. Әйбәт, ихлас күңелле кеше сезнең ирегез, мең-мең рәхмәт аңа. Ярдәме зур булды миңа, зур. Ә менә минем бурычымны алыгыз, рәхим итеп! *(Акча суза.)*

Фәүзия. Туктагыз әле! Сез ни сөйлисез? Минем ирем исән түгел, үлде бит ул!

Юлаучы. Үлде?! Ничек?

Фәүзия. Поездга тапталып.

Юлаучы. И-их! Кичерегез, белмәдем. Мескенкәем. Авыр туфрагы җиңел булсын... Аңламыйм?! Нишләп бу үлем җирдән гел яхшы кешеләрне генә алып китә икән? *(Пауза.)* Гафу итегез, ә ул кайчан үлде соң?

Фәүзия. Ел ярымнар элек. Гыйнварда ел ашын үткәрдек.

Юлаучы *(каушап).* Ел ярым?! Бу мөмкин түгел! Бу хәл моннан бер атна элек кенә булды.

Фәүзия. Бер атна?! Аның үлгәненә инде ел ярым бар.

Юлаучы. Сәер, бик тә сәер.

Фәүзия. Ә бәлкем, сез башка кеше белән бутыйсыздыр?

Юлаучы. Белмим. Ирегез ветеринар идеме?

Фәүзия. Әйе. Колхоз ветеринары.

Юлаучы. Сәер... Караңгыдан ничек сиздермичә килеп чыкса, шулай сиздермичә генә югалды да бит ул.

Фәүзия. Эшкә ул гел ат җигеп йөри иде.

Юлаучы. Аты ак маңгайлы түгел идеме?

Фәүзия. Әйе. Алаша ат. Без аны Акмаңгай дип йөртә идек. Тик ул атны инде күптән ит комбинатына озаттылар...

Юлаучы *(аптырап).* Ни әйтергә дә белмим инде...

Фәүзия. Ә ул ничек киенгән иде?

Юлаучы. Ялгышмасам, шакмаклы күлмәктән. Башында кепкасы да бар иде.

Фәүзия. Әйе, ул нәкъ шулай киенә иде.

Юлаучы. Туктагыз әле! Нишләп соң без һаман да баш ватабыз! Аның фотосы бардыр бит?

Фәүзия. Әнә каршыгызда тора! *(Диварда эленгән Фазылның рамкадагы фотосына күрсәтә.)*

Юлаучы. Ул. Әйе, ул.

Фәүзия *(елар хәлгә җитеп).* Гафу итегез... Сез Фазылны исән дип әйтмәкче буласызмы?!

Юлаучы. Исән, димәк.

Фәүзия. Көлмәгез миннән! Әйтеп торам бит, ирем үлде минем, поездга тапталып үлде. Мин аны үзебезнең авыл зиратына җирләдем. Кем җибәрде сезне, кем?!

Юлаучы. Кем булуымны әйттем. Кичерегез, мин фәкать бурычымны түләр өчен генә кердем. Кичерегез... мәгез...

Акчаларны өстәлгә салып чыгып китә.

Фәүзия. Сез... сез кая? *(Эзләнә.)* Сез... кая соң... *(Маңгаен уа.)* Саташаммы соң? Өрәкләргә ышанмыйм ышануын. Тик бу юлаучы шулкадәр дә Фазылга охшаган иде бит! Нәрсә бу? Саташумы... *(Елый.)* Бар нәрсә дә сине хәтерләтә... Фазыл... *(Хисләнә.)* Исән чагыңда кадереңне белмәгәнмен, кичер... Йөрәк җылымны тулысынча бирә алмаганмын... Син минем бердәнбер газиз ярым бит... Фазыл... Хәтерлисеңме, Казанда укыганда, мин торган тулай торакка син бер кочак чәчәк алып кергән идең. Кайдандыр урманнан, болыннан җыйган идең син аларны. Бүлмәм ап-ак чәчәккә, чәчәк исенә тулды... Бүлмә генәме? Бөтен дөньям, җаным шау чәчәккә тулды... Мин чәчәкләр арасында калдым, ә син кайдыр чыгып югалдың... *(Җырлый.)*

Ак чәчәкләр бүләк иттең,
Яме калды бүлмәмдә.
Белмим кая киткән юлың,
Бәлки, бүтән күрмәм дә.

Бергә булыйк без гомергә,
Бәхет язмыш кулында.
Ак бәхетләр юлдаш булсын
Синең киткән юлыңда...

Ак чәчәкләр бүләк иттең,
Икәү бергә булганда.
Яннарымда беркем дә юк,
Ялгыз күңлем тулганда.

Фәүзия җырлаганда Извиль, Сәкинә керәләр, тыңлап торалар.
Аларның кулларында ап-ак чәчәкләр.

Ак чәчәкләр бүләк иттең,
Шунда минем бәхетем.
Ялгыз итсә итсен язмыш,
Өзмәсен тик өметем...

Берникадәр югалып йөргәннән соң, син тагын минем янга килдең. Шуннан бирле без бер-беребездән беркайчан да аерылышмадык. Безне хәтта үлем дә аера алмады... Фазыл...

**ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Фәүзия *(сискәнеп).* Әй Аллам! Извиль! Шулкадәр дә әтиеңә охшап калгансың! Коеп куйган Фазыл! Кайда йөрисең син, чукынмыш малай?!

Извиль. Син шундый матур итеп җырладың, әни, без таң калып тыңладык. Болар сиңа, әни! *(Чәчәк бирә.)*

Фәүзия. Чәчәкләр! Кыр чәчәкләре! Рәхмәт.

Извиль. Болынлыктан җыйдык. Сәкинә белән бергә.

Сәкинә. Исәнме... әни... *(Чәчәк бирә.)*

Фәүзия *(алып).* Әни?! Ничек?

Извиль. Әни! Сәкинә сиңа, әни, дип эндәшеп ялгышмады. Без өйләнешергә уйладык. Синнән рөхсәт сорарга дип килдек.

Фәүзия. Килдек... Син нәрсә, монда яшәмисеңмени? Безнең йорт кешесе түгелмени?

Извиль. Яшим дә... Без Сәкинә белән иң элек никах укытырга булдык. Соңыннан язылышырга иде исәп.

Фәүзия. Ничек?! Минем белән киңәшмичә, аңлашмыйчамы?

Извиль. Менә шуның турында сөйләшергә дип килдек тә бит инде!

Фәүзия. Шулкадәр ашыгычмыни?! Иртәрәк түгелме соң әле? Аннан... аннан мин сезнең өйләнешүегезне теләмим.

Извиль. Беләбез...

Фәүзия. Ни беләсез?

Извиль. Сәбәбен беләбез. Галимхан абый аркасында.

Сәкинә. Әни аркасында да.

Фәүзия. Юк, аның өчен генә түгел. Хәер, мин үзем дә белмим.

Извиль. Ә нишләп теләмисең безнең өйләнешүебезне?!

Фәүзия. Мин шулай телим!

Извиль. Горурлыгың, үзсүзлегең белән син үз-үзеңә каршы киләсең бугай, әни. Әгәр дә син риза булмыйсың икән, без...

Фәүзия. Чү! Кызма! *(Кызуы сүрелә төшә.)* Балалар, нишләп сез мине аңларга теләмисез соң, ә?! Нишләп миңа уйларга ирек бирмисез?!

Извиль. Синең өчен яңалык булырга тиеш түгел иде бу, әни.

Фәүзия. Әйе, мин ишеткән идем бу турыда. Тик алай ук тирәнгә киткәндер дип уйламаган идем. Сез менә кисәк кенә кайттыгыз да, кисәк кенә теләгегезне белдердегез. Мин әлегә әзер түгелмен җавап бирергә...

Извиль *(аңлап).* Без сине ашыктырмыйбыз, әни. Уйла, без сиңа комачау итмибез. Шулай бит, Сәкинә!

Яшьләр бакча ягына чыгалар.

Фәүзия *(ялгызы).* Нишләргә? Кемнән киңәш сорарга? Ни өчен соң әле мин Галимхан белән туганлашырга тиеш? Ә Мөршидә апага кодагый дип эндәшергә тиеш? Ә икенче яктан... балалар... Алар бер-берләрен яраталар. Аларның бәхетенә каршы төшәргә хакым бармы соң минем? Нишләргә? Ике арада калдым бит, ике упкын арасында. Кем миңа ярдәм кулын сузар? Кем бар? Фазыл... Фазылның рухы... җаны... Фазыл, нигә эндәшмисең, бир бер киңәш?!

Фазылның тавышы. Минем җан — синең җан, минем тавыш — синең тавыш, минем сүз — синең сүз. Әгәр дә без, кешеләр, бер-беребезне бу дөньяда кичерә алмасак, ул яманлык вә явызлыктан гына торыр, яшәүнең мәгънәсе дә калмас иде. Упкынга тәгәрәмәүнең бер генә юлы бар: балаларыңнан аерылма, аларның бәхетенә каршы килмә... Фәүзия...

Извиль, Сәкинә керәләр.

Фәүзия. Балалар! Мин сезнең бәхетегезгә каршы төшә алмыйм, андый хакым да юк минем. Язмышлар хәл ителгән вакытта бөтен булган үпкәләрне онытып, дошманлык хисеннән югары булырга кирәк. Сезнең кебек үк мин дә кайчандыр бәхетле булганмындыр! Әгәр Ходай миңа шундый бәхетсезлек биреп, газиз иремне, ярымны, балаларымның атасын тартып алган икән, нишләп соң әле мин аңа карап кына газиз баламны, сезне бәхетсез итәргә тиеш?! Мин риза. Бәхетле булыгыз, балалар! *(Елый.)*

Извиль. Рәхмәт, әни. Әни! Мин сине кайчандыр рәнҗеткән идем, гафу ит шуның өчен мине, әни! *(Әнисен кочаклый.)*

Сәкинә. Әни! *(Фәүзия Сәкинәне кочагына ала, үбә.)*

Фәүзия. Сез ачыккансыздыр да инде... Чәй куеп җибәрегез. Духовкада тавык та бар...

Сәкинә. Хәзер, барысын да үзем эшлим.

Фәүзия. Улым! Суыткычта саклап торган шәраб бар, ач, бәйрәм булгач бәйрәм булсын инде!

Извиль. Хәзер, әни!

Музыка уйный. Шәраб ача.

**СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Саимә керә. Бер аякка аксый.

Саимә *(сөенеп).* Йа Хода! Бу өйгә дә шатлык килер көннәр бар икән! Ни булды? Нәрсә дөньяның астын өскә китерәсез?

Извиль. Өйләнәм, Саимә апа!

Саимә. Ә?! Ярар, бик әйбәт, бик күркәм! Бәхетле булыгыз, тигез гомер итәргә язсын! Кызның чибәрен эләктердең инде, чукынчык, чибәрен! Мотоцикллы булдың инде, тиздән хатынлы да булырсың!

Фәүзия. Мотоцикл?! *(Извильгә.)* Мотоцикл алдыңмыни? Нинди акчага?

Саимә. Галимхан биргән акчага.

Фәүзия *(комод шүрлегенә үрелеп).* Мә, хәзер үк кайтар!

Извиль. Әни, мин Галимхан абый биргән акчага матай алмадым. Мин ул акчаны сеңелкәшкә җибәрдем. Матайны Гайнаннан алып тордым. Вакытлыча йөреп торырга. Ә Галимхан абый биргән акчаны мин эшли башлагач ук кайтарып бирәм.

Сәкинә. Алмас ул аны. Туй өчен, дияр...

Фәүзия *(комод шүрлегеннән акча алып).* Бусы сезнең туегызга булыр, Алла боерса!

Саимә. Шатлыгың зур инде, Фәүзия!

Фәүзия. Фазыл үлгәннән бирле, безнең өйдә бәйрәмнең булганы юк иде әле.

Саимә. Әйтмә дә инде, бигрәкләр дә иртә китеп барды якты дөньядан.

Фәүзия. Өзгәләнеп елаган, үз-үземне кая куярга белмәгән, хәтта үземә кул салырга уйлап йөргән чакларым да булгалады. Яшермим.

Саимә. Алла, диген!

Фәүзия. Бары тик балаларны уйлап кына андый хәтәр адым ясамадым. *(Елый.)*

Саимә. Ие, ие... Син миңа үч тотма инде, Фәүзия. Шул Галимханның сүзен тыңлап, шул җүләр хатны язып, синең алда бик тә оятлы була яздым. Ачуланма инде, ни әйтсәң дә, без күршеләр бит, ут күршеләр. Мин бит үзем дә ялгыз, бәхетсез инде. Малаем да кайтмады... Кемгә кирәк мин?

Фәүзия. Әгәр без бер-беребезне кичермәсәк, бу дөнья гел яманлык вә явызлыктан гына торыр иде. Фазыл сүзләре...

Саимә. Ие, ие. Әле дә ярый шул явыз Галимханга чыкмадың. Ходай коткарды. Бүген күрдем үзен. Тәмам чыгырыннан чыккан, миңа кычкырынган була. Әллә теге төшергән икмәген кире алып менәргә инде?!

Фәүзия. Аңарда хәзер икмәк кайгысы түгел.

Саимә. Әй, белмәссең бу ирләрне!

Сәкинә. Әни, өстәл әзер!

Извиль. Әйдәгез, якынрак килегез!

Фәүзия. Үзегез генә, улым. *(Саимәгә.)* Кызымны сагынам. Тиздән күрешербез. Үз янымнан беркая да җибәрәчәк түгел мин аны. Ул хәзер минем бердәнбер юанычым булып калырга тора.

Саимә. Ие, малайның хәзер яңа тормышы башлана.

Извиль *(кулына гармун алып).* Их, бер күңелегезне күтәреп җибәрим әле! *(Җырлый.)*

Җилләр исә ярларга,
Дулкын бәрә кыяга.
Ак пароход күренсә,
Чынга аша хыял да.

Җилләр исә, чәчләрең
Чәчеп тарафка.
Яшьлек мәхәббәтебез
Дәшә безне еракка.

Алда безне ни көтәр?
Шатлык вә сагыш көтәр.
Сөенеп вә көенеп,
Яшьлек еллары үтәр.

Ак пароход ак бәхет
Алып килер безгә дә.
Яшьлек мәхәббәтебез
Дәшә ерак диңгезгә...

**ТУГЫЗЫНЧЫ КҮРЕНЕШ**

Галимхан керә. Чырае караңгы. Тынлык.

Сәкинә *(сизенеп)*. Әни... *(Ишеккә атыла.)*

Галимхан. Кичер, кызым... Анаң вафат...

Сәкинә туктап кала.

Извиль. Их, әти, шундый матур бәйрәмнең ямен җибәрдең бит!

Гармун күреге, шомлы тавыш чыгарып, салынып төшә.

Пәрдә.

## ЯЛГЫЗ ТӘКӘРЛЕК

*Ике пәрдәле мелодрама*

**КАТНАШАЛАР:**

Зәйнәп — 43 яшьтә.
Гөлсирин — аның кызы, 25 яшьтә.
Шакир — авыл советы рәисе, 59 яшьтә.
Маһруза — аның хатыны.
Рамазан — аларның уллары, 29 яшьтә.
Хәят— Зәйнәпнең үги анасы, олы яшьтә.

Вакыйга авылда бара.

### БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Авыл, сазлык урын. Уртада ялтырап күл ята. Бу — Яксаз күле. Илаһи тынлык. Күл өстеннән пар күтәрелә. Үзәк өзгеч тәкәрлек тавышы ишетелә. Салмак кына көй агыла*.

**ПРОЛОГ**

*Хрущев заманы. Авыл советы рәисе бүлмәсе. Шул чорның реквизитлары. Чатта зур кара өстәл. Диварда кызыл байрак. Юлбашчы рәсеме. Өстәл янында — Шакир. Ул бер кара шәүлә сыман. Бүлмәдәге ут тоньк, бүлмә эче өстәлдәге абажурдан, баганадагы фонарьдан төшкән ут яктысыннан гына яктыра. Шакир үзен эре тота. Йөзе кырыс, җитди. Аның каршысында урындыкта унҗиде яшьлек Зәйнәп утыра. Ул җилкәсенә арзанлы ак шәл бөркәнгән.*

Шакир *(йодрык төйнәп).* Сеңлем! Сиңа күпме аңлатырга була. Җибәрә алмыйм мин сине калага, җибәрә алмыйм! Белешмә дә, рөхсәт кәгазе дә бирә алмыйм. Бигайбә!

Зәйнәп. Нишләп?

Шакир. Ярамый. Партия кушмый. *(Пышылдап.)* Илнең рөхсәте юк. Аңлыйсыңмы син, юкмы?

Зәйнәп. Аңлыйм... тик...

Шакир. Аңласаң, бик әйбәт, бар, өеңә кайт. Иртән ындырга эшкә чыгасыңны онытма!

Зәйнәп *(еламсырап).* Шакир абый, зинһар, үтенеп сорыйм!..

Шакир. Юк, булмый! *(Пауза.)*

Зәйнәп. Шакир абый! Миңа авылдан китәргә кирәк. Мине монда берни дә тотмый.

Шакир. Кая, кемнән качасың? Әниең вафат булса да, әтиең исән бит әле. Фронтовик әтиең исән.

Зәйнәп. Әтиемне Хәят апа карый. Хәят апа әйбәт кеше. Кешелекле. Ирен сугышта югалткан. Әтине ташламас...

Шакир. Ә ни өчен китәсең авылдан? Күңелсезмени соң монда?

Зәйнәп. Минем укыйсым килә. Укып, кеше буласым.

Шакир. Авылда да кеше булырга була. Партия карарларын ишеткәнең юкмыни соң синең? Яшьләр хәзер авылдан китәргә атлыгып тормыйлар. *(Елмаеп.)* Ә бәлкем, кияүгә дә чыгып куярсың, ә?

Зәйнәп. Миндә кияүгә чыгу кайгысы юк. Минем укыйсым килә. Врач буласым.

Шакир. Укы. Бездә укыган кешегә пачут. Партия ни ди әле...

Зәйнәп. Көлмәгез, зинһар. Паспорт алыр өчен, зинһар, рөхсәт кәгазе бирегез?!

Шакир. Һе! Җиңел генә. Кабатлап әйтәм: мин сине җибәрә алмыйм. Җибәрергә хакым да юк. Синең өчен, җаныкай, закун бозасым да, Себер китәсем дә юк. Юк!

Зәйнәп. Кемнәрдер китә бит. Кемнедер җибәрәсез!

Шакир. Ә кемне җибәргән бар соң безнең? Кемне? Шуларның берсен генә булса да исеме белән атап әйт әле?!

Зәйнәп. Кем... әнә... Кыштырларныкы...

Шакир. Шулай. Тик Кыштыр Сабирының ун баласы бар, матурым. Балаларын туйдыра алмый. Өйләрендә кысанлык, тарлык. Совет закуны буенча, ишле гаилә балаларына шәһәргә китәргә рөхсәт. Шуңа күрә дә Кыштыр малаена мин, авыл советы рәисе, рөхсәт бирдем.

Зәйнәп. Ә миңа?

Шакир. Ә сиңа — юк. Син гаиләдә бер генә. Сиңа рөхсәтем юк.

Зәйнәп *(ялынып).* Шакир абый, зинһар, кире какмагыз үтенечемне. Сездән генә тора бит инде. Сез, теләсәгез, барысын да эшли аласыз.

Шакир *(көлемсерәп).* Көндез абый, кичен җаный... Ярар. Шулай да булсын ди. Мин бу җаваплылыкны үз өстемә алдым да ди. Ә ни өчен? Ни бәрабәренә! Нәрсә, бушкамы?

Зәйнәп. Акчам бар барын. Тик аз, юлга җитәрлек кенә.

Шакир. Акча? *(Пауза.)* Син нәрсә, сеңлем, мине ришвәт ала дип уйлыйсың мәллә? Ялгышасың, партийный мин.

Зәйнәп. Сез мине дөрес аңламадыгыз. Әгәр дә сез андый булсагыз, сезгә Ленин ордены биргән булырлар идемени?! *(Пауза.)* Зинһар, бирегез шул рөхсәт кәгазен! Гомер сезгә бурычлы булып калырмын, Шакир абый! *(Тезләнә.)*

Шакир *(янына килеп).* Син нәрсә, тор тизрәк! Тор, диләр сиңа, кеше күрүе бар. Тор! *(Торгыза.)*

Зәйнәп *(торып).* Их! Бер генә юлы да юк микәнни соң бу читен хәлдән чыгуның?!

Шакир *(астыртын елмаеп).* Бар... Нигә юк? Бар ул, нигә булмасын. Бар!

Зәйнәп. Нинди?

Шакир *(мутланып).* Зәйнәп, чибәр син! Ай, чибәр! *(Көйләп.)* Алма кебек пешкән чагың, миңа ни кирәк тагын?!

Зәйнәп *(уңайсызланып).* Аңламадым... Ничек?

Шакир. Ничек? Ә менә ничек! *(Зәйнәпне кочып.)* Бул минеке!

Зәйнәп *(коты очып).* Ә?!

Шакир. Бир. *(Пауза.)* Ә мин сиңа рөхсәт кәгазе бирермен.

Зәйнәп. Сез нәрсә?! Сез мине кем дип белдегез! Оят бит бу! Хурлык!

Шакир. Әй! Нәрсәсе оят инде аның?!

Зәйнәп. Сезнең бит хатыныгыз бар.

Шакир. Мин бит сине хатынлыкка чакырмыйм.

Зәйнәп. Мин бит кыз кеше!

Шакир. Бик зур нәрсә икән! Ха-ха! Кемгә дип сакларга булдың ул гыйффәтлегеңне?! Кемгә? Кала этләренәме?!

Зәйнәп *(еларга җитешеп).* Сез бик тупас. Сез миннән көлмәгез... Кирәкми...

Шакир. Юк, җаным, мин синнән көлмим дә, мин сине көчләмим дә. *(Сәгатькә карап.)* Инде соңга калдым. Кич булган. Өйгә кайтырга кирәк. Өйдәгеләр көтеп зарыкканнардыр. Бүген печән кайтарырга тиешләр иде. *(Җыена.)*

Зәйнәп китмәкче була.

Тукта! Ой, матур да соң син! *(Зәйнәпне кочып.)* Җә, ярат инде бер Шакир абыеңны! Ярат, күр бер күңелен!

Зәйнәп *(тартылып).* Җибәрегез, җи-бәр...

Шакир. Җә, җә, акрын, шаулама, ишетүләре бар.

Читтә Маһруза күренә. Аларны күреп кире чигенә. Яшеренә.

Зәйнәп. Кагылмагыз миңа!

Шакир. Ашыкма. Аңла, мин синнән файдаланырга җыенмыйм. Син бит миңа ошыйсың, Зәйнәп. Соң, минем дә йөрәгем бар бит, бар...

Зәйнәп. Китегез!

Шакир. Мин бит яратам сине. Яратам!

Зәйнәп. Ни сөйлисез сез? *(Кыштырдаган тавыш ишетелә.)* Әгәр бу сүзләрегезне хатыныгыз ишетеп торса, оятыгыздан нишләр идегез икән?

Шакир. Нәрсә?! Искә төшермәле шуны! Яратып яшәмим бит мин аның белән! Миңа син кирәк, син! Син чибәр, яшь, аңардан өстен, күпкә өстен... *(Тавыш кабатлана. Тыңлананалар.)* Борчылма... Җил исә, җил... йә күселәр йөри... Нигезе черегән. Сиплисе бар... Әй, чукынып китсен! Кил әле монда! Кил! Якынрак кил! *(Тартып китерә.)* Туйганчы, бер рәхәтләнеп үбим әле үзеңне! Кил! Ай, җаным!

Зәйнәп *(тартылып)*. Ки-рәкми, зинһар... *(Чарасыз.)* Сез нишлисез соң?.. *(Шакир аны көчләп үбә.)*

Шакир. Кирәк. Шулай кирәк... Син риза, шулаймы?
Зәйнәп. Сорамагыз берни дә...
Шакир. Яхшы. Сорамыйм... Зәйнәп, матурым...

Шакир Зәйнәпнең күлмәк изүен чишеп җибәрә. Аның күкрәгеннән үбә. Зәйнәп аңа каршы торырлык көч табалмый. Шакир аны өстәлгә китереп сала. Кызның шәле идәнгә очып төшә. Ул кызны коча, үбә.

Зәйнәп *(байракка төшерелгән Ленин сурәтен күреп).* Юк!
Шакир. Ни булды?
Зәйнәп. Монда түгел.
Шакир. Ә кайда? *(Пауза.)* Ә! Киттек! Әйдә, киттек! Түгәрәк күл буена! Яксазга!
Зәйнәп. Юк, анда барырга ярамый.
Шакир. Нишләп?
Зәйнәп. Каһәрле күл ул.
Шакир. И-хи-хи! Юк нәрсә, ышанма! Мин барында бернидән дә курыкма, ишеттеңме? Киттек! Тизрәк! *(Өстери.)*
Зәйнәп. Юк, туктагыз!
Шакир. Нәрсә тагын?
Зәйнәп. Шәлем, минем шәлем...
Шакир. Әйдә инде, нинди шәл тагын! Киттек! Тизрәк!

Зәйнәпне өстерәп алып чыгып китә. Тарантас кузгалган тавыш. Артларыннан карана-карана Маһрузакерә. Шәлне табып ала. Ертмакчы була. Ертылмый. Аңа читен. Елый-елый әкрен генә тез чүгә. Караңгылык. Ул югала. Яктылык күл өстенә төшә. Көй агыла. Тәкәр-
лек кычкырып куя. Караңгылык.

**БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Шактый вакыт узган. Яңа заман. Мотоцикл тавышы ишетелә. Рамазан, Гөлсирин күренәләр. Күл буе. Шул ук Яксаз күле. Рамазан, кызны җитәкләп, күл буена алып төшә. Гөлсирин шәһәрчә киен-
гән, шортыдан.

Рамазан. Менә шушы инде ул безнең күлебез! Безнең болото! Матурмы?!
Гөлсирин *(артык исе китмичә).* Ничё! *(Киная белән.)* Әй, син, авыл, шәһәрдән мең кабат ямьле вә хуш, бер кеше юк урамда, нинди тын вә нинди хуш! *(Рамазан тын калып тыңланып тора.)* Нигә дәшмисең? Син мине шушы болотага карап утырырга дип алып килдеңме? *(Рамазан аңа гашыйк күзләре белән карап куя. Гөлсирин әллә нишләп китә, йөзен җыера.)* Карама миңа шулай итеп! Күз карашың әллә нинди!
Рамазан. Нинди?
Гөлсирин *(киная белән).* Тра-ги-чес-ки!
Рамазан. Бар да шулай ди. Нишлим? Менә мин шундый авыр кеше инде, шундый булып туганмын, күрәсең. Мин моңа гаепле түгелмен. *(Күлгә таш ата.)* Таш ничек очты, җиңел очты, әй! Күрдеңме? *(Пауза.)* Ә синең белән җиңел миңа, шундый җиңел...
Гөлсирин. Синең белән оча күңел, шулаймы?!
Рамазан. Чынлап әйтәм.
Гөлсирин. Мин дә уйнап әйтмим.

Рамазан, Гөлсирин янына килеп, аның кулыннан ала.

Рамазан *(аңа төбәлеп).* Рәхмәт сиңа. Син мине ялгызлыктан коткардың.
Гөлсирин *(кулын алып).* Туктале! Болай ярамый! Мин сине коткаручы да, батыручы да түгел. Әгәр син минем белән болай җитди итеп сөйләшсәң, мин...
Рамазан. Нишлисең?
Гөлсирин. Башка егет белән җилдерәчәк... мотоциклда...
Рамазан *(кызып).* Ә-ә! Сиңа мин түгел, матай кирәкмени соң?! Кирәк икән, әнә ал да җилдер! Бар, кабызып бирәм!
Гөлсирин. Җитте! *(Үпкәләп.)* Хва-тит!
Рамазан. Ә бәлкем, миңа суга сикерергәдер, ә?
Гөлсирин. Нигә?

Рамазан. Мин суга сикерсәм, бәлкем, күңелең күтәрелеп китәр. Кала кызларының күңелен шулай гына ачып була торгандыр!

Гөлсирин. Ну, бар, сикер инде! *(Рамазан сикерергә җыена башлагач.)* Җүләр! Хва-тит!

Рамазан *(тукталып).* Ачуланма, Гөлсирин. Эх! Сине монда алып килеп ялгыштым мин.

Гөлсирин. Нигә?

Рамазан. Безнең тирәдә шундый бер сүз йөри: шушы күл буенда очрашкан парлар гомергә дә бергә була алмыйлар, ялгыз калалар...

Гөлсирин. Һе, тапкансың! Син шуңа ышанасыңмы?

Рамазан. Мин моңа ышанмас та идем. Ләкин бу пәриле күл буенда очрашкан парлар кавышканнан соң да аерылышалар. Статистика! *(Гөлсирин янына килеп.)* Хәер, синең белән безгә бу нәрсә янамый. Без бит синең белән дуслар гына, шулай бит?!

Гөлсирин. Шулай.

Рамазан *(Гөлсиринга кул биреп).* Киттек!

Гөлсирин. Кая?

Рамазан. Авылга. Күңел ачарга.

Гөлсирин. Ә монда?

Рамазан. Монда ярамый. Күңел ача торган җир түгел бу.

Гөлсирин. Ә кайда соң ул күңел ача торган җир?

Рамазан. Бүген кич клуб бакчасында яшьләр җыела. Шунда барырбыз. Сиңа анда күңелле булыр! О'кей?!

Гөлсирин. О'кей!

Рамазан. Киттек!

Гөлсиринне алып китә. Кузгалып киткән мотоцикл тавышы ишетелә.
Тәкәрлек кычкырып куя. Музыка. Караңгылык.

**ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Хәят өе. Иске, борынгы җиһаз. Өйдә Хәят, Зәйнәп.

Зәйнәп *(кибеттән кайтып кына кергән).* Әй бу авыл! Һаман шул! Капкадан аркылы чыгуга ук, кемлегеңне тикшерергә тотыналар. Кем ул? Нигә кайткан? Сорау арты сорау! *(Үзалдына.)* Ә ул мине танымады да булса кирәк. Артымнан карап калды калуын... *(Пауза.)* Хәят апа!

Хәят *(эш белән мәшгуль).* Әү! Әү, җаным?!

Зәйнәп. Ой... һич кенә дә сиңа әнкәй дип эндәшергә өйрәнмәдем. Агач тел мин, агач тел...

Хәят. Зыян юк, зыян юк...

Зәйнәп. Әнкәй... Мин алып кайткан тәм-томнардан бер дә авыз итмисең син, ә? Күпме конфет, күпме печенье, шоколад...

Хәят. Әй, расхутлангансың, кызым, бик тә расхутлангансың. Бәрәңге ашап өйрәнгән авызга күбрәк булган... Зәйнәп, хәзер бәрәңге бәлеше пешерәбез. Атаң бик ярата иде бәрәңге бәлешен. *(Елап ала. Зәйнәп аны юата.)* Зәйнәп, әллә, мәйтәм, базга төшеп бәрәңге алып менәсеңме?

Зәйнәп. Юк, юк, төшмим. Базда бака күп анда. Мин бакадан куркам.

Хәят. И-и! Бакадан куркалар димени инде! Бакалы җирдә хәтта су да чиста була, диләр...

Зәйнәп. Юк! Ни генә дисәң дә төшмим.

Хәят. Ярар, ярар, борчылма, үзем төшәрмен.

Чиләк күтәреп чыгып китә.
Зәйнәп дивардагы ир кеше фоторәсеменә төбәлә. Кулы белән сыйпый.
Күңеле тула.

Зәйнәп. Әй, әткәй, әткәй, кичер мине, мин бит сине күмәргә дә кайта алмадым, кичер...

Шакир керә. Шактый олыгайган. Тамак кыра. Зәйнәп, сискәнеп, аңа таба борыла.

Зәйнәп. Син?!

Шакир. Әйе, мин... ачуланмасаң... Керергә ярыйдыр бит?

Зәйнәп. Кергәнсең бит инде.

Шакир. Абау. Болай төксе итеп каршы алырсың дип уйламаган идем.

Зәйнәп. Ә мин сине ничек — колач җәеп каршы алырга тиешме?! *(Пауза.)*
Шакир. Ә мин сине урамда бер күрүдә үк таныдым, Зәйнәп, таныдым. Шулай... Ә син бер дә үзгәрмәгәнсең, син һаман да шул ук. Чибәр, төз.
Зәйнәп. Син нәрсә, минем чибәрлегемә сокланырга дип килдеңме?
Шакир. Юк, билгеле. Әйе, анысы да бар инде... Мин синең белән сөйләшергә дип килгән идем.
Зәйнәп. Ә минем синең белән сөйләшәсем килми.
Шакир *(каушап).* Шулай дисең инде... Озакка кайттыңмы?
Зәйнәп. Озакка.
Шакир. Шулаймы?! *(Ни сөенергә, ни көенергә белми.)*
Зәйнәп. Тик сине күрергә дип кайтмадым. Хәят апайны күрергә кайттым... Нигез тарала, дип хат язгач, кайтмыйча булдыра алмадым.
Шакир. Ник, яхшы гамәл, минемчә... Бер рәхәтләнеп сөйләшеп утырасым килгән иде синең белән, хатирәләрне яңартып...
Зәйнәп. Мине монда синең белән хатирәләр яңартырга кайтты дип уйлыйсың мәллә?! Сыйларга коньяк та алып кайтмадым, яхшылыгың өчен магарыч!
Шакир. Зәйнәп, ни бит...
Зәйнәп. Кирәкми! Мин ял итәргә дип кайттым. Миңа шау-шу кирәкми, Шакир абый...
Шакир *(сөенеп).* Соң, миңа да кирәкми. Нәкъ менә өстенә бастың. Ишеткәнсеңдер, мин быел көзгә пенсиягә чыгам. Аллага шөкер, рәислектән котылам. Шунысын да әйтим, мине бик зурлап озатырга торалар. Суверенный Татарстанның пачут грамотасын бирергә торалар. Бәлкем, түшемә Рәсәйнең кара кошы да кунар. Зур-зур хезмәтләрем өчен! Ә ул кара кош тавыш-гауганы яратмый, ай, бер дә яратмый. Хәзер миңа тыныч кына, матур гына пенсиягә чыгарга кирәк.
Зәйнәп. Чык. Миннән рөхсәт.
Шакир. Кем белә бит, кем белә... алдагысын... Шулай да җылы сүзең өчен рәхмәт сиңа.
Зәйнәп. Беттеме сүзең? Бетсә, бар, кайт, ишек ачык. Орденга күкрәгеңне киңәйтә тор! Бар!
Шакир *(таптанып).* Зәйнәп, туктале. Мин бит сине егерме биш елдан артык күрмәдем. Уйлап кара — егерме биш ел!
Зәйнәп. Әгәр кайтмаган булсам, син мине йөз егерме биш ел да күрмәгән булыр идең.
Шакир. Зәйнәп... гомер узган... үткәнгә кире кайтып булмый. Үткән ялгышларны сүтүдән ни мәгънә?! Әйе, синең алда гаебем зур... зур инде, зур. Кичерә алсаң, кичерерсең. Тик мин генә гаепле идеммени соң анда? Иле шундый иде бит, кабахәт, әшәке заман!
Зәйнәп. Заманага гына сылтарга ярамый. Мин ул заман белән бүгенгенең аермасын күрмим. Каршымда шул бер үк Шакир әфәнде!
Шакир. О! Сөйләшергә өйрәнгәнсең!
Зәйнәп. Ә нәрсә үзгәрде? *(Пауза.)* Шул ук принциплар, шул ук мескенлектә ярышу. Мин ул заманны аклаучы да, гафу итүче дә түгел.
Шакир. Шәп... Укырга җибәреп дөрес эшләгәнмен, дөрес. Тик изге эш тиз онытыла шул. Ни әйтсәң дә, мин сине укырга җибәрдем, сине, Зәйнәп, сине генә... *(Зәйнәпне кочмакчы була.)* Сиңа сыенасым килә, Зәйнәп...

Зәйнәп Шакирны бар көченә этеп җибәрә. Шакир абынып егыла.

Зәйнәп. Бар, чыгып кит яхшы чакта! Күземә күренәсе булма!
Шакир *(торып).* Яхшы, яхшы, китәм, тик, зинһар, тавыш кына куптарма... Их, сөйләшеп булмады...

Гөлсирин керә. Шакир аңа текәлеп катып кала.

Гөлсирин. Хәерле иртә! *(Шакирга.)* Исәнмесез!
Шакир. Исәнме!..
Гөлсирин. Мам! Ашыйсы килә! Ни бар? *(Өстәл янына утыра.)* Ой... йокы туймады... *(Киерелеп ала. Бер Шакирга, бер әнисенә карый.)* Мам, ну че, а?!

Шакир Гөлсирингә карап тора да чыгып китә.

Мам, кем ул, ә?
Зәйнәп. Кеше.
Гөлсирин. Күрәм кеше икәнен.
Зәйнәп. Сиңа кем булса да бер түгелмени?
Гөлсирин. Ну и... даже сорарга да ярамый! *(Ашый, эчә. Зәйнәп аңа карап тора.)*

Зәйнәп. Кызым...

Гөлсирин. Ну, че, мам?!

Зәйнәп. Ошыймы сиңа авылда?

Гөлсирин. Ошый. *(Уйнап.)* Әй, син, авыл, шәһәрдән мең кабат ямьле вә хуш. Бер кеше юк урамда, нинди тын вә нинди хуш... *(Көлә.)*

Зәйнәп. Төне буе кайда йөрдең? Нишләп өйдә кунмадың?

Гөлсирин. Мин чиннектә йокладым. Анда рәхәт. Түбәнең буеннан-буена каен себеркесе элгәннәр. Ах, аның исе! Ну просто прелесть! Кыскасы, бернинди дә дезодорант кирәк түгел! Просто баш әйләнә шул истән!

Зәйнәп. Күрәм, башың болай да әйләнгән синең. Кара аны, бөтенләйгә әйләнеп китмәсен. Бүген тышта кунмыйсың, өйдә кунасың.

Гөлсирин. Нигә?

Зәйнәп. Син бүген төнге өчтә генә кайттың.

Гөлсирин. Каян белдең?

Зәйнәп. Төнлә капкадан кергәнеңне ишеттем. Кайда йөрдең?

Гөлсирин. Ну вот! Мам, ведь я же не ребенок, а! Миңа егерме биш яшь.

Зәйнәп. Син миңа илледә дә бала булачак. Менә минем яшькә җит әле. Кияүгә чыгарсың, балаларың булыр... Аннан аңларсың! Кайда булдың?

Гөлсирин. Ну вот, опять контроль! Калада контроль, дачада контроль! Инде монда авылда да контроль! Когда это кончится? Ни себе, ни людям!

Зәйнәп *(үзенекен тәкрарлап).* Кайда булдың, дим?

Гөлсирин. Ну, кайда? Клубта! Без күңел ачтык...

Зәйнәп. Төне буемы? Кем белән таныштың, әйт?!

Гөлсирин. Ну, берәү... Арттан йөри инде шунда...

Зәйнәп. Исеме ничек?

Гөлсирин. Белмим. Мин шаярам гына бит.

Зәйнәп. Шаярып ут чыгара күрмә. Авыл егетләре кала кызларына бик тиз гашыйк булалар. Авылда кызлар аз...

Гөлсирин. Ну, мам, миңа просто кызык аның белән. Мин шаярам, ә ул мине ка-та-ет!

Зәйнәп. Кем соң ул?

Гөлсирин. Кем? Ну бер авыл егете инде...

Зәйнәп. Авыл егете, дисең инде?! Ә кем баласы икәнен беләсеңме?

Гөлсирин. Каян белим. Миңа аның нәселе нигә? Мин бит аңа кияүгә чыгарга җыенмыйм.

Зәйнәп. Исеме бардыр бит?

Гөлсирин. Бар.

Зәйнәп. Ничек?

Гөлсирин. Ра-ма-зан!

Зәйнәп. Рамазан... Ничә яшьтә?

Гөлсирин. Белмим. Миннән олырак бугай. Ну, мам, нигә инде ул?

Ана белән кыз сөйләшкәндә, клубта җырланган «Тәкәрлек тавышы»
җыры яңгырый. Рамазан тавышы белән.

Зәйнәп. Кем малае икәнен дә белмим, дисең инде?

Гөлсирин. Юк, белмим. Белергә дә теләмим.

Зәйнәп *(катгый).* Ә син бел. Бүген үк бел кем баласы икәнен!

Гөлсирин. Ярый, мам, белермен.

Зәйнәп *(кузгалып).* Шул заман кая йөри бу дәү әниең? Базда берәр нәрсә булмасын тагын. Бар әле карап кер! Бар инде, бар!

Гөлсирин. Ну, мам, барам бит инде! Барам!

Чыгып китә.

Зәйнәп. Нигә керде бу Шакир? Ни кирәк аңа?

Хәят керә. Кулында чиләк. Чиләге төшеп китә. Бәрәңгеләре тәгәри.

Ни булды, Хәят апай?

Хәят *(йөрәген тотып).* Күпме шул Акбүз атны ихатага кертергә маташтым. Кермәде капкадан. Хәзер генә аңладым нигә кермәгәнен: ат бит бәрәңге ашамый, ат бит солы ашый. *(Бер ноктага төбә-*

*леп.)* И-и картлык! Шуны да оныткканмын! Ат бит бәрәңге ашамый, ат бит солы ашый. Мин бит сине юкка гына чакырып кайтармадым, кызым. Солы алып кайтырга кирәк!

Зәйнәп. Хәят апай... алышына башлаган...

Хәят. Кызым...

Зәйнәп. Хәзер, хәзер, тынычлан. Җыям, үзем җыям... *(Бәрәңгеләрне җыя.)*

Хәят. Бәрәңге кабыгын идәнгә ташлама. Чүп чиләгенә сал. Сарыклар бик яратып ашый аны.

Зәйнәп. Ул сарыклар сиңа нәрсәгә инде? Аларны карарга сәламәтлегең дә юк бит.

Хәят. Әй, кызым, авыл сарыксыз тора алмый ул. Авылда сарыгың булмаса, бәрәңгене кемгә ашатырсың? Менә син дә кайттың, син дә булышырсың.

Зәйнәп. Мин монда булганда, билгеле, булышырмын. Тик мин киткәч... *(Пауза.)* Апай... Әнкәй... Син Рамазан атлы егетне беләсеңме?

Хәят. Рамазаннар күп бездә. Кайсысын әйтәсең?

Зәйнәп. Каян белим... Ә ни... Шакирның улы ни атлы?

Хәят. Кайсы Шакир ул?

Зәйнәп. Силсәвит Шакир инде.

Хәят. Ә! Перес Шакирымы! Шель оправдывает шредства... Таптың искә алыр кеше. Мөртәт. Сарыкларым игенгә кергән өчен миңа штраф суктырды. Кадалып киткере! Аның күк канечкеч! *(Алмашынып.)* Кайчан солы алып кайтасың инде? *(Зәйнәп, аңламыйча, Хәятка карап тора.)* Кызың кайда соң әле?

Зәйнәп. Белмим. Синең арттан чыгарып җибәргән идем.

Хәят. Ә, шулаймы? Туктале, мин аны солы эзләргә җибәрим әле. Үзем бәрәңге бакчасына корт җыярга чыгыйм. Күптән корт җыйган юк. Ашап бетерә бәрәңгене бу корт тәресе!

Зәйнәп. Йөрмә инде, бәлкем, ятып торырсың?!

Хәят. Юк, безгә керәсе ат конфет та ашамый. Хи-хи-хи! *(Чыга.)*

Зәйнәп. Алышына башлаган апай, алышына.

Як-ягына каранып, Шакир керә.

Зәйнәп *(сискәнеп).* Син?! Тагын син?!

Шакир. Зәйнәп... ни... бит... мин киткән дә булыр идем. Тик ни...

Зәйнәп *(кулын юып).* Ни кирәк сиңа тагын?

Шакир *(әсәрләнеп).* Ул... Ул минем кызыммы? *(Урам ягына күрсәтә.)*

Зәйнәп. Юк, монда синең кызың юк.

Шакир. Аны күрүгә үк, мин әллә нишләп киттем. Менә монда *(йөрәк турын тотып)* нидер өзелеп киткәндәй булды. Ул безнең теге татлы кичебезнең җимеше, шулай бит?! Зәйнәп?! *(Зәйнәп дәшми. Урындыкка утыра.)* Димәк, дөрес?! *(Пауза. Ни сөенергә, ни көенергә белми.)* Ә бала туу турында нигә хәбәр итмәдең?

Зәйнәп. Кирәк идеме соң сиңа андый хәбәр?! Сөенгән булыр идең микән? Ул заманда уйнаштан туган балаң барлыгын белсәләр, эшеңнән генә түгел, рисвай итеп, авылыңнан ук куып чыгаралар иде бит. Беркемгә дә белгертмәгәнгә рәхмәт әйт инде.

Шакир. Рәхмәт. *(Башын аска иеп.)* Берүзеңә генә бала үстерү авыр булгандыр димәкче булам.

Зәйнәп. Ә кая барасың?

Шакир. Иргә дә чыкмадың?

Зәйнәп. Юк, чыкмадым.

Шакир. Сораучылар булгандыр бит?

Зәйнәп. Булды. Сораучылар... Тик аларның берсенә дә минем балам кирәк булмады, аларга мин кирәк булдым.

Шакир. Синең мине күралмаска хакың бар. Ләкин мин дә ул вакытта синнән файдаланырга уйламадым. Мин бит яратып, без бит яратышып кына... без бит...

Зәйнәп. Яратып? Сөйләмә әкият! Нинди ярату булсын ди анда? Ни сөйлисең син?!

Шакир. Дөресен сөйлим, Зәйнәп, дөресен. Мин бит сиңа яшертен генә гашыйк булып йөрдем. Сине яратасым, сөясем килде. Ләкин мин өйләнгән, теләсәм дә, яратмаган хатынымнан аерыла алмадым. Законы шундый иде, әхлаксыз дип эштән бушатулары бар иде. Ә ярату менә монда йөрде, монда — йөрәктә...

Зәйнәп. Җитәр! Күпме комедия куярга була! Кемгә кирәк синең бу буш сүзләрең? Кемгә?

Шакир. Миңа, менә миңа кирәк. Кайчан да булса мин дөресен сөйләргә тиештер бит инде?! *(Зәйнәп көлеп җибәрә.)* Ә нигә көләсең? Мин синең белән кушылырга риза, ә син көләсең. Ә нәрсә?! Балалар үскән. Аерылуы хәзер җиңел. Икәү шәһәргә китәбез дә барабыз. Акча күп.

Зәйнәп. Җитте! Ни сөйләгәнеңне аңлыйсыңмы син, юкмы? Нинди китү ди ул, нинди тору? Мин бит сине күралмыйм!

Шакир. Мин бит... баланың атасы...

Зәйнәп. Юк! Синең балаң түгел ул! Син аның атасы түгел! Хәзер үк чыгып кит!

Шакир. Ярый, ярый, шаулама! Сиңа бер үтенечем бар: белмәсеннәр иде авылдашлар аның минеке икәнлеген!

Зәйнәп. Белмәсләр, бар. Тынычлап йокла, тыныч кына пенсияңә чык. Бар, кит! *(Этеп-төртеп чыгара башлый.)*

Шакир *(үзалдына).* Ни пычагыма дип кайткан ул авылга, ни пычагыма?

Гөлсирин керә.

Гөлсирин. Исәнмесез! Тагын бер кат!

Шакир. Исәнме... кызым... әй... хуш булып тор...

Як-ягына каранып чыгып китә.

Гөлсирин. Мам! Ә кем ул, ә?!

Кереп китә. Караңгылык.

**ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Эңгер-меңгер. Көтү кайткан. Мотоцикл тавышы ишетелә. Бу — Рамазан. Гөлсирин, колагына наушниклар тагып, капка төбендә музыка
тыңлап утыра. Рамазан күренә. Ул башына каска кигән.

Рамазан. Ну, Гөлсирин, син нәрсә инде, ә?! Бөтен көчемә акыртам, ә син ишетмисең дә. Әйдә, киттек!

Гөлсирин. Кая?

Рамазан. Яксазга. Үрдәк атарга йә булмаса куян. Сөйләштек бит инде. Хәзер кереп әтинең мылтыгын алып чыгам да...

Гөлсирин. Нигә үрдәк?

Рамазан. Ну, куян атарбыз. Алар кич үзләре фара яктысына чыгалар.

Гөлсирин. Кирәкми, мин кызганам аларны.

Рамазан. Һавага атарбыз. Телисеңме, мин сине мылтыктан атарга өйрәтәм?!

Гөлсирин. Бигрәк тагын! Юк, мин бармыйм. Әни дә рөхсәт итми.

Рамазан. Әйдә инде, син бала-чага түгел анаңнан рөхсәт сорарга.

Гөлсирин. Юк, булмый.

Рамазан. Киттек әйдә, матай йөртергә өйрәтәм.

Гөлсирин. Правда?!

Рамазан. Ие!

Гөлсирин *(торып).* Да! Это круто!

Рамазан. Киттек!

Гөлсирин *(икеләнеп).* Юк, әнигә әйтмичә ярамый. Әйдә, бергә әйтик. Ул әле синең белән танышырга да теләгән иде.

Рамазан *(теләмичә генә).* Юк инде, үзең генә әйт.

Гөлсирин. Мам! Мам!

Зәйнәп күренә.

Зәйнәп. Нәрсә?

Гөлсирин. Минем матай йөртергә өйрәнәсем килә.

Рамазан *(Зәйнәпкә).* Исәнмесез!

Зәйнәп. Исәнме... *(Озак кына Рамазанга карап тора.)*

Рамазан. Без хәзер кайтабыз. Мөмкиндер бит?

Зәйнәп *(кырыс).* Син кем малае?

Рамазан. Мин?!

Зәйнәп. Әйе, син!

Рамазан. Шакир малае.

Зәйнәп. Кайсы Шакир? Влач Шакирмы?

Рамазан *(йөзен чытып).* Нинди сорау алу соң бу? Юк, миңа ошамый бу. Ярый, сау булып торыгыз! *(Китә башлый.)*

Гөлсирин. Ну, мам, син бигрәк инде! *(Рамазанга.)* Мин синең белән!

Зәйнәп. Юк, беркая да бармыйсың! *(Тота.)*

Гөлсирин. Барам! *(Ычкына.)*

Зәйнәп. Тукта! Аңлашыйк! Кая чабасың?!

Гөлсирин. Соңыннан! Рамазан!

Рамазанга ияреп китә.
Мотоцикл кузгалып киткән тавыш ишетелә.

Зәйнәп. Әй Аллам! Әйе, бу — шул. Шакир малае! Кызым, кызым, нишлисең син?!

Маһруза керә. Бер-берсенә карашып торалар.

Маһруза *(сынаулы караш белән).* Таныдыңмы?

Зәйнәп. Маһруза апа бит, әйеме? Исәнмесез... Безгәме?

Маһруза. Сиңа. Әтисен дә күмәргә кайтмаган кешенең хәзер генә нигә кайтканын беләсем килгән иде. Егерме биш елдан соң авылга кайтып төшүең сәеррәк күренә?!

Зәйнәп. Ял итәргә кайттым. Җәйге ялга. Хәят апай чакырып кайтарды... Нигез тарала, нигез...

Маһруза *(кырыс).* Зәйнәп... Мин — авыл хатыны. Без шәһәр халкы кебек нечкә итеп сөйләшергә өйрәнмәгән. Без турыдан бәрергә яратабыз. Минемчә, син безнең тормышны җимерергә кайткан.

Зәйнәп. Мин?! Сезнең тормышны?!

Маһруза. Ие. Шакир белән безнең тормышны.

Зәйнәп. Сезнең тормышыгызда минем ни катнашым бар?

Маһруза. Уйнама, Зәйнәп. Мин барысын да беләм.

Зәйнәп. Нәрсә беләсез? (*Пауза.*) Йә, нигә дәшмисез?

Маһруза. Теге вакытта... сез силсәвиттә чөкердәшеп утырганда, мин анда идем бит, мин барысын да күреп, ишетеп тордым.

Зәйнәп *(тетрәнеп).* Сез... Сез барысын да беләсез...

Маһруза. Ие. Бәхетсезлеккә каршы. Белмәгән, күрмәгән булсам, яхшырак булыр иде дә бит... *(Күз яшьләрен сөртә.)*

Зәйнәп. Ә Шакир? Ул сез белгәнне беләме соң?

Маһруза. Юк, белми. Тавыш куптармадым. Ә кая барасың — кулда балалар. Кайгымны эчемә җыеп яшәдем. Шул гомер эчендә күпме күз яше түккәнемне бер үзем генә беләм. (*Пауза.*) Ә ул төнне печән өелмичә калды. Малаем Рамазан, печән өстеннән егылып төшеп, башын имгәтте. Сәер булып үсте. Сүз күтәрми. Бик тиз кызып китә.

Зәйнәп. Мин гаепле инде?

Маһруза. Ә син ничек уйлыйсың?

Зәйнәп. Гаепне бер миннән генә түгел, ирегездән дә эзләгез, Маһруза апа.

Маһруза. Алай икән...

Зәйнәп. Әйе. Мин үзем дә кәгазь корбаны гына.

Маһруза *(усал).* Ие... Авылдан китүнең башка юлын тапмаган инде син. *(Зәйнәп дәшми.)* Әгәр син шул юлга бармаган булсаң, ул сине берни дә эшләтә алмаган булыр иде. Ирләрне кемнәр аздыра? Ирләрне менә синең кебекләр аздыра.

Зәйнәп. Җитте. Мин сезнең алда акланып торырга җыенмыйм. Хушыгыз!

Маһруза. Тукта, ашыкма. Әйт, Шакир сиңа ни өчен килде? Син чакырдыңмы аны?

Зәйнәп. Ә! Менә эш нидә икән?! Юк, мин аны чакырмадым. Ул үзе килде. Куркып килгән. Берәр хәл булмасын дип. Аңа бит хәзер матур гына пенсиягә чыгарга кирәк. *(Пауза.)* Карагыз әле, үткәндә казынуда файда юк. Бүген өстебезгә тагын бер бәла килергә тора. Әнә безнең балаларыбыз бер-берсе белән танышып, дуслашып та өлгергәннәр. Безгә шул турыда уйларга кирәк. *(Өйгә кереп китә.)*

Маһруза *(ялгызы).* Чынлап та, кайчан танышырга өлгергәннәр соң алар? Моңа кадәр түздең, Маһруза, инде монысына ничек түзәрсең?!

Елап китеп бара. Караңгылык.

**ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Яксаз күле. Кич. Пар күтәрелә. Яр буенда учак яна. Учак янында Рамазан, Гөлсирин. Рамазан гитарада уйный. «Тәкәрлек тавышы»
көенә җырлый. Тәкәрлек кычкырып куя. Гөлсирин куркып китә.

Рамазан. Курыкма...

Гөлсирин. Нәрсә ул?

Рамазан. Тәкәрлек... *(Тәкәрлек тавышы кабатлана.)* Курыкма, кош кына ул. Сазлык кошы. Дөрес, яманаты чыккан. Имеш, ялгызлык юлдашы. Әгәр дә аны юк итсәң, кешеләр, бәлкем, ялгызлыктан котыла алырлар, ә?!

Гөлсирин. Ә ничек юк итәсең аларны?

Рамазан. Атарга! Атабыз...

Рамазан, мылтыгын алып, төрле якка ата башлый. Гөлсирин куркып
кычкыра. Рамазан мылтыгын ташлый. Хәлсезләнеп ава.

Файдасыз. Ялгызлыктан барыбер качып котылып булмый. Ялгызлык чире ул минә монда... җанда. Аның үзәк өзгеч тавышы һаман да минем җанны телгәли. Тәкәрлек мин ул, Гөлсирин, мин, мин ул ялгызлык юлдашы, мин... Шул кошка төбәп атканда, әйтерсең лә үземә аткан кебек булам...

Гөлсирин. Куркам мин ул коштан. Нишләп шулкадәр өзгәләнә соң ул? Әнә тагын! Әнә тегесе... Әллә парын эзли микән?

Рамазан. Мөгаен, шулайдыр.

Гөлсирин. Рамазан...

Рамазан. Әү?!

Гөлсирин. Ә нишләп син өйләнмәгән?

Рамазан. Хе! Мин ике мәртәбә өйләнеп карадым. Беренчесен күрше авылдан урлап, чанага салып алып кайттым.

Гөлсирин. Чанага салуны урлау диләрмени?

Рамазан. Ха-ха... Урладык дип әйтсәк, бик үк дөрес тә булмас. Чынында исә кыз үзе риза иде. Тик әти-әниләр генә ошатмадылар үзен. Законны бозасың, мине халык алдында хур итәсең, дип, әти башымны ашады. Өйгә кертмәделәр. Кире кайтарып куйдым. *(Пауза.)* Икенчесен каладан алып кайттым. Авыл кызы иде үзе. Влач анысын да ошатмады. Безнең нәселгә бара торган түгел бу, синнән олы, шактый таушалган, дип теңкәмә тиде. Кире калага илтеп куярга куштылар. Каршы килеп карадым. Язылышмыйча гына авылның бер буш өендә яшәп тә карадык. Әти аннан да куып чыгарды. Шуннан соң калага качтык, тик тормыш барып чыкмады. Мин укый гына идем әле ул вакыт. Ә әти-әниең ярдәм итмәсә, калада яшәве җиңел түгел шул. Хушлашырга туры килде. Алар димләгән кызларга өйләнмәдем. Яратмыйча ничек өйләнергә кирәк?! Инде менә өченче тапкырында барып чыкмаса, белмим, нишләргә инде?! Йә кач моннан, йә үз-үзеңә кул сал... Башка юл юк...

Гөлсирин. Җүләр. Тәүбә, диген!

Күк күкрәп, яңгыр ява.

Рамазан *(кулыннан алып).* Тәүбә! Тәүбә! Мин җүләр, әйеме?!

Гөлсирин *(елышып).* Рамазан!

Рамазан. Нишлим мин?

Яшен яшьни.

Гөлсирин. Мин куркам, Рамазан. *(Рамазанга елыша.)*

Рамазан. Курыкма... Яныңда мин бар... *(Кочаклый.)*

Кара шәүлә пәйда була.

Гөлсирин. Анда кемдер бар.

Рамазан. Ә! Кара шәүлә!

Гөлсирин *(коты очып).* Кем?!

Рамазан. Ул тагын монда! Әһә, тагын килдеңме?! *(Мылтыкны ала.)*

Гөлсирин. Нишлисең син? Кем ул?

Рамазан. Монда еш күрәм мин аны. Минем арттан йөри. Минем үлемемне тели. Юк, мин аңа бирешмәм. Без бергә булганда, ул безгә орына алмас. *(Карана.)* Күрәсеңме, ул инде югалды! Җиңелде әлегә...

Гөлсирин. Шулай да мин куркам, Рамазан.
Рамазан. Курыкма, мин бит синең янда... бәгърем... кочакла, кочакла.

Гөлсирин Рамазанның кочагына керә. Рамазан аны үбә. Көй яңгы-
рый. Җырлыйлар.

Рамазан.

Төнге ай нурында,
Тирән күл ярында
Яктык без яшьлекнең учагын.
Син — минем бердәнбер,
Мин — синең бердәнбер,
Кил, бәгърем, кил ачып кочагың...

Бергә.

Тәкрарлек —
Тавышың үзәк өзәрлек.
Бир канат — очарга,
Күкләрне кочарга,
Юк чамам түзәрлек.

Гөлсирин.

Төн яна учакта,
Мин синең кочакта,
Сөй мине, һичкайчан юатма.
Тәкәрлек тавышы,
Ул — йөрәк сагышы,
Сакла син сөюне, югалтма.

Кушымтаны бергә башкаралар.

Рамазан.

Төнге ай нурында,
Тирән күл ярында
Ишеттем тәкәрлек тавышын.
Шул кошның көендә,
Ишеттем көнендә,
Ишеттем үземнең язмышым.

Кушымтаны бергә башкаралар.

Көй агыла. Тәкәрлек кычкырып куя.

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Таң атып килә. Хәятләр өе. Зәйнәп ялгызы. Өстенә җылы кофта бөр-
кәнгән. Ишек шакыйлар.

Зәйнәп *(ачып).* Гөлсирин?!. Кызым?!.

Шакир керә.

Шакир. Кызыңны көтәсеңме?
Зәйнәп. Көтәм.
Шакир. Көтмә. Күл буенда алар. Без күрешкән күл буенда.
Зәйнәп. Ничек?!
Шакир. Машинага утырып, күлгә барсам, алар шунда.
Зәйнәп. Ә нигә алып кайтмадың?
Шакир. Бик ярсып барган идем дә, баргач сыгылдым да төштем. Алар бер-берсен яраталар кебек.
Зәйнәп. Алар бер-берсен яратырга тиеш түгелләр. Алар абый белән сеңел. Аларда бер кан, алар бертуганнар.

Шакир. Шулай... Кая барып җиттек? Төртелдек, ай, төртелдек. Нишләргә?

Зәйнәп. Ә мин беләм нишләргә кирәген. Безгә китәргә кирәк. Мөмкин кадәр тизрәк.

Шакир. Соңгарак калмадык микән?! Алданрак, алданрак китәргә кирәк булган.

Зәйнәп. Минем кызым шәһәрдә тора, синең улың — авылда. Киткәч, аергач, бер-берсен тиз онытырлар.

Шакир. Кыз онытыр да, бәлкем. Ә минеке, улым дип тә дәшәсем килми шуңа, онытмас. Артыннан ук бастырып барыр. Дивана бит ул, натуральный дивана. Акламады өметемне, ай, акламады. Укыттым. Укып кеше булыр дип уйладым. Булмады. Йөри әнә хәзер шар тибеп... Дөньясы дөрес түгел, янәсе. Дөнья һаман да шул ул, ул үзе никудышный. Өйләнә алмагач, асылынырга йөрде бит, дивана! *(Пауза.)* Карале! Ә бәлкем... Әгәр өйләнешәбез, дисәләр, каршы килмәскәдер?! Абый белән сеңел икәнлекләрен дә әйтмәбез. Бала таптырмабыз, ә?!

Зәйнәп. Ни сөйләгәнеңне үзең аңлыйсыңмы соң син?! Бу бит кан алыштырмау, нәсел корыту дигән сүз. Безне фаҗигагә илтә торган нәрсә.

Шакир. Фаҗига?! Таптың сүз... фаҗига, имеш. Әнә нинди фаҗига алып киләләр алар безгә.

Зәйнәп. Ә бәла башы бездә.

Шакир. Ярар инде! Вакыты ул түгел! *(Каранып.)* Син үзең генәдер бит?

Зәйнәп. Хәят апай түр якта, яткан, авырый. Ә нәрсә?

Шакир. Зәйнәп! *(Кул изи. Пышылдап.)* Бу безнең арада гына калырга тиеш. Маһрузага белдерергә ярамый. Ишетәсеңме? Зинһар, безнең серне ача күрмә! Әйтмә аңа берни дә... *(Пауза. Шикләнеп.)* Хатын синең янга килмәгәндер ич? Килмәдеме? Нигә дәшмисең?

Зәйнәп. Килде.

Шакир *(каушап).* Килде? Син чакырмагансыңдыр бит?

Зәйнәп. Юк. Ул үзе килде.

Шакир. Соң...

Зәйнәп. Ул барысын да белә.

Шакир *(коты очып).* Бе-лә?

Зәйнәп. Әйе.

Шакир *(Зәйнәпкә ябышып).* Син?! Син әйттеңме?! Син! Син — юха елан!

Зәйнәп. Ал кулыңны! *(Этеп җибәрә.)*

Шакир. Син... син... шуның өчен кайткан, безнең тормышны бозар өчен кайткан. Ах, син су... у... у-у-у...

Зәйнәп *(кабынып).* Әйтеп бетер! У-ух! *(Тезе белән Шакирның билдән түбән җиренә төртә.)* У-ух!

Шакир бөгелеп төшә. Зәйнәп кулына табуретка ала.

Кагылып кына кара, башыңны бәреп ярам!

Шакир *(чигенеп).* Ярар инде, ярар, бетте... бетте, дим бит инде...

Зәйнәп. Тыңла, мин хатыныңа бер сүз дә әйтмәдем. Ул үзе барысын да белә.

Шакир. Ә ничек белсен ул? Каян?

Зәйнәп. Теге вакытны силсәвиттә ул барысын да күреп, ишетеп торган.

Шакир. Ә?! *(Сыгылып төшә.)* Ну, Маһруза, ну, хатын! Менә бу хатын, ичмасам! Күпме түзгән... дәшмичә... Ә бала турында беләме?

Зәйнәп. Юк. Анысын белми бугай...

Шакир. Менә монысы ярый, белмәве әйбәт. Баланың кемнән икәнлеге беленсә, башлар очачак монда, башлар. Их! Ялгышлык җибәрдем. Бик зур ялгышлык. Ниемә? Яшьлегеңә, чибәрлегеңә, төз буеңа алданып... Җилкәңә бөркәнгән ак шәлең харап итте мине, ак шәлең... *(Торып чыга башлый.)* Карале, теге вакыт шәлең кая югалды синең? Мин аны җир бетереп эзләдем. Табалмадым. Эзсез югалды... Кая югалды ул?

Маһруза керә. Кулында ак шәл.

Маһруза. Менә ул... минем кулда... Мә, алыгыз!

Шакир. Маһруза, син монда?

Маһруза. Егерме биш ел буе сандыкта ятты ул. Алыгыз татлы хисләрегез хатирәсен.

Шакир. Маһруза...

Маһруза. Кирәкми. Миңа синең аклануың кирәкми. *(Зәйнәпкә шәлне атып.)* Мә, ал, Зәйнәп, бу шәл тагын синеке булды.

Зәйнәп. Миңа кирәк түгел ул. Мин андый хатирәләргә мохтаҗ түгел. *(Шәлне читкә ташлый.)*

Маһруза. Юк инде, аны читкә ташлап кына котылып булмый. Күңел рәнҗешен, җан әрнүен. Ә кемне гаепләргә? Шакир, синеме? Зәйнәп, синеме? Ә бәлкем, башка берәүне? Бәлкем, дөньясы гаепледер?! Белмим. Кемне гаепләргә дә белмичә менә сезнең каршыгызда басып торам!

Шакир *(кычкырып).* Мин! Мин генә гаепле! Әйттем бит инде! Шуннан нәрсә? Шуннан кемгә җиңел?! Үткән- беткән. Аның бүгенгесе хәтәррәк. Әнә безнең дивана аның кызына гашыйк булган. Аңа тагылган. Әгәр өйләнәм дисә, безгә нишләргә?

Маһруза. Әгәр дә Рамазан өйләнәм дисә, әгәр кыз аңарга кияүгә чыгарга риза булса, мин каршы килмәм.

Шакир. Ни сөйлисең син?!

Маһруза. Синең белән зина кылган хатын белән туганлашасым килмәсә дә, мин бу юлы улыма каршы килә алмам. Улым хакына риза булырмын.

Зәйнәп. Мин каршы! Мин сезнең белән туганлашырга теләмим. Мин моңа каршы.

Маһруза *(үчекләгән сыман).* Ә мин каршы түгел.

Зәйнәп. Ни өчен миңа шундый җәза? Ни өчен? Нинди гөнаһым өчен?

Маһруза. Нинди гөнаһың өчен?! Билгеле инде нинди гөнаһың өчен...

Зәйнәп Шакирга карый. Шакир агарынып башын аска ия, ияк кага.

Маһруза. Сез тагын миннән нидер яшерәсез?! Әйтегез! Йә, нигә дәшмисез? Әй-те-гез!

Хәят күренә.

Хәят. Ай, җаным, нинди тавыш дип уянсам, сез икән лә... Егерме биш елдан артык очрашмый торгач, сүзләрегез күп җыелгандыр шул. Булмаса, өстәл корыйк. Капкалап, сөйләшеп утырырсыз. Әнә Зәйнәп алып кайткан алмалар бар. Алып чыгыйм әле, каядыр почмакка куйган идем... *(Шакирга кырын карап.)* Мәе генә юк инде?!

Зәйнәп. Без сөйләшеп бетердек инде, Хәят апа.

Маһруза. Әйе, рәхмәт, Хәят тәтәй.

Хәят. Рәхмәтен соңыннан әйтерсез. *(Почмак ягына кереп китә. Эзләнә.)*

Зәйнәп. Апай каты авырый. Бу хәлендә ничек калдырып китәргә белмим?! Җүнле туганы да юк бит. Кем карар аны, әгәр мин китсәм?! Кем? *(Хәят артыннан керә.)*

Шакир. Маһруза, кайтыйк. *(Маһруза дәшми.)* Син мине кичералмыйсыңдыр инде, шулай бит?!

Маһруза. Сорама, Шакир. Әрнетмә йөрәгемне. Син мине бик нык рәнҗеттең. Тик нишлим, син минем ирем. Миңа никадәр генә авыр булса да, мин сине кичерергә тиешмен.

Шакир. Кичер, әгәр кичерә алсаң... Тавыш чыгармыйсы иде. Бу сер безнең арада гына калсын иде.

Маһруза. Әлегә кадәр кузгатканым булдымы соң?!

Караңгылык.

**ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Ишегалды. Шакир, Маһруза. Мотоцикл килеп туктаган тавыш. Капкадан Гөлсирин, Рамазан керә.

Гөлсирин *(чит кешеләрне күреп).* Ой...

Зәйнәп керә.

Зәйнәп *(Гөлсирингә).* Кайттыңмы? Кер.

Гөлсирин. Кемнәр болар?

Зәйнәп. Рамазанның әти-әнисе. Таныш бул: Шакир абыең, Маһруза апаң.

Гөлсирин. Исәнмесез...

Рамазан *(Маһрузага).* Әни, берни дә булмагандыр ич?

Зәйнәп *(сүзгә кушылып).* Булды. Кызымны алып киттең дә югалдың. Керфек какмыйча төне буе көтеп утырдым.

Рамазан. Ачуланмагыз инде... Вакытның узганын сизми дә калганбыз.

Гөлсирин. Мам, ачуланма инде.

Шакир *(нидер сизенеп).* Нәрсә булды инде бу? *(Рамазанга.)* Нәрсә, тагын өйләнергә булдыңмы? Ну, нәрсә тукыдым мин сезгә?!

Рамазан. Әйе. Без Гөлсирин белән бер-беребезне яратабыз. Кыскасы... *(Зәйнәпкә.)* Мин Гөлсириннең кулын сорар идем... сездән...

Зәйнәп *(Гөлсиринга).* Кызым, син аңа чыгарга ризамы?

Гөлсирин «әйе» дип башын чайкый.

Рамазан. Сез безне җиңелдән купкан дип уйламагыз. Без бит инде тормыш корыр яшьтә. Тагын ни кирәк? Нигә дәшмисез? Әткәй, бәлкем, авылда гына язылышырбыз, ә? Сельсоветта. Расхуды да аз булыр.

Шакир. Акыллы баш!

Рамазан. Әнкәй, син каршы түгелме?

Маһруза. Юк, мин каршы түгел.

Гөлсирин. Ә нәрсә комачаулый соң?

Авыр тынлык. Барысы да бер-берсенә карашалар.

Рамазан. Берни дә аңламыйм.

Гөлсирин *(төшенеп).* Ә мин аңлый башладым булса кирәк. *(Рамазанга.)* Фамилияң ничек әле синең?

Зәйнәп *(сискәнеп).* Нигә ул?

Рамазан. Әйттем ич инде, Мәрданов.

Гөлсирин. Минем Мәрданова.

Рамазан. Булса соң...

Өйдән Хәят чыга. Алмалар салынган тәлинкә тоткан.

Гөлсирин. Безгә синең белән кавышу насыйп булмас, Рамазан.

Рамазан. Нигә? Әллә кире уйладыңмы?

Гөлсирин. Юк, Рамазан... Сәбәбе башка: без синең белән бертуганнар...

Хәятнең кулыннан алмалары төшеп китә. Җиргә тәгәри. Барысын да аңлаган Хәят, елап, өйгә кереп китә.

Синең дә, минем дә әтием бер. Менә шушы кеше — Шакир. *(Кулына алган алмасын ачу белән Шакирга ата.)*

Шакир алманы тотып алып, Маһрузаның алдына сала да, читкә тайпыла.

Маһруза *(йөрәген тотып).* Ай Ходаем! Сизенгән идем бит, сизенгән идем! *(Елап.)* Ярабби... Ходаем... Нәрсә эшләдек синең алда? Шулкадәр безне газапларга?! Ни гаебебез бар синең алда? Ярабби... *(Маһруза ава башлый. Алмалары җиргә тәгәри. Шакир аны тотып кала. Коча. Тынычландыра.)*

Рамазан. Дөресме бу, Зәйнәп апа?!

Зәйнәп. Дөрес, Рамазан. Гөлсириннең дә атасы Шакир.

Гөлсирин *(киная белән).* Менә шулай, Рамазан. Җаный дип йөрисең, абый булып чыга, абый дип йөрисең, җаный булып чыга бу прагматик заманда. Таныш булыйк! *(Кулын бирә.)*

Рамазан *(Гөлсириннең кулына сугып).* Юк, мин моңа ышанмыйм!

Шакир *(Рамазанга).* Болай ярамый, тавыш күтәрмә! Мин билгеле кеше.

Рамазан *(кычкырып).* Юк! Без абый белән сеңел түгел! Без егет белән кыз! Мин аны яратам, ул мине ярата! Ярата! Бетте!

Шакир. Кычкырма! Әниеңнең йөрәге тотты!

Рамазан. Яратам! Бетте!

Шакир *(үчекләп).* Яратам, яратам... *(Капканы шар итеп ача.)* Яратсаң, әнә бар, бөтен авылга чыгып кычкыр! Бар!

Рамазан. Гөлсирин, син ышанма бу кешегә! *(Шакирга күрсәтеп.)* Бу кеше гомер буе ялган сөйләде. Бер төрле сөйләде, икенче төрле яшәде. Ул әнә хәзер дә шуны куа. *(Пауза.)* Китик моннан, Гөлсирин!

Гөлсирин. Юк... Рамазан... хакыйкать безнең якта түгел...

Рамазан. Нинди хакыйкать?

Гөлсирин. Без — абый белән сеңел. Тагын гөнаһка батарга кирәкми. Болар баткан баткан инде, ә безгә кирәкми.

Рамазан *(моңсу).* Нидер өзелде...

Чыгып йөгерә. Мотоцикл кузгалган тавыш килә.

Маһруза. Улым! Рамазан! Тукта! Шакир, бар артыннан! Ул-бу булмасын! Бар!

Шакир чыгып китә.

Маһруза *(Гөлсирингә).* Син! Син генә гаепле моңа! Син!

Чыгып йөгерә.
Гөлсирин кычкырып көлә. Аның көлүе ачы, зәһәр.

Гөлсирин. Ха-ха! Ашыйсы килә, ни бар?!
Зәйнәп. Ни булды сиңа?
Гөлсирин. Ниһаять, мин дә әтине күрдем. Син аны ниндидер бер сәрхуш, бу дөнья кешесе түгел, аны күрсәң, ата тойгысын ят итәрсең, дигән идең. Юк, бу сәрхуш түгел... Кая, ни бар ашарга?
Зәйнәп. Кызым, җыен, безгә китәргә кирәк.
Гөлсирин. Ә ул хәтта миңа, исәнме, кызым, дип тә әйтмәде.
Зәйнәп. Кызым, җыен!
Гөлсирин. Юк, мин бүген китә алмыйм.
Зәйнәп. Нигә?
Гөлсирин. Абыемны бу хәлдә калдырып китә алмыйм.
Зәйнәп. Нигә ул сиңа?! Ничә еллар аның барлыгын белмәдең. Хәзер нәрсәгә ул сиңа?
Гөлсирин. Мин бит аны яратам, юк, яраттым... *(Күз яшьләрен сөртеп.)* Миңа шундый читен, мам...
Зәйнәп. Кызым, әйт дөресен, сезнең арада нәрсә булса да булдымы?
Гөлсирин. О чем ты, мам?!
Зәйнәп. Күл буенда нишләдегез?
Гөлсирин *(рәнҗеп).* Ну, син бөтенләй, мам!
Зәйнәп. Яшермә, сөйлә дөресен!
Гөлсирин. Синнән соң мин дә дөресен сөйләрмен, мам.
Зәйнәп. Аңардан бала табарга ярамый. Бер каннан туган бала гарип булып туа.
Гөлсирин. Мам, минем башка сүзем юк, хуш, пока! Син үзең ни сөйләгәнеңне дә белмисең.

Алма калдыкларын тибеп чыгып китә. Зәйнәп ялгызы гына ишек төбендә утырып кала. Өйдән Хәят чыга. Капкага таба бара.

Зәйнәп *(сискәнеп).* Син кая, Хәят апа?
Хәят *(саташып).* Капка төбенә ат килгән.
Зәйнәп. Нинди ат? *(Тора.)*
Хәят. Җәйләүдән кайткан. Кертергә кирәк.
Зәйнәп. Син кертергә тиешмени аны?! Нәрсә сөйлим мин?
Хәят. Ир-ат эше миңа калды. Атаң сиңа өмет баглаган иде, ә син атаңның өметен акламадың. Туган нигезеңне туздырасың...
Зәйнәп. Әйе, мин гаепле инде, мин. Һаман да мин. Нишләп соң әле бөтен начарлыкны миннән генә эзлисез?! Ә бәлкем, син гаепледер барысына да, ә?! Ни пычагыма дип мине монда чакырып кайтардың?! Нигез туза, имеш. Тузсын! Ниемә ул? Тузган әйбер тузарга тиеш... Син үзең гаепле, син! Бәлкем, син әтигә кияүгә чыкмаган булсаң, мин авылдан китмәгән дә булыр идем. Шул Влачның астына да ятмаган булыр идем. Димәк, бөтен бәланең башын синнән эзләргә кирәктер, ә?!
Хәят *(йөрәген тотып).* Кызым...
Зәйнәп *(тотып алып).* Хәят апай... әнкәй... кичер мине... каты әйтеп ташладым... кичер, зинһар!
Хәят. Кызым... мин бит сине сагындым. Синнән башка якын кешем юк бит минем. Ташлама мине...
Зәйнәп. Юк, мин сине беркайчан да ташламам. Ой, кулларың салкын, сиңа җылы кирәк, җылы җитми сиңа, җылы. Әйдәле, төрен менә шушыңа, әйдә, кадерлем! *(Шәл белән төрә.)* Әйдә...
Икесе дә ишек төбенә утыралар. Зәйнәп Хәятне кочаклый.

Әй, кадерлем минем... ялгызкаем минем... без бит икебез дә ялгызлар, әйе, без барыбыз да ялгызлар...

Караңгылык. Музыка.

**ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Яксаз күле. Яр кырыенда Рамазан. Ялгызы. Кара шәүлә пәйда була.

Рамазан. Килдеңме?
Шәүлә *(тавыш).* Килдем.
Рамазан. Нигә килдең?
Шәүлә. Үзең чакырдың, шуңа килдем.
Рамазан. Шатлан. Йөрәгем ватык. Күңелем сынык. Җиңдең. Инде теләсәң нишләт, мин синең иркеңдә.
Шәүлә. Мин моны бик озак көттем. Ниһаять, син — минеке!
Рамазан. Күпме качарга тырыштым, тик синнән качып котылып булмады. Мә, ал инде, ал җанымны! *(Күлмәген ерта.)* Мә! Юк! Мин сиңа җиңел генә бирелмәм! *(Мылтыктан күккә ата.)*

Шәүлә югала. Рамазан шаркылдап көлә.

Гөлсирин тавышы. Рамазан!

Гөлсирин күренә.

Рамазан *(айнып).* Син үзең килдеңме, әллә җибәрделәрме? *(Мылтыкны аңа юнәлтә.)*
Гөлсирин *(мылтыкка күрсәтеп).* Нигә ул сиңа?
Рамазан. Тәкәрлек атам бит...
Гөлсирин. Абый... Рамазан... әйдә, кайтыйк авылга...
Рамазан. Кит, Гөлсирин... *(Мылтыгын күтәреп, ярдан күл эченә керә.)*
Гөлсирин. Син кая, Рамазан?
Рамазан. Яр кырыенда утырып кына тәкәрлек атып булмый, эчкә, күлгә керергә кирәк.
Гөлсирин *(кычкырып).* Рамазан! Абый! Кирәкми!

Шакир, аның артыннан Маһруза күренә. Алар Рамазанны эзләп килгәннәр.

Зинһар... ярдәм итегез!

Рамазан яр ягына борылып карый. Шакир аңа Кара шәүлә булып күренә.

Рамазан *(саташып).* Тагын килдеңме? Шаярма, кит, Кара шәүлә!
Шакир. Улым, акылыңа кил, бу бит мин — әтиең!
Маһруза. Улым... нишлисең... җаным... Бу бит синең әтиең...
Шакир. Улым, чык судан, хур итмә мине!
Рамазан. Тидерә алмасам, хур булырмын, ә тидерсәм — юк! *(Елмая.)*
Шакир. Сөйләшик бер ирләрчә! *(Рамазанга якыная.)*
Рамазан *(аңына килеп).* Кичер... әткәй... Синең ышанычыңны аклый алмадым. Син яраклашкан дөньяга мин яраклаша алмадым... Синең гөнаһыңны, әткәй, мин үз каным белән юам, үз каным белән...
Гөлсирин. Рамазан... абыем... сөеклем... Кирәкми! Мин бит сине яратам!
Рамазан. Соң инде... сөеклем... Әнкәй... бәхил бул...

Ату тавышы. Рамазан ава. Шакир күлгә атыла. Маһруза йөрәген тотып җиргә егыла.

Гөлсирин *(Шакирның юлына каршы төшеп).* Китегез! Якын килмәгез аңа! Сез — харап итүчеләр! *(Суга кереп.)* Тимәгез аңа! Ул минем абыем... сөекле абыем...

Үзәк өзгеч тәкәрлек тавышы ишетелә.

*(Күккә текәлеп).* Юк... Ул инде беркемнеке дә түгел... Беркемнеке дә... Ул очар кош... Ул ...тәкәрлек... Ул юк... аның җыры гына калды... җыры... *(көйләп):*

Төнге ай нурында,
Тирән күл ярында
Яктык без яшьлекнең учагын.
Син — минем бердәнбер,
Мин — синең бердәнбер,
Кил, бәгърем, кил ачып кочагың...

Тәкърлек —
Тавышың үзәк өзәрлек,
Бир канат — очарга,
Күкләрне кочарга,
Юк чамам түзәрлек...

Пәрдә.

## АРТЫК ГОМЕР

*Ике пәрдәле драма*

**КАТНАШАЛАР:**

Мәүлия — урын өстендә ятучы сырхау карчык, 80 яшьтә.
Ярулла — аның ире.
Сабир — Мәүлиянең бертуган энесе, пенсия яшендә.
Сария — аның хатыны.
Халисә — Ярулланың бертуган сеңлесе, 57 яшьтә.
Әмир — аның улы.
Тәүфыйк — Мәүлиянең апасының малае, 50 яшьтә.
Регина— Сабирның кызы, 23 яшьтә.
Карт.
Күрше хатыны.

Вакыйга авылда бара.

### БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Авыл. Өй эче. Уң якта: таушалган кәнәфи, кәнәфидә — мендәр, мендәрдә — Коръән. Чаршау белән корылган караватта (мич янында) — Мәүлия. Ул тәсбих тартып, дөньядагы һәр тавышка колак салып ята. Кич булып килә. Күзгә шыксыз вакыт. Чолан ягыннан, бер табак
ботка күтәреп, Ярулла керә. Табакны карчыгының алдына куя.

Ярулла. Аша!

Мәүлия *(дога кылып).* Ходаем, тамактан аерма.

Ярулла. Синекен аермас, безнекен аерса да.

Мәүлия. Син шулай дисең дә, соңгы вакыт тамактан азык үтми башлады бит әле.

Ярулла. Ни булды?

Мәүлия. Эч поша нигәдер?!

Ярулла *(кул селтәп).* Эч пошулар була инде ул. Бер синдә генә түгел... Тыныч кына ятсана!

Мәүлия. Алай, алай...

Ярулла. Тәүфыйкның бер капчык тары ярмасы озакка җитәр, Алла боерса, кыш чыгарбыз әле ничек тә!

Мәүлия. Җитәр, җитәр, Алланың биргәненә шөкер! *(Ботканы читкә этәрә.)*

Ярулла. Сарыкларга тимик. Киртәң тулып сарыгың да тормагач, авылда яшәүнең ни куанычы бар. *(Утыра.)* Кәҗәбез корып үлде. Шул кәҗә кебек миңа да корып үләргә язгандыр инде!

Мәүлия *(коты очып).* Алла, диген! Сиңа кадәр мин үләсе бар әле.

Ярулла. Сөйләмә юкны! Син әле үлмисең. Үлəреңне ун ел көттек бит инде. Ә үлем синең бер генә тишегеңә дә кереп карамады. Аякларың йөрмәсә дә, йөрәгең таза синең, йөрәгең. Минем күк нужа кыып та йөрмисең, урының җылыда.

Мәүлия *(юмалап)*. Әй, мулла абзый, зарланма әле, зарланма. *(Кеткелдәп көлеп куя.)*

Ярулла. Минме мулла?! Аптырагач, кеше табалмагач, миннән мулла ясадылар да куйдылар. Көлке! «Әлһәүле»дән башканы белмим.

Мәүлия. Аптырама. Галимнәр аз хәзер, гыйлем тикшерүчеләр дә юк.

Ярулла *(кисәк кенә күтәрелеп).* Ярар. Синең эшең беткән. Чыгып, терлекләргә су эчереп керим әле. *(Тора.)* Уф, кәеф юк бүген нигәдер? *(Су тулы ләгән каршына килә.)*

Мәүлия. Ярулла!

Ярулла. Нәрсә инде?

Мәүлия. Син кая?

Ярулла. Кая... Ләгән каршында...
Мәүлия. Нишлисең аның каршында?
Ярулла. Күтәрәм.
Мәүлия. Күтәрмә!
Ярулла. Күтәрмичә ничек чыгарасың ди аны, син торып күтәрмәссең бит!
Мәүлия. Күтәрмә, зинһар, өстерәп кенә чык.
Ярулла. Өстерәп чыгарга арба түгел бит ул. *(Күтәрә.)* Ай! Ай! Билем! *(Бөгелеп төшә.)*
Мәүлия. Ни булды?
Ярулла *(бер билен, бер эчен тотып).* Ай... үләм... эчем... билем...
Мәүлия *(елап).* Кил монда, кил миңа якынрак...

Ярулла, шуышып, Мәүлия янына килә.

Ярулла. Мәүлия... Тыңла мине, авыр булса да тыңла. Әгәр дә мин үлә-нитә калсам...
Мәүлия. Алла, диген!
Ярулла. Тыңла, бүлдермә... Синең үзең генә калуың бар. Балабыз юк, димәк, син туганнар кулына калачак. Авыру кешене, үзең беләсең, берәү дә бушка карамый, акчаң булса гына... Безнең җыйган акчабыз бар, кассада... утыз мең... Гөнаһ шомлыгына каршы, мин синең алда зур хата кылдым. Кешегә эшләгән яхшылыгым сиңа яманлык булып төшә күрмәсен дим инде...
Мәүлия *(картының башыннан сыйпап).* Ходайның күңеле иркен. Борчылма...
Ярулла. Тыңла... Мин ул утыз меңне, ашыгып, Халисә малае Әмир исеменә яздырган идем. Куштанланып. Әгәр әби үлсә, мин сине шәһәргә җылы фатирыма алып китәм, дип вәгъдә биргән иде. Хәзер инде миңа берни дә кирәк түгел, мине мәңгелек караңгы фатир көтә... Кичерә алсаң, кичер мине, Мәүлиякәй. Мин карт юләр! Мин сине акчасыз, ач-ялангач калдырдым! *(Елый.)*
Мәүлия. Йә, йә, шулкадәр хафаланма инде, Аллага тапшырган, нишлисең бит! *(Дога кыла.)*
Ярулла. Синең өчен кайгырам, сине кызганам. Яхшылап тыңла: кассадагы акчаның кенәгәсе сандыкта ята, ә сандык, үзең беләсең, синең карават астында. Әгәр дә мәгәр Әмир каладан кайтып, акча кенәгәсен даулый башласа, бирмә! Ишеттеңме?!
Мәүлия. Кемгә бирим соң?
Ярулла. Сабирга бир. Энеңә. Ул олы кеше, ышанычлы, сине бәладә калдырмас.

Радиодан көй яңгырап ала.

*(Җиңел сулап.)* Мәүлия...
Мәүлия. Әү, җаным!
Ярулла. Исеңдәме?
Мәүлия. Исемдә...
Ярулла. Өйгә килен булып төшкәнең.
Мәүлия. Син мине кыш көне, чанага салып, бүләккә дип алган ак мамык шәлең белән аякларымны төреп алып кайткан идең. Кулукуллары да бар ие.
Ярулла. Бар идеме?
Мәүлия. Уң як тәртәгә тагылган иде. Шуның тавышы әле дә колак төбендә чыңлап тора.
Ярулла. Болай начар яшәмәдек бугай инде яшәвен. Рәнҗеткән чакларым булса, кичер, үпкәләп калма... (*Пауза.*) Балабыз гына булмады, бала! Картаймыш көнебездә бер таянычыбыз, ярдәмчебез булган булыр иде. Булмады! Тәүфыйкны биш ел карап үстердек. Качты соңыннан барыбер... әниләренә...
Мәүлия. Үзең алып биргән виләсипидеңә утырып.
Ярулла. Кеше баласы кеше баласы шул инде. Ул синеке түгел. Нишлисең бит... Тәүфыйк болай ярый ла ул, бабасын онытмый, әз-мәз булса да тондыргалап тора. Халисә малае Әмирне генә аңлап бетерә алмыйм әле мин... *(Тыңланып.)* Сумалет тавышы димме?!

Капка ачылган тавыш ишетелә.

Мәүлия. Беркемне дә көтмибез ләса, кем булыр икән?!
Ярулла. Авыр булса да торып карыйм әле! Уф! *(Авырлык белән күтәрелә.)* Пагудасы да каһәр төшкән кебек бит: коя да коя яңгыр... *(Тәрәзә каршына килә.)*
Мәүлия. Кемне күрәсең?
Ярулла *(каранып).* Нindидер бер шәүлә күрәм, ир кешегә охшаган димме?!
Мәүлия. Әмир түгелдер ич?

Ярулла. Шул. Шул, ахрысы... *(Пауза.)* Ул.

Мәүлия. Ни дип кайтты икән?

Ярулла. Улыңны йә киленеңне бәрәңге алырга җибәр дип анасына хат язып җибәргән идем. Менә кайтып та җитте, бәрәңге алынып беткәч. Шул бәрәңге аяктан екты да инде мине! *(Коръән китабын янына салып, кәнәфигә ава.)* Уф Алла! *(Мәүлиягә.)* Кара аны, берүк җебеп төшә күрмә! Бирмә кенәгәне!

Әмир керә. Кызмача. Кулында сумка.

Әмир. Берәр җан иясе бармы бу йортта, юкмы?! Әллә инде үлеп, дөмегеп беттегезме?! *(Каранып тора.)* Ә?!

Ярулла *(күтәрелеп).* Ә! Әмир! Кайттыңмы?! Уз әйдә, торып каршы алырлык хәлем юк.

Әмир. Кычкырып сөйлә, тавышың ишетелми.

Ярулла. Улым!

Әмир. Вәт! *(Пауза.)* Нәрсә?

Ярулла. Аягың салганчы, әнә шул ләгәндәге суны терлекләргә чыгарып керсәнә!

Әмир ләгәнгә кереп баса.

Тфү! Ләгънәт! (*Пауза.*) Син нәрсә инде шулкадәр! Мин сиңа ләгәндәге суны терлекләргә чыгарып сал, дидем, ә син шуңа шакшы аякларың белән кереп бастың.

Әмир. Гафу ит, бабай, мин монда сарык караргa кайтмадым, сине күрергә дип кайттым.

Ярулла. Мине күрергә иртәрәк кайталар аны! *(Пауза.)* Ярар. Сүз сөйләп торуның мәгънәсе юк. Өйдәгеләр ничек анда?

Әмир. Ярый шунда.

Ярулла. Әниең ни хәлләрдә?

Әмир. Ни булсын аңа! *(Исенә килеп.)* Авырып ята әле. Сезгә сәлам әйтергә кушты. Бүтән авылны күреп булмас инде дип, арттан елап калды. *(Үзалдына.)* Ов-чар-ка!

Ярулла. Минем хатны алдыгызмы?

Әмир. Алган идем кебек.

Ярулла. Алгач, нишләп суң бәрәңге алышырга кайтмадыгыз?

Әмир. Әй, бабай, һаман шул бәрәңгеңне сөйләмә әле, ә! Мин бит сине сагынып кайттым, йә, бер кочаклыйм инде үзеңне! *(Кочагын җәеп, Ярулла янына килә.)*

Ярулла. Кит, кит, орынма миңа! Баш күтәрерлек тә хәлем юк. Әнә башта әбиең белән исәнләш!

Әмир. Ә! Хәзер! *(Мәүлия янына килә.)* Исәнме, әбекәй! *(Мәүлия, куркып, чаршауны ябып куя.)* Бабай, бу йортта минем кирәгем шулкадәр генә икән, минем белән кайберәүләр хәтта исәнләшергә дә теләмиләр.

Ярулла. Бәйләнмә инде син аңа. Авыру кеше бит.

Әмир. Юк, бабай, син нәрсә инде, мин бит әбекәйне яратам, би-ик яратам. *(Чаршауны ачып.)* И карт тәресе! Сөйләшмәгән була бит әле! Кара, кара, ничек күз кырые белән генә карап ята. Ха-ха! *(Чаршауны каты итеп тартып куя.)*

Ярулла. Улым, кил әле монда, утыр.

Әмир *(Ярулла янына килеп).* Бабай! Беләсеңме, мин бит машина алырга җыенам! Машина... «Девятка»!

Ярулла. Шулаймыни! Гаҗәп: моңа кадәр бер дә машина алам дип сөйләнгәнең булмады.

Әмир. Алырга кирәк. Бөтен кеше машинада йөри, ә мин кемнән ким?! Хәзер кассада акча тотуның мәгънәсе юк.

Ярулла. Кассада акчаң бармыни соң?

Әмир. Бар.

Ярулла. Күпме?

Әмир. Утыз мең.

Ярулла. Ай-яй! Белмәдем... Миннән яшердеңме?

Әмир. Юк, бабай, минем синнән бернәрсә дә яшергәнем булмады. Яшергән бер генә нәрсәм дә юк. Мин менә шул утыз мең акчаны авыл сберкассасыннан алырга дип кайткан да идем инде.

Ярулла. Каян? Нәрсә ул?

Әмир. Белмәгәнгә сабышма, бабай. Минем авылдагы сберкнижкамда утыз мең сум акчам бар. Исеңдәме?

Ярулла. Ә! Син шул акчаны әйтәсеңмени?! Исемдәсен исемдә лә... Әмма син ул акчаны ала алмассың шул.

Әмир. Нигә?

Ярулла. Әлегә без исән бит әле.

Әмир. Сез үлгәнне көтсәң... Миңа хәзер кирәк акча. Арзанга машина алам, сөйләшкән кешем дә бар.

Ярулла. Юк, улым, булмый. Авырга алма инде.

Әмир. Димәк, бирмим, дисең инде?! Алдадың, сүзеңдә тормадың. Васыять яздырганда син бөтенләй икенче кеше идең, киң күңелле идең, ә хәзер бөтенләй икенче төрле сайрый башладың. Уйла, бабай, уйла!

Ярулла. Мин уйлаган инде, улым. Уйлыйсы уйларым күптәннән уйланып беткән.

Әмир. Бердәнбер ышанычлы кешеңне, яраткан оныгыңны югалта күрмә. Кыскасы, йә мин, йә акча? (*Чыгып китә*.)

Ярулла. Уф... Сулыш кыса... китереп терәделәр... кабер авызына...

Мәүлия. Киттеме?

Ярулла. Китте... китәр, бар! Тиз генә котылам димә инде син аңардан! Васыятьне дә бит ул эчертеп кенә яздырды. Ялгыштым, әй, ялгыштым! *(Мәүлия янына килә. Тезләнеп утыра.)* Миңа хәзер берни дә кирәкми: ни акчасы, ни дөньясы!

Әмир керә. Кулында бер шешә аракы.

Әмир. Бабай!

Ярулла *(сискәнеп).* Нәрсә?

Әмир *(аракы күрсәтеп).* Әйдә, берәрне!

Мәүлия *(күреп).* Әмир җаным, эчертмә бабаңны, болай да чак кына йөри.

Әмир. Их, бабай, бабай, мине дә бераз кызгансагыз икән сез, ә! Мин бит эшләмим хәзер. Заводны яптылар. Эшсез, бер тиен акчасыз йөрим.

Ярулла. Ә син үзең кеше җәлли беләсеңме соң? Кала кадәр каладан кайткансың, әби белән бабайга дип бер күчтәнәч тә кыстырып кайтмагансың.

Әмир. Күчтәнәч?! *(Исенә төшереп.)* Бар бит ул күчтәнәч, бар. Алып кайттым мин күчтәнәч. Туктале, сумкада иде бит ул. Кайда сумка? Ә, менә кая, идәндә ята... *(Сумканы күтәрә.)*

Ярулла. Алып кайткан күчтәнәчен дә кешечә тапшыра алмаган бәндәдән ни көтәргә була?!

Әмир. Бабай, менә ул күчтәнәч! Әни тыгып җибәрде! Юк нәрсә юк монда... Мә, менә! *(Сумка суза.)*

Ярулла. Әбиеңә бир.

Әмир *(сузып).* Мә, әби!

Мәүлия *(алып).* Рәхмәт яусын инде, Әмир улым, аяк-кулларың сызлаусыз булсын! *(Дога кыла.)*

Әмир. Әйдәле, бабай, утырышыйк әле, сиңа салкын идәндә утырырга ярамый. Билеңә салкын тидерерсең йә... *(Яруллааны торгыза.)*

Ярулла. Рәхмәт. Их, шушы картлыкны! *(Өстәл янына утыра.)*

Әмир *(стаканнарга аракы салып).* Бабай, сал, әйдә! Бәлкем, хәл кереп китәр үзеңә.

Ярулла *(ымсынып).* Юк, ярамый. Бу зәхмәтне миңа күрсәтәсе булма, ишеттеңме? Күрмисеңмени соңгы хәлемдә утырганымны?!

Әмир. Яшисең әле син, таза син.

Ярулла. Яшәрсең, бар. Аллаһы Тәгалә гомернең артыгын бирми ул. Вакыты җитүгә бер минут та тотмый, ала да китә.

Әмир эчеп куя. Тагын сала. Ярулла ымсынып аракыга карап тора.

Мәүлия *(тыңланып).* Нишләп тынып калдылар соң әле болар? Ул-бу булмагандыр ич? *(Пауза.)* Ярулла!

Ярулла. Нәрсә кычкырасың инде?!

Мәүлия. Ярулла!

Ярулла. Суймый торганнардыр ич?!

Мәүлия. Син кая?

Ярулла. Монда... өстәл янында.

Мәүлия. Эчмә! Синең иләс-миләсләнеп китә торган гадәтең бар.

Ярулла. Ярар, тик кенә ят инде, син әйтмәсәң дә беләм.

Әмир. Ну нәрсә, бабай, бирәсеңме? Бүләбезме акчаны? Мин бик комсыз кеше түгел алай, акчаның яртысына да риза.

Ярулла. Әбиеңнән сора. Ул риза булса, алырсың. Кенәгә миндә түгел.

Әмир. Әбидәмени? *(Ярулла дәшми.)* Их, бабай, бабай!

Ярулла. Мин хуҗа түгел хәзер бу йортта, миндә берни дә юк. *(Тиз генә аракы эчеп куя.)*

Әмир. Тагын?!

Ярулла *(йөткереп).* Юк, җитәр... *(Хәлсезләнеп кәнәфигә барып ава.)*

Әмир *(үзалдына)*. Булмады бу, килеп чыкмады. Хәйлә җитмәде. Хәйлә. Акчасыз кайтсам, теге овчарка башымны чәйнәр инде. Алып кайтсам, акчаның чиреген бирермен дигән иде бит. Нишләргә? Почтага барып, книжкасыз гына сорап карарга мәллә? Юк, бирмәсләр. Бабайның гомере күп калмаган, үлә-нитә калса, акча —минеке! Тик книжка кирәк, шуның кулда булуы кирәк. Ә ул — әбидә. Ул, иманым камил, әбинең сандыгында инде. Сандык ачкычы кайда? Шайтан белсен! Әллә сандыкның капкачын каерып кына ачаргамы? *(Сандык янына килә.)* Менә ул! *(Мәүлия караваты астында яткан сандыкның капкачын каерып, эченә кулын тыга.)* У-ух!

Мәүлия *(чаршауны ачып).* Ярулла, синме ул?

Әмир *(Ярулла тавышы белән).* Мин.

Мәүлия. Ни эзлисең анда?

Әмир. Сандыкның ачкычын карыйм. *(Бер кулы белән матрас астын капшый.)* Кая?!

Мәүлия *(танып).* Әстәгъфирулла! Әмир, нишлисең син? *(Әмир ягына авыша. Әмирнең кулы сандык капкачына кысылып кала.)*

Әмир *(әче тавыш белән)*. Ай! Ай! Кулым бетте, кулым! У-у!

Кулын тартып ала. Сикереп тора.

Ярулла *(күреп).* Әмир! Тилмертмә безне!

Әмир. У-у! Кулым! Кулым!

Ярулла. Без үлгәч, барысы да сиңа калыр. Бакчасы да, йорты да... Көт инде әзрәк, көт.

Әмир *(ярсып).* Кирәкми! Кирәкми! Акчагыз да, йортыгыз да, үзегез дә кирәкмисез! Дөмегеп китегез! Мин сезне күмәргә дә кайтмаячак... *(Чаршауны Мәүлиянең башына каплап чыгып йөгерә.)*

Мәүлия. Ярулла, кил әле... *(Чорналып.)* Ярдәм ит...

Ярулла. Киләм, киләм... *(Кузгала.)*

Мәүлия. Киләсеңме?

Ярулла. Киләм бит инде. Сабыр ит бераз... Җайраплан түгел ләса...

Мәүлия. Чаршауны рәтлисе иде.

Ярулла. Чаршауны түгел, безне рәтләргә кирәк, безне. *(Чаршауны күтәрә.)* Бирмәдеңме?

Мәүлия. Нәрсәне?

Ярулла. Кенәгәне, мәйтәм, бирмәдеңме, дим?!

Мәүлия. Юк, нишләп бирим, сандыкны ача алмады. Аңарда ачкыч юк. Ә кая соң аның ачкычы?

Ярулла. Матрас астында, синең аяк очыңда.

Мәүлия. Ярар, Аллага тапшырган инде.

Ярулла. Хәлем бер дә әйбәт түгел... Мәүлия... үләрмен, ахры... *(Бөгелеп төшә.)*

Мәүлия. Әй Аллам, нишләргә соң инде?! Ичмасам, Сабир да килеп чыкмый. Ике айга бер мәртәбә булса да килә торган иде. Күрше дә керми...

Ярулла. Мәүлия...

Мәүлия. Әү, җаным?

Ярулла. Бәхил бул... *(Пауза.)* Китеп ятам әле... Үлә калсам, бәхил бул...

Мәүлия *(күз яшьләрен сөртеп).* Әй Аллам!

Ярулла кәнәфигә үрмәли.

Ярулла!

Ярулла. Нәр-сә...

Мәүлия. Алай-болай яман хәл була калса... Синең үлгәнеңне мин ничек белермен соң?

Ярулла *(көч-хәл белән).* Мин... менә шулай кулымны күтәреп ятармын. Әгәр дә кулым төшсә... бәхил бул...

Мәүлия. Йа Хода, берүк мәрхәмәтеңнән аерма! *(Тиз-тиз генә дога укып ала.)*

Машина килеп туктаган тавыш ишетелә. Бераздан өйгә шаулашып
Сабир, Сария, Тәүфыйк керәләр.

Сабир. Йә, малайлар, килеп җиттек! *(Пауза.)* Нишләп яталар икән бу пәри йортындагы адәмнәр?! *(Каранып.)* Бөтенләй тәртип калмаган бит бу йортта. Бу чаршау нишләгән соң бу? Өзелеп төшкәнме? *(Чаршауны күтәрә.)* Апа! Апа!

Мәүлия *(сөенеп).* И Сабирҗан, рәхмәт төшкере! Ходай ишеткән минем ялваруларымны, ишеткән. Йә, бер дога кылыйк инде.

Утырышып дога кылалар.

Сабир. Хәлләрегез ничек?

Мәүлия. И-и, әйбәт түгел шул бер дә, әйбәт түгел.

Сабир. Ни булды?

Мәүлия. Бабагыз үләргә ята.

Сабир. Кая?

Мәүлия. Әнә шунда... урында...

Сабир. Нишләп соң аны керүгә үк әйтмисең?! *(Сариягә.)* Сария, карале, ни булган аңа?

Сария Ярулла янына килә. Тәүфыйк та якыная.

Мәүлия *(Сабирга).* Үзең генә килдеңме?

Сабир. Юк, Сария дә, Тәүфыйк та монда.

Мәүлия. И Алланың рәхмәте!

Сария *(кычкырып).* Җизни!

Тәүфыйк. Җизни!

Сария. Дәшми.

Сабир. Үлмәгәндер ич?

Тәүфыйк. Исән булырга тиеш.

Сария *(Яруллань тотып).* Аяк-куллары салкын. Врач чакыртырга кирәк.

Сабир. Кулы нишләп күтәрелеп тора соң аның?

Тәүфыйк. Акылындадыр ич?

Мәүлия. Исән... Кулы күтәрелеп тора. *(Елмая.)*

Сабир. Нишләп күтәреп тора соң ул аны?

Мәүлия. Без шулай сөйләшеп куйган идек. Исән булса, кулы күтәрелеп торыр, төшсә, үлгән булыр. Ярабби...

Сабир *(Тәүфыйкка).* Төшереп кара әле кулын, нишләр микән?

Тәүфыйк Ярулланың кулын төшермәкче була. Кул төшми.

Тәүфыйк. Агач күк каткан. Төшерә торган түгел.

Сабир. Ярар төшмәсә. Димәк, исән әлегә.

Регина керә.

Озак йөрисең, кызым. Машина ишегеп яптыңмы?

Регина. Ишегалдыннан кергәндә, ниндидер бер ир кеше белән очраштым. Мине күрүгә, киртә эченә кереп качты.

Сабир. Күзеңә генә күренәдер. Караңгыда агач кәүсәсе дә кеше шәүләсе булып күренә.

Регина. Күрдем. Яшь егеткә охшаган.

Тәүфыйк *(астыртын).* Яшь кызларның күзенә гел яшь егетләр генә күренә инде.

Сабир. Эшләр начар, кызым, җизни бабаң үләргә ята.

Сария. Якынрак кил, кызым, ишек катында торма.

Регина *(читенсенеп).* Куркам... үлгән кешедән...

Сабир. Курыкма, ул әлегә үлмәгән. Исән. *(Сариягә.)* Сөйләшеп карале җизни белән, бәлкем, берәр сүз ала алырсың.

Сария *(Яруллага).* Җизни! Җизни!

Ярулла. Әү...

Сария. Мине ишетәсеңме?

Ярулла. Ише-тәм...

Сария. Таныйсыңмы мине?

Ярулла. Таныйм... Сария...

Сабир. Сорале, көткән кешесе юк микән?

Сария. Көткән кешең юкмы, җизни, беркемне дә көтмисеңме?
Ярулла. Юк... көт-мим... *(Башын чайкый.)*
Сария. Халисәне дә көтмисеңме?
Ярулла. Кайтмыйм... дигән, юк...
Сария. Карале, Сабир, җизнидән гел аракы исе килә, әллә салган инде?
Тәүфыйк *(стаканнарга күрсәтеп).* Салуы хак. Үзе генә дә түгел, икәү салганнар.
Регина *(тәрәзәдән карап).* Ишегалдында кемдер йөри.
Сабир. Син кеше куркытып йөрмәле, кит тәрәзә буеннан! *(Мәүлиягә.)* Апа, сезнең янга бүген килүче-китүче булмадымы?
Мәүлия. Булды. Халисә малае Әмир кайтты.
Ярулла *(кычкырып).* Мәүлия...
Мәүлия *(елап).* Әү, әү...
Ярулла. Бир-мә...
Сабир *(Мәүлиягә).* Нишләп соң безгә килүгә үк әйтмәдең?!
Мәүлия. Аның күчтәнәчләре дә бар ие әле... Бер сумка...
Сабир *(Тәүфыйкка).* Бар, чыгарып бир сумкасын, үз юлын карасын!

Тәүфыйк сумканы алып чыгып китә.
Сабир тәрәзә янына килә.

Ярулла *(соңгы сулышын сулап).* Мәүлияү... бәхил бул... бир-мә... *(Күтәрелгән кулы төшеп китә.)*
Сария. Балалар! Бабагыз үлде!
Мәүлия *(яшь аралаш).* Ясин... Ясин... *(Дога укый.)* Ясин вәлкоръәнәм хәким, иннә кәләмин...
Регина. Әти!
Сабир. Нәрсә, кызым?
Регина. Бабай үлде!
Сария. Җизни үлде.
Мәүлия *(дога укуын дәвам итә).* ... вәҗә галәмин...
Сабир *(тәрәзәдән күзен алмыйча).* Амин.

Моңсу көй агыла.

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шул ук картина. Өй эчендә бушлык сизелә: җиһазларның күбесе чыгарылган. Өстәлнең бер читенә бәлешләр тезелгән, җимешләр өелеп тора. Өйдә Мәүлия, урта бер урында Сабир, аның тирәсендә
Сария, Тәүфыйк, Регина. Төштән соң. Кич булып килә.

Сария. Бабагызның өчесе дә үтеп китте. Җидесен үткәреп булырмы, юкмы?
Сабир. Җидесен генә түгел, кырыгын да үткәрербез, Алла боерса. Бездән калмас. Мине, балалар, бөтенләй икенче нәрсә борчый бит әле! Нәрсә, дисезме? Әбиегез белән нишлибез? Кая куябыз аны?
Тәүфыйк. Уйлашырга кирәк инде, абый.
Сабир. Әбиегезнең кассада утыз мең акчасы барын барыгыз да яхшы беләсез. Кызганыч, кулыбызда книжка була торып та без ул акчаны ала алмыйбыз. Бабагыз Ярулла үзе исән чагында бик зур хата җибәргән, бу турыда ул әбиегезгә дә сөйләгән булган. Ул кассадагы барлык акчаны Халисә малае Әмиргә васыять итеп яздырган. Безнең бурыч шундый. Безгә апаның акчасын кайтарып бирергә кирәк. Нишлибез? Ничек хәл кылабыз?
Тәүфыйк. Судлашырга кирәк, дөреслек безнең якта. Халык безне аңлый, безне яклый. Суд та аңлар, яклар дип уйлыйм.
Сабир. Дөрес. Кайвакыт син дә акыллы гына сүзләр әйтеп куясың, Тәүфыйк энем. Закон дигән гамәлнең безнең өчен бер уңай ягы да бар. Анда болай диелгән: «Караучысыз калган гарип-горабаның васыять ителмәгән байлыкның да ярты өлешен алырга хакы бар». Димәк, утыз меңнең яртысын без судлашмыйча да ала алабыз. Тик калган яртысын да җилгә очырасы түгел иде бит. Башта мин ул утыз меңне Халисә белән яртылаш бүләргә дә уйлаган идем. Ләкин аларның монда кайтып кылган яман га-

мәлләрен күргәч, минем алардан күңелем кайтты. Алар карчыкка тиешле акчаны да бирергә теләмиләр. Шуңар күрә мин ул имансызларга бу йорттан бер генә тиен дә бирмәскә булдым.

Тәүфыйк. Дөрес. Бик дөрес. Башта Халисә абыйсын күмәргә дә кайтмады. Мал бүләргә кирәклеген исенә төшергәч, бик тиз кайтып җитте.

Сабир. Шушы мескен карчыкны соңгы валчык икмәгеннән дә мәхрүм итәргә җыенган адәм актыкларына мин берни дә бирмәячәкмен!

Сария. Акрын, ишетә күрмәсен.

Сабир. Ишетсен! Җаны чыксын! Мин аңардан курыкмыйм. Мин аңа кергәч тә шул сүзне әйтәчәк! Кая ул?

Сария. Келәттә йөри. Һаман әйбер эзли.

Сабир. Менә, менә.

Сария. Абыйсын җирләгәннең икенче көнендә үк мал бүләргә тотынды. Башта книжка эзләде. Табалмады. Аннан абыйсының иске-москыларын җыйнарга тотынды. Почтальон керткән соңгы пенсия акчасына кадәр бөтереп тыкты...

Сабир. Күпмеләп иде анда?

Сария. Сигез йөз.

Сабир. Син шуны бирдеңме?

Сария. Кулдан тартып алды.

Сабир. Менә нишләтә кешене комсызлык!

Сария. Аның әле планнары зур.

Сабир. Нәрсә тагын?

Сария. Җизнинең өеннән дача ясарга җыена.

Сабир. Дача?! *(Көлә.)* Дача кирәк түгел аңа, йортның акчасы кирәк. Хәленнән килсә, бүген үк сатар иде ул йортны. Юк шул, соңгарак калды. Колхоз рәисе белән сөйләшеп куйдым инде. Йортны колхоз үзенә сатып алачак, ә акчасы апага булыр.

Тәүфыйк. Сатарлыгы юк инде бу йортның, черегән бит. Белмим, күпмегә алырлар?

Сабир. Күпмегә алсалар да ярар, үзенеке үзенә булыр.

Тынлык. Мәүлиянең бәет көйләгәне ишетелә.

Йә, ярар! Бу кадәресе аңлашылды бугай. Инде иң читене: апа белән нишлибез?

Тәүфыйк. Ничек?

Сабир. Апаны кая куябыз?

Тәүфыйк. Авылга алып кайтабыз.

Сабир. Анысын үзем дә яхшы беләм. Алып кайтабыз авылга. Тик кемгә?

Тәүфыйк. Кемгә дип... Бергәләп карарбыз инде.

Сабир. Апаңның авылда өч туганы бар. Мин, Тәүфыйк, Зөлфия. Мәүлия — минем бертуган апам. Тәүфыйк — Мәүлиянең апасының улы. Зөлфия — апаның бертуган сеңлесе. Туганнары шактый инде апаның, җитәрлек...

Сария. Зөлфия качты.

Сабир. Кешенең кем икәнлеге бәла килгәч кенә беленә икән шул. Йә! Нишлибез апа белән?

Тәүфыйк. Бергәләп карарга булыр инде. Акчасын бүләргә дә...

Сабир. Ничек?

Тәүфыйк. Бер ай бездә, бер ай сездә. Бер ай, әйтик, Зөлфия апаларда.

Сабир. Анда-монда тибеп йөртергә ул футбол тубы түгел. Авыл халкы ни дияр? Ул моңа үзе дә риза булмас!

Тәүфыйк. Бөтенләйгә алалмыйм. Минем үземнең дә өйдә бер карчык ята бит инде. Хатынның анасы... Аны мин түгел, хатын караячак.

Сабир. Аңлашылды. Башка сөйләмәсәң дә була. Шулай әйтерсең дип уйлаган идем инде мин. Әйе, син дә карчык өстенә карчык җыя алмыйсың. Шуңа күрә дә апаны сиңа көчләп тагып булмый.

Тәүфыйк. Юк. Карый алмыйсыз сез ул авыру карчыкны, хәзер сезнең үзегезне карарга вакыт җиткән.

Сабир. Анысы да дөрес. Авыру карчыкны җилкәмә күтәреп, мунчага ташый торган вакытларым үтте шул инде. Тыштан ялтырасам да, эчтән тузган. Без шул алдагы инерция белән генә йөрибез инде... Тик ни генә булмасын, без барыбер карчыкны карарга тиешбез, ул безнең өстә. Шуңар күрә уйлашырга кирәк...

Тәүфыйк. Акчасын бүләргә дә...

Регина. Мин аны үзем белән тулай торакка алып китәм, минем белән торыр. Шулай бит, әбекәй?!

Сария. Туктагыз әле! Нишләп соң без баядан бирле курчак уены уйныйбыз?! Апаның үзеннән сорарга кирәк, ул да кешедер бит! Әйтсен кемгә кайтырга теләгәнен!

Сабир. Акыллы сүз әйттең, хатын. Әйдә, сорыйк үзеннән. Нишли ул, йоклыймы, уянганмы?

Тәүфыйк. Эше беткән аның. Ята Аллаһысы белән сөйләшеп...

Мәүлиянең бәет көйләгәне ишетелә.

Сабир *(елмаеп).* Эше худта моның. Без монда, җан талашып, аның язмышын хәл итеп утырабыз, ә ул җыр көйләп ята.

Сария. Нәрсә көйли ул?

Регина. Бәет. Бабайга багышлап бәет чыгарган.

Мәүлия бәет көйли. Елый. Дога кыла.

Сабир *(Сариягә).* Сора.

Сария *(Регинага).* Кызым, син генә сора инде?!

Регина. Әбекәй!

Мәүлия. Әү, җаным, ни бар?

Регина. Синнән сорыйлар...

Мәүлия. Нәрсә сорыйлар?

Регина. Кемгә кайтасың? Безгәме, Тәүфыйк абыйларгамы, әллә...

Мәүлия. Төш күрдем, кызым... Төп йортка кайтып төшкәнмен икән...

Сабир. Төп йортка, диме?

Регина. Әйе.

Сабир. Димәк, безгә инде.

Тәүфыйк. Төш кенә бит ул.

Сария. Сөйләп бетерсен инде! Тыңлыйк...

Мәүлия. ...төп йортка кайтып төшкәнмен икән дә терелеп аягыма басканмын. Караңгы төн. Бакчага кереп барам...

Сария. Кайсы бакчага? Арткысынамы, алгысынамы?

Сабир. Кайсына булса да бер түгелме?!

Тәүфыйк. Төш кенә бит инде ул.

Мәүлия. Бакчада кызарып чияләр пешеп утыра...

Сария. Чия булгач, арт бакча инде.

Мәүлия. Бер чия агачыннан чия җимеше алып ашадым. Өч данә ашадым. Дүртенчесенә үрелгән идем, кемдер кулымнан тотып алды...

Регина. Кем?

Мәүлия. Шайтан белсен инде аны... Ниндидер адәм инде шунда... Менә шул адәм: «Бу бакчада тукланыр азыгың калмады, бар, башка җирдән эзлә!» — дип, мине бакчадан куып чыгарды... Тамак өзелү инде бу. Төшне дә шуңа юрадым.

Сария. Нәрсә дип юрадың?

Мәүлия. Өч чия өч ел гомер дигән сүз. Тагын өч ел гомер генә яшисе калган...

Сабир. Нәрсә ди ул?

Сария. Өч ел гомерем калган, сезне тагын өч ел җәфалыйсым калган, ди.

Тәүфыйк. Яши әле ул, озак яши.

Сабир. Яшәве көн кебек ачык. Йөрәге таза. Җил тими аңа. Консерва банкасында яткан кебек ята рәхәтләнеп... Мин бит аны авылга алып кайтып, бер аякка бастырган идем инде. Ишегалдының бер башыннан икенче башына җеп суздым. Шырпы ташыттым. Җепкә тотынып бара, җепкә тотынып кайта. Тәмам аякка бастырып җибәргән идем инде мин аны. Терелеп китте ул бездән. Өенә кайткач, авырыйм дип, кабат җылы мич башына менеп яткан. Халисә кунакка кайткан булган. «И апам, җаным, син авырыйсың, сиңа җылы кирәк бит!» — дип, тегене мич башыннан төшермәгән дә. Шуннан тагын кәкрәеп катты ул. Тагын аяксыз калды. *(Пауза.)* Мин торгызам әле аны, торгызам!

Тәүфыйк. Соң инде, абый, соң.

Сабир. Соң түгел, нишләп соң булсын. Теләсәм, мин үлгән кешене дә торгыза алам. Үз кирәген үтәрлек кенә булса да йөрерлек итәм әле мин аны. *(Мәүлия янына килә.)* Әнә карагыз сез аңа! Аның сул кулы бөтенләй йөрми, ә уң кулының өч кенә бармагы хәрәкәт итә. Азыкны авызына алып кабар өчен өч

кенә бармак калдырган. Җәйгә чыккач терелтәм әле мин аны, билләһи, терелтәм! *(Мәүлиягә.)* Апа, әйдә, бераз кыймылдат аякларыңны, кыймылдат!

Мәүлия *(аңламыйча).* Нәрсә дидең?

Сабир. Бераз физкультура яса, дим, аяк-кулларыңны селкет!

Мәүлия аякларын селкетә.

Менә! Менә! Маладис!

Мәүлия. Булмый... аякларым бик сызлый...

Сабир. Сызлар да бетәр! Әйдә, әйдә! Иренмә! Мин синнән кеше ясыйм әле, ясыйм, Аллаһы боерса!

Сабир арты белән борылуга, Мәүлия аягын селкетүдән туктый. Сабир борылып карагач, кабат селкетә.

Сария *(Сабирга).* Синнән генә шикләнә!

Сабир. Йа Хода! *(Көлешәләр.)*

Тәүфыйк. Полиартрит аңарда.

Сабир. Полиартрит түгел, ялкаулык көчле аңарда, ялкаулык. Озак яши әле ул, бездән дә калачак.

Сария. Бездән дә калмасын иде инде.

Сабир. Калачак. *(Регинага.)* Яшьләр кулына гына калмасын инде!

Регина. Сиңа, әти, яшьләрне хурларга гына булсын инде.

Сабир. Хурламыйм. Дөресен әйтәм. Хәзерге яшьләр үзләрен көйләргә генә өйрәнгәннәр.

Регина. Яшьләрнең дә төрлесе бар. Авыру әти-әнисен караучылар да шактый.

Сабир. Бала ата-анасын карарга тиеш ул. Шуның өчен үстерәсең дә инде баланы. Мин, әнигә ярдәмем тисен дип, Үзбәкстанга киткән җиремнән кайттым. Ач, хәерче Татарстанга кайттым. Әткәй герман сугышында үлде, ә әни, мин кайткач, икенчегә кияүгә чыкты. Сария белән өйләнешкәннән соң, әнием үлеп китте. Әниең белән без авыру үги атабызны соңгы сулышына тиклем карадык.

Сария. Ул вакыт халык икенче иде бит, мәрхәмәтле, иманлы...

Сабир. Хәзерге киленнәр үги аталарын түгел, үз аталарын да карамыйлар.

Сария. Элек хатыннар ирләреннән куркып торганнар. Хәзер ирләр хатыннарыннан куркалар. Сезгә атап әйткән сүзем шул: апаны мин караячакмын. Теләп түгел, Сабирның туганы булганы өчен генә караячак.

Регина *(торып).* Әни, ә без кайчан авылга кайтабыз?

Сария. Туйдыңмы?

Регина. Арыдым.

Сабир. Син генә түгел, барыбыз да арыдык, кызым. Беребезнең дә бу үрмәкүч оясында минут та артык торасы килми. Кая ашыгасың?

Регина. Авылга кайтуга ук, районга китәм. Яңа спектакль чыгарасы бар.

Сабир. Нәрсә куясың? Тагын мәхәббәтме?

Регина. Әйе.

Сабир *(киная белән).* Вудевиль?!

Регина. Водевиль.

Сабир. Ясалма әйбер, димәк. Юк-бар нәрсәгә кызыкма син, куйсаң, чын әйбер куй. Тормышчан, халыкчан булсын. Халык күрә, халыкны алдап булмый.

Регина. Андый әсәрләр язмыйлар хәзер.

Сабир. Юк икән, үзең утырып яз. Менә әбиең турында яз. Чагылдыр аның ачы язмышын... Нинди вакыйга, ә! Нинди гыйбрәтле хәл!

Сария. Яз, кызым, яз, белмәгәнеңне үзем әйтеп яздырырмын.

Сабир. Халисә белән улы Әмирнең кыланышлары үзе бер театр бит ул!

Регина *(тәрәзәдән карап).* Театрың әнә капкадан кереп килә. Аңа бер егет тә ияргән.

Сария. Әмир тагын кайтты микәнни? Әнисен алырга кайткандыр инде!

Тәүфыйк *(тәрәзәгә якын килеп).* Шул, Әмир!

Сабир *(көлеп).* Наследник!

Халисә керә.

Халисә. Малаем кайтты. Бүген үк китәргә исәп.

Сабир. Киткән кешегә юл ачык!

Халисә *(усал итеп).* Тиз котылырга җыенасың әле син бездән, бик тиз!

Сабир. Кумыйм. Калыгыз.

Халисә. Яратмыйсың инде безне?

Сабир. Әйе, яратмыйм. Ә ни өчен мин сезне яратырга тиеш әле?

Халисә. Бөтенләйгә исәптән чыгарып ташларга уйладың. Начармы-яманмы, мин мәрхүмнең бертуган сеңлесе. Безгә дә бу йорттан нинди дә булса өлеш чыгарга тиештер бит инде?!

Сабир. Тиештер. Башта мин сезгә бүлеп бирергә уйлаган идем, тик соңыннан кире уйладым. Ә ни өчен кире уйлаганымны син инде бик яхшы беләсең!

Халисә. Син мине үзең белән чагыштырма, Сабир. Син гомерең буе нәчәлник булдың, балда майда гына йөздең. Малың да, абруең да җитәрлек. Ә минем менә бернәрсәм дә юк.

Сабир. Бар, нишләп булмасын.

Халисә. Нәрсәм бар?

Сабир. Казанда өч бүлмәле фатирың бар.

Халисә. Әйе, бар. Хәерче фатир. Мин хәзер пенсиядә. Улым эшләми. Утырып ашарга урындык та юк бит безнең өйдә.

Сабир. Мескенләнмә. Мескенләнү сиңа төс түгел.

Халисә. Мәрхәмәтсез!

Сабир. Ә синең үзеңдә бармы соң ул мәрхәмәтлелек? Авыру карчыкның соңгы тиенենә кулың сузасың бит син?!

Пауза.

Халисә. Ярар. Бәхәсләшүдән файда юк. Тыңлагыз, минем сезгә бер тәкъдимем бар.

Сабир. Нинди тәкъдим?

Халисә. Минем малаем бар.

Сабир. Беләбез малаеңны.

Халисә. Сезнең кызыгыз...

Сабир *(торып).* Йә, шуннан? Сөйләп бетер!

Халисә. Менә шушы ике йөрәкне бергә кушсак, безнең арада барган бәхәсләр бик тиз тынар иде дип уйлыйм мин.

Сария *(чәчрәп).* Бусы ни дигән сүз тагын?! Нәрсә, минем кызым риза булыр дип уйлыйсыңмы синең исерек малаеңа кияүгә чыгарга?!

Регина *(кызып).* Мине хурларга җыенасызмы?! Ул сезнең исерек малаегызга кияүгә чыгарга түгел, мин аның чыраена карарга да чирканам!

Халисә *(чигенеп).* Ходаем!

Регина. Мин сезне кайтканнан бирле күзәтеп торам. Сезнең ни өчен кайтканыгызны да яхшы беләм. Сез мәрхүм җизни бабайны искә алырга түгел, авыру, мескен карчыкны таларга дип кайткансыз. Мал кайгысы сезнең чыраегызга ук чыккан! Әнә барыгыз, оятсыз йөзегезне көзгедән барып карагыз!

Халисә *(йөзен каплап).* Әстәгы! Мондый киленең булса, өйдән чыгып качарсың, билләһи!

Көлешәләр. Әмир керә.

Әмир. Тә-ә-әк! Исәнмесез! *(Сабирга.)* Сабир кода сез буласызмы?

Сабир. Кодасын белмим. Сабир абзаң мин булам.

Әмир. Бир!

Сабир. Нәрсә?

Әмир. Бир, давай!

Сабир. Мин сиңа берни дә тиеш түгел, энекәш!

Әмир. Тиеш. Акча минеке. Ул минем исемгә язылган.

Сабир. Ялгышасың. Акчага тәтәң хуҗа: закон буенча да, намус буенча да.

Әмир. Бир книжканы! Син — карак. Син минем акчамны урладың. Мин сине судка бирәм. Бир!

Сабир. Яхшы. *(Кесәсеннән кенәгә чыгарып.)* Бирәм мин сиңа бу книжканы, бирәм. Мә!

Әмир. Бир...

Сабир. Ал! *(Кенәгәне югары күтәрә.)*

Әмир *(сикергәләп).* Уйнама, бир!

Сабир. Бирәм. Тик бер шарт белән.

Әмир }
Халисә } *(икесе бергә).* Нинди шарт?

Сабир. Болай. Әгәр дә син тәтәңне үзеңә карарга алып кайтсаң, акча тулысы белән синеке булачак. Йә, ничек?

Әмир. Китәм, алып китәм...

Сабир. Тик яхшылап карарга инде, шәләй-вәләй йөртергә түгел.

Сария. Авыру карчык каравы, ай-яй, җиңел нәрсә түгел шул.

Тәүфыйк. Утыз меңе генә түгел, йөз меңе дә күзгә күренмәскә мөмкин.

Әмир. Карыйм, карыйм... алып китәм... Тик хәзер үк түгел.

Сабир. Ә кайчан?

Әмир. Машинам юк минем, авылга да попутный белән генә кайттым.

Сабир. Табам мин сиңа машина, тик алып кына кит. Үзем үк илтеп бирәм. *(Пауза.)* Тик син башта әбиеңнән сора...

Әмир. Нәрсә сорарга?

Сабир. Риза микән ул сезгә кайтырга?!

Халисә. Кирәк түгел безгә ул карчык. Шул гына җитмәгән иде. Бөтен өйнең ямен җибәрәчәк бит ул!

Мәүлия. Сария, Сария, кайда син?

Сария. Монда, апа, монда мин, ни булды? *(Мәүлия янына килә.)*

Мәүлия. Бернәрсә искә төште. Кияүгә чыкканда, Яруллам миңа җылы мамык шәл бүләк иткән иде. Чоланда гардеробта эленеп тора ул. Бабаң истәлеге. Алып кер әле шуны. Сезгә кайтырга чыккач, аягымны шул мамык шәлгә төреп кайтырмын.

Сабир *(Халисә белән Әмиргә).* Ишеттегезме?! Сезгә кайтырга уенда да юк аның.

Халисә. Ул сезнең туганыгыз, сез аны карагыз да инде. Җаныгызга төшәчәк әле ул сезнең, төшәчәк! Әйтте диярсез!

Сария. Каргама, Халисә. Олы була бел. Авыру кешене карау — изге гамәл.

Карт керә. Култык таягына таянган.

Карт. Әссәламегаләйкем!

Сабир. Вәгаләйкем!

Карт утырып дога кыла.

Ни йомыш?

Карт. Мин күрше авылда яшим. Шуннан килдем. Хәйбулла абзагыз булам мин. Йомышым шундый: минем карчыгым, авырып, өч ел урын өстендә ятты. Карчыгым терелсә, муллага биш йөз тәңкә акчалата сәдака бирермен, дип нәзер кылган идем. Аллаһының рәхмәте, хатыным терелеп китте... Ә ни... хәзрәт үзе кая соң әле?

Сабир. Хәзрәт мәрхүм. Өченче көн генә җирләдек.

Карт. Шулаймы?! Кызганыч, бик тә кызганыч... Кемгә бирим соң инде? *(Акча суза.)*

Сабир. Карчыгы исән, аңа бир.

Халисә. Монда бир! *(Акчаны тартып ала.)* Абый акчасы бу!

Сабир. Имансыз да икәнсең!

Халисә. Улым, әйдә, киттек! Безгә монда көн калмады. Киттек! Төргәкләр чоланда. Пароходка соңга калмыйк! *(Сабирга.)* Хуш!

Чыгып китә.

Әмир. Әле мин монда кайтачак! Күрерсез, акча минеке булачак!

Ишекне каты итеп ябып чыгып китә.

Карт. Ярар, китим инде...

Сабир. Кайсы авылдан килдем дип әйттең әле?

Карт. Моннан гына мин... Ярый, оланнар, сау булып торыгыз, тик талашмагыз. Аллаһы Тәгалә беребезгә дә гомернең артыгын бирмәгән, барчабызны да теге дөньяда, ахирәттә көтәләр.

Чыгып китә.

Сабир. Сәер карт. *(Тәүфыйкка.)* Бар әле, картны кире бор! Безнең белән машинада кайтыр. Бигрәк каты коя яңгыр...

Тәүфыйк чыгып китә.

Регина. Әти, кайтабызмы?
Сабир. Кайтабыз. Күптән китәсе идек инде, Халисәләрнең киткәнен генә көтеп тордык.
Регина. Әти, мин пьесамны яза башладым инде. Ул менә болай башлана...
Сабир. Тәмамларга вакыт инде, кызым. Спектакль тәмамланып килә...

Тәүфыйк керә.

Тәүфыйк. Юк.
Сабир. Нәрсә юк?
Тәүфыйк. Карт юк. Әйтерсең җир йотты...
Сабир. Сәер.
Сария. Бу йортка җеннәр ияләшмәгәннәрдер ич?!
Сабир. Ярар, җитте. Безгә дә җыенырга кирәк.
Сария. Апаны нишләтәбез?
Сабир. Шәленә төрәбез дә машинага чыгарып салабыз.
Сария. Ярар. Мин шәлен алып керим әле!

Чыгып китә.

Тәүфыйк. Бәрәңгеләрне, утыннарны нишләтәбез?
Сабир. Алары калып торырлар. Бер килеп алырбыз әле. *(Утыра.)* Уф, эт булып арыдым. *(Мәүлия чаршауны ачып карый.)* Китәбез, апа, хәзер! Әйберләреңне генә җыйныйк та!
Мәүлия. Үзем кая, әйберләрем дә шунда булыр инде.
Сабир *(көлеп).* Әйбер, имеш! Нәрсәң бар соң синең?! Кара син бу хәерчелеккә! Үрмәкүч оясы бит бу! Берәр ай килмичә торсам, бөтенләйгә пәрәвез каплап китә иде бит...

Сария керә.

Сария. Юк. Апаның шәле юк.
Сабир. Кая киткән?
Сария. Халисә алып киткән. Гардеробның астын өскә китергән.
Сабир *(торып).* Карак! *(Пауза.)* Бөтен ил караклар белән тулды.

Күрше хатыны  керә.

Күрше хатыны. Исәнмесез! Китмисездер бит?
Сабир. Китәбез. Хәзер үк.
Күрше хатыны. Әби дә китәме?
Сабир. Китә ул да.
Күрше хатыны. Алайса саубуллашып калыйм инде. Гомер буе күршеләр булып яшәдек, әле тагын кайчан күрешербез?! Мәүлия әби! Мәүлия әби!
Мәүлия *(танып).* И күршекәем, җаным, син икән!
Күрше хатыны. Синең белән саубуллашырга дип кердем, яңа урыннарга исән-имин генә барып җит инде. Яңа җирдә инде яңача булыр, тик безне дә онытма. *(Күз яшен сөртеп ала.)*
Мәүлия *(елап).* Онытмам, җаным, онытмам. Без бит синең белән, күрше, бик тату яшәдек. Рәхмәт инде сиңа, авыр чакларымда бик булыштың, рәхмәт!
Күрше хатыны. Хуҗалар китәбез, диләр!
Мәүлия. Шулайдыр шул... *(Уйлана.)* Тик мин китмим әле...
Тәүфыйк. Нишләп?
Мәүлия. Мин болай уйладым: бер көнгә монда калам. Йоласы шундый. Иртән-иртүк карчыклар килерләр, һәркайсы белән сөйләшеп, саубуллашып калырга телим.
Сабир. Апа, зинһар, юләрләнмә, ә!
Сария. Әйтмә. Сине кем ашатыр да, кем эчертер?!
Мәүлия. Янда күрше бар бит...
Сария. Алай да дуамал инде син!
Күрше хатыны. Калсын, калсын. Бер көндә генә берни булмас, мин янында булырмын.
Мәүлия. Бер көнгә генә калдырыгыз инде, иртәгә килеп алырсыз. Укымаган намазларым калды.
Сария. Апа, нишләп алай итәсең инде?!
Сабир. Ярар. Ялынмагыз. Бала-чага түгел, үзе белә торгандыр. Бүген безнең болай да кешеләр күп, әйберләр дә шактый. Калсын, иртәгә килеп алырбыз.

Сария. Күршегә бик зур рәхмәт инде. Без апа янына килалмый торганда да, мунчасын ягып, чәен куя торды. Карады апаны, карады.

Сабир. Шуңар күрә дә апаның биш казын мин аңа бирәм.

Күрше хатыны. И-и! Кирәкмәс иде инде!

Сабир. Ал, ал!

Күрше хатыны. Рәхмәт. Шундый изге кешеләр булып чыктыгыз әле сез, бөтен авыл халкы сезнең изгелеккә мөкиббән киткән.

Сабир. Әйдәгез, җыеныйк. *(Тәүфыйкка.)* Син машинаны җылыта тор. Мә, ал ачкычны! *(Ачкыч бирә.)*

Тәүфыйк чыгып китә.

Күрше хатыны. Мин казларны карап керим әле, ашарларына салыйм.

Чыга.

Сабир *(Тәүфыйкка)*. Кирәген генә ал, машинага сыярлык булсын.

Сария. Менә бу матрасны алырга кирәк. Чиста ул. Апаны шунда яткызырбыз.

Сабир *(Регинага).* Кызым, әниеңә булыш!

Регина *(Коръән китабын алып).* Коръәнне үзем белән алырга ярыймы?

Сабир. Нишлисең аның белән? Син аны барыбер укый алмыйсың!

Регина. Әти, ә нишләп әбинең ялгызын гына калдырабыз?

Сабир. Иртәгә килеп алабыз дидек түгелме соң?!

Регина. Шулай да ялгыз калдыру килешмәс аны.

Сабир. Килешмәсә, кал әбиең янында.

Регина. Куркам мин бу өйдә.

Сабир. Шулай булгач?!

Урам ягында казлар каңгылдашкан тавыш ишетелә.

Сария *(тәрәзәгә ташланып).* Күрше хатыны казларны куып үзләренә алып чыгып бара.

Сабир. Яна! Без киткәнне дә көтеп тормый. Халык гел биргәнне генә ярата шул.

Сария. Беребез дә өметсез яшәмибез, барыбыз да өмет итә.

Сабир. Чукынып китсеннәр!

Сария. Сабир, әйт әле, син бу карчыкны акчасына гына кызыгып асрамага алмыйсыңмы, ә?!

Сабир. Нәрсәсенә кызыгасың аның! Кызыгыр вакытлар үткән инде, үземнеке үземә җитә. Тик бу бичара карчыкны мин дә карамагач, кем карар соң?!

Сария. Авыр булачак. Аның бөтен авырлыгы миңа төшәчәк. Мин үзем дә ярты тере. Шулай да түзәргә туры килә инде.

Сабир. Беләм. Тик үзем исән чагында мин аны ташлый алмыйм. Мин үлгәчтен карарсыз инде...

Сария. Баласы юк, баласы булса...

Сабир. Балаларга да хәзер бик ышаныч юк, үзең исән йөргәнгә сөенеп торырга кирәк.

Сария. Өч ел гомерем калды, ди...

Сабир. Өч чияне әйтәсеңме?! Аны да төрлечә аңларга була, төрлечә... Бар курыкканым шул, шушы карчык аркасында туганнар арасында низаглар килеп чыкмасын иде инде, низаглар...

Машина тавышы ишетелә.

Сария. Карале! Тәүфыйк бабаңның биш мең акчасын алып торган булган, шул турыда ул сиңа берни дә әйтмәдеме?

Сабир. Әйтер, бар! Аласы булса әйткән булыр иде!

Сария. Тәүфыйкка ни бирәбез соң?

Сабир. Бабасы биргән бит инде. Башкасын өмет итмәсен. Мин монда байлык таратырга дип килмәдем.

Пауза.

Мәүлия *(Регинага).* Кызым, кил әле минем янга!

Регина *(килеп).* Тыңлыйм, әбекәй!

Мәүлия *(елмаеп).* Сөбханалла! Кызым, синең йөргән егетең бармы?

Регина *(елмаеп).* Бар...

Мәүлия. Әйбәтме?

Регина. Әйбәт...

Мәүлия. Мин әйткәнне тыңла: яраткан кешеңне кулыңнан ычкындырма. Әнә без бабаң белән ничек яшәдек. Булды, булды аның да галәмәтләре! Халисә аны миннән аертырга да йөрде. Аңа яшь хатын да тапты. Тик Яруллам мине ташламады. Мәүлиямнең нәселе яхшы, нәселе өчен генә булса да аерылмыйм, дигән, бахыр... Кияүгә чыкканда, иреңнең нәселен белеп чык, кызым. Инде чыккачтын, аерылып, бозылышып йөрерлек булмасын! Мә, менә шушы нәстәне кесәңә тыгып куй әле! *(Бөти бирә.)*

Регина. Нәрсә бу?

Мәүлия. Бөти. Сөйдергеч бөтие. Яраткан егетең беркайчан да ташламас, Аллаһы боерса!

Регина *(алып).* Рәхмәт, әбекәй.

Мәүлия. Кызым, бабаңның Коръән китабы синең күзеңә чалынмадымы?

Регина. Өстәлдә ята. Әллә кирәкме?

Мәүлия. Киткәндә яныма куеп китәрсең әле. Укый алмасам да, янымда торсын. Миңа хәзер берни дә кирәкми бу дөньяда, миңа Аллаһы белән генә очрашасы калды...

Тәүфыйк керә.

Тәүфыйк. Булды. Машина әзер.

Сабир. Әйдәгез, утырышыйк. Юлга чыгар алдыннан бер дога кылып алыйк. *(Утырышалар.)* Ягез, бер дога! *(Дога кылып.)* Вакыт... китәргә кирәк...

Сария. Китәбез... Тәтәгез белән саубуллашыйм да... *(Мәүлия янына килә.)* Апа, апа, дим! Бөтенләй калдырып китәләр дип уйлый күрмә тагын. Иртәгә Сабир килер. Үпкәләп ятма тагын! Апа! Нигә дәшмисең... *(Тыңлана.)* Йокыга киткән... Үлгән дип торам, котларым очты! Йоклый... Пеф-пеф итеп...

Сабир. Арыгандыр...

Тәүфыйк. Йоклаган булып кына кыланмыймы икән?

Сария. Белмим инде. Аллага тапшырган... Их бу гомерләр! Артык гомерләр... Берәүгә дә бәйрәм түгел ул. Шул артык гомерләрдән сакла инде, Ходаем, үз яныңа вакытында ал! Үз көнеңне үзең күралмый башлагач, бу яшәүдән ни мәгънә...

Сабир. Киттек!

Регина. Әти! Әбекәйне бүген үк алып кайтыйк!

Сабир. Бу турыда сөйләштек бит инде!

Регина. Әгәр...

Сабир. Нәрсә әгәр?

Регина. Әгәр дә ул үлеп китсә?

Сабир. Ничә ел үлмәгәнне, бер көндә генә үлмәс. Әйдә, җыен, киттек! Саф һавага чыгыйк тизрәк, саф һавага!

Сария. Уф, минем дә башым әйләнә...

Сабир, Сария, Тәүфыйк чыгалар. Регина Коръән китабын Мәүлиянең баш очына куя, уйланып тора. Тәүфыйк керә.

Тәүфыйк. Сария апа сумкасын калдырган, кая икән инде? *(Сумканы табып ала.)* Җен авырлыгы моңарда!

Регина чыгып китә.

Таш тутырганнармыни?! Картны әйтәм, абыйны, хәйләкәр дә инде! Тәтәнең акчасы булмаса, алмас иде ул аны, алмас иде! Их! (*Сумканы күтәреп чыгып китә.)*

Тынлык. Машина кузгалып киткән тавыш ишетелә. Моңсу көй агыла. Шыгырдап ишек ачылып кала.

Мәүлия *(моңсу).* Йоклаган булып юри генә яткан идем, ышандылар да тагын. Алдадым үзләрен, алдадым. Ярар. Аллаһы боерса, бар да рәтләнер әле. Хәзер күрше кереп җитәр, иртәгә хатыннар килерләр... Аллага шөкер... Әлһәмделиллаһи... *(Дога кыла.)* Йә Алла... *(Йокыга талып ала.)*

Урамда гармунда уйнап узалар. Мәүлия сискәнеп уянып китә.

*(Елмая.)* Яшьләр клубка җыелалар... Ярулла исән ...чагында кергәлиләр иде... Хәзер кермәсләр шул инде... Өйдә кеше юктыр дип уйлый торганнардыр инде... җан иясе... Бигрәк караңгы... Күрше кереп ут та кабызмый, ичмасам... *(Гармун тавышы ераклаша.)* Киттеләр... *(Дога укый.)* Амин...

Кулына Коръән китабы ала. Китабы кулыннан төшеп китә, аңын югалта. Тынлык урнаша. Ябылмый калган чолан ишегеннән көзге җил-

нең хәвефле авазы гына ишетелеп тора.

Пәрдә.

## ЯЛГЫЗ КАЕН КҮЗЕ

*Ике пәрдәле мелодрама*

КАТНАШАЛАР:

Вәсимә — тол хатын, 45 яшьтә.
Фидан — аның улы, 20 яшьтә.
Ясминур — Вәсимәнең бертуган сеңлесе.
Мәүлет — эшкуар, 46 яшьтә.
Кафия — аның кызы, 23 яшьтә.
Зөһрә — клуб хезмәткәре, 18 яшьтә.
Хәмит — 17 яшьтә.
Кара күләгә.

### БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

#### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Кичкырын. Урман алды. Тауда, калкулыкта каен агачы үсә. Бер якка авышкан, ботак-кәүсәләре каерылган. Тирә-ягында башка төрле агач, үсемлек үсмәгәнгә, ул ялгыз булып күзгә ташлана. Фидан, Зөһрә күренә. Кулга-кул тотынышканнар. Каен каршында туктап
калалар. Тынлык.

Зөһрә. Юк, мин шулай да аңламыйм...
Фидан. Нәрсә аңламыйсың?
Зөһрә. Нишләп син мине, очрашкан саен, шушы ялгыз каен янына алып киләсең?

Пауза.

Фидан. Сиңа монда ошамыймы?
Зөһрә. Ошый. Ошамаса, килмәс идем. Тик шомлы урын бу...
Фидан (*уйчан)*. Һәр кешенең үзенә генә якын, йөрәгенә яткан урыны, җире була. Бала чактан ук мине менә шушы тау итәгенә тартты, шушы ялгыз каен янына. Без яшь чакта бу тирәдә ике каен үсә иде. Инде хәзер берсе генә калган... Хәтерлисеңме?
Зөһрә. Хәтерлим. Ни булган аңа? Кистеләр микән?
Фидан. Юк ла... Кем киссен инде аны. Корыды ул. Парлы иде алар... Хәзер берьялгызы гына калды. Аның да инде ботаклары каерылган, җил-давылдан имгәнгән...
Зөһрә (*моңсу).* Парын сагына торгандыр ул да...

Пауза.

Фидан (*көлемсерәп).* Юкка моңсуланма!
Зөһрә. Нигә?
Фидан. Ялгыз түгел ул. Без басып торган җирдән генә ул шулай ялгыз булып күренә. Әйдәле! (*Кулыннан тарта*.)
Зөһрә. Кая?
Фидан. Тау итәгенә меник... чак кына... (*Биегрәк урынга күтәреләләр.)* Әнә, күрәсеңме, аста нихәтле каен үсеп утыра! Сузсаң — кулың тияр!
Зөһрә. Минем әле монда кадәр үк менгәнем булмады. Ай!

Зөһрә кулын суза. Чайкала. Фидан аны тотып кала. Кочаклый.

Фидан. Мин бит синең белән монда уйнап сөйләшер өчен килмәдем, Зөһрә, саубуллашырга дип килдем.
Зөһрә. Әйе...
Фидан. Ике елга түзәрсең бит?!
Зөһрә. Юк.

Фидан (*аптырап).* Юк?!

Зөһрә. Сагынуга түзалмам, Фидан, сагынуга.

Фидан. Мин дә... *(Пауза.)* Әйдә, без болай итик...

Зөһрә. Нишлик?

Фидан. Вәгъдәләр бирешик.

Зөһрә. Ничек?

Фидан. Болай. Син ике ел минем армиядән кайтканны көтәсең. Беркем белән дә йөрмисең. Кияүгә дә чыкмыйсың... Укырга да кермисең. Клубта гына эшлисең. Армиядән кайтуга ук, без синең белән өйләнешәбез. Ризамы? (*Пауза.)* Килештек?!

Зөһрә. Килештек.

Фидан. Вәгъдәме?

Зөһрә. Вәгъдә.

Фидан (*сөенеп).* Вәгъдә, вәгъдә... Без синең белән, мин кайткач, шушы каен янында очрашырбыз, яме, Зөһрә! Вәгъдә?!

Зөһрә. Вәгъдә... вәгъдә... (*Фиданга сыена*.)

Фидан (*кочаклап*). Каен шаһит, Зөһрә... онытма... Аңа ялганлап булмый, ул безне күреп тора... Беләсеңме, аның күзләре бар?

Зөһрә. Ничек?

Фидан. Кешеләрнеке кебек үк аның җаны да, күзләре дә бар. Әгәр дә вәгъдәңдә тормасаң, каенның каргышы төшә, диләр... (*Кочаклашалар. Көй агыла.)*

Зөһрә. Кайтыйк инде... Соң бит...

Фидан. Әйдә болай итәбез... Без бүген йокламыйк...

Зөһрә. Сезне иртән-иртүк, машинага төяп, авылдан алып китәрләр. Йокың туймаса, читен булыр үзеңә*... (Фиданның башыннан сыйпый.)*

Фидан (*исе китмичә генә*). Анда баргач, әле тагын ике ел йоклыйсы бар. Ничек диләр әле... «Солдат спит, а служба идет...» диләрме?!

Зөһрә. Кайтыйк, Фидан. Анаң эзләр... Җыенасың да бар... Арыгансыңдыр...

Фидан (*башын аска иеп*). Бар инде әзрәк... Озату кичәсе күңелле узды, шулай бит?! *(Пауза.)* Их! Бөтен кешенең күзе бездә булды, Зөһрә! Ә, юк, синдә булды, синдә... Их, матур да соң син, Зөһрәм!

Зөһрә. Җитте... күз тидерәсең... Әйдә кайтыйк...

Фидан (*кузгалып).* Әйдә... (*Зөһрәне кулыннан ала. Күзләренә төбәлә.)* Вәгъдә?!

Зөһрә. Вәгъдә!

Фидан. Вәгъдә... (*Зөһрәне үбә. Үбешәләр*.)

Зөһрә (*хисләнеп)*.

> Сагынырсың, өзелеп сагынырсың,
> Сагыш утларында янарсың.
> Сагыш тулы йөрәк тибешеңдә
> Кайтыр көннәреңне санарсың.

Фидан<br>
Зөһрә } *(икесе бергә җырлыйлар).*

> Көтә белгән йөрәк гел сагына,
> Сагынмаса, туктый тибүдән.
> Төсен җуйган көзгә яфрак сыман,
> Саргаялар җаннар сөюдән.

Фидан.

> Авыр булыр берүзеңә, җанкай!
> Ялгыз каен яфрак койганда,
> Син килерсең монда мине сагынып,
> Үз-үзеңне ялгыз тойганда...

Караңгылык. Музыка. Рекрутлар җыры яңгырап ала: «Без авылдан киткән чакта, күтәрелде томаннар, исән-имин кайталмасак, сау булыгыз,
туганнар...»

**ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Авыл. Яз көне. Фиданнар өе. Бертөрле генә җиһаз. Диварда Фиданның армия хезмәтендә төшкән фотолары эленгән. Вәсимә мич янында
кайнаша. Кулында тимер кисәү. Ясминур керә.

Ясминур. Апа! Апа!

Вәсимә. Абау! Ни булды? Нәрсә дип шулкадәр шаулыйсың?!

Ясминур. Сөенче!

Вәсимә. Нинди сөенче?! *(Пауза.)* Җә, әйт инде!

Ясминур. Улың кайтты. Фидан... армиядән...

Вәсимә. Кит аннан! (*Кулыннан кисәве төшеп китә.)* И... и... балам... (*Яулык чите белән күз яшьләрен сөртә*.) Чынмы бу?!

Ясминур. Чын. Кайтып килә. Кече күпер янында калды...

Вәсимә. Нинди күпер?

Ясминур. Гашыйклар күпере янында инде. Солдатны күреп алдым да синең янга йөгердем.

Вәсимә. Бәрәкалла! Бәрәкалла! Нинди шатлык! Нинди сөенеч! Әле бер-ике атнасыз кайта алмам дип язган иде бит соңгы хатында. Күңелем сизде сизүен — иртәдән кулым эшкә бармады. Аптырагач, мичягып, бәлеш куеп җибәрдем. Бәлеш аңа насыйп булган икән, улыма насыйп булган...

Капка ачылган тавыш ишетелә.

Кайтты... Карале, ул түгелме?! (*Ясминур тәрәзә янына килә. Чак кына тәрәзә төбендәге гөлне бәреп төшерми*.) Җә, җә, әкрен... Солдат кайта дип...

Ясминур (*карап*). Ул, ул!!!

Вәсимә. И... җаным... и... (*Исенә төшеп*.) Карале, Ясминур, балабыз шулкадәр ерак җирдән кайткач, аны күрергә кунаклар килми калмаслар. Бар әле тиз генә кибеткә. Бер-ике шешә эче су алып мен әле!

Ясминур. Акчасы...

Вәсимә. Яздырып кына ал, пенсия алгач, төшереп түләрмен... (*Ясминур китмичә тора*.) Җә, нәрсә тагын?

Ясминур (*үпкәләп*). Сөенчегә нәрсә?

Вәсимә. Әй Аллам! (*Кул юа торган җирдән бер сабын кисәге чыгарып бирә.)* Мә инде, мә!

Ясминур (*аптырап*). Шушымы? (*Сабынны иснәп карый*.)

Вәсимә. Соң... тагын ни кирәк сиңа? Азмы әллә?!

Ясминур. Аз түгел дә...

Вәсимә. Соң... шулай булгач?

Ясминур (*чыраен сытып*). Ярар инде... чаптым... (*Тиз-тиз чыгып китә.)*

**ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Ишегалдында Ясминур белән Фиданның шаулап-гөрләп кочаклашкан, күрешкән тавышлары ишетелә. Фидан керә. Солдат формасыннан.
Аркасында «вещмешок».

Фидан. Әнкәй!

Вәсимә. Улым!

Фидан. Исәнме, әнкәй!

Вәсимә. Кайтып җиттеңме, улым?! Исән-сау гына... Аллага шөкер! Аллага шөкер! (*Кочаклашалар*.)

Фидан. Юл бик ерак булды, әнкәй. Владивостоктан поезд белән ун тәүлек кайттык. Ә монда попутка белән... Хәер, бик теләп утырттылар, солдат хәлен аңлыйлар икән шоферлар.

Вәсимә. И улым, көтмәгән дә идем... Шулай тиз кайтып җитәрсең дип уйламадым да... Бер-ике атнасыз кайтмассың дип торган идем...

Фидан. «Дембель»не бик тиз бирделәр, әнкәй, шуңа да тиз кайттым.

Вәсимә. И-и... Әйдә чишен! Туган йортыңа кабат ияләшергә туры килер инде үзеңә. Казармаларыңны, частьләреңне онытырга туры килер.

Фидан. Тиз генә онытып булмастыр шул. (*Өстәл артына утыра.)*

Вәсимә. Чишен, сал формаңны! Күлмәк киеп җибәр! Ач шифоньерны!

Фидан (*сискәнеп*). Шулхәтле өйрәндем армия тормышына, гел комбат килеп керер төсле!

Вәсимә. Тәти апаңны күрдеңме?

Фидан (*елмаеп*). Күрдем. Авызы колагына җиткән.

Вәсимә. Җитәр дә... Ул бит сине яшьтән үк яратты. Кияүгә дә чыкмады, шуңа күрә баласы да булмады. Аннан... читкә китеп, исән-сау әйләнеп кайтудан да зур бәхет, зур сөенеч юктыр ул. Заманалары бик хәтәр бит хәзер. Әнә күрше авылдан Хәсәнша малаен нишләттеләр?! Чечнәдә үтереп кайтардылар. Цинковый табут килеп төште өйләренә! Менә нинди зур кайгы! (*Елап ала*.) Аллага шөкер! Исән-сау кайттың! (*Фиданга карап тора*.) Ябыккансың... Киткәндә мондый түгел идең...

Фидан. Бардыр инде, әнкәй. Курортка бармадым бит, армиядә хезмәт иттем. Десант!

Вәсимә. Ие... Ашарыңа да җитмәгәндер инде?!

Фидан. Булды инде... җитмәгән чаклары да... Сиңа рәхмәт, әнкәй, теге вакыт, чирләп киткәч, бик нык ярдәм иттең. Әгәр дә акча җибәрмәгән булсаң, бәлкем, тиз генә терелә дә алмаган булыр идем. Ул яхшы дарулар өчен акчаны кемнән алдың соң син? Әйтеп тә язмадың...

Вәсимә. Алла ярдәм бирде, улым, Алла. Атаң хакына, атаң истәлегенә... Бар бит инде ул ярдәмчел кешеләр, бар. Син, әйдә, булганы белән авыз итә тор инде. Тиздән бәлеш тә пешеп чыгар, Алла боерса...

Фидан *(кузгалып).* Бәлешне соңыннан, кичкә ашарбыз. Бер чынаяк чәй эчәм дә, әйләнеп кайтам әле мин. (*Баскан килеш кенә чәй эчә.)*

Вәсимә. Каян?

Фидан. Урамнан.

Вәсимә. Кая шулкадәр ашыгасың? Кайтып кына кердең бит әле!

Фидан (*елмая, анасының җилкәсеннән сөя*). Кая шулай ашкынасың, йөрәк... Их, әнкәй! Кая ашкынганымны беләсең бит инде, сорамасаң да була.

Вәсимә *(үпкәләгән булып*). Беләм. Шулай инде... үсеп җиткәч, әнкәйләр түгел, җанкайлар якын була.

Фидан. Әнкәй, үпкәләмә... Мин сине бик тә яратам. Мин сине бик тә сагындым. Синнән дә якын кешем юк минем бу дөньяда. Тик... без сүз куешкан идек, кайтуга ук күрешербез дип... Ничек анда минем Зөһрәм?! Күргәнең булдымы?

Вәсимә. Ничек күрмим! Гел кереп йөрде. Бик еш керә ул безгә. Синең миңа язган хатларыңны да кереп кат-кат укый торган иде. Тик син аңа миңа караганда күбрәк яза идең бугай хатларыңны...

Фидан (*кочаклап*). Әнкәй, ярар инде, үпкәләмә... *(Пауза.)* Әнкәй, ә ул сиңа ошыймы?

Вәсимә. Ә нишләп ошамасын ди... Ошый, бик тә ошый. Чибәр, акыллы, олыны олы, кечене кече итә белә...

Фидан. Бик яхшы. Тәртип алайса, әнкәй.

Вәсимә. Тик...

Фидан *(сагаеп).* Нәрсә?!

Вәсимә. Ясминур апаң гына бик яратып бетерми аны...

Фидан (*елмаеп*). Ясминур апаның ни өчен яратмаганын беләбез инде. Ярар, әнкәй, мин киттем, очрашып күрешик инде Зөһрә белән... Соңыннан сөйләшербез... Кичкә, яме, әнкәй...

Вәсимә. Кая? Өенә барасыңмы?

Фидан. Белмим... Йә өенә, йә каен янына...

Вәсимә. Нинди каен?

Фидан. Каен янына инде, әнкәй, ялгыз каен... Шунда күрешербез дип сүз куешкан идек. (*Әсәрләнеп чыгып китә.)*

Вәсимә. Әй бала, бала! Итәктә чакта сөйдерәсең, итәктән төшкәч көйдерәсең. (*Иснәнеп*.) Әй бу бәлешне әйтер идем... һич пешеп чыкмады инде, чурту! (*Кулына кисәү алып, мич каршында бөтерелә*.)

**ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Мәүлет керә. Матур, ыспай киенгән. Кыяфәте үтә дә эшлекле. Һавалы сөйләшә.

Мәүлет. Исәнме, Вәсимә!

Вәсимә *(сискәнеп*). Абау! *(Чүлмәк капкачын төшереп җибәрә*.) Куркыттың... Әллә кем дип торам!

Мәүлет (*елмаеп*). Соң, мин әллә кем түгелме соң инде?! Ә?! (*Көлә.)*

Вәсимә (*кулларын алъяпкычына сөртеп*). И-и... Йөз-кыяфәтең күз тимәслек инде синең, Мәүлет, күренекле кеше инде син! Шәп син, шәп! Төс-кыяфәтең генә түгел, күңелең дә бик әйбәт... Кешеләргә ярдәм итәргә генә торасың, синең кебекләр күбрәк булсын иде бу дөньяда... э... э...

Мәүлет. Син мине алай артык мактамале, Вәсимә, бозып куюың да бар.

Вәсимә. Ай-яй, бозарсың сине, бар. Син аягыңда нык басып торасың. Әй, нәрсә сөйләнеп торам соң әле мин... Утыр әйдә, бәлеш тә пешә... (*Чыраен сытып, мич ягына карап ала.)*

Мәүлет. Утырам, рәхәтләнеп утырам.

Вәсимә. Ашыкмыйсыңмы? Син бит кешедә озак утыра белмисең.

Мәүлет. Бер басасы урынга, биш мәртәбә баса торган кеше, димәкче буласыңмы. (*Утыра.*) Тик тора торган заман түгел хәзер, Вәсимә. Тик торсаң, хәзер артыңа китереп басалар. Көндәшләр күп. Сәүдә эше тәк кенә түгел ул, ул көн-төн чапканны, яхшы итеп санаганны ярата...

Вәсимә. Шулай инде, шулай... (*Кыенсынып.*) Ни... Мәүлет...

Мәүлет. Ни бар?

Вәсимә (*каршына утырып*). Синең алда оят та инде... Сиңа теге бурычымны һаман да түләп бетерә алганым юк бит әле... Иремнең пособиясен алгач ук...

Мәүлет (*үпкәләгән булып*). Вәсимә... Иреңне хөрмәт итә идем бит мин. Чын дуслар идек. Тайгада бергә урман кистек...

Вәсимә. Ие... Заһитым агач астында калды, ә син менә кеше булып калдың. *(Пауза.)* Бераз гына көт инде...

Мәүлет (*кырыс*). Вәсимә, туктале! Юк сүз сөйләмә! Мин бит синнән акча сорап килмәдем... *(Пауза.)* Улың кайткан дип ишеттем.

Вәсимә. Ә... ие... әле генә кайтып керде... Сөбханалла!

Мәүлет. Исән-сау?!

Вәсимә. Исән, Аллага шөкер! Сөенеч инде бу, зур сөенеч! Бердәнбер бит, бердәнбер улым!

Мәүлет. Кәефе ничек?

Вәсимә. Әйбәт... кәефе дә... Начар булырга сәбәп юк. Авыр вакытта улыма бик ярдәм дә иттең инде... Рәхмәт... Ходай сине исәнлектән ташламасын... Сиңа чәйне ничек ясыйм, сыек итепме, куемы? (*Чәй ясый башлый*.)

Мәүлет. Мин чәй эчмим. Чәй чырайны боза. Утыр, кыбырсыма, синең белән сөйләшәсе бар.

Вәсимә (*утырып*). Сүлә, тыңлыйм.

Мәүлет. Улың кая китте?

Вәсимә. Улым... чыгып китте. Иптәшләрен күрергә. Ике ел күрешмәгәннәр бит.

Мәүлет (*ышанмыйча*). Иптәшләре янына?! *(Пауза.)* Ну, ярый, шулай да булсын ди! Эш менә нәрсәдә. Күреп торасыңдыр минем синең янга юкка гына килмәгәнемне. Мин сиңа изге теләкләр белән килдем, Вәсимә. Кыскасы... Син беләсең, мин озак сөйләргә яратмыйм. Мин синең белән туганлашырга уйладым.

Вәсимә *(аптырап*). Туганлашырга?! Ничек итеп?

Мәүлет. Белмәгәнгә сабышма.

Вәсимә. Чы-ын! Белмим, мин берни дә белмим.

Мәүлет. Минем кызым бар. Сүз Кафия турында бара...

Вәсимә. Ие... Кызың исән-саудыр бит?

Мәүлет. Исән. Кабатлап әйтәм, миндә Кафия бар, синдә — Фидан...

Вәсимә (*төшенә башлап*). Ие...

Мәүлет. Синең Фиданың миңа ошый. Армиягә китәр алдыннан минем кибеттә шофер булып эшләп алды. Товар ташыды. Сынатмады. Атасы кебек үк уңган егет. Хәер, минем кызым да төшеп калганнардан түгел. Минем белән беррәттән сәүдә итә. Акчаны шәп саный, исәп-хисапны тота белә. Иң мөһиме: ул синең Фиданыңа гашыйк. Миңа шунысы мәгълүм.

Вәсимә (*ни әйтергә белмичә*). Ие...

Мәүлет. Кушырга иде безгә шушы ике яшь йөрәкне.

Пауза.

Беләм мин синең нәрсә әйтергә теләгәнеңне, беләм...

Вәсимә (*коелып*). Нәрсә...

Мәүлет. Син миңа ялганладың. Бүтән алай эшләмә. Малаең, кайтып җитмәс борын (*ирония белән*), Гайшә кызы Зөһрә янына чапты, шулай бит?!

Вәсимә (*баш чайкап*). Нишлим инде... Яшьтән үк бер-берсен яраттылар бит. Яшьләргә ничек каршы киләсең...

Мәүлет (*кинәт кычкырып*). Кирәк! Кирәк каршы килергә! Җүнле бала ата-анасы сүзеннән чыгарга тиеш түгел. Ата-ана ул һәрвакыт файдага әйтә...

Вәсимә. Әй Аллам, мин нишли алам инде?!

Мәүлет (*сабыр*). Ашыкма, тынычлан. Аек акыл белән уйлап кара. Менә син улыңның яраткан кызы бар, дисең инде! Кем соң ул?! Нинди кыз ул?! Нинди бала?! Уйнаштан туган бала. Нәсел-нәсәбе билгесез. Ә анасы кем? Беркатлы, эшсез, җүнсез хатын. Алкоголичка! Ә син шул затсыз, тотнаксыз хатын белән туганлашырга җыенасың?!

Вәсимә. Нәселе яхшы булу кирәк инде анысы, бик тә кирәк.

Мәүлет. Әлбәттә. Әлбәттә кирәк. Менә мине генә алыйк. Мин ничек өйләндем Рәсимәгә?! Минем өчен аның кем булуы, нинди нәселдән булуы бик тә әһәмиятле иде. Иң элек аның бик ныклап нәсел-нәсәбен тикшердем. Нәселендә җүләрләр юкмы, сәрхушләр, төрмәдә утыручылар булмаганмы? Атасы — күрше авылда парторг, анасы — мәктәп директоры. Акыллы, булдыклы, бай тормышлы кешеләр. Ата-анасы җүнсез булса, мин Рәсимәгә өйләнгән булыр идемме?! Юк, билгеле. Яратам дип кенә өйләнергә ярамый. Ярату бер көнлек кенә ул. Рәсимә минем таянычым булды. Ата-анасы да бик нык ярдәм итте. Күтәрелеп киттем... Бүгенге көндә минем дүрт кибетем бар. Бишенчесе Казан янында төзелеп ята...

Вәсимә. Булган кеше инде син, Мәүлет, булган.

Мәүлет (*торып*). Ә ничек күтәрелдем?! (*Маңгаена сугып.*) Менә мондагы акыл белән! Кибетләрне кеше йөрми торган урында түгел, ә юл өстендә төзеттем. Авыл халкы хәерче, ә юлдан калын кесәлеләр йөри. Аллага шөкер, акча, ягъни навар кереп кенә тора. Дөньясын җимертеп яшибез, Вәсимә, җимертеп...

Вәсимә (*тыны кысылып*). Ие...

Мәүлет. Тик... тормышның бер генә ягы китек әлегә... Кызым кияүдә түгел. Үзенә кияү тапмаслык кыз түгел ул, билгеле! Тик үзем яшь, таза чагымда кызымны кияүгә бирәсе иде. Димләүчеләр, сораучылар булды, күп булды. Тик араларында төпле егет очрамады. Сәүдә эшен тартырлык, тиешенчә алып барырлык акыллы, эшчән егет кирәк. Кияү итеп мин бер генә кандидат күрәм: улың Фиданны.

Вәсимә. Белмим инде...

Мәүлет (*басым ясап*). Иң мөһиме: минем кызым синең улыңны ярата.

Вәсимә. Бер сүз дә әйтә алмыйм...

Мәүлет. Кавыша алсалар, бер кибетне аларга бирәм. Иң яхшысын! Туйга өр-яңа машина бүләк итәм! Менә бу алачыгыңа... гафу ит... өеңә ремонт ясатып, газ кертәм...

Вәсимә. Үзе кайтсын инде... ансыз ничек хәл итәсең инде?..

Мәүлет. Улың кая эшләргә җыена?

Вәсимә. Кайда дип... Минем яннан китмәс инде... Колхозда калыр...

Мәүлет (*елмаеп*). Йә Себергә китәр, шулаймы?! *(Пауза.)* Буш хыял бу! Инде күптән аңларга вакыт: колхоз бетте!

Вәсимә. И-и, шундый данлыклы колхозны бетерерләр микәнни?!

Мәүлет (*кызып). Бетте бит инде! Ни чәчә алмыйлар, ни уралмыйлар, ни сугалмыйлар! Техника юк! Ә техникасыз җирне ашлап булмый. Ашламасаң, җир икмәк бирми... Инде биш ел колхозчылар хезмәт хакы күрмиләр... Мескеннәр! Улыңны хәерче итәсең килсә, тык аны колхозга, эшләсен бушлай! Карарбыз, күпмегә җитәр түземлеге! Тайгага чыгып качмаса, атасы сымак... Ә мин анда булдым, мин тайганың нәрсә икәнен яхшы беләм. Менә монда... (*җилкәсенә сугып*) үз җилкәмдә татыдым мин аны... Йә?!

Вәсимә. Белмим... Мин каршы түгел түгелен дә... Җиңә алырмын микән мин аны?!

Мәүлет (*Вәсимәнең җилкәсеннән сөеп*). Аңла, теләсә кемне җиңәргә була. Кызыксындыра гына белергә кирәк. Мин үзем дә аның белән сөйләшермен. Тик аңа хәтле... Син улыңның тел төбен белергә тырыш, аңладыңмы?

Вәсимә (*баш чайкап*). Аңладым...

Мәүлет. Сау булып тор! (*Чыга башлый*.)

Вәсимә. Китәсеңмени? Ә бәлеш?!

Мәүлет. Бәлеше соңыннан, соңыннан... кодагый... (*Чыгып китә.*)

**БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Ясминур керә. Кулында сумка.

Ясминур. Нишләп тиз җибәрдең кунакны?

Вәсимә. Китте... *(Пауза.)* Башыма уй, йөрәгемә борчу салып китте...

Ясминур. Ни булды?

Вәсимә. Кафиясен минем улыма бирергә тели.

Ясминур. Ә, менә ничек?! (*Сумкасын урындыкка куеп.*) Әйбәт! Әйбәт тәкъдим!

Вәсимә. Нәрсәсе әйбәт булсын инде аның?!

Ясминур. Апам! Әгәр дә син бу тәкъдимне кире каксаң, җүләр буласың. Тотарга да Фиданны Кафиягә өйләндерергә кирәк!

Вәсимә. Өйләнмәсә...

Ясминур. Өйләнмичә кая барыр...

Вәсимә *(уйланып*). Ие... Мин үзем болай бик каршы түгел түгелен дә... Мәүлет кебек асыл ирләр белән туганлашу зур дәрәҗә инде ул... э... э... Дан гына ул безнең өчен... Тик... Фидан ни әйтер бит. Ул бит Зөһрәне ярата...

Ясминур (*ярсып).* Тапкан сөяр кеше... Аптырама! Анысын миңа тапшыр! Кирәк икән, егетне авыштырырбыз да, кирәк икән, сихерләрбез дә!

Вәсимә. Рәхмәт, сеңлем...

Ясминур. Тик сиңа ярдәм итәр өчен генә алына дип уйлама тагын. Минем күптәнге үчем бар.

Вәсимә. Нинди үч?

Ясминур. Белмәгән булып кыланма инде. Әллә хәтерең начарландымы?! *(Пауза.)* Анасын сөймим дә соң шул Зөһрәнең. Гайшә минем егетемне тартып алды... моннан егерме ел элек... Каладан килгән... мелиоратор... Зөһрәнең атасы шул иде бит инде...

Вәсимә. Ә... Ирекне әйтәсеңме?

Ясминур. Без бит Ирек белән өйләнешергә дип сүз куешкан идек. Ул мине калага алып китәм дип вәгъдә бирде. Тик шул әрсез Гайшә генә килеп керде арага. Бик тә әрсез иде бит ул!

Вәсимә. Яшь чагында чибәр иде, кәнишне!

Ясминур. Ә мин бик тә тыйнак, бик тә сабыр идем. Әллә нигә алгысыды шул Гайшәгә. Соңыннан... бала ясады да качты. Барыбер бергә булалмадылар.

Вәсимә. Аның Ирекгә дә җүнле булмагандыр шул инде, хатын-кызны алдап, соңыннан ирекле булырга яраткандыр.

Ясминур. Минем белән кушылган булса, бар да әйбәт булган булыр иде әле. Бер дигән итеп торган булыр идек! Бәхетемне җимерде шул Гайшә тәресе, гомерлек ялгыз итте. Гомер кичерәсем юк аны!

Вәсимә. Онытырга вакыт инде!

Ясминур. Юк, апа! Җитте! Үч алырга вакыт җитте! Әгәр дә улыңны шул уйнаштан туган кызга өйләндерәсең икән, өеңә башка аяк та басмаячакмын. Ант итеп әйтәм, ипи тотып ант итәм! (*Кулына икмәк ала*.) Мәүлет янына кереп чыгарга кирәк...

Караңгылык.

**АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ**

Каен янында. Зөһрә, Фидан. Алар кулга-кул тотынышып җырлыйлар. Илаһи музыка.

Зөһрә.

Саубуллаштык синең белән
Язларның акларында.
Сине уйлап моңландым мин
Сагынган чакларымда.

Фидан.

Үтте айлар, үтте еллар,
Кабат ак язлар килде.
Һавадагы кошлар кебек
Сагынып кайттым сине.

Бергә.

Бу дөньяда кемдер кайта,
Ә кемнәрдер китәләр.
Ялгызлар гына, сагынып,
Сөйгәннәрен көтәләр.

Зөһрә.

Ялгыз каен шавын тик мин
Тыңлый һәм аңлый беләм —
Мин еласам, ул да елый,
Мин көлсәм, ул да көлә...

Бергә.

Бу дөньяда кемдер кайта,
Ә кемнәрдер китәләр.
Ялгызлар гына, сагынып,
Сөйгәннәрен көтәләр...

Фидан. Зөһрә!
Зөһрә. Фидан! (*Кочаклашалар*.)
Фидан. Зөһрәм, мин сине сөям... Югалтмыйк бу җырны, гомергә югалтмыйк... Бергә булыйк...
Зөһрә. Югалтмыйк, Фидан, югалтмыйк...
Бергә. Югалтмыйк... (*Музыка кабат яңгырый. Ике яшь йөрәк каенлыкта, бии-бии, югалалар.)*

Караңгылык.

**ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Бер-ике атна вакыт үзган. Фиданнар өе. Ясминур керә. Өстенә матур, затлы күлмәк кигән. Көзге каршында бөтерелә. Икенче яктан Вә-
симә чыга. Кулында тәсбих.

Ясминур (*җырлап*).

Зәңгәр күлмәгеңне киярсең,
Иркәм, миңа, бәгърем, диярсең.
Кояш батып, таңнар атканда,
Мине сагнып янып көярсең.

Зәңгәр күлмәк, зәңгәр күлмәк,
Кемнәр аның иясе?
Зәңгәр күлмәгемне киеп,
Килә янып сөясе...

Вәсимә. Абау! Кем бу?!

Ясминур, елмаеп, Вәсимәгә таба борыла.

Каян алып кидең мондый затлы күлмәкне?
Ясминур. Килешәме?
Вәсимә (*башын чайкап*). Килешә, алай да килешә! *(Пауза.)* Акчам юк дип зарланасың, үзең әллә нәрсәләр алып киясең.
Ясминур. Үзем алмадым.
Вәсимә. Ә кем?
Ясминур. Кода алды.
Вәсимә. Нинди кода?
Ясминур. Нинди кода булсын ди инде, Мәүлет кода.
Вәсимә. Әстәгы... Инде шулай бүләкләр дә таратамыни Мәүлет?!
Ясминур. Ие... Мин хәзер яучы. (*Көлә*.)
Вәсимә. Нинди яучы инде син?!
Ясминур. Ә менә шундый!
Вәсимә. Кем ягыннан?
Ясминур. Кыз ягыннан. Билгеле, егет ягыннан да... Алла теләсә!
Вәсимә (*иске күлмәген төзәткәләп*). Юкка йөрмисең микән?!
Ясминур. Нишләп алай дисең? Күлмәгемнән көнләштең мәллә?
Вәсимә. Ай, исем китте!
Ясминур (*үртәп*). Ай, ай!
Вәсимә. Фиданны килештерү, ай-һай, авыр булачак сезгә! Бүләгеңне кире кайтарып бирергә туры килмәсен!

Ясминур. Килмәс, килмәс. Андый ук затсыз кеше түгел ул Мәүлет. Кибетенә кергән идем... үзен күреп сөйләшермен дип... Яшьләрне кавыштыру турында авыз гына ачкан идем, киштәсеннән алып тотты да өстемә кидереп чыгарды...

Вәсимә. Яратасың инде...

Ясминур. Ә андый коданы ничек итеп ошатмаска, ничек итеп яратмаска кирәк ди. Андый коданың, апа җаным, кулыннан гына үбеп торырлык. (*Күлмәк путасын кысып бәйли.)* Ул әле сиңа да бүләк әзерли, бик зур бүләк.

Вәсимә (*турсаеп*). Кирәкми миңа бернинди дә бүләк! Миңа тынычлык кирәк.

Ясминур (*кызып*). Син нәрсә, улыңны Мәүлет кызына өйләндерергә риза түгелмени?!

Вәсимә. Ризасын риза да... Өйләнмәс ул аңа, өйләнмәс...

Ясминур. Өйләнер. Өйләндерергә кирәк.

Вәсимә. Белмим... Зөһрәм, дип авыз суын корытып торганда...

Ясминур. Җитте. Ул эшне миңа калдыр. Ачысын да, төчесен дә үзем татырмын... Кая соң әле ул бывший сержант?

Вәсимә. Йоклый. Йокысыннан уянмаган. Армиядән кайтканнан бирле йоклап туя алмый. Тавышланма, йокласын инде.

Ясминур. Төне буе Зөһрәсен саклап йөри ул иптәш сержант, шуңар йокысы туймый аның.

Вәсимә (*кул селтәп*). Ярар, кеше тикшермә инде!

Ясминур. Ә син сөйләштеңме соң?

Вәсимә. Нәрсә?

Ясминур. Кабат-кабат сөйләштеңме, дим, улың белән. Коданың ниятләрен ирештердеңме аңа? (*Вәсимә уйчан*.) Нәрсә телеңне йоттың?

Вәсимә. Әйткәләдем инде...

Ясминур. Йә?!

Вәсимә. Соң... гел уенга гына бора...

Ясминур. Сөйләшүең шундый гына булган, димәк.

Вәсимә. Үпкәләде. Хыянәтче, диде. «Әни, син Зөһрәне яратканны күреп торасың, ә миңа тиктомалдан ниндидер Мәүлет абый кызын китереп тыгасың!» — ди... Кыскасы, теләми ул Кафиягә өйләнергә.

Ясминур. Теләсен. Таләп ит!

Вәсимә (*сискәнеп).* Ничек итеп?! Алар бит Зөһрә белән сүз куешканнар. Алар яшьтән бер-берсен сөяләр. Вәгъдәле алар... Ничек итеп, ничек итеп... бер-берсен сөйгән ике яшь йөрәкне мин, ана кеше, аера алыйм ди. Теләсә ни әйтегез, ләкин минем моңа көчем җитми. (*Елый*.) Аннан... теләмим дә... Баламны бай итәм, авызымны май итәм, дип, улымны яратмаган кешесенә өйләндерә алмыйм инде мин...

Ясминур. Җебегән син! Син миңа шуны әйт: коданың сүзләрен улыңа җиткердеңме син, юкмы?

Вәсимә. Җиткердем. Көлде генә... (*Шаркылдап көлеп күрсәтә*.)

Ясминур (*сискәнеп*). Абау! Шулкадәр ямьсез итеп көлмәсәң, ярамасмыни?! Аңлашылды. Кит әле! (*Вәсимәне читкә этә*.) Синнән эш чыкмаячак. Читкә кагыл син! Бу эшне миңа тапшыр! Улыңны бәхетле итәсең килсә...

Вәсимә (*киная белән*). Теләсәң нишлә инде... Күрәсең, синең кулдадыр безнең язмыш... (*Көрсенеп елмаеп куя*.)

Ясминур. Бар, улыңны уят.

Вәсимә. Уят...

Ясминур. Бар, бар, уят инде! (*Вәсимәне эткәләп кертеп җибәрә.)* Ах, апай, ах, Фидан, белмисез шул әле сез, белмисез, на что я спасобна! На что... (*Тыңлана-тыңлана югала*.)

**СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Фидан керә. Кәефе юк. Ишек ягына карангалап ала да, башын аска иеп, өстәл янына килеп утыра. Вәсимә керә. Улына сәерсенеп карап ала да, чәй ясый башлый. Каушый. Кулыннан бал кашыгы төшеп китә. Күтәрә.

Вәсимә (*касәне Фидан алдына этеп*). Улым... *(Пауза.)* Нигә дәшмисең? Кәефең юкмы соң?

Фидан. Әни, мин барысын да ишетеп тордым. (*Касәне кире этә.)*

Вәсимә *(сискәнеп).* Ишеттең?!

Фидан. Шулкадәр кычкырып сөйләшкәч, ничек уянмыйсың да, ничек ишетмисең ди.

Вәсимә. Җә... ни әйтәсең...

Фидан (*бераз тын торганнан соң*). Минем сүзем юк, әнкәй. Нәрсә соң бу? Без Зөһрә белән өйләнешергә дип сүз куештык, ә сез нишлисез?! Нәрсә җитми ул Ясминурга, ул аждаһага?!

Вәсимә. Ясминур олы кеше, апа тиешле кеше...

Фидан. Төкерәм мин аңа! Дөнья болгатучы! Чүпрәк өчен корсакбайга сатылып өлгергән. Мине Мәүлет кызына өйләндермәкче була. Инде син дә шуңа тагылмакчы буласың?!

Вәсимә. Мин түгел, улым...

Фидан. Ә кем соң, кем?!

Вәсимә. Заманалар башка... Тормыш, улым, тормыш...

Фидан. Тормыш ул бүген генә түгел, тормыш гел булган, бездән соң да булачак. Нәрсә, мин Мәүлет кызыннан башка яши алмам мәллә? Минем нәрсә, үз башым юкмы?! Җүләрме мин?! Гарипме әллә?! *(Пауза.)* Зөһрәне алам да, китеп барам калага...

Вәсимә. Мине, анаңны, ялгыз калдырыпмы?..

Фидан. Китәм. Монда яшәүнең ни яме бар? Җитмәсә сүз белән бутый башладылар... Кем чыгара ул гайбәтне, кемгә кирәк кеше котырту?! Имеш, Зөһрә мин армиядә чакта...

Әкрен генә Ясминур керә.

Акый малае белән буталган икән, болар бер-берсен бик яратканнар икән дә, соңыннан әллә кайларга барып, әллә ниләр эшләп ятканнар икән... Ялган бит бу! Чеп-чи ялган!

Ясминур (*тыныч*). Юк, энем, бу ялган сүз түгел, дөрес сүз бу.

Фидан (*усал*). Ә... син әле мондамыни, китмәдеңмени?! (*Киная белән.*) Халык тарафдары. Ә халык әйтсә, хак әйтә, шулай бит, тәти апай?! Бу гайбәтләрнең серенә төшсәң, монда синең кул уйнагандыр әле, уйнамыйча калмагандыр. Мин белеп торам: бу гайбәтләр, бу буш сүзләр махсус эшләнә, мине Зөһрәдән аерыр өчен эшләнә. Минем көнче икәнлекне белә торып, минем йомшак ягыма бәреп! *(Пауза.)* Юкка! Юкка йөрисез! (*Йодрык белән өстәлгә суга*.)

Вәсимә (*куркып*). Улым, тынычлан, зинһар!

Ясминур. Хаклыктан качып булмый, дустым. Ә дәлилләр җитәрлек.

Фидан (*киная белән*). Нинди дәлилләрең бар соң синең?! Йә, сөйлә ачыктан-ачык! (*Утыра.)*

Ясминур. Сүнгән йолдызлар...

Фидан (*аңламыйча*). Нәрсә сүнгән...

Ясминур. Зөһрәң клубта эшли... Акый малае белән ничек итеп авылдан авылга спектакль куеп йөргәннәрен ишеткәнсеңдер инде. «Сүнгән йолдызлар» спектаклен! Зөһрә Сәрвәрне, Акый малае Хәмит Исмәгыйльне уйнады...

Фидан. Соң, уйнасалар. Ул бит Зөһрәнең эше! Ул шуңа акча ала, авылдашларына хезмәт күрсәтә.

Ясминур. Күрсәтте инде! Шәп итеп уйнады! Ул уен бик тиз уйнашка әйләнде.

Фидан *(торып*). Тәти апа, җитәр сиңа! Җитәр!

Ясминур (*рольгә кереп*). «Исмәгыйль, син мине сөясеңме?» (*Ирләр тавышына күчеп.)* «Мин сине сөям дию генә аз, Сәрвәр... Менә мин сине... мин сине... юк бит, юк, аңлатырга сүз юк! Менә мин сине шулкадәр сөям, яратам, дус күрәм». *(Юри саташып.*) «Зөһрәм...» «Хәмит...» «Җаным... Күңелеңне тыныч тот! Мин дә шулай ук. Синнән аерылуны сизгәндә, минем дә шулай йөрәгем үлә. Безнең йөрәкләребез моннан соң үлмәсләр... Ышан, мин синнән башкага чыкмыйм...» Мин Фиданга чыкмам, сиңа чыгармын... (*Җырлый*.)

Каз канаты каурый-каурый,
Сәлам язарга ярый.
Ир канаты маллар даулый,
Каз канаты яр даулый...

Җыр көенә әйләнә.

Фидан (*пьесадагы Надир мәхдүм сыман*). «Кит моннан, шайтан карчык! Инде син Зөһрәмнең башын ашарга йөрисеңме?! Юк, барып чыкмас! Ычкын моннан! Менә сиңа, яучы карчык! Менә сиңа!» (*Ясминурны буа. Ул гырылдый. Егыла.)*

Вәсимә (*коты очып*). Улым! Үтерәсең! (*Арага керә.)*

Фидан. Чукынып китегез! (*Чыгып китә*.)

Вәсимә. Ясминур! Ясминур!

Ясминур. Ә?!

Вәсимә. Исәнме син?!

Ясминур. Нәрсә булсын миңа! (*Шаркылдап көлә.*) Җиңәрсең алай гына Ясминурны!
Вәсимә. Әй дивана, тәмам котымны алдың! Нишләргә инде?..
Ясминур. Әзерлән!
Вәсимә. Нәрсәгә тагын?
Ясминур (*торып*). Ял көне коданы чәйгә алабыз. *(Пауза.)* Кафияне дә чакырырга онытма.
Вәсимә. Кодагый ялда түгелме соң әле?
Ясминур. Анысы мөһим нәрсә түгел. Безгә Фиданны өйләндерү мөһим.
Вәсимә. Хак сүз.
Ясминур (*пышылдап*). Аннан, ни... Мин чуаш карчыгыннан бер хикмәт алып кайттым.
Вәсимә. Нәрсә ул?
Ясминур. Нәрсә икәнен сорама. (*Кечкенә кәгазь төргәге чыгарып.*) Менә шушы үләнне төнәтеп, һәркөнне улыңның эчкән чәенә салып тор. Сиздерәсе булма... Сихер үзенекен итәр, улыңны алыштырып куйган кебек булыр... Алла боерса! (*Төргәкне Вәсимәгә тоттыра.*)
Вәсимә (*шомланып*). Алла боерса... Алла боерса...

Караңгылык.

**ТУГЫЗЫНЧЫ КҮРЕНЕШ**

Каенлык. Эңгер-меңгер. Фидан кемнедер көтә. Бертуктаусыз як-ягына карана. Кесәсеннән фотография тартып чыгара. Мыскыллы караш ташлый. Ертып атмакчы була. Бераз уйланып торганнан соң, кире кесәсенә салып куя. Хәмит күренә. Фиданны күргәч, каушап
кала. Туктый. Фидан үзе аның янына килеп баса.

Фидан. Килмәссең дип уйлаган идем...
Хәмит. Ә нишләп...
Фидан. Курыкмыйсыңмы?
Хәмит. Ә нишләп куркырга?!
Фидан. Әйбәт килеп чыкмады, егет. Мин армиядә хезмәт итәм, туган илемә булган бурычымны үтим. Ә син... миңа төкерәсең! Мәхәббәтемә!!! *(Пауза.)* Әйт дөресен: әгәр дә син чын егет икәнсең... Зөһрә белән йөрүең дөресме?!
Хәмит (*тыныч, ләкин астыртын*). Дөрес.
Фидан (*авыр тын алып*). Нишләтергә сине?! Мин бит сине, беләсеңме...
Хәмит. Берни дә белмим. Гаебем юк. Ул үзе миңа тагылып йөрде.
Фидан (*каушап*). Үзе...
Хәмит. Әйе... Кыз үзе теләгәч, миңа нишләргә кала...
Фидан. Карале, егет, син үз сүзләреңә җавап бирәсеңдер бит?! Әгәр синең бу сүзләрең ялган икән, мин сине җиде кат җир астыннан табып, җиде кат тиреңне салдырачакмын, ишеттеңме? (*Хәмитнең якасыннан тота.*) Ант ит!
Хәмит. Ант...
Фидан. Тагын бер кат!

**УНЫНЧЫ КҮРЕНЕШ**

Зөһрә күренә.

Фидан (*аптырап*). Зөһрә...

Хәмит чыгып китә.

Син... монда?! (*Зөһрә баш чайкый.)* Без бит синең белән көтү кайтканнан соң күрешербез дип сөйләшкән идек...
Зөһрә (*Фиданның җилкәсенә башын куеп*). Начар төшләр күрәм, Фидан. Кемдер (*каен ягына ишарә ясап*) һаман күзәтә кебек мине... Күзләр, күзләр, күзләр күрәм, артта да, алда да... Күзләр, кара шомлы күзләр... Күзләр, сүзләр ишетәм, сүзләр...
Фидан. Ни булды сиңа, Зөһрә?! Чирләмисеңдер бит?! (*Аны читкә этә.*) Ныклап сөйләшәсе иде синең белән, Зөһрә!
Зөһрә. Сөйләш! Нәрсә?
Фидан *(кискен*). Нәрсә түгел, ә кем?! (*Хәмит киткән якка күрсәтә.)*

Зөһрә. Син кемгә күрсәтәсең?!

Фидан (*киная белән*). Җан дустыңа.

Зөһрә (*чынбарлыкка кайтып*). Кемгә, кемгә?! Минем җан дустым, сөекле кешем бер генә, ул — син!

Фидан. Алдашма. Аңламаган булып кыланма.

Зөһрә. Аңладым. Бөтен авыл халкы сөйли, туганың Ясминур сөйли, моңа ничек итеп ышанмаска, шулай бит?!

Фидан (*башын аска иеп*). Сөйлиләр шул... Нигә сөйлиләр?..

Зөһрә *(кискен*). Ә син кемгә ышанасың соң?!

Фидан. Ә кемгә ышаныйм соң?!

Зөһрә. Миңа! *(Пауза.)* Ышанмыйсыңмы?!

Фидан. Ышанам да...

Зөһрә. Юк, син миңа ышанмыйсың. Исеңә төшер — мин бит сиңа вәгъдә бирдем. Әнә теге ялгыз каен янында, сине көтәргә дип, сиңа хыянәт итмәскә дип, чын күңелемнән вәгъдә бирдем. Сиңа шул азмы?!

Фидан. Зөһрә, мин инде бала-чага түгел... Әллә нинди «каен вәгъдәләре»н искә төшереп утырыр яшьтән чыктым. Мин өйләнер яшькә җиткән егет...

Зөһрә. Күз тиюдән дә курыкмыйсыңмы?

Фидан. Нинди күз тиюдән?!

Зөһрә. Ялгыз каен күзеннән...

Фидан. Юк! Төкерәм каенына! Син... син вәгъдәңне боздың! Син миңа хыянәт иттең! Әле генә җан дустың... Хәмитең, ант итеп, барысын да сөйләп китте... *(Мыскыллы.*) Өстерәлчек!

Зөһрә. Кызык.

Фидан. Нәрсәсе кызык?! Бернинди дә кызык күрмим мин монда!

Зөһрә. Минем әти дә әнигә кайчандыр шул сүзләрне әйткән. Уйнашчы... Мәңгегә шул сүз тагылып калган әнигә. Инде хәзер миңа да шул ук сүзне әйтәләр.

Фидан. Алма алмагачыннан ерак төшми, күрәсең.

Зөһрә. Ә кем әйтә?! Мәктәптән үк өзелеп гашыйк булган, ике ел аңа тугры булган сөекле кешем әйтә...

Фидан. Тугры, имеш. Җә, нәрсә әйтә аласың соң? Үзеңне акларлык бирәр сүз әйтә аласыңмы, юкмы? (*Зөһрә дәшми.)* Юк бит, юк! Бер сүз дә әйтә алмыйсың. Ничек итеп җан дустың белән күрше авылда куныП йөргәннәреңне сөйләрсең, бәлкем, миңа да, ә?! Спектакльдән соң. Сөйлә. Тәҗрибәң белән уртаклаш. Минем өчен, кызлар тәнен татымаган яшь егет өчен, кызык булыр ул. Ә менә бу нәрсә?! (*Кесәсеннән фото чыгара*.) Кочаклашып төшкәнсез бит! Йә, нәрсә бу?! Моңа ничек ышанырга?! (*Фотоны ертып, Зөһрә өстенә сибә. Зөһрә егеткә усал итеп карап куя. Фидан, шомланып, күзләрен читкә ала*.) Нигә дәшмисең?..

Зөһрә (*кырыс*). Югал күземнән!

Фидан (*аңламыйча*). Ә?!

Зөһрә (*усал*). Пошел отсюда! Салдафон! (*Фидан кисәк кенә китеп бара*.) Күренмә бүтән күземә... (*Елый.)* Кеше сүзе, кеше сүзе керде безнең арага! Күз тиде безнең сөюгә!.. (*Җырлап.*)

Таңнарыбыз — алсу таң иде,
Кичләребез — айлы кич иде,
Язларыбыз — нурлы яз иде,
Җырларыбыз — җылы наз иде...

Кеше сүзе, кеше сүзе
Керде арага безнең,
Җанны боздай өшеттергән
Җилләре булып көзнең...

Караңгылык.

**УНБЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Вәсимәләр өе. Веранда ягы. Вәсимә кодаларны чәй эчәргә алган. Өстәл янында — Мәүлет, аның кызы Кафия. Вәсимә өстәлгә бәлеш китереп куя. Ясминур бер утыра, бер тора. Тәрәзә янына килә. Карана. Табындагылар аның хәрәкәтенә игътибар итмәскә тырышалар. Ләкин барысы да эчтән генә Фиданның эштән кайтуын көтәләр.

Вәсимә *(бөтерелеп)*. Менә шунда уртагарак куйыйк әле бәлешне. (*Куя*.) Кода, авыз итегез. *(Кафиягә.)* Әйдә, кызым, син дә, тартынма. Йөзе килгән микән инде бәлешнең?!

Мәүлет (*кабып).* Килгән, килгән... Борчылма... код... Кызым, авыз ит, алай ярамый... (*Кафия бер мәртәбә кабып куя да бәлешне читкә этә. Аның кәефе юк.)*

Вәсимә (*Ясминурга*). Утыр инде, кайта ул тиздән...

Ясминур (*ишетмәгәнгә сабышып*). Ә?!

Вәсимә. Табынга утыр, дим.

Мәүлет (*килештерергә теләп*). Бәлешең, чынлап та, тәмле булган, кодагый. Мәҗлестән мәҗлескә йөреп, бәлеш төбе ашаган муллаларның ничек ашказаннары бозылмый икән, ә?! (*Көлә.)* Шуңа аптырыйм...

Фидан керә. Өсте-башы мазутка буялган.

Вәсимә *(сөенеп)*. Улым, көттердең.

Фидан (*коры гына*). Исәнмесез.

Мәүлет. Исәнме...

Вәсимә. Әйдә, улым, кулларыңны ю да өстәл янына утыр. (*Фидан өйгә керә*.) Тышта гына ю! Анда сабын да бар.

Фидан *(киреләнеп*). Юк, мин өйдә, умывальникта юам. (*Веранда ишеген ябып, умывальникта кулын юа*.)

Мәүлет өйгә керә. Егеткә сокланып карап тора.

Мәүлет. Юкка, юкка син миңа үпкәлисең, дускай.

Фидан. Үпкәләп нишләгән бар соң әле?!

Мәүлет. Үч тотасың кебек.

Фидан. Мин беркемгә дә үч тотмыйм.

Мәүлет. Анысы яхшы. Син шуны аңла: мин сиңа фәкать яхшылык кына телим. Мәгълүмдер дип уйлыйм, без синең әтиең белән кайчандыр бергә уйнап үстек, бергә бер класста укыдык, бергә шаярдык, бергә кайгырдык, бергә кызлар артыннан йөрдек. Чын дуслар идек. Соңыннан бергә урман кистек, агач аудардык. Ни аяныч, егылды атаң, егылды... Агач астыннан мин өстерәп чыгардым аны, мин... Минем кулда үлде атаң. Ишеткәнсеңдер...

Фидан (*сагаеп*). Яшьтәшләр икәнегезне беләм. Ләкин әтинең синең кулда үлгәнен ишеткәнем булмады.

Мәүлет. Күземә карап, күземә карап үлде... Их, дускай, син күп нәрсәләрне белмисең шул. Атаң үлгәндә, сиңа өч кенә яшь иде шул әле. Кафиягә алты. Ул соңрак өйләнде. Анаң соңрак тапты. Атаң, яңа йорт салам дип, урман кисәргә китте. Мине дә ияртте. Миңа бармаска була иде, билгеле. Яшәргә йорт бар, акча бар, хатын бар, бала бар. Бар да бар. Ләкин атаң сүзенә каршы килә алмадым. Киттек. Ә бәла аяк астында яткан икән...

Фидан (*тизрәк юына башлап*). Син моны миңа юкка сөйләмисең, сизеп торам. Нигә кирәк бу?

Мәүлет. Сизенүең дөрес... Әйе, мин моны сиңа атаңның васыятен җиткерү өчен сөйлим.

Фидан (*сискәнеп*). Нинди васыять?

Мәүлет. Атаң минем кулда җан бирде, дип әйттем бит, минем күзгә карап... Җаны чыгарында әйтте. Болай диде: «Синең кызың, минем ир балам бар. Мин исән кала алмам. Сиңа тапшырам. Әгәр балалар исән-сау үсеп җитсәләр, хәлеңнән килсә, син аларны бергә куш...»

Фидан (*башына салкын су коеп*). Әти... шулай дидеме?

Мәүлет. Шулай диде. Бу атаңның васыяте. Ул аны соңгы сулышында әйтте.

Фидан. Андый чакта кеше ни әйтмәс. Дөресме бу?

Мәүлет. Ә син ничек уйлыйсың?

Фидан (*борылып*). Күзгә карап әйт!

Мәүлет (*күзләрен читкә алып*). Менә бу сезгә дигән беренче бүләгем. (*Өстәлгә машина ачкычлары куя.)*

Фидан. Нәрсә бу?

Мәүлет. Туй бүләге. Машина... *(Пауза.)* Уйла, Фидан, уйла... (*Чыгып китә.)*

Фидан, юеш башын сөлгегә чорнап, уйга кала. Музыка агыла. Агач ауган, яфрак кыштырдаган авазларга кеше тавышлары (персонажлар) кушыла. Алар Фиданга: «Уйла, Фидан, уйла!» — дип эндәшәләр. Каяндыр Зөһрәнең тавышы килеп керә: «Вәгъдә, Фидан, вәгъдә...» Аның йомшак, назлы тавышы катылана: «Югал күземнән, югал!» Тавышлар кайтаваз аша көй булып кечкенә симфониягә әвереләләр.
Ишек ачылган, ишек шыгырдаган тавыш симфонияне өзә.

**УНИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Кафия керә.

Фидан (*саташып*). Зөһрә... Зөһрә... син... (*Кафияне танып.)* Ә... син икәнсең әле... (*Кафия, бик нык кыенсынып, ишек катында басып кала*.) Ни булды?

Кафия. Анда сине чакыралар...

Веранда ягында көлгән, шаярышкан тавышлар ишетелә. Бераздан тавышлар тына. Ясминур ишек ярыгыннан карый.

Фидан. Кемнәр алар? Ни кирәк аларга?

Кафия. Алар... (*Еларга җитешеп.*) Хуҗалар, әти, мин... *(Пауза.)* Чыгасыңмы?

Фидан (*торып).* Хәзер, чыгам! (*Мазутлы иске күлмәген салып ата. Әнисе үтүкләп куйган өр-яңа ак күлмәген кия башлый.)*

Кафия (*кыенсынып*). Яхшы. (*Чыгарга кузгала.)*

Фидан. Тукта. (*Кафия туктап кала*.) Кафия...

Кафия. Әү?!

Фидан. Син кызмы?

Кафия (*каушап*). Аңламадым...

Фидан. Сафмы син?!

Пауза.

Кафия. Саф. (*Оялып башын аска ия.)*

Фидан. Чынмы бу?!

Кафия кисәк кенә ишек ягына атыла.

Тукта! (*Кафия туктый.)* Чык миңа! (*Киная белән*.) Әгәр дә теләгең булса...

Кафия. Ялгышасың. Бер минем теләк кенә түгел бу. Миннән бигрәк әти тели бу кавышуны.

Фидан (*каударланып*). Ә нәрсә?! Миңа чыкмас идеңмени?! (*Күкрәк киереп*.) Мин бит авылда бер дигән егет. Төс-кыяфәтем килгән, кулымнан эш килә, кызлар минем өчен өзелеп торалар! Ә?!

Кафия. Син мине... мыскыл итәсең кебек...

Фидан. Юк, киресенчә. Мыскыл итмим, хөрмәт итәм. Тормышта, дөньяда гамьле булуың өчен хөрмәт итәм мин сине. Акыллы, сабыр, тыйнак булганың өчен яратам. *(Күлмәген төймәли*.)

Кафия (*өздереп).* Юк, син мине яратмыйсың.

Фидан. Әйе, анысы дөрес...

Кафия. Яратмыйсың, ә үзең...

Фидан (*галстук тагып*). Ә кем белә... Бәлкем, тора-бара ярата да алырмын. (*Өстәл өстендәге машина ачкычларын алып, аларны кулында уйнатып ала.)* Менә шулай...

Кафия. Әгәр дә...

Фидан. Тс-с! (*Костюм кия, одеколон сибә*.) Мин әзер. (*Кафия каршына килеп баса.)* Йә, бир кулыңны! (*Кафия кулын бирә*.) Менә хәзер син минеке. Минекеме?

Кафия (*баш кагып*). Синеке.

Фидан (*кыланыбрак*). Минеке. Гөрләтеп туй итәрбез, матур-матур балалар үстерербез. Бергә-бергә озын, озак бәхетле гомер итәрбез! (*Кафияне күтәреп ала*.) Киттек!

Ясминур киң итеп ишекне ача.

Ясминур. Рәхим итегез! *(Көйләп.*)

Әй икегез, икегез,
Икегезнең битегез.
Икегез дә пар килгәнсез,

Тигез гомер итегез...

Фидан ишектән уза. Ишек ябыла. Ялгыз өй моңсуланып калган кебек була. Моңсу көй агыла. Веранда ягында шаулашкан, гөрләшкән тавышлар ишетелә. Бераздан алар, туй җырлары белән алмашына.

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Вәсимәләр өе. Өйдә беркем дә юк. Машина килеп туктаган тавыш ишетелә. Кухонный уголок күтәреп, Фидан керә. Иске өстәлне алып ата, аның урынына яңасын куя. Тавышка икенче яктан Вәсимә чыга.

Вәсимә (*йөрәген тотып*). Әй, синмени әле бу? Котымны алдың, кем икән дип торам!

Фидан. Менә сиңа өр-яңа кухонный уголок алып кайттым. Күннән эшләнгән. Миннән бүләк...

Вәсимә (*артык исе китмичә*). Күрәм. Расхутлангансың. Әлегә искесе дә ярап торыр иде. Читенсенәм сездән, яшьләрдән бүләк алырга.

Фидан. Читенсенмә. Син бит минем әнием. Синең матур итеп яшәргә хакың бар... Аннан... яңа йортка күчкәнче, без Кафия белән синдә торып торырга булдык.

Вәсимә. Имәндә икән чикләвек. Кодалар өе тар булды инде алайса?!

Фидан. Юк, киресенчә. Артык киң. Рөхсәт итсәң, без монда торып торыр идек.

Вәсимә. Билгеле. Мин шат кына.

Фидан. Әнкәй, син минем холкымны яхшы беләсең. Тора алмыйм мин кеше йортында. Анда ничек кенә уңай, ничек кенә җайлы булса да.

Вәсимә. Беләм. Атаң да шундый иде. Кая гына китсә дә, төнгә калса да, кешедә кунмый, өйгә кайта торган иде.

Фидан. Без монда яшәгән арада, йортны карыйсы иде. Ни әйтсәң дә, туган нигез бит.

Вәсимә. Алла теләсә. Бу уголокны Кафияң белән сөйләшеп алдыңмы соң?

Фидан. Без аның белән һәрчак сөйләшеп эш йөртәбез. Акчаны да бергә тотабыз. Тиенен тиенгә... (*Уголокның урындыкларын ташый.)*

Вәсимә. Соңыннан сүзе булмасын дим инде.

Фидан. Булмый, нишләп булсын. Хатын минем күзгә генә карап тора.

Вәсимә. Шулай да...

Фидан *(уголокны көйләп*). Минем хатын — чын хатын. Безгә охшамаган. Хис, моң кебек төшенчәләр аңа хас түгел. Ул — эш кешесе. Бөтен эшнең тәртибен белә, барысына да өлгерә. Мине дә сәүдә эшенә өйрәтә.

Вәсимә. Өйләнгәнеңә үкенмисең алайса. Уңдың хатыныңнан. Халык мактый үзен. Тик...

Фидан (*сагаеп*). Нәрсә?

Вәсимә. Балагыз гына юк, балам...

Фидан. Булыр әле.

Вәсимә. Өйләнешкәнегезгә ике ел вакыт узды. Белмим инде.

Фидан (*уголокка утырып*). Тикшерелдек. Икебез дә сау-сәламәт. Врачлар да аптырый. Тиздән Казанга барырга торабыз. Бер зур табиб янына...

Вәсимә. Мин беләм.

Фидан. Нәрсә беләсең?

Вәсимә. Күз тигән сезгә, кемнеңдер күзе тигән.

Фидан. Кемнең күзе тисен инде безгә?!

Вәсимә. Каргышы төшкән...

Фидан. Кем әйтте?

Вәсимә. Үзем әйтәм. Ясминур да шулай ди.

Фидан. Ул әйтер...

Вәсимә. Сихер, ди ул аны. Зөһрә ясап ята, ди сихерне. Ул авылдан китмичә, сихер бетмәячәк, ди.

Фидан. Әнкәй! Тимәгез әле шул Зөһрәгә! Аның бернинди дә гаебе юк.

Вәсимә (*улына текәлеп*). Күрәм, күзләреңнән күреп торам — оныта алмыйсың син аны, яратасың һаман да. Онытырга телисең, ләкин килеп чыкмый. Бәхетсез син, улым, яраткан кешеңне ташлап... (*Канәфигә утыра.)*

Фидан. Мин бәхетсез түгел. Минем хәзер бар нәрсәм дә бар.

Вәсимә. Тыштан бәхетле булып кыланасың, ә эчеңдә еланнар йөгерешә. *(Пауза.)* Зөһрәне әйтәм, син өйләнгәч, бигрәкләр дә өзгәләнде инде, бәгырь. Син армиядә хезмәт иткәндә, ул миңа «әни» дип

эндәшә иде инде. Хатының кебек прусты аптыраганнан түгел, чын йөрәгеннән, ихлас күңелдән эндәшә торган иде. Туйга җыенганда, өйдә үзем генә идем, минем янга керде дә: «Әни, туйга кереп, бер күзем белән булса да Фиданга карап алыйм әле!» — диде. Мин рөхсәт бирмәдем. Туйны бозарсың, кызым, йөрмә, соңыннан үзеңә читен булыр, дидем. Тыңлады тагын. (*Елап ала*.) «Нишләп шулай килеп чыкты соң бу? Нишләп бу дөнья шундый мәрхәмәтсез?» — дип, каршымда елады, бичара...

Фидан (*кызып*). Әнкәй! Җитәр, ә! Кияүгә чыга алмаган ниндидер кыз өчен күз яше сыгып утыра алмыйм мин хәзер. Минем эшем күп. Мин — эш кешесе! (*Вәсимәгә текәлеп*.) Миңа кара, әнкәй, миңа! Мин алдан кем идем?! Кулларым, киемнәрем кара мазутка баткан хәерче, акчасыз механизатор идем. Ә хәзер кем?! Кара! Кем хәзер мин?! Менә кара, нинди матур әйбер алып кайттым үзеңә! (*Уголокка күрсәтә.)* Кайчан ала алыр идек әле без аны?!

Вәсимә (*күз яшьләрен сөртеп*). Әтиең күрсә, сөенер иде инде.

Фидан. Мин әтине бөтенләй белмим. Нинди кеше иде соң ул?

Вәсимә (*торып*). Әтиең әйбәт кеше иде. Тик иртә харап булды, иртә...

Фидан. Син аңа яратып чыктыңмы?

Вәсимә. Яратып! Без яратышып өйләнештек. Ул үлгәннән соң, беркемгә дә карый алмадым. Заһитны сагынып, аны кайчандыр сөя алуымнан сөенеп яшәдем.

Фидан (*әнисен кочып*). Син бәхетсез, әнкәй.

Вәсимә. Юк, мин бәхетсез түгел. Син бар... Атаң бар...

Фидан. Юк бит инде ул.

Вәсимә. Бар. Минем өчен ул бар. Ул миндә яши. Кеше китә, ә ярату китми ул, улым, китми.

Фидан (*читкә тайпылып*). Анысы шулай...

Вәсимә. Нишләп атаң турында сорадың? Күптән сораганың юк иде.

Фидан. Әтине төштә күрдем.

Вәсимә. Ничек?

Фидан. Ялан кырда ята икән. Бар көченә кычкыра. Ярдәмгә чакыра. Мин йөгерәм. Иксез-чиксез дала буйлап йөгерәм дә йөгерәм... Таңда гына эти янына барып җиттем. Ята. Күзләрен (әле дә күз алдымнан китми!) кып-кызыл кан баскан. Кап-кара кул... Кем кулыдыр, белмим, әткәйнең муеныннан кысып тоткан да... буа аны... Әткәйнең тыны кысыла... Иртән, саташып, уянып киттем... Үзем үк буылып ятам икән...

Вәсимә (*шомланып*). Нәрсәгә юрадың?

Фидан. Ни дип юрарга да белмәдем. Шикләнәм. Әткәйне үтергәннәр. Кемдер үтергән аны. Акыллы, сау-сәламәт кеше тик торганнан гына башын агач астына тыкмас...

Вәсимә (*дулкынланып*). Ни сөйлисең син?! Авызыңнан җил алсын! Кара аны, бу турыда бүтән авыз да ачасы булма!

Фидан (*аптырап*). Туктале, нишләп шулхәтле кызасың син?!

**ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Ишек ачылып китә. Мәүлет, Ясминур керәләр.

Вәсимә (*сискәнеп*). Кода, исәнме!..

Мәүлет. Исәнме.

Ясминур (*чәчрәп*). О, апай, котлыйм! Яңа мебель алгансыз икән! (*Уголокны капшап.)* Миңа да кирәк бит мондый нәрсә!

Фидан (*киная белән*). Синең акчаң җитми аны алырга.

Ясминур. Кредитка бирерсез.

Фидан. Бездә кредит юк, син яхшы беләсең.

Ясминур. Бурычка.

Фидан (*тупас*). Бурычка дип күп алдың инде, әле һаман да кайтарганың юк.

Ясминур (*Мәүлеткә елмаеп*). Кода ярдәменнән ташламас әле.

Мәүлет (*авыр сулап*). Алла теләсә.

Вәсимә. Кода, балалар монда күчеп киләләр. Син каршы түгелдер ич?

Мәүлет. Юк. Мин каршы түгел. Үзләре теләгәч. Тик шуны аңламыйм: безнең ташпулатны ташлап, нигә бу шаламага, гафу итегез, монда килергә кирәк булды?! Урын аз мәллә бездә?

Ясминур. Әйтмә дә. Сездә җәннәт бит инде. Хәтта бәдрәф тә өйдә.

Фидан. Минем монда җаным тыныч, җанга рәхәт. Туган йорт бит.

Мәүлет. Үзгәрдең, кияү, үзгәрдең. Ис ала башладың, башка чыктың.

Ясминур. Сихер кергән аңа, сихер.

Мәүлет. Туктале, шул сихерең белән! Минем әйтәсе сүзем бар...

Төртелеп кала. Фиданга текәлә. Авыр тынлык. Фиданның кәрәзле телефоны шалтырый.

Фидан (*телефонга*). Ало! Әйе... (*Телефонын сүндереп.)* Гафу итегез, мине Кафия чакыра... Әнкәй, кичкә күрешербез! *(Чыгып китә.)*

Вәсимә. Ни сүзең бар, кода?

Мәүлет. Улың Зөһрә янына йөри башлаган.

Вәсимә. Кит аннан! Булмас! Кем әйтте? Кем күргән?

Ясминур. Мин күрдем.

Вәсимә. Кая, ничек, яла якмасана балага!

Ясминур. Беркөннәре...

Мәүлет. Ярар, җитте. Йөз мәртәбә сөйләдең инде син аны миңа. Кияүне зурдан гаеплисе килми. Ул ир кеше, ымсынырга мөмкин. Монда Зөһрә гаепле. Ул аны аздыра. Шуңар күрә минем бер уем бар, кыласы гамәлем... Ул уйнашчы кызны ничек тә калага озатырга кирәк. Ләкин ул болай гына китмәячәк. Мин аңа каладан бер бүлмә алып бирергә уйлыйм. Эзе дә булмасын иде аның монда!

Ясминур (*чәчрәп*). Бүлмә тагын аңа! Болай гына китсен! Нигә шулай зурлыйсыз икән уйнашчы Гайшә кызын?!

Мәүлет *(Ясминурга*). Тынычлан! Тыгылма кирәкмәгән җиргә. Алынган инде ул. Бар ул бүлмә.

Вәсимә. Белмим инде. Анасы бик каты авырый бит. Анасын ташлап китә алыр микән?!

Мәүлет. Анасын үзе белән алып китәр. Йортын сатар. Калада авыруларны шәп дәвалыйлар. Мин кичә аның янына ике кешемне җибәрдем. Аңлаттылар аңа барысын да, яхшы аңлаттылар...

Вәсимә. Аңламаса, әгәр аңларга теләмәсә?

Мәүлет. Яхшылап сөйләшкәнне дә аңламаса, үзенә үпкәләсен инде. Чарасын тиз күрербез. (*Елмаеп.*) Башка юл юк, кызлар, бер генә юл бар, бер генә. Әле мин сезгә тагын бернәрсә сөйлим. (*Утырышалар.*)

Караңгылык.

**ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Болытлы көн. Эңгер-меңгер. Болдыр. Фидан атылып чыга. Туктап, кәрәзле телефонга баскалап ала. Аннан урам ягына атлый. Каршына Зөһрә чыга.

Фидан (*сискәнеп).* Зөһрә? Син?!

Зөһрә. Көтмәдеңме?

Фидан. Юк... Монда юк...

Зөһрә. Синең килгәнеңне көтеп тора алмадым. Минем сүзем бар.

Фидан (*артка борылып*). Сөйләшә торган урын түгел бу. Дошманнар өйдә калды. Ну, ярар, сөйлә, тиз сөйлә!

Зөһрә. Минем янга ике егет килде.

Фидан. Нинди егетләр?

Зөһрә. Мәүлет абый кешеләре.

Фидан. Кемнәр?

Зөһрә. Мин аларны танымадым.

Фидан (*аңлап*). Ә-ә, аңладым. Алар безнең «крыша» булырга мөмкин.

Зөһрә. Авылда да бармыни соң андыйлар, мин аларны шәһәрдә генә бар дип уйлый идем.

Фидан. Алар кайда да бар. Кара таракан кебек. Хәер, аларсыз да булмый. «Крыша»сыз сәүдә эшен алып барып булмый. Ну, ярар, нәрсә дип килделәр соң алар синең янга?

Зөһрә. Мәүлет абый минем авылдан китүемне тели. Теләп кенә калмый, шуны таләп итә. Иң гаҗәбе шул: алар миңа калада бүлмә дә әзерләп куйганнар.

Фидан. Ышанма аңа. Алдый ул.

Зөһрә. Алдаса да, алдамаса да, миңа барыбер. Мин авылдан китмим. Менә адресы, менә бүлмәнең ачкычы! Ал! Тапшыр үзләренә! (*Кәгазь кисәге белән ачкыч суза.*)

Фидан (*алып*). Китмисең, димәк.

Зөһрә. Юк, китмим. (*Фидан кузгала башлый.)* Аннан... мин синнән шуны сорар идем. Хатларымны кире кайтарсаң иде.

Фидан. Нигә?

Зөһрә. Синдә калуын теләмим. Чит кеше кулына эләгүен дә теләмим. Көлә-көлә укуларын да теләмим.

Фидан. Хәзер үк кирәкме?! Хәзер үк бирә алмыйм. Әйттем ич, өйдә Ясминур, әни. Аулак вакытта үзем алып килермен бер.

Зөһрә. Юк. Син башка минем янга килмисең.

Фидан. Нигә?

Зөһрә. Хатының бар, гаиләң. Сүз чыгуын теләмим. Килмә, йөрмә!

Фидан. Бу ни дигән сүз? Синнән башка тора алмыйм мин. Зөһрә, ялгыштым, ишетәсеңме, ялгыштым Кафиягә өйләнеп. Син дә, ичмасам, йөрәгемә тоз салып торасың.

Зөһрә. Нигә кирәк мин сиңа? Син бит болай да бәхетле, Фидан.

Фидан. Юк, мин бәхетсез, Зөһрә!

Зөһрә. Нишләп инде?! Әгәр син миңа өйләнгән булсаң, бу тиклем күтәрелә дә алмаган булыр идең. Байлыгың да, яхшы эшең дә, яхшы машинаң да булмаган булыр иде. Йөрер идең тузанга, мазутка батып. Көн дә ватылган тракторыңнан туеп, ямьсезләнә барган хатыныңны сүгеп. Аннан мине күралмас хәлгә җитәр идең. Син миңа өйләнмәвең белән бәхетле, Фидан.

Фидан. Юк. Зөһрә, нишләптер мин трактор йөрткән, сине күрергә ашкынып йөргән көннәремне үлеп сагынам. Кайтыр идем әле. Кер сабыны белән кара майга каткан кулларымны юар идем, ә син токмачлы ашларыңны пешереп, балаларны юындырып табынга утыртыр идең. Менә кая ул бәхет! Яраткан кешең белән булу ул бәхет. Зөһрә, әллә нәрсә булды миңа, үзем дә аңламыйм...

Зөһрә. Күз тиде сиңа, Фидан, күз, каен күзе...

Фидан. Күз тиде?!

Зөһрә. Борчылма, узар.

Фидан. Узарга охшамый. Ходай безгә бала да бирмәде. Хөрмәт итәм Кафияне, ләкин ярата алмыйм! Көт аз гына, Зөһрә, без барыбер бергә булачак, көт... Вакыт җитәр...

**ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Ишек яртылаш ачыла. Ишектә Ясминур күренә. Яшьләрне күреп алгач, атылып ук чыга.

Ясминур (*чәрелдәп*). Нәрсә, инде монда ук килеп җиттеңмени? Авыл башы гына җитмәгәнмени очрашырга?! Кешенең өенә килеп тормышын бозарга уйладыңмы?!

Мәүлет (*чыгып).* Ни булды? Нәрсә кычкырасың?! (*Зөһрәне күреп.* ) Ә... менә нәрсә икән!

Ясминур *(Мәүлеткә*). Менә, миңа ышанмаган идең! Инде хәзер үз күзең белән күрдең!

Фидан. Тәти апа, тынычлан әле. Бу базар түгел!

Ясминур. Юк, мин алай тиз генә тынычлана торганнардан түгел. Мине тынычландырыр өчен чәчең белән җир себерергә кирәк, җаным!

**БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Кинәт кенә Кафия керә. Ул йөгергән. Сулышы капкан.

Кафия *(усал*). Фидан, сине күпме көтәргә була?! Товар кайтты... (*Зөһрәне танып.*) Бу нәрсә тагын?! Кем бу?

Фидан. Танымыйсың мәллә?

Кафия. Таныганга әйтәм. Нишләп йөри монда бу өстерәлчек?!

Ясминур (*көлеп*). Кунакка чакырган.

Кафия *(Зөһрәгә*). Һаман да Фиданны оныта алмыйсыңмы?! Уйнашчы...

Зөһрә (*катгый*). Мине мыскыл итмәвегезне сорар идем.

Кафия. Алла! Тәртипле бала! Мин сине чакырмадым, үзең өстерәлеп килгәнсең бит.

Ясминур (*Зөһрәгә*). Кит моннан яхшы чакта! Бар, кеше тормышын бозып йөрмә! Анаң түшәктә ята, кайтып анаңны кара. Бар, бар, ничу! (*Зөһрәне этә-төртә башлый.*)

Фидан (*Ясминурның кулын борып*). Кит моннан!

Ясминур (*йөзен чытып*). Ай, ай, кулымны сындырдың! *(Читкә тайпыла.)*

Фидан. Син аждаһага пычагым да булмый. Тыңлагыз әле... Зөһрә мине генә түгел, ә барыбызны да күрергә дип килгән. Ул менә шушы ачкычларны алып килгән, шуларны хуҗасына тапшырырга дип... (*Ачкычларны чыгарып күрсәтә.*)

Кафия. Кем ачкычлары болар? *(Пауза.)* Ник дәшмисез?

Фидан (*Мәүлеткә текәлеп*). Белмәгән булып кыланма, яме!

Мәүлет (*хәйләләп*). Ә нинди ачкычлар соң ул? (*Иңнәрен җыерып.*) Мин берни дә белмим.

Зөһрә (*шаккатып*). Сез... белмисез... Аларны миңа сезнең кешеләр китерде.

Мәүлет. Кемнәр соң алар? Мин беркемне дә белмим.

Зөһрә. Алар миңа: «Мәүлет абыең сиңа бүлмә бүләк итте, ике көн эчендә җыен да калага тай», — диделәр.

Фидан (*Мәүлеткә*). Дөресме бу?

Мәүлет. Сез миңа ышанасызмы, әллә шушы акылсыз уйнашчы кызыйгамы?! Мин китим әле. Мине көтәләр. (*Кузгала.*)

Зөһрә. Фидан, күрсәт адрес кәгазен. Ул кәгазь Мәүлет абый кулы белән язылган. (*Фидан икеләнеп тора.*) Күрсәт... (*Барысы да Фиданга текәләләр.*) Фидан...

Фидан (*башын аска иеп*). Юк миндә андый кәгазь.

Зөһрә (*өзгәләнеп*). Фидан, син кемнәргә ышанасың? (*Фидан, кыенсынып, туктап кала.)* Кемнәргә?!

Мәүлет (*Фиданга*). Ә товарны кем кабул итә?!

Зөһрә. Фидан, бир хатларымны. Кире кайтар...

Фидан (*Ясминурга*). Тәти апа, сервантта Зөһрәнең мин армиядә чакта язган хатлары ята. Бир шуларны!

Ясминур (*кабынып*). Хәзер, энекәш! (*Өйгә атыла.*)

Фидан (*сиздермичә генә Мәүлетнең кесәсенә ачкычларны салып*). Киттек, әти, безне эш көтә!

Мәүлет (*Кафиягә*). Ә син барып торма. Без кияү белән икәү товарны кабул итәрбез. Шулай бит?!

Фиданны җилкәсеннән сөя. Өйдән Ясминур атылып чыга. Аның кулында хатлар.

Ясминур. Мә, менә, чукынып кит шул хатларың белән! (*Хатларны җиргә сибә, һавага очыра.*)

Зөһрә (*җыйнап*). Тимәгез миңа. Минем сезгә бернинди дә начарлык ясаганым булмады. Минем авылда каласым килә. Тимәгез миңа! Минем әнием бар. (*Елый.*) Ул авырый. Ул беркая да китмәячәк! Әнием... Бердәнберем, якын кешем!..

Фидан (*тынычландырырга теләп, ялгышын аңлап*). Зөһрә...

Зөһрә (*ярсып*). Тимәгез миңа! Минем авылдан китәсем килми! Ходай өчен тимәгез миңа, тимәгез!.. (*Хатларны җыя. Саташа. Берсен ала, берсен ташлый.)* Ходаем, ни гаебем бар минем сезнең алда?!

Каты итеп яшен яшьни. Зөһрә тезләнә. Күккә карап ялвара. Барысы да, әсәрләнеп, күккә төбәлә. Яшен яшьни. Күк күкри. Мәхшәр.

**АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ**

Вәсимәләр өе. Фидан өстәл янында исәпләп, санап утыра. Вәсимә бияләй бәйли. Бер улына, бер бәйләмгә карый.

Фидан (*кәгазьләрен кырыйга ташлап*). Юк, әнкәй, теләсәң ни әйт, минем эш түгел бу сәүдә эше. Дебет, кредит, табыш, навар... ух!

Вәсимә. Зато акчасы бар.

Фидан. Белмим... Мин нигәдер чәчү чәчкән, сука сукалаган егетләрдән көнләшәм хәзер.

Вәсимә. Нишлисең... Замана башка, улым, замана. Кешеләр бик нык үзгәрделәр. Элеккеге ихласлык, киң күңеллелек каядыр юкка чыкты. Хис түгел, акыл өстенлек итә хәзер. Төкерәләр хәзер җаныңа! Адәмнәр малга, акчага табына. Өч сумга атасын, анасын сатып җибәрергә дә әзерләр. Артык хисләләр, олы җанлылар йә сыналар, йә эчәргә сабышалар. Көчлеләр, акыллы башлар мал җыялар, байлык туплыйлар...

Фидан. Бушлык... Яман бушлык... Эч поша... аннан... Нидән бу?!

Вәсимә. Эчең бик пошса, бар, ишегалдына чыгып, утын ватып кер! Мунча ягарга утын калмады.

Фидан. Утынны без җитәрлек ваттык инде, әнкәй. Ие... Күңелгә ятмаган эш, яратмаган хатын...

Вәсимә. Аерыл... нитсә...

Фидан. Хе! Җиңел генә... Көчләп өйләндердегез дә... Аерыл, имеш... Их, әнкәй, мин күптән аерылган бит инде... Өйләнгәндә үк... Күңелем белән...

Вәсимә. Зөһрәң...

Фидан. Әнкәй... кирәкми. Искә төшермә... Мин болай да аның алдында гаепле... нык гаепле...

**ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Ишек ачылып китә, Хәмит пәйда була. Кыйналган, таушалган — таякка таянып йөри. Вәсимә, Хәмитне күреп, сискәнеп китә. Фидан
урынында кала.

Хәмит (*карлыккан тавыш белән*). Исән... месез...

Фидан (*әйтерсең ул аның киләсен көткән, аңа таба борылмый да*). Исән әлегә... *(Пауза.)* Киләсеңне белдем. Сөйләделәр синең турыда... Ни кирәк?

Хәмит дәшми. Вәсимәгә карап тора.

Әнкәй, чыгып тор әле. Калдыр икебезне. Бер-ике матур сүз әйтим әле мин бу чибәр егеткә!

Вәсимә. Ярар. Тик тәртипле генә, улым, яме. (*Икенче бүлмәгә кереп китә*.)

Хәмит. Барысын да беләсең, димәк?!

Фидан. Беләм. Калада бик әйбәтләп кыйнаганнар икән үзеңне.

Хәмит. Сөенәсеңдер инде?!

Фидан. Юк, сөенмим. Кайчан гына уйнак егет идең, инде хәзер... Карарлыгыңны да калдырмаганнар. Гарип, чын гарип. Урамда бер күреп калдым үзеңне. Шул кирәк сиңа дип эчтән генә сөенгән идем. Ә хәзер сөенмим. Аллага шөкер, Ходайның җәзасын алдың. Тагын нәрсә әйтим сиңа?! Башка сүзем юк.

Хәмит. Минем сүзем бар. (*Бусагадан узмакчы була*.)

Фидан. Бусагадан узасы булма! (*Хәмит туктап кала*.) Сөйлә, тиз сөйлә!

Хәмит. Мин гаепле синең алда, Фидан. Шул гаебем миңа тынгылык бирми.

Фидан. Ялгышасың. Синең гаебең юк. Узган эшкә салават, брат, узган-беткән. Мин бу турыда сөйләшеп, әллә кайчангы күңелсез хатирәләрне искә төшереп утырасым килми. Хуш!

Хәмит. Фидан...

Фидан (*катгый*). Хуш, дидем мин сиңа!

Хәмит. Шайтан котыртты мине, шайтан... Мин бит Зөһрәгә юкка яла яктым. Үз теләгем белән түгел, билгеле...

Фидан. Кем?

Хәмит. Мәүлет абый котыртты мине. Кыскасы, мин укырга теләдем. Армиягә китәсем килмәде. Ә хәзер акчасыз бер генә вузга да керәм димә. Ул мине укырга кертергә, миңа акча бирергә, мине армиядән калдырырга вәгъдә итте... *(Пауза.)* Нәрсә өчен дисеңме? Зөһрәгә яла яксам әгәр. Яла яктым. Алдаштым. Менә хәзер ипи тотып, алдыңа тезләнеп ант итәм: орынмадым Зөһрәгә, йөрмәдем мин аның белән. Ул сине яратты, сине көтте...

Фидан. Ә фото?

Хәмит. Нинди фото?

Фидан. Бергә кочаклашып төшкән фото. Ул бит бөтен авыл егетендә бар иде. Барысыннан да җыеп чыктым. Җәмгысе унбишкә җыелды.

Хәмит. Ул бит монтаж, фотомонтаж. Аны теләсә нинди фотосалонда ясатырга була. Мәүлет абый ясатты аларны. Зөһрәнең пляжда коенган ярым шәрә фотосын мин табып бирдем. Ул күрмәгәндә кызның альбомыннан урладым...

Фидан (*башын чайкап*). Уйнак егет син, әй, уйнак!

Хәмит. Уйнак... Уйнак булсам, синең каршыңда култык таягы белән басып тормас идем. Җүләр булдым, дивана! Кемгә ышандым?! Акча да бирмәде, укырга да кертмәде. Сорадым, янына бардым. Кабат вәгъдә итте. Көт, диде. Көттем. Син өйләнгәч, кабат бардым. Кире борды. Янадым. Ачу чыкты. Бер атна да үтмәде, Казанның караңгы бер почмагында каты итеп изделәр. Аңа хәтле үк сизендем. Арттан күзәтеп йөрделәр. Шуның алдыннан гына көне буе күз тартты.

Фидан. Кемнәр?

Хәмит (*пышылдап*). Минем уйлавымча, Мәүлет абый кешеләре. Шулчак мәҗлестән кайтучы кешеләр килеп чыкмаган булса, мине үтерәләр иде бит алар, билләһи, үтерәләр иде...

Фидан. Үлсәң, җиңелрәк булган булыр иде сиңа.

Хәмит. Бәлкем... Ә Зөһрә белән без дуслар идек, фәкать дуслар. Ясминур апай гына чыгарды ул гайбәтне. Ышанасыңмы?

Фидан (*торып*). Син инде мине икенче мәртәбә ышандырырга җыенасың. Башта начар, ә хәзер уңай якка. Син инде икенче мәртәбә минем язмышым белән уйныйсың. Кем син?! Акчага сатылып, яшьлек мәхәббәтемнән көлгән иблис койрыгы... Кем син?! Нишләп син һаман минем янда? Ни кирәк сиңа?!

Хәмитне якасыннан алып селки. Суга. Хәмит ава.

Вәсимә (*йөгереп керә*). Фидан! Зинһар! Суга күрмә!

Хәмит авырлык белән торып баса. Фидан аңа кабат кул күтәрә, тотып алып селки.

Фидан. Ник кайттың?! Кит! Үтерәм! (*Кул күтәрә.)*

Вәсимә. Кирәкми! Утыртырлар!

Фидан *(ярсып*). Ү-ү-терәм!

Вәсимә *(арага кереп)*. Кирәкми! Ул болай да гарип... Бала бит әле ул...

Пауза.

Хәмит (*елап*). Зур гөнаһ кылдым, зур җинаять. Сезгә ачылып, мин бушандым. Миңа җиңел хәзер, күпкә җиңел. Кичерегез мине, кичер мине, Фидан!

Фидан читкә борыла.

Вәсимә *(Хәмиткә*). Сиңа безнең янга түгел, Зөһрә янына барырга кирәк иде, улым. Ул кичерсә, без дә кичерербез.

Хәмит. Син хаклы, Вәсимә апа, хаклы. (*Чыгып китә*.)

Вәсимә. Алданган бу бала. Аңардан үч алудан файда юк. Явызлык ятьмәсе тирәндә ята, улым, тирәнгә яшеренгән. Кодада хикмәт. Мин сиңа бер сер ачасым килә. Тик син аны беркемгә дә сөйләргә тиеш түгел!

Фидан. Юк, әнкәй, сөйләмәм.

Вәсимә. Атаң үлгәннән соң, миңа бер кешедән хат килде. Ул кеше атаң белән бергә урман кискән булган. Ул атаңның үлемендә Мәүлетне гаепли. Аның аркасында калган атаң агач астында. Мәүлет агачны каршы яктан аударган. Атаң моны сизмәгән, агач кискән...

Фидан. Кая ул хат?

Вәсимә. Яндырдым. Сез өйләнешкәч үк. Озак сакладым мин аны. Берәрегезнең кулына килеп керер дип курыктым. Аннан... мин ул хатка бик үк ышанып та бетмәдем. Ничек итеп Мәүлет иң якын дустын үтерә алган? Ни өчен?

Фидан. Мин ышанам. Элегрәк, бәлкем, ышанмаган да булыр идем. Ә хәзер аның кем икәнен, нинди явыз кеше икәнлеген аңлагач, икеләтә ышанам. Бер генә нәрсәне аңламыйм: ни өчен үтергән ул әтине?

Вәсимә. Бәлкем, акча өчендер... Акча өчен чукынып китә торган адәм бит ул Мәүлет.

Фидан. Кая да шул акча!

Вәсимә. Алар Марида ярты ел эшләгәннәр иде инде. Заһит, вафат булыр алдыннан, зур акчалар алган. Совет акчасы белән шактый күп ул. Ул акчалар эзсез югалдылар. Мин атаңның эшләгән җиренә хәтле бардым. Акчаны эзләделәр, тик табалмадылар. Бәлкем, ул кода кесәсенә кергәндер, ә?!

Фидан. Кулыннан тотмагач, әйтүе кыен...

Вәсимә. Шуннан кайткач, Мәүлет каладан йорт сатып алды. Ул йорт тузган торакка әләкте. Өч бүлмәле фатир алды. Аны сатып, авылда кибетләр салдырды.

Фидан. Аның хәзер калада ике фатиры бар. Ләкин аңардан миңа җиңел түгел. Миңа аның кешене күз яше белән елатып тапкан малы да, байлыгы да кирәк түгел. Аның күзенә туп-туры карап әйтер вакыт җитте. Һәм мин аны әйтәчәк тә!

Вәсимә. Белмим, инде, улым... Кирәк микән? Бик астыртын, явыз кеше бит ул...

Фидан (*уйланып*). Йә, ничек яшәргә соң инде миңа? Кемгә ышанырга? (*Киная белән.*) «Атаң минем кулда җан бирде», имеш... Тфү! Күзен төртеп тишәсе... Бер генә юл, бер генә юл кала миңа. Зөһрәм янына барып, алдына тезләнеп, гафу итүен сорарга. Бәлкем, кичерер. Бәлкем, бергә кушыла алырбыз.

Вәсимә. Соң булмасын, улым...

Фидан (*сискәнеп*). Нишләп алай дисең, әнкәй?

Вәсимә. Анасы үлгәннән бирле бик нык үзгәрде Зөһрә. Саташа. Йортында янгын чыккач, бөтенләй бетereште, бичара! Йорты яртылаш янды, хәзер чоланда гына яши...

Фидан. Яндырдылар ул йортны. Авылдан китмәгән өчен.

Вәсимә. Акылы зәгыйфьләнгән баланың. Төннәр буе урамда йөри. Эзләп йөри... Нидер...

Фидан. Нәрсә эзли?

Вәсимә. Үлем.

Фидан (*шомланып*). Үлем?!

Караңгылык.

**СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Караңгы көз. Җиргә яфраклар коелган. Шомлы төн. Каенлык. Бу урын кечкенә генә паркка әйләнгән. Уртада — эскәмия. Агачлар шәрә. Тынлык. Ак киемдә (берникадәр туй күлмәген хәтерләтә) Зөһрә пәйда була. Ул әкрен генә биеп керә. Әйләнә. Җирдәге яфракларны
күтәреп һавага чөя...

Зөһрә (*җырлап*).

Киттең өзгәләп үзәкне,
Утка салып йөрәкне.
Нигә, Ходай, алдың миннән
Син бердәнбер теләкне?!
Сагышлансам, киләм, бәгърем,
Каеныбыз янына.
Без икебез — ике ялгыз —
Яшьлегебез таңында.

Кушымта:

Әллә Ходай ялгыш кына
Ялгышты микән үзе,
Әллә тиде микән безгә
Ялгыз каенның күзе...*

Музыка тына.
Зөһрә эскәмиягә утыра.

(*Зөһрә үз-үзе белән сөйләшеп).* Гомер җырын, сөю җырын бергә җырларбыз дип хыялланган идек синең белән, Фидан. Ни кызганыч, җырлый алмадык. Юк, юк, әле бит соң түгел! Үзең шулай дидең түгелме соң?.. (*Тыңланып.*) Килдеңме, Фидан. Күрәсең килеп килдеңме? Утыр яныма. Кулыңны бир!.. (*Кулын суза*.)

Эскәмиянең сул ягында Кара күләгә (Үлем) пәйда була. Сәхнәдә караңгылык һәм яктылык контрасты (яртылаш) туа. Зөһрә, куырылып,
кулын читкә ала.

(*Коты очып*.) Кем син?

Үлем. Үлем.

Зөһрә. Сәер исем.

Үлем. Исем түгел, чынбарлык.

Зөһрә (*кабатлап*). Исем түгел, чынбарлык. Нигә килдең, Үлем?!

Үлем. Сине алырга килдем. Хушлаш якты дөньяң белән.

Зөһрә. Ни өчен? Ни гаебем бар синең алда?

Үлем. Үлем алдында беркемнең дә гаебе юк. Үлем — үтерүче. Өстән килде хәбәр.

Зөһрә *(ялварып*). Алма мине, Үлем, калдыр... Мин бит әле яшь, бик тә яшь. Минем әле яшисем, бик тә яшисем килә. Сөясем, сөеләсем килә! Калдыр...

Үлем. Мин ике сөйләмим. Әзерлән.

Зөһрә *(көйләп*). Мин китәрмен, Үлем, ашыктырма, кума мине, кума дөньядан, үз-үземә үлем юрасам да, мин тормыштан әле туймаган. Мин туймаган тормыш газабыннан һәм чыкмаган яшәү уеннан, кем юксыныр, әгәр таң алдыннан мин югалсам яшьлек туеннан. Кума мине, кума...

Үлем. Син мине хисләндерә алмыйсың. Минем өчен хис юк, җан юк. Минем өчен үлем генә бар.

Зөһрә. Үлемкәем, сабыр ит инде аз гына. Егетемне көтәм. Килер, килми калмас. Кочар ул мине, назлар. Бир вакыт, бир аз гына...

Үлем. Кем килергә тиеш?

Зөһрә. Егетем! Яраткан егетем. Без аның белән һәр көн күрешәбез. Коча, иркәли ул мине. Ярата. Менә, күрәсеңме, битемдә, йөземдә, күкрәгемдә нинди эзләр калды... Алар утлы мәк сыман балкып янып торалар...

Үлем (*елмаеп*). Әйтерсең лә кояш белән үбешкәнсең! *(Зөһрә, кызарып, башын аска ия. Үлем сабырсызлана.)* Тик бер син генә булсаң икән?! Мин меңнәрне үтерергә тиеш! Мин вакытка тугры хезмәт итәм. Эш муеннан, ә мин карт. Минем өчен һәрбер минут кадерле. Җыен әйдә, кызыкай, вакыт җитте! *(Кузгала.)*

Зөһрә (*тезләнеп*). Сөюем хакына, калдыр мине...

Үлем. Яхшы. Төн — синеке, ә таң алдыннан мин сине үтерәм! (*Кузгала.)* Ризамы шуңа?!

Зөһрә. Риза. Тик сөеклемә тимә, сөюне үтермә...

Кара күләгә югала. Арткы планга күчә. Ул Зөһрәне көтә.

(*Сул якка атылып*). Фидан! (*Уң якка атылып*.) Фидан... (*Тыңлана.*) Юк, син юк! Фидан, мин чакырам сине, ә син юк! Әйтерсең лә төнге урманда ике сагыш йөри, ике ут... *(Пауза.)* Сөю һәм Үлем. Алар игезәкләр кебек. Гел янәшә йөриләр. Кая Сөю, шунда — Үлем. Кая Үлем, шунда... *(Пауза.)* Гомер җырын, сөю җырын сиңа җырларга насыйп булгандыр, күрәсең. Хуш, Фидан! Хуш, җаным! (*Каен ягына атлый. Каенны кочаклый. Ак яулыгы каенга асылынып кала. Аны Кара күләгә каплый*.)

**ТУГЫЗЫНЧЫ КҮРЕНЕШ**

Фидан күренә. Карана. Ялгыз каенга күз ташлый. Ак яулыкны күреп өнсез кала. Йөрәген тота.

Фидан. Зөһрә... (*Кычкырып*.) Зөһрә! (*Зөһрәнең үле гәүдәсен күтәреп чыга*.) Ни булды соң сиңа, бәгърем, нишләдең син?.. (*Зөһрәне күкрәгенә кыса*.) Зөһрәм, кичер мине, кичер! *(Җырлап.)*

Ак Каенга бер ялгыз кош
Кунып сайрый моң-зарын.
Ул да югалтты микәнни
Минем кебек үз парын?
Кем уйлаган шулай безне
Язмыш аерыр диеп.
Каршыма чыгарсың төсле
Ак күлмәгеңне киеп...

Кушымта:

Әллә Ходай ялгыш кына
Ялгышты микән үзе,
Әллә тиде микән безгә
Ялгыз каенның күзе...

Караңгылык.

**УНЫНЧЫ КҮРЕНЕШ**

Шунда ук. Мәүлет, Ясминур, Кафия, Вәсимә пәйда булалар.

Ясминур. Харап булды кызый, харап булды... Ходайның каргышы төшә, диләр бит... Үзе дә, анасы да харап булды... Кызыкты шул бала кеше малына, кеше иренә кызыкты...

Кафия. Каеннан Фидан өстерәп төшергән. Башка кеше табылмаган, күрәсең...

Вәсимә (*чын тавыш белән*). Таш бәгырьле булмыйк, балалар... Зөһрәне бөтен авыл халкы күмде, соңгы юлга озатканда бөтен авыл елады. Инсафлы, саф күңелле иде шул, бичара...

Ясминур. Җүнле кеше асылынмый ул, апа. Мордар киткәннәрнең рухын Ходай кабул итми, диләр.

Кафия. Аларның җаннары күккә ашалмыйча, түбәндә очып йөри икән...

Вәсимә. Сездән дә түбән түгелдер инде...

Кафия (*усал*). Кая минем ирем?

Ясминур. Кая минем энем?

Вәсимә. Сәфәрдә... Кая киткәнен белмим, әйтмәскә кушты! Эзләмәскә... Ул монда яши алмас. Читен аңа. Монда аңа бар да Зөһрәне хәтерләтә...

Мәүлет (*алга чыгып*). Ничек болай килеп чыкты соң бу?! Барысын да исәпләп-санап, алдын-артын карап эш иткән идем ләбаса?! Аңламыйм, һич кенә дә аңламыйм... Ничек болай килеп чыкты соң бу?!

Вәсимә. Син барысын да дөрес исәпләгәнсең, кода. Тик бер генә нәрсәне оныткансың: җирдә чын сөю, чын мәхәббәт барын... (*Күккә текәлә.*)

«Ялгыз каен» көе агыла. Ул симфониягә әверелә.

Пәрдә.

## «КЫЗЫМА КИЛЕР ЙӨЗ КЕШЕ»

*Ике пәрдәле комедия*

**КАТНАШАЛАР:**

Тархун.
Җәүһәрия — аның хатыны.
Гөлназ — аларның кызлары, 17 яшьтә.
Наҗия
Җария } Җәүһәриянең сеңелкәшләре.
Лемонтий.
Сәрвиназ — шәфкать туташы.

Вакыйга провинциаль шәһәрдә бара.

### БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

«Хрущевка» тибындагы ике бүлмәле фатир. Фатирның зал ягы. Пәрдә ачылганда, Тархун, җиңсәләрен сызганып, счет төймәсе салып утыра. Җәүһәрия, борчылып, сәгатькә карап ала. Кул эшен ташлап, кызының диварда эленгән рәсеме каршына килә.

Җәүһәрия. И бала, бала! Әле кайчан гына, елата-елата, үзеңне балалар бакчасына йөртә идем! Инде менә дәү үстең, дәү кыз булып җиттең! *(Усал карап.)* Аздың! Вакытында өйгә дә кайтмый башладың! *(Пауза.)* Карале, атасы!

Тархун. Ни бар, анасы?

Җәүһәрия. Гөлназны әйтәм, бик тә үзгәрде соңгы вакытта, гел уйланып, моңсуланып йөри.

Тархун *(счет төймәсен салып).* Бала тез өстендә сөйдерә, тездән төшкәч көйдерә, дип белмичә әйтмәгәннәрдер инде борынгылар.

Җәүһәрия. Дөрес булса, аның янына ниндидер бер егет тә килеп йөри, диләр. Кемдер инде ул, әлегә күргән юк!

Тархун. Ә?! Бер-бер хәл була күрмәсен, анасы, бер-бер хәл.

Җәүһәрия. Бер карап торган кызыбыз бар инде!

Тархун. Бер янында ике дә була ул... тәк... *(Саный.)* Дебет... кредит... тәк... суммасы...

Җәүһәрия *(эче пошып).* Әй! Һаман акча санайсың да акча санайсың! Тик өйдә акча гына юк.

Тархун. Хәзерге акчаны, җанкисәгем, санасаң гына инде, санап юансаң гына. Бухгалтер бит мин. Менә пенсиягә чыккач та эшләп йөрергә мәҗбүрмен.

Җәүһәрия. Ә кызны мин үстердем, мин, үземнең хезмәт хакыма. Шуңар күрә дә якын ул миңа. Комсомол взносына хәтле үзем түләп бардым бәгырькәччәемнең! Элегрәк бөтен әйткән сүземне тыңлый, үти торган иде. Ә хәзер мин алып биргән киемне дә кими. Ала белмим, имеш! Ярар, ире киендерер!

Тархун *(хыялланып).* Үсте кызыбыз, үсте. Без генә картайдык. Хәтерлисеңме икән... Гөлназны йоклатканда һаман да җырлый торган идең... Ничек әле аның көе? «Кызым, кызым...»

Җәүһәрия. Әйе, әйе, искә төште.

Тархун

Җәүһәрия } *(икесе бергә җырлыйлар).*

Кызым, кызым, кыз кеше,
Кызыма килгән йөз кеше.
Йөз кешенең арасыннан
Сайлап алыр үз ишен.

Кызым, кызым, кыз кеше,
Кызыма килер йөз кеше.
Йөз кешедән иң булганын
Сайлап алыр кыз кеше.

Кызым, кызым, кыз кеше,
Минем татлы җимешем.
Килер-китер йөз кешедән
Кызым табар үз ишен...

Кызым, кызым, кыз кеше,
Кызыма килер йөз кеше...

Җәүһәрия. Килә башларлар инде, килә башларлар! *(Пауза.)* Күңелем бер дә тыныч түгел, нигә алай микән?

Тархун. Алар килерләр... Тик хәзер туйлар үткәрү, ай-һай, читен нәрсә бит, әй! Бер-бер хәл...

Җәүһәрия. Әй, туктасана ла! *(Үчекләп.)* Бер-бер хәл дә, бер... Шулай сөйләнеп йөрсәң, җаелеп утырсаң, бер-бер хәлнең булып куюы да бар. *(Сәгатькә карап.)* Унике тулды. Кая йөри бу кыз, ә?! Киногa китте мәллә?

Тархун. Бәлкем. Бүген «Эмануэль» була дип ишеттем. Вәт, анасы, яхшы кино, ди, ул! Анда анадан тума йөриләр, ди...

Җәүһәрия. И-и! Шул кинодагы шәрә кызларга карап кына күңелең юатсаң инде, буш куык! Сөйләп торган буласың бит әле, өеңдәге хатыныңа да игътибар бирмисең!

Тархун. Их, хатын! Минем белән күпме яшәп тә, иреңне өйрәнеп бетермәгән икәнсең әле. Сәбәп кенә булсын, анысы булса, йоклаган хатынны да уятырлык көч бар әле миндә!

Җәүһәрия. Ирләрнең шул картайгач куәте телгә күчә, диләр, дөрес икән!

Ишектә кыңгырау тавышы.

Кайтты! *(Ишек ача.)* Ә! Күрше икән! Кызым кайтты дип торам.

Лемонтий керә.

Лемонтий. Хәерле төн! Тартырыма беткән. Юктыр бит сездә?

Җәүһәрия. Абзаңның тартмаганын беләсең бит инде!

Лемонтий. Хатын тагын чит илгә чыгып китте бит әле. Объединенный Арабский Эмиратка. Бөтен спекулянт шунда бара хәзер, товарга...

Җәүһәрия. Байыйсыгыз бар икән.

Лемонтий *(кул селтәп).* Әй, миңа җиткән лә ул, хатынга җитми байлык.

Тархун. Байлык кемгә дә җитми инде ул. *(Санаудан туктап.)* Кем анда? Ә! Лемонтий! Лемон... Исемеңне ялгышрак әйтеп ташладым бугай, гафу ит...

Лемонтий. Зыян юк. Мин инде хәзер үземнең чын исемемне дә оныта башладым. Лемонтий дип сүз кайтарып сөйләшә башлагач, тактылар да куйдылар бит шул исемне. Лемонтий дип...

Тархун. Лемонтий! Лемонтий! Яңгырый! Нәкъ рекламадагы күк... Ле-мон-тий!

Лемонтий *(кайтарып)*. А-О-у! М-М-М!

Тархун *(көлеп)*. Шул МММнар тирәсендә йөрсәң генә инде син, башкага ярамыйсың! Акча да күбрәк сугар идең...

Пауза.

Лемонтий. Тартырыңа юкмы дип кергән идем... Өч ай хезмәт хакы алган юк. Завод ябылырга тора. Халявщиклар күбәйде! Һаман шул реклама да реклама, ә эшләүче юк!

Тархун. Мин тартмыйм. Әмма җыеп куйган тәмәкем бар. Совет заманыннан калган. Талонга биргәннәр иде. Каяле? Тик бәясен белмим, хәзерге чын бәясен?!

Җәүһәрия. Тикшереп торма инде, булса, тот та бир!

Тархун эзләнә.

Лемонтий *(Җәүһәриягә).* Гөлназыңны көтәсеңме?

Җәүһәрия. Әйе. Соңлады...

Лемонтий *(елмаеп).* Ә беләсеңме?! *(Колагына пышылдый.)* Вәт тәк то!

Җәүһәрия катып кала.

Тархун *(тәмәкене табып).* Ул вакытта унбиш тиен булган. Хәзерге акча белән ничә сум була инде, яле, исәпләп карыйк әле!

Счет төймәсе янына килә.

Җәүһәрия *(Тархунның кулыннан тартып алып).* Мә, ал! *(Лемонтийга бирә.)* Бу саранннан гомердә дә бушлай әйбер ала алмассың!

Лемонтий. Рәхмәт. *(Ала.)* Миннән ярдәм кирәк булса, мин әзер һәрчак! *(Чыгып китә.)*

Тархун. Юкка. Бизнес эшләп алган булыр идек. Аңла, без хәзер социализмнан капитализмга күчү чорында яшибез. Шуңар күрә һәр тиен санаулы булырга тиеш. Югыйсә үзең беләсең, банкрот!

Җәүһәрия. Без күптәннән банкрот инде. Кырык меңгә якын акчабыз сберкнижкада ятып калды. Янды. Ашамадык, эчмәдек. Ул вакытны кырык меңгә өч «Волга» машинасы алырга була иде. Хәзер аңа нәрсә аласың?! Бер каз түшкәсе тисә тия инде аңарга!

Тархун. Борчылма. Тиздән гаражны сатабыз, шул саткан акчаны банкка салабыз. Процентка утырырбыз, дивиденд алырбыз. Чит илдә акыллы башлар барысы да дивидендка яшиләр...

Пауза.

Җәүһәрия *(дулкынланып).* Кая йөри бу, ә?! Туктале, иптәш кызына шылтыратып алыйм әле. Лемонтий да күңелгә шом салып китте...

Ишектә кыңгырау тавышы.

Йа Хода!!! *(Ишекне ача.)*

Гөлназ керә.

*(Кычкырып.)* Кая йөрисең син, ә?!

Гөлназ. Әни, акрын, күршеләр ишетмәсен!

Җәүһәрия. Күршеләрдә ни эшем бар минем? Кайда йөрдең?

Гөлназ. Кинога бардым.

Җәүһәрия. Ялганлама. Егетең белән ме?

Гөлназ. Әни, син барысын да беләсең, белгәчтен нигә соң сорыйсың?

Җәүһәрия. Кызым, сиңа ни булды, ә? Син нишләп шундый күңелсез?

Тархун нидер яза башлый.

Кичә сиңа нинди егет ияргән иде?

Гөлназ *(кәефсез).* У-у! Җиткергәннәр дә!

Җәүһәрия. Җиткермичә! Бу бит сиңа Мәскәү түгел, кечкенә шәһәр. Монда берни дә яшерә алмыйсың, кызым. Әйт, кем ул?

Гөлназ. Алыпсатар. Мәскәүдән килгән. Монда бизнес эше белән шөгыльләнә.

Җәүһәрия. Бу яңа күлмәгеңне дә ул алып бирдеме?

Гөлназ. Ул, әни, ул. Тынычлан. Тынычландыңмы инде?

Җәүһәрия. Нишләп син безне аның белән таныштырмыйсың?

Гөлназ. Без аның белән яңа гына хушлаштык. Машинасына утырып, ул бүген Мәскәүгә китеп барды.

Җәүһәрия. Үпкәләшмәгәнсездер ич? Кайтамы соң тагын?

Гөлназ. Белмим. Хәбәр бирергә тиеш.
Җәүһәрия. Ә хәбәр бирмәсә?
Гөлназ. Бирмичә кая китәр?!
Җәүһәрия. Егетләргә күбрәк ышан. Адресын алдыңмы? Әти-әнисе кемнәр?
Гөлназ. Сезнең кебекләр.
Җәүһәрия. Безнең кебек кенәмени?! Бездән дә яхшырак гаилә белән кушылырга тырыш инде син, кызым, шуны исеңнән чыгарма.
Гөлназ. Мин әлегә берни дә әйталмыйм.
Җәүһәрия. Ярар, ярар, үпкәләшә генә күрмәгез инде, яме! *(Җырлый.)*

Бигрәк күркәм икән егетең,
Ашыгып көтәм күрешү сәгатен.
Мәскәүләрдә дисең фатиры,
Булсаң иде шуның хатыны!

Үпкәләшә инде күрмәгез,
Терәлмәсен комга көймәгез.
Бер-берегезне яратыгыз,
Таһир-Зөһрәдән ким сөймәгез!

Шатлыгымнан күңлем очына,
Куанычым сыймый эчемә.
«Волга»сына утырып, авыл урап,
Йөрсәң иде тузан эчендә.

Үпкәләшә инде күрмәгез,
Терәлмәсен комга көймәгез.
Бер-берегезне яратыгыз,
Таһир-Зөһрәдән ким сөймәгез!*

Гөлназ. Әйттем бит инде, әлегә берни дә әйталмыйм дип!
Тархун. Хатын, йокы мәсьәләсен хәл итәсе иде бит.
Җәүһәрия. Хәзер урын җәям!

Икенче бүлмәгә кереп китә.

Тархун. Әниең сине һаман да кечкенә сабый бала итеп күрә, борчыла синең өчен. Ә минем киңәшем шул: ашыкма кияүгә чыгарга, ашыкма.
Гөлназ. Ашыккан юк, әти, әни нигәдер ашыктыра.
Тархун. Кияүгә чыгулар, өйләнешүләр, ай-һай, бик күп чыгымнар сорый хәзерге заманда. Әйтик... *(Счет төймәсен сала.)*
Гөлназ *(көлеп).* Әти, ярар инде!
Тархун. Ярый. Егетнең исеме ничек соң?
Гөлназ. Салих.
Җәүһәрия *(икенче бүлмәдән).* Тар-хун...
Тархун. Мөселман егете икән, исеме матур. *(Киерелеп.)* Әле дә ярый дөнья мәшәкатьләреннән арынырга йокы бар. И-их!

Кереп китә.

Гөлназ. Уф! Сорау алалармыни! *(Җиңел сулап куя.)* Абау, ни булды миңа? *(Күкрәген тота.)* Күңел болгана... Әгәр, әгәр дә врач әйткәннәр дөрес булса... мин нишләрмен?! *(Елый.)* Алдады мине, ташлады... Алдады... Ахры, яңа тормыш башлады... Ниләр күрер, ниләр кичәр ялгыз калган кызның башлары...

Күрше бүлмәдән Җәүһәрия чыга.

Җәүһәрия. Ни булды сиңа, кызым? Танырлык түгел сине, үзгәргәнсең?

Гөлназ йөзен яшерә.

Сөйлә, яшермә! Атаң алдында, бәлкем, сөйләргә дә ояласыңдыр?! Күреп, сизеп торам, кызым, нидер булган?!

Гөлназ. Әнием... ялгыштым мин... *(Пауза.)* Алдандым...

Җәүһәрия. Әстәгъфирулла! Ни дисең син?

Гөлназ. Салих белән ачуланыштык. Мин пар түгел аңа. Аның Мәскәүдә икенче кызы бар икән, ул бүген барысын да әйтте... Без бит бүген киногa бармадык, ә кунакханә номерында булдык...

Җәүһәрия. Әй, балам, балам, чукынчык кыз! Әйттем бит мин сиңа!

Сугарга дип кулына әйбер ала.

Гөлназ *(Җәүһәриягә кагылып).* Әни!

Җәүһәрия. Нәрсә тагын? Әйтеп бетер!

Гөлназ. Белмим инде... ничек дип әйтергә дә... иң яманы...

Җәүһәрия. Йә?!

Гөлназ. Әни, минем балам булачак!

Җәүһәрия *(өнсез калып).* Ә?!

Тархун чыга.

Тархун. Менә сиңа мә!

Җәүһәрия. Әй Аллам! Күңелем сизенгән иде аны, сизенгән иде. Әй кызым, кызым, нишләдең соң син, ә?! Үләм! *(Кычкырып.)* Ү-ү-терәм!

Кызга ташлана. Гөлназ кача.

Тархун. Тукта! Кызның гаебе юк монда, баланың атасын эзләтергә кирәк!

Җәүһәрия. Тю-тю инде аның атасы, тю-тю! Әй кызым, кызым, бер генә дә уйлап эш итә белмисез, сыерчык оясы белән уйнагандай кыланасыз. Егетләрнең татлы сүзләренә ышанырга ярый димени, кызым. Алар барысы да алдакчылар, аларга шул, ачуым бер килмәгәе, йоклап алырга гына булсын.

Гөлназ. Юк, әни, безнең мәхәббәт уенга охшамаган иде.

Тархун. Нәрсә булса да эшләргә кирәк. Бер-бер хәл булганчы...

Җәүһәрия. Ә нишләргә кушасың? Нишләргә? Безнең гаилә абруйлы, безне бөтен шәһәр белә. Ә шәһәребез кечкенә, ишетелсә — сүз китәр. Хурлык, ах, нинди хурлык! Кызым, гаиләгә тап төшердең. Йә, инде хәзер нишләргә уйлыйсың?

Гөлназ. Мин уйладым инде, әни.

Тархун. Ә бәлкем... ни... врачка барып... ни...

Гөлназ. Юк! Мин баланы табачакмын! Ул минем беренче мәхәббәтем истәлеге булып калыр. Минем өчен борчылмагыз, кара кайгыга батмагыз. Мин бу шәһәрдән китәм... Сезне хур итмәм.

Җәүһәрия. Китеп кая барасың?

Гөлназ. Берәр куыш табылыр әле шунда.

Җәүһәрия. Әй кызым, кызым, ник кенә безне шулай кара кайгыларга салдың икән?! *(Елый.)* Берәр урын, берәр урын, дисең инде... *(Бик нык уйга калып.)* Табармын мин сиңа урын, кызым, табармын...

Тархун. Юк, Гөлназ беркая да китмәячәк.

Җәүһәрия. Мине дә тыңлагыз әле! Кызым, син авылга кайтырсың, авылдагы абыем янына. Абый белән дә, килен белән дә бик ныклап сөйләшербез, аңлатырбыз хәлне...

Тархун. Абыең урманда яши түгелме соң синең? Кызыңны җәнлекләр янына урманга качырырга булдыңмыни инде?

Җәүһәрия. Тагы да әйбәт. Авыл халкы да белмәс. Ул — урман каравылчысы. Сине, кызым, анда күрүче дә, белүче дә булмас.

Тархун. Иртәме-соңмы, халыкка барысы да билгеле булыр. Баланы яшереп булмый, бала бит ул әйбер түгел.

Җәүһәрия. Утыр урыныңа, счет төймәңне сал! Мин сезне тыңладым, инде хәзер мине тыңлагыз! Мин ничек әйтсәм, нәкъ шулай булыр. Болай... *(Гөлназга.)* Баланы табарсың. Ләкин ул тапкан бала синеке булмас. Аны мин табам, бала да минеке булыр.

Гөлназ. Ә ул бала миңа кем булыр соң?

Җәүһәрия. Кем булсын, кем буласы билгеле инде. Кыз туса — сеңел, малай туса — энекәш.

Гөлназ. Абау! Ничек була соң инде бу? Болай ярамый торгандыр бит, әни?!

Җәүһәрия. Йоклаганда яраган бит, хәзер дә ярар.

Тархун. Ә кем сиңа ышаныр?

Җәүһәрия. Ышанырлар, ышандырырлык итеп башкарырбыз. Җиренә җиткереп.

Тархун. Сиңа пенсиягә чыгарга вакыт җитә бит инде?!

Җәүһәрия. Җитсә! Әнә Кытайда бер туксан яшьлек хатын бала тапкан, ди. Егерме биш баласы бар, соңгы иренә егерме сигез. Безне ничек өйрәттеләр: туган ил сораса...

Тархун. Туган ил сорар ул.

Гөлназ. Әти дә карт бит инде.

Җәүһәрия. Булмагае. Бала гына булсын. Бала туса, аның ничек туганын, кемнән туганын бик сорап тормаслар. Бөтенесе дә законлаштырылган булыр: нигезе бар.

Гөлназ. Бала туар, ә мин нишләрмен?

Җәүһәрия. Телисең икән, оч, телисең икән, кияүгә чык. Син — ирекле кош. Бик сагынсаң, кайтып килеп карарсың, миңа булышырсың.

Гөлназ. Әни, болай ярамый.

Җәүһәрия. Ярамый, ярамый, ярамыйга карамый! Җитте! Булды! Сезне бик күп тыңладым! Үзеңне дә, безне дә кеше алдында хур итәсең килмәсә, минем тәкъдимемә риза бул. Йә?!

Гөлназ Тархунга карый.

Тархун. Бернишләп тә булмый, кызым, язмышка буйсынырга кирәк. Расхуты зур була инде, зур...

Гөлназ *(елап).* Риза.

Җәүһәрия. Ярар. Ялгышны елап кына төзәтеп булмый. Бер син генә түгел, бик күпләр белән була торган хәл.

Тархун *(хатынына).* Эшең белән нишлисең?

Җәүһәрия. Эштән китәргә туры килә инде.

Тархун. Декретка ничек чыгарсың? Кем сиңа белешмә бирә? Ничек врач янына барасың? Декретный түләмәгәч, финанска бәрә инде бу, расхут өстенә расхут...

Җәүһәрия. Бәрә инде, җаным, бәрә. Хәзер гел расхут өстенә расхут чыгып кына торачак. Ә син шуны санап торачак.

Тархун. Тапмыйча гына булмыймы соң?

Җәүһәрия. Син миңа әйтәсеңме?

Тархун. Халыкны ничек ышандырмакчы буласың? *(Корсак турыннан күрсәтеп.)* Бала булгачтын, ул ничектер сизелергә, күренергә тиештер бит инде?!

Җәүһәрия. Әй, исең киткән икән! *(Бер кечкенә мендәрне алып, корсак астына тыгып куя. Халатын төймәли.)* Коеп куйган ана. Охшаганмы?

Тархун. Тач!

Гөлназ. Во!

Көлешәләр. Караңгылык. Икенче көн иртән. Яктырып килә. Гөлназ (эчке күлмәктән) торып, музыка куя. Гимнастика ясый. Ишектә
кыңгырау тавышы. Җәүһәрия йөгереп чыга, Тархун күренә.

Җәүһәрия. Кем йөри анда таң тишегеннән?

Гөлназ. Әни, йөрмә, үзем ачам!

Лемонтий керә.

Лемонтий. Исәнмесез-саумысез! Борчыдым бугай...

Тархун. Берәр хәл булмагандыр ич, Лемонтий?

Лемонтий. Булды шул. Әле генә телевизордан хәбәр иттеләр. АО МММны япканнар, инде хәзер «Хопер-инвест»ка да тотынганнар...

Тархун. Нишләп аңа башың авырта?

Лемонтий. Бөтен ваучерларымны, сатмыйча, шул «Хопер...»га тыккан идем. Яптылар конторны — коры калдым!

Тархун. Нигә?

Лемонтий. Халявщиклар күбәйгән, әрәмтамаклар! Ә сез ваучерларыгызны кая куйган идегез?

Җәүһәрия *(корсак турыннан күрсәтеп).* Менә монда!

Лемонтий. Абау, күршекәем, сиңа ни булды соң? Юанаеп киткәнсең димме?!

Гөлназ. Безнең әни гел шундый бит инде ул. *(Урын-җирне җыя.)*

Лемонтий. Юк ла инде. Әле кичә генә сездән чыктым бит... Карале, мәйтәм, Җәүһәрия бер дә картаймый, билләре гел яшь кызларныкы кебек, дип уйлап кына куйган идем әле.

Тархун. Син, Лемонтий, бик тә любопытный булып чыктың бит әле, барысын да күреп, белеп торасың!

Җәүһәрия. Исең китмәсен, Лемонтий, үзгәргәнмендер, үзгәргәндер.

Лемонтий. Бер төн эчендәме?

Җәүһәрия. Сүз бил турында түгел, ә бала турында бара. Ишетмәдеңмени?! Минем тиздән балам булачак, мин балага уздым!

Лемонтий. Бу-у-улмас!!! *(Пауза.)* Вәт бит, ә! Чынлап та! Кем уйлаган бит... *(Көйләп.)* Шоколад имеет разделить успех, даже в маленьком кусочке о-о... лесной о-орех!

Гөлназ. Человек-реклама!

Тархун. Син бу рекламаларың белән саташып беткәнсең бит инде, Лемонтий. Ышанма син аларга, барысы да ялган, берсе дә безнең файдага түгел.

Лемонтий. Мин, күрше, ышанырга өйрәнгән, мин хәтта хатыныма да ышанам. Безнең бит аның белән балабыз булмады. Булмады дип, булды инде алар, тик яшәп кенә китмәделәр. Таба торды, тапкан берсе үлә торды...

Гөлназ. Әни, мин авылга әйберләремне җыйный торам.

Җәүһәрия. Җылы киемнәреңне әзерлә. Тиздән салкыннар җитә. Чемоданнарың актар...

Тархун. Мин юынып алыйм әле.

Югала.

Җәүһәрия. Лемонтий, өеңә караклар керә күрмәсен.

Лемонтий. Зыян юк. Фатир ишеге өч катлы минем хәзер. Кермәсләр. Карале... Чибәрләнеп киткәнсең димме?!

Җәүһәрия *(көязләнеп).* В сорок пять — баба ягодка опять!

Лемонтий. Хатын-кызга килешә. Гомерем буе бала турында хыялланып яшәдем. Синең кебек сылу, акыллы хатынны мин кулымда гына күтәреп йөртер идем.

Тархун чыга.

Җәүһәрия. Тархунның мине гомерендә дә күтәреп караганы булмады.

Тархун җәлт кенә хатынын күтәреп ала.

Лемонтий. Тик мин бернәрсәне аңлап бетерә алмыйм...

Тархун. Нәрсә аңламыйсың?

Лемонтий. Кайчан өлгердегез, дим?

Җәүһәрия. Анысын абзаңнан сора инде.

Лемонтий. Бер дә, мәйтәм, карават шыгырдаганы ишетелмәде.

Тархун. Караватның монда ни катнашы бар?

Лемонтий. Карават шыгырдатмыйча гына булмый бит инде ул...

Тархун. Нишләп булмасын?

Җәүһәрия. Бәлкем... йоклаган чагыңа туры килгәнбездер?

Лемонтий. Уяныр идем. Сезнең аста гына яшәп ятам бит. Инде шактый вакыт бар караватыгыз шыгырдамаганга!

Тархун. Безнең карават шундый, шыгырдамый.

Җәүһәрия. Әйе, шыгырдамый безнең карават.

Лемонтий. Безнең илдә шыгырдамый торган карават юк.

Тархун. Төнлә генә түгел, көндез дә шыгырдый ул, шыгырдатсаң.

Лемонтий. Мин бит көндез дә өйдә. Заводта эшләүчеләрнең барысы да ял итүчеләр хәзер.

Тархун. Анысы безгә кагылмый. Туктале, ә син нишләп безне тыңлап ятасың? Бер-бер хәл ясарга җыенмыйсыңдыр ич?

Лемонтий *(ачу белән).* Ваша киска купила бы «Вискас»!

Чыгып китә.

Җәүһәрия. Хи-хи!

Тархун. Ни булган аңа?

Җәүһәрия. Шайтан белсен инде аныкын!

Тархун. Гел синең тирәңдә генә бөтерелә...

Җәүһәрия. Әллә көнләшәсең инде?

Тархун. Җитте, ташларга кирәк бу уенны! Күрдеңме, хәтта күршең дә ышанырга теләми!
Гөлназ. Әни, ташлыйк, ә?!
Җәүһәрия. Юк. Хәзер соң инде, соң. Лемонтий барысын да күрде, ишетте. Иртәгә бөтен шәһәр ишетәчәк. Юк, уйлаган, башлаган гамәлдән кире кайту юк. *(Үзен көзгедән карый.)*
Тархун. Ярар. Уен тек уен. Шунысын да онытма: өйгә кеше җыелачак... Туганнарың, апаларың, сеңелләрең һәм башкалар...
Җәүһәрия. Килсеннәр. Күрсеннәр. Һәркайсына ачык чырай, такта чәй. Берсеннән дә куркып, оялып тормам!
Тархун. Шул шул. Чәй дә мәй... Тархун, акча давай...

Гөлназ киенә.

Җәүһәрия. Үз балаңнан кызганма инде.
Гөлназ. Әни, әйт әле, зинһар, син моны минем хакка эшлисеңме?
Җәүһәрия. Синең өчен эшләмичә, кем өчен эшлим инде тагын, күрше өчен түгел. Син бит минем бердәнбер яраткан кызым! Ана өчен баласыннан да якын кеше юк.

Утырышалар.

Тархун. Әниең синең өчен ут йотып тора, ә әтиең эчтән яна, бел шуны, кызым.
Җәүһәрия. Ана хыялы бер генә, сине, кызым, яшь, чибәр мөселман егетенә биреп, тәти оныклар үстерергә. Берәр әйбәт егет очраса, сезгә фатирымны калдырып чыгарга да әзер.
Тархун. Ә үзең кая торырга уйлыйсың?
Җәүһәрия. Шалашта. *(Көлә.)*
Гөлназ. Андый егет очраса, мин үзем дә аның белән шалашта торырга әзер.
Җәүһәрия. Кызым, мине яхшылап тыңла. Бала тапканчы, сиңа шәһәрдә күренергә ярамый. Тапкач, алып кайтырсың, законлы рәвештә теркәрбез. И эше бетте, кодагый!
Гөлназ *(торып)*. Хуш, әни! Хуш, әти!
Тархун
Җәүһәрия } *(икесе бергә)*. Хуш кызым!

Гөлназ китеп бара. Караңгылык.

Шул ук картина. Җәүһәрия, Тархун гәпләшеп утыралар.

Җәүһәрия. Барып җиткәндер инде. Киткән җиреннән исән-имин генә әйләнеп кайтырга язсын инде балама... Караңгы төшеп килә... Тавыш-тынсыз гына майтарып чыксак иде инде бу хәйләбезне!
Тархун. Гауга чыгармаска иде инде...

Ишектә кыңгырау тавышы. Курка-курка ишек ачалар. Наҗия керә.

Наҗия. Җизни!
Җәүһәрия. Ай, әйтеп кенә бетердек!
Наҗия. Апай, җаным, ишеттек, котлыйм үзеңне! *(Үбә.)* Дөрестер бит?
Тархун. Каян, кемнән ишеттең?!
Наҗия. Кемнән ишеткәнемне әйтеп тормыйм, анысы мөһим әйбер түгел. Ну, җизни, йә, бер үбим үзеңне! *(Үбә.)*
Тархун. Лемонтий җиткергәндер инде, каһәр! Әйттем мин сиңа, хатын, Лемонтийга серне ачарга ярамый, дип.
Наҗия. Әй, ярар инде, тыйнакланып маташма, тагын бер үбим әле үзеңне! Маладис, тырышкансың! *(Үбә.)*
Тархун. Ни өчен һаман мине?!
Наҗия. Ничек инде ни өчен? Әкият сөйләп торма инде! Мин, кәнишне, көтмәгән идем синнән! Маладис! *(Тагын үбә.)*
Тархун *(күңеле булып)*. Рәхмәт, балдыз, рәхмәт җылы сүзләрең өчен!
Наҗия. Апай, шушы яшеңдә бала табу синең өчен зур батырлык. Менә күрерсең, синең турында гәҗиттә язып чыгарлар әле.
Тархун *(коты очып)*. Язма! Кирәкми!
Җәүһәрия. Анысы кирәкмәс иде инде.

Нaҗия. Юк, юк, бик артык тыйнакланма. Хәзерге заманда бала табу бик зур батырлык, что сез! Мин шундый шатландым, шундый шатландым! Аяз көндә яшен суккандай булды бит бу миңа мондый шатлыклы хәбәрне ишетү. Киттем... Чаба-чаба, йөгерә-йөгерә... Саташам дип торам. Башым әйләнде. Шатлыктан, башка автобуска утырып, бөтенләй икенче якка китеп баргaнмын. Ярты юл узгач кына акылыма килдем. Шоферга әйтеп, автобусны кире бордырттым. Апайның бәбәе булачак, дигәч кенә тыңлады, кире китте. Автобустан төшүем булды, каршыма бозау хәтле бер дәү эт килеп басты. Җибәрми генә бит, ямьсез тәре! Ир кеше булса бер хәл, эт бит! Сөйләп тә, аңлатып та карыйм. Белмим бит ул эткә ни кирәген, белсәм, бирер идем. «Васька, Вась!» дигәч кенә каршымнан китеп барды. Аллага шөкер, төнгә калып булса да, килеп җиттем. Җизни, карт булсаң да, маладис, тырышкансың! Йә, бер үбим инде үзеңне!

Тархун. Җитәр инде, җитәр!

Нaҗия. Син алай бик артык тыйнакланма инде. Иртәгүк корреспондентлар, кооператорлар, ә юк ла, операторлар чакыртам.

Тархун. Чакыртма!

Нaҗия. Юк, чакыртам! Килсеннәр! Язсыннар! Төшерсеннәр! Ну, алар килсә, төшерәләр инде! Ә мин шундый шатландым, шундый шатландым, бигрәк тә җизни өчен! Синнән бәхетле кеше юктыр хәзер, шулай бит, җизни!

Тархун. Миннән дә бәхетсез кеше бар микән әле бу дөньяда!

Нaҗия *(көлеп).* Әй, алай димәле! Күзләреңнән үк күреп торам, шатлыгың йөзеңә чыккан. Менә безнең апабыз сине ничек ярата, син дә аны ярат инде! И җизни, маладис! Кыскасы, мин сезнең өчен бик тә шатмын!

Тархун. Кемгә шатлык, кемгә кайгы.

Нaҗия. Тел төбеңне аңладым, җизни. Бала булгач, расхут күп чыга дип уйлыйсыңдыр инде син. Борчылмагыз, миңа китерерсез, үзем карармын. Гомерем бала-чагасыз үтеп бара, минем өчен бала тансык кына ул.

Тархун. Шулай да кем әйтте соң сиңа?

Нaҗия. И-и! Яшереп яткан булалар тагын, соң, бөтен шәһәр белә бит инде!

Тархун<br>Җәүһәрия } *(икесе бергә).* Бөтен шәһәр?!

Нaҗия. Белсә ни! Шатланырга гына кирәк, сөенергә! Бу бит редький случай! Ярар, мин бер иркенләп килермен әле! Иркенләп килербез...

Җәүһәрия. Наҗия, син алай бөтен кешегә әйтеп, хәбәр биреп йөрмә инде!

Нaҗия. Әйтәм, ничек инде әйтмәскә ди шундый хәбәрне?! Җария апага да, туганнарга да, барчасына да! Язам! Яздыртам!

Тархун. Бетерәсез!

Нaҗия. Мин горурланам сезнең белән! Сез минем өчен әле генә өйләнешкән яшь парлар кебек. Их, бер бәби туенда да утырасы иде бит! *(Елап ала.)* Горурланам! Бигрәк тә җизни белән! Маладис, җизни! *(Тархунны коча.)* Очтым! *(Туктый.)* Ә, юк, очмадым икән әле! Апа, үзеңне кара! Җизни, апага булыш!

Тархун. Хатынга булышу минем изге бурычым.

Нaҗия. Сезнең кебек матур гаилә дөньяда юк! Очтым, очтым... Килербез!

Наҗия китә.

Җәүһәрия. Сыерчык! Сайрады да китеп барды!

Тархун. Ничек ди, ә! Җизни маладис, ди!

Лемонтий, ишектән кереп, тиз генә йокы бүлмәсенә кача.

Җәүһәрия. Таптың мактаныр нәрсә! Буш куык!

Тархун. Бер дә буш димиләр әле, маладис, диләр.

Җәүһәрия. Уф, арыдым. Бу мәшәкать килеп чыккач, адәм рәтле ял иткән дә юк. Безнең ишек нишләп гел ачык тора соң ул?

Тархун. Аның ябылганы да юк. Тукта, ябып керим әле. *(Яба.)* Карале, хатын, мин дә синең белән ятып торыйм әле, гел-гел аерым йоклап, бер-беребездән бизеп куймыйк, дим.

Җәүһәрия. Синең белән безгә кысан булыр.

Тархун. Яңа караватalырга һич кенә дә акча җиткереп булмый шул, гел расхут чыгып кына тора.

Тархун Җәүһәриягә ияреп йокы бүлмәсенә керә. Шулчак «Каравыл!» дигән тавыш ишетелә. Йокы бүлмәсеннән Лемонтий атылып чыга.
Аның артыннан Тархун.

Тархун. Жулик! Бандит!

Җәүһәрия күренә.

Җәүһәрия. Ходаем! Котым алына дип торам! Караватастына ук кереп яткан бит! Ну, Лемонтий!
Тархун. Безне тикшерергә дип кердеңме?
Лемонтий. Сезне түгел — караватны! *(Пауза.)* Алдамагансыз! Караватыгыз чынлап та шыгырдамый икән!

Йөгереп чыгып китә.

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Берникадәр вакыт узган. Үзгәреш сизелә: бер чатта бала караваты тора. Тархун счет төймәсе тартып утыра. Җәүһәрия шактый калынайган, кәнәфигә сөялеп, оекбаш бәйли.

Җәүһәрия
Тархун } *(икесе бергә җырлыйлар).*

Төшләреңдә синең кем икән,
Малай микән, әллә кыз микән?
Малай булса күлмәк алырбыз,
Ә кыз булса итәк алырбыз.

Җәүһәрия.
Җүләр, җүләр, ай, җүләр,
Шушы җүләрләр белән җүләрләнеп,
Үтә минем гомерләр.

Бергә.
Малай туса ыштан алырбыз,
Ә кыз туса яулык алырбыз.
Алла биреп, үсеп җитсәләр,
Ыштансыз да әле калырбыз.

Тархун.
Җүләр, җүләр, ай, җүләр,
Шул җүләрләр белән җүләрләнеп,
Үтә инде гомерләр.

Җәүһәрия. Чыннан да кем булыр икән? Малаймы, кызмы?
Тархун. Ир бала булсын иде инде.
Җәүһәрия. Ә кыз булса?
Тархун. Исәпләп табарга кирәк булган.
Җәүһәрия. Син миңа әйтәсеңме?
Тархун *(кул селтәп).* Әй, буталып беттем инде мин сезнең белән, синең бала табачагыңа шулкадәр ышанып беттем.
Җәүһәрия. Ярар. *(Торып.)* Бу туган көнне ничек итеп уздырып җибәрергә инде?! Берсен дә чакырмадым, килсәләр килерләр үзләре. *(Көзге каршына килеп.)* Бүген тагын берне өстәдем. *(Корсак астын сыйпап.)* Шулкадәр читен, чыдар хәл калмады... эссе... Гөлназдан да хәбәр юк, вакыты җиткәндер бит инде.
Тархун. Кисәткән идем мин сине. *(Счет төймәсен сала.)*

Җәүһәрия. Сеңелкәшләр килерләр инде, аларны каршы аласы булачак. *(Үпкә белән.)* Хатыныңның бүген туган көне. Чабып йөрисе урынга, счет салып утырган буласың.

Тархун. Миннән канәгать булмагач, нишләп чыктың соң?

Җәүһәрия. Счет төймәсен тарткан саен, кесә калынаер дип өмет итеп чыккан идем.

Телефон шалтырый.

Ало! Юк, роддом түгел, фатир бу. *(Трубканы куя.)* Гөлназ шалтырата дип торам. *(Кызының рәсеме каршына килеп.)* Әнисенең туган көненә дә кайта алмасын инде, ә! Сагындым шулкадәр дә үзен! Бер хәбәре дә юк бит чукынчыкның! Абый да килеп чыкмый, ичмасам!

Тархун. Көлкегә калганчы, барысын да ачып салырга кирәк халыкка.

Җәүһәрия. Юк, безнең серне беркемгә дә ачарга ярамый, хәтта туганнарга да. Үзебез өчен генә түгел, туачак бала өчен дә кирәк ул.

Тархун *(торып).* Тукта, почта яшниген карап керим әле, хат-мазар юк микән?! *(Чыга.)*

Җәүһәрия *(корсагын карап).* Кыяфәте китә башлаган бит әле моның. Кунаклар алдында оятка кала күрмим. И, җан кисәкләрем, бигрәк уңайсыздыр инде сезгә анда! Сезне карарга да вакыт юк бит! *(Рәтләп куя.)*

Тархун керә.

Тархун. Менә, хатын, сине котлап берничә открытка килгән. Телеграмма да бар. Менә... Сәмарканнан язалар, шигырьләп җиффәргәннәр. *(Укый.)* «Туганым Җәүһәрия! Сине туган көнең белән чын күңелдән котлыйбыз! Сиңа озын гомер, саулык-сәламәтлек телибез! Тик без бернәрсәне аңлап бетермәдек: кызың бала табамы, әллә үзеңме? Аңлатып яз. Рәсимә». Тәк... Бусы хат. Кемгә бу? Миңа икән! Тархун Тариховичка диелгән. Кемнән? Ә! Олы абыйдан! Мәскәүдән...

«Хөрмәтле вә гыйззәтле туганнарыбыз! Чәчәкле Татарстанда яшәп ятучы Тархун туган, Җәүһәрия килен! Мин үз гомеремдә ике зур вакыйгага кичердем. Беренчесе — Гагаринның дөньяда беренче мәртәбә космоска очуы булса, икенчесе — пенсиягә чыккан иптәш татаринның ата кеше булуга әзерләнүе. Маладис, брат, так держать, до того шатбыз, что шатлык хисләребезне кәгазь кисәгенә генә сыйдырып булмый. Бала тууга ук хәбәр бирегез, сезнең продукцияне күрергә кайтырбыз, иншалла! Абыең».

Җәүһәрия. Ә нишләп минем турыда бер сүз дә юк?

Тархун. Ә нишләп булмасын, менә бит... «Бездән киленгә чуктин-чук сәлам...»

Җәүһәрия. Вәт сиңа! Газаплары миңа, даны сиңа! Салып атам болай булгач, чукынсын мендәрләрең! *(Сала башлый.)*

Тархун. Юк, карчык, салырга ярамый. Баланы табарга кирәк. Син инде безне юләргә чыгарма. Исәнсау котылсаң, мин сиңа алтын муенса алып бирергә нәзер әйткән идем.

Җәүһәрия. Әй Аллам! Ниләр генә күрми бу татар хатыны!

Тархун. Ниләр генә күрсәтми бу татар хатыны! *(Күреп.)* Тукта, монда нидер бар! Извещение... на сумму... тысяча рублей... Ни бу? Бу акча безгә керәсеме, әллә чыгасымы? Тизрәк барып тикшерергә кирәк! Пение үсәргә мөмкин, пение... Киттем!

Җәүһәрия. Озак йөрмә. Кунаклар киләсе бар...

Тархун чыгып китә.

Уф! Шушы җүләр белән үтте дә китте инде гомер! *(Почта актара.)* Сөбханалла! Кызымнан... открытка... *(Укый.)* «Әнием! Бәгърем! Котлыйм! Сине туган көнең белән үбеп, кочаклап кызың Гөлназ!» Туктале, кызым, үзең турында нишләп бер кәлимә дә сүз язмадың? Бала белән нәрсә? Ничек соң син анда? Әй кызым, кызым! *(Елап ала.)*

Лемонтий керә. Киенгән, ясанган.

Лемонтий. Ирең юк, ахры?! Кая китте?

Җәүһәрия. Зур-зур эшләр белән китте.

Лемонтий. Бала ничек соң, бала?

Җәүһәрия. Әй, нәрсә булсын инде аңа.

Лемонтий. Читендер инде сиңа, җайсыздыр?

Җәүһәрия. Җайсыз, бик тә җайсыз. Каурый йоннары, үтереп-үтереп, тәнне кытыклый.

Лемонтий. Бала, алты ай тулгач, аягы белән тибенә башлый.

Җәүһәрия. Каян беләсең?

Лемонтий. Китаптан укыдым. Менә. *(Китап күрсәтә.)* «Яшь анага киңәшләр». Ал, кирәк булыр. *(Бирә.)* Йөзеңдә бер дә шатлык күрмим. Тархун синең бала табуыңа каршы, ахры. Ә син курыкма, миңа таян. Теләсәң, баланы бергәләп үстерәбез.

Җәүһәрия. Ничек? Минем ирем бар бит.

Лемонтий. Яшермә. Син бит иреңне яратмыйсың. Әгәр дә миңа чыксаң, балаңны үземнең бала итеп кабул итәрмен, үзем карармын. Бездән дә бәхетле кеше булмас бу дөньяда. *(Пауза.)* Җәүһәрия, мин сиңа күптән әйтергә йөрим, мин сиңа гашыйкмын. Бу йорттан да күптәннән күченеп киткән булыр идем, тик син генә мине тотып калдың. Сине ратканга, һәр көн сине күрәсем килгәнгә генә шушында калдым. Хатын белән аерылам, тиздән мин ирекле кош!

Җәүһәрия. Әй, Лемонтий, понти-монти! *(Көлә.)*

Лемонтий *(көлеп).* Онытып та торам. Туган көнең белән! *(Бер кесәсеннән чәчәк, икенчесеннән шампанское, өченчесеннән шоколад чыгара.)* Котлыйм!

Җәүһәрия. Рәхмәт. *(Чәчәкләрне ала.)* Боларны өстәлгә куй! Рәхмәт сиңа, Лемонтий, ты просто прелесть! *(Үбә.)*

Лемонтий. Зур үс! «Мммденс» тает во рту, а не в руках! Мин әле сиңа тагын бер бүләк әзерләдем. Анысын әлегә күрсәтергә ярамый, ирең бик көнче...

Ишектә кыңгырау тавышы.

Җәүһәрия. Килделәр...

Лемонтий. Кемнәр?

Җәүһәрия. Сеңелкәшләр! *(Ишекне ача.)*

Нәҗия, Җария керә. Кулларында чәчәкләр, сумкалар.

Ай-һай, соңлап йөрисез, ә! Чәйләр суынып бетә бит инде!

Нәҗия. Апаны көттем. Иреннән, балаларыннан аерылып бетә алмый.

Җария. Котлыйбыз, апа! Җизни кая? Кая автор?

Нәҗия. Авторны, авторны! *(Кул чаба.)*

Үбешәләр, кочаклашалар.

Җария *(Лемонтийны күреп).* Синдә кунак та бар икән әле!

Җәүһәрия. Бу безнең күршебез... Лемонтий...

Җария
Нәҗия } *(икесе бергә).* Беләбез, беләбез!

Лемонтий. Җәүһәрия, мин сиңа тагын бер бүләк әзерләгән идем, хәзер алып керәм. Сюрприз!

Җария. Нинди сюрприз? Сер булмаса, безгә дә әйт әле?

Лемонтий. «Мммденс» — лучший подарок для женщины!

Җария. Ждем-с! До первой звезды-с! *(Көлә.)*

Лемонтий чыгып китә.

Кайчан сиңа килмә, өеңдә гел шул. Юкка гына йөрми торгандыр әле, кара аны! Хәер, йөри алганда, йөреп калырга кирәк. Яшьрәк чакта, балалар табып йөргән чакта, ирем йөрде, ә хәзер мин йөрим. Ие! Бер көнлек дөнья бит бу! Йөреп, дөньяның рәхәтен күреп калырга кирәк! Бер ун елдан безгә әйләнеп караучы да булмас, шулай бит, Нәҗия?!

Нәҗия. Дөрес. Көтеп утырырга ярамый икән шул бу дөньяда.

Җәүһәрия. Әйдәгез, утырыгыз өстәл янына!

Нәҗия. Син, апа, утыр, авырлык килә күрмәсен!

Җария. Әй Ходаем, аздырасың инде апаны. Пычагым да булмый... Дүрт бала таптым, дүртесе дә тап-таза, дүртесе дә исәннәр. Чукынып киткерләре! Белмиләр кадеремне!

Нәҗия табынны карый.

Җәүһәрия. Чәйнек, аш газда.

Җария. Керен дә юдым, ашарына да пешердем, кибетенә дә чаптым. Кул кушырып утырмадым, Аллага шөкер!

Утырышалар.

Җәүһәрия. Эчегез, әйдәгез, авыз итегез!

Нәҗия *(Җәүһәриягә).* Ничек соң, апай, хәлең бик авыр түгелме?

Җәүһәрия *(белештермичә).* Әй, салып кына атасы килә!

Җария. Дөрес. Хәзерге заманда юләр кеше генә бала таба. Шундый читен заманнар киләсен белсәм, дүрт бала табып ятмаган да булыр идем. Рәхәтләнеп чәй дә эчалмыйм мин ул балалар белән. Беркая да чыга алмыйм. *(Чәй эчә.)*

Нәҗия. Баласыз тормыш та тормышмыни инде?! Менә мине генә алыгыз. Дүрт стена саклап өйдә утырам берьялгызым.

Җария. Ә мин рәхәтләнеп утырыр идем әле. Туйдым шул бала-чага көен көйләп. Дөньяның читенә чыгар идем дә утырыр идем аякларымны селкеп! *(Аякларын чалындырып утыра.)* Тапма, апа, син бу баланы!

Нәҗия. Ә мин табар идем. Әти белән әни генә гаепле. Башта егетләр белән йөрмә, ярамаган эш эшләп ташлама, дип теңкәмә тиделәр. Егетләрне качырдым. Сайландым. Сайлый-сайлый ялгызым утырып калдым. Күңел өчен генә булса да бер бала таба алмадым. Нишләп мин шундый бәхетсез булдым икән, ә?! *(Елап ала.)*

Җария. И-и! Юк өчен балавыз сыкмале! Алайга калса, мин әле синнән дә бәхетсезрәк. Иртән торасың: «Әни, давай, әни, давай!» Матур итеп «Әни!» дип тә эндәшә белмиләр бит алар, давай гына! Чыдарга кирәк бит шуңа, түзәргә кирәк, тимер булырга, тимер!

Җәүһәрия. Минем дә саулыгым шәптән түгел.

Җария. Шәп булмагач, ник табасың?

Нәҗия. Ә бәлкем, терелеп, яшәреп китәр?!

Җария. Юк инде, һәрнәрсәнең үз вакыты. Син бит, апа, хәзер олы яшьтә. Баланы аны үз вакытында табарга кирәк. Гөлназны тапкансың бит, шул җиткән иде инде. Сиңа хәзер кызыңны кияүгә биреп, оныкларыңны карап утырырга вакыт җиткән. *(Пауза.)* Нәҗия, әйдәле, син бик матур җырлыйсың, җырлале теге җырыңны!

Нәҗия моңсу җыр җырлый башлый. Җырлап бетерә алмый, елый.

Җәүһәрия. Кызлар, әйдәгез, эчәбез!

Нәҗия. Сиңа ярамый бит.

Җария. Нигә ярамасын, аңа ярый.

Нәҗия. Бала «не то» туарга мөмкин.

Җария. Әй, эчмичә дә тормадым. Ничә бала таптым, берсе дә «не то» булмады әле.

Нәҗия. Ә үзең балаларыңны гел яманлап кына утырасың.

Җария. Ә нәрсә булган минем балаларыма? Минем балаларым күк балалар тапсагыз иде әле! Матурлар, чибәрләр, акыллылар! Мин аларны үз вакытында таптым, ә апа, юләр, картайган көнендә табарга җыена. Бала табам дип, йә син үләсең, йә...

Нәҗия. Әстәгъфирулла!

Җария. ...йә балаң гарип туачак. Тфү, тфү, кәнишне!

Нәҗия. Алла, диген!

Җәүһәрия. Ә мин курыкмыйм. Менә карап торырсыз. Балам сау-сәламәт булып туачак. *(Шампанское ача.)*

Нәҗия. Шулай булсын. Исән-имин генә тусын инде!

Җария. Әйдәгез, сезнең исәнлеккә!

Җәүһәрия. Исәнлеккә-саулыкка!

Нәҗия. Исән генә котылырга язсын! Бәби туйларында да утырырга язсын!

Җәүһәрия. Амин, шулай булсын! *(Эчәләр.)*

Җария. Гарип бала дигәннән...

Нәҗия. Апа, җитәр инде сиңа!

Җария. Туктале, сөйләп бетергәнне көт. Алла сакласын, кәнишне, нинди генә балалар тумый! Атаанасы да, нәселе дә сау, ә бала гарип туа. Ерак китәсе юк. Минем төпчек Илнурым белән нәрсә булды... Таптым... алып кайттым... хәлем юк... ятам... Каенанам ванна бүлмәсендә Илнурны юып ята. Әни, бала ничек, исән-саумы, дефекты юкмы, дим... И, килен, ди бу, балаң болай сау-сәламәт, тик бер генә кимчелеге бар, ди. Балаңның бер колагы юк, ди... Ышанмый торам. Китереп күрсәтте. Чыннан да, баланың бер колагы юк!

Нәҗия. Илнурны әйтәсеңме? Колагы бар ла аның!

Жария. Хәзер бар. Сәбәбе нидә: тегенең колагы эчкә баткан. Ниндидер состав җитмәгән диме шунда, состав! Каерып-каерып тарта торгач, адәм рәтенә килде баланың колагы, Алланың рәхмәте! *(Көлешәләр.)*

Наҗия. Җизни кая соң безнең?

Җәүһәрия. Эш белән китте. Хәзер кайтып җитәр.

Жария. Туган көнеңдә ирең өйдә юк. Күршең монда йөри. Күрше дигәннән, бер мәзәк искә төште әле. Сөйлимме?

Наҗия. Сөйлә, бәлкем, кызык булып китәр.

Жария. Берәүләрнең малае сөйләшә белми икән. Тумыштан. Доктор әйткән: балагыз сөйләшер, ләкин бала беренче өч исемне атаган кешеләр көнендә үк үләрләр, дигән. Ярар. Бала әби, дигән, әби үлгән. Бабай, дигән, бабалары үлгән. Беркөнне әниләре кибеткә чыгып киткәч, өйдә әтисе белән малае гына утырып калган. Малай тоткан да: «Әти!» — дигән. Әтисе, куркып, үләргә җыена башлаган. Яңа костюмын, яңа күлмәген кигән. Утыра икән бу үлем көтеп. Шул вакыт әниләре кайтып кергән дә иренә: «Кая дип шулкадәр киендең, кая җыендың, әле генә күршебез үлде!» — дип әйткән, ди. *(Көлешәләр.)*

Җәүһәрия. Мораль?!

Жария. Балаң күршедән булмасын!

Җәүһәрия. И оятсызлар! Сез мине кем дип беләсез, ә?!

Наҗия. Җизни кайтмас, ахры. Элек без җыелыша идек тә лото уйный идек. Биешә торган идек...

Лемонтий керә.

Җәүһәрия. Әйдәгез, биибез!

Наҗия. Апай, куй әле теге мин яраткан чегән романсын!

Жария. Куй, апа! Әйдәгез, биибез! О, Лемонтий, син буйдак, Наҗия дә буйдачка, давай, биибез!

Җәүһәрия музыка куя. Бию көе яңгырый. Жария, өстенә шәл бөркәнеп, Лемонтий белән бии. Лемонтий Наҗия ягына авыша. Җәүһәрия дә биеп китә. Биегәндә аның бүксәсе әле бер, әле икенче якка тирбәлә. Наҗия, коты очып, апасына карап тора. Бию кызганнан-кыза.

Тархун керә. Кулында посылка.

Наҗия. Җизни кайтты, җизни!

Жария. Әле генә сине искә төшергән идек. Кая йөрисең син? Хатыныңның туган көне! Кыек юлда йөрмисеңдер ич?! *(Көлешәләр.)*

Тархун. Исәнмесез! *(Җәүһәриягә.)* Ни... элемтә юк, диделәр...

Жария. Бер-бер хәл килеп чыкмагандыр бит?

Җәүһәрия. Кемгә бу? *(Посылканы карап.)* Тархун Тариховичка диелгән. Тагын синңа!

Жария. Яле, яле, нәрсә анда?

Җәүһәрия *(посылканы яшереп).* Хәзер түгел, кунаклар киткәч ачарбыз. Әнә барыгыз, лотогызны уйнагыз!

Наҗия. Җизни, әйдә лото уйныйбыз.

Тархун. Уемда лото уены түгел әле!

Жария. Әйдә, җизни, моңсуланма, лото уйныйбыз!

Наҗия *(Җәүһәриягә).* Апа, әйдә син дә!

Җәүһәрия. Арыдым әле, кәефем юк.

Наҗия<br>Жария } *(Тархунны тарткалап).* Җизни, әйдә уйныбыз?!

Тархун. Туктагыз инде, хатынга бер-ике кәлимә генә сүз әйтергә ирек бирегез!

Жария. И-и! Сөйләшеп туймагансыз икән әле! Без киткәч сөйләшерсез!

Тархун *(ачу белән).* Туктагыз инде!

Наҗия, Жария, үпкәләгән кыяфәттә, лото уйнарга утыралар.

Җәүһәрия *(Тархунга).* Нишләргә уйлыйсың?

Тархун. Башым катты инде. Юл өзелгәндер, күрәсең. Син, карчык, юкка башладың бу тамашаны, юкка...

Наҗия. Әй Алла, серләшеп туймагансыз икән әле!

Жария. Без нәрсә, сезнең серләшкәнегезне тыңларга килдек дип уйлыйсызмыни монда?! Җизни, оялыр идең, апаның туган көне!

Тархунны лото уйнарга утырта.

Лемонтий чыгып китә. Сәрвиназ керә.

Сәрвиназ. Исәнмесез! Мин Сәрвиназ Гарипова булам. Шәфкать туташы. Адресыгызны дөрес бирмәгәннәр, бик озак эзләргә туры килде.

Җәүһәрия. Тыңлыйм, ни йомыш?

Сәрвиназ. Апа, ачуланмагыз, сез нишләп врачка күренмисез?! Бездән яшереп бала табарга уйлыйсыз икән.

Җәүһәрия. Кемнән ул?

Сәрвиназ. Дәүләттән.

Җәүһәрия. Каян белдең?

Сәрвиназ. Менә шәһәр гәҗитенә язганнар! *(Гәҗит күрсәтә.)*

Җәүһәрия *(өйдәгеләргә).* Шауламагыз әле! Т-с-с! *(Барысы да тынып калалар.)*

Сәрвиназ *(укып).* «Заманалар авыр булуга карамастан, яшьләрнең күпчелеге инде бала табудан баш тарткан чорда да халык арасында фидакарь шәхесләр бетмәгән. Халык чишмәсе саекмаган икән. Шул уңайдан пенсия яшендәге Җәүһәрия ханымның бала табарга батырчылык итүе безнең күңелләребезгә шатлык вә ямь өсти. Булачак баланың атасы Тархун Тариховичның да бу фидакарьлеккә өлеш керткәнен исәпкә алып, шәһәр хакимияте карары нигезендә, яңа туган баланы бала табу йортыннан олы йөрәкле ата һәм ана өч бүлмәле фатирга алып кайтырлар...»

Барысы да. Ура! Ура! Менә кая бәхет! Моны юарга кирәк! Их!

Сәрвиназ. Ярамый. Тавышланмагыз! Баш врач, шушы хәлне белешергә дип, мине сезнең янга җибәрде. Әгәр дә анда язылган фактлар дөрескә чыкса, бу безнең поликлиника, безнең шәһәр өчен зур ЧП булырга мөмкин. Врач шулай диде...

Җәүһәрия *(үзалдына).* Тархун биргәндер инде бу хәбәрне гәҗиткә, Тархун! Партизан, шпион!

Сәрвиназ. Апа, җаным, сез бит яшь кеше түгел, бездән яшереп бала табарга җыену сезнең өчен дә, безнең өчен дә начар.

Җәүһәрия. Сеңлем, син кем өчен күбрәк кайгырасың, минем өченме, әллә үзең өченме?

Сәрвиназ. Сезнең өчен. Билгеле, үзем өчен дә. Авылдан килеп, әле яңа гына эшкә урнаштым, эшемне югалтасым килми. Ә сез килегез, күренегез врачка!

Җәүһәрия. Борчылма, сеңлем, минем балам сау-сәламәт туачак.

Сәрвиназ. Сез баланы кайда, өйдә табарга җыенасыз мәллә? Кендек әбисен чакыртып?!

Җәүһәрия *(саташып).* Авылда... урманда... җиләкле аланда... Күбәләкләр, бөҗәкләр арасында...

Сәрвиназ. Апа, мин сезне аңламыйм?!

Җәүһәрия. Каравыл ызбасында, салам ястыкта... Кендек әбисен чакыртып...

Сәрвиназ. Әбиләргә генә ышанырга ярамый, аның өчен медицина бар. Медицинага ышанырга кирәк.

Җәүһәрия. Ярар, борчылма, килермен. Бүген булмаса, иртәгә. Кызымнан хәбәр көтәм.

Сәрвиназ. Рәхмәт сезгә!

Җәүһәрия. Ни өчен?

Сәрвиназ. Сүземне тыңлаганыгыз өчен. Мин сезгә поликлиниканың телефон номерын калдырам.

Җәүһәрия. Кирәге юк. Кызым белә ул телефонны.

Сәрвиназ. Мин сезгә менә бу китапларны калдырып китәм. Бала турында монда барысы да язылган. *(Җәүһәриягә китаплар тоттыра.)*

Җәүһәрия. Ярар, кызыма бирермен, укыр.

Сәрвиназ *(аңламыйча).* Кемгә?

Җәүһәрия. Тархун!

Тархун *(килеп).* Ни бар, әнисе?

Җәүһәрия. Тархун, менә поликлиникадан шундый чибәр туташ килгән, шәфкать туташы...

Тархун. Беләм килгәнен.

Җәүһәрия. Мин врачка бармаган, күренмәгән өчен ачуланырга дип килгән.

Тархун. Соң, бар. Нигә бармыйсың?

Җәүһәрия. Миңа әйтәсеңме?!

Тархун *(исенә төшеп).* Әй, әйе бит әле!

Җәүһәрия *(кычкырып).* Ай! *(Эчен тота.)*

Сәрвиназ *(коты очып).* Апа җаным, башланды!

Тархун да эчен тотып егыла.

Тархун. Ай! Ай!

Сәрвиназ *(Тархунга).* Абый, абый, кан басымыгызны үлчик әле!
Җәүһәрия. Абзагызны карагыз, минем хәл ярый.
Сәрвиназ *(Тархунның кан басымын үлчәп).* Абый, хәлең ничек?
Тархун. Ярый, ярый.
Сәрвиназ. Авырткан җирегез юкмы?
Тархун *(эчен күрсәтеп).* Менә монда!
Җәүһәрия. Ай! Чукынды!
Сәрвиназ *(Җәүһәриягә).* Апа җаным, утыр, сиңа авырдыр, хәзер «скорый» чакыртам!

Лемонтий керә. Балалар бишеге күтәргән.

Лемонтий *(тантаналы).* Җәүһәрия! Кабул итеп ал! Бүләк! Татар бишеге! Үз кулым белән ясадым!
Җәүһәрия *(сокланып).* Рәхмәт инде!
Лемонтий. Исегез китмәсен, кимсетеп карамагыз. Тукай да, Такташ та бишектә тирбәлгәннәр. Кстати, Илһам да бишекне ят күрмәгән. Бишек балага моң бирә. Ә коляска нәрсә ул: даңгыр-доңгыр! Шуңа да балалар «не то» булып үсә. Ә бишек! Бишек — горур яңгырый!

Җария сумкасыннан бала әйберләре чыгара.

Җария. Апа, онытып та торам! Без бит синең булачак балаңа бүләкләр алып килдек, бала әйберләре. Искеләре дә бар инде. Әллә кем кимәгән, минем шустриклар гына кигән. Дөнья булгач, алары да ярап куяр.
Җәүһәрия. Рәхмәт. Сал әнә шунда!
Җария. Лемонтий, бишегең бигрәк тә матур икән, салыйм әле шунда! *(Бала әйберләрен бишеккә сала.)*
Тархун *(терелеп).* Карале, Лемонтий, болай бүләкләр белән керүең начар түгел, билгеле. Тик без синнән мондый зур бүләкне кабул итеп алалмыйбыз!
Лемонтий. Ялгышасың, күрше. Мондый бүләкне бүләк итәргә минем хакым бар. Ә бәлки, мин Җәүһәриягә гашыйктыр, ә?!

Барысы да тынып калалар.

Тархун *(сүзсез калып).* Ә?!
Җәүһәрия. Юк, Лемонтий, синең яраткан кешең Наҗия. Икегез дә буйдак, бирегез бер-берегезгә кулыгызны!

Наҗия, Лемонтий бер-беренә кулларын бирәләр.

Лемонтий
Наҗия } *(икесе бергә җырлыйлар).*

Эзләдем мин сине айдан,
Йолдызлардан эзләдем.
Җиде матур арасыннан
Иң матурын күзләдем.
Таптым, таптым,
Гүзәлем, бәгырькәем шул,
Алтыным, чибәркәем!

Минем йөрәк синекеннән
Ныграк тибә икән.
Синең күзләр минекеннән
Назлырак сөя икән.

Таптым, таптым,
Гүзәлем, бәгырькәем шул,
Алтыным, чибәркәем!

Җәүһәрия. Ой! *(Эчен тота.)*
Сәрвиназ. Апа җаным, пульсыгызны тикшерик әле!

Җәүһәрия *(беләген ачып).* Мә, өйрән!
Сәрвиназ *(тикшереп).* Ай-яй, шундый каты тибә!
Җәүһәрия. Аның аяк тавышлары минем йөрәк тибешем белән кушыла...
Сәрвиназ. Болай булмый. Мин сезгә «скорый» чакыртам!
Җәүһәрия. Ялгышасың, сеңлем. Минем кызым, кызым кайтып килә...

Гөлназ керә. Кулында чәчәкләр.

Гөлназ. Әни!
Җәүһәрия. Кызым! *(Кочаклашалар.)* Мин сине шундый көттем, кызым, нишләп бер хәбәрең дә юк, кая йөрдең, җүнсез?!
Гөлназ. Әни, мин синең туган көнеңә кайталмыйча булдыра алмадым. Ачуланма! Бәхет телим! *(Чәчәкләр бирә.)*
Җәүһәрия. Кызым, мин сине бүтән беркая да җибәрмим. Мин инде үзем артыңнан барырга уйлаган идем... *(Карана.)* Кызым, ә кая... бала?!
Гөлназ. Юк, әни, бернинди дә бала юк.
Җәүһәрия. Юк?! Нишләп, син безне алдадыңмыни?
Лемонтий. Всегда и везде пользуйтесь тампксом — это очень удобно!
Гөлназ. Нишлим... Ай көттем, ике көттем... өч көттем... Юк... Димәк, врачлар ялгышканнар...
Сәрвиназ. Юк сүз. Врачлар беркайчан да ялгышмыйлар.
Җәүһәрия. Җүнсез кыз! Кая соң бала?
Җария. Апа, нишләп әле син кызыңнан бала таптырасың, ә?!
Җәүһәрия. Нәрсә соң инде бу?! Ул бит минем төшләремә үк керә башлады. Мин аны кулларыма алып назладым, иркәләдем... Ә син, кызым, минем өметемне акламадың. Мин бәхетсез, бик тә бәхетсез ана! Мә сезгә, мә! *(Халатын чишеп җибәрә.)*
Сәрвиназ *(куркып).* «Скорый», «Скорый»!

Мендәрләр коела, йон оча. Көлешәләр. Гөлназ югала. Сәрвиназ аңын
җуеп егыла. Аны, күтәреп алып, урынга салалар.

Җария *(телефоннан).* Алло! «Скорый»мы?! Тизрәк килегез! Монда сезнең шәфкать туташыгыз үләргә ята! Ха-ха! *(Трубканы куя.)*

Тархун посылканы ача. Аракы шешәләре тартып чыгара.

Тархун. Авылдан авылдашлар җибәргәннәр. Туй ясарга дип, бәби туе! Бар да бар, тик бәби генә юк! Их, Салих, Салих! Гомерем буе яратмадым эшен ахырына җиткереп эшләмәгән кешеләрне!

Гөлназ телеграмма тотып керә.

Гөлназ. Әни! Телеграмма! Салихтан!
Җәүһәрия. Укы! Ни язган?
Гөлназ. «Гөлназым! Синең алда гаеплемен... Ачуланышуыма үкенәм хәзер. Яратам, сагынам сине. Көт, тиздән кайтырмын! Риза булсаң, туй итәрбез. Үбеп, синең Салихың...» Әти! Әни! *(Тархун белән Җәүһәрияне кочаклый.)* Әни, син боларның барысын да минем өчен эшләдең бит, әйеме?!
Җәүһәрия. Ана баласы өчен ни генә кылмас, кызым!
Гөлназ. Әти, әни! Мин сезгә бик күп борчулар китердем, сез мине кичерегез инде, әгәр кичерә алсагыз?!
Җәүһәрия. Без кичермәсәк, кем генә кичерер икән, балам! Борчылыр урын юк, безгә туйга әзерләнергә кирәк! Шулай бит, туганнар?!
Бергә *(җырлап).*

Бәхет алып килсен сезгә
Тынгысыз күңелегез.
Дуслык сулышын югалтмый,
Бер юллардан йөрегез.

Кушымта:
Ак чәчәкләргә күмегез
Сез бүгенге туйларны.
Вәгъдәләшеп ярәшләшкән

Бу сөйкемле ярларны.

Тормыш юлларын кичкәндә
Теләкләр уртак булсын.
Өй тутырук бала-чага,
Колаклар чыңлап торсын.

Кушымта:
Ак чәчәкләргә күмегез
Сез бүгенге туйларны.
Вәгъдәләшкән, ярәшләшкән
Бу сөйкемле ярларны.

Пәрдә.

## ҖЫРЛАП КЕРӘБЕЗ,
## ҖЫРЛАП ЧЫГАБЫЗ

*Танылган режиссер,*
*педагог Рөстәм Фатыйховның*
*якты истәлегенә багышлыйм*

*Ике пәрдәле сатирик комедия*

**КАТНАШАЛАР:**

Дәмдинов.
Дәмин.
Дәрья.
Маһруй.
Ләлә.
Жуков.
«Сыерчык».
Бибигөлҗамал.
Официантка.
Кара кеше.

Вакыйга Архангельск шәһәрендә бара.

### БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Кунакханә бүлмәсе. Яңа гына сәфәргә чыккан Дәмин белән Дәмдинов, тыныч кына гәпләшеп утыралар.

Дәмин. Бу Архангельск шәһәренә нәрсәгә дип җибәргәннәр инде безне?! Безнең сәнгатьне аңларлык берәр кеше табылыр микән монда, ә?! (*Пауза*.) Карале, малай, теге архангел Гавриилның бу Архангельск белән берәр бәйләнеше бар микән, ә?

Дәмдинов. Бар.

Дәмин. Ә кем соң ул архангел Гавриил?

Дәмдинов. Ул безнең атабыз.

Дәмин караватка ава. Тишек оекбашын сала.

Дәмин *(шыңшып).* Күңелсез монда. Урамга чыгып, эт булып өрәсе килә. Үзебез белән, ичмасам, теге биюче кызны да алмадык. Ярап куйган булыр иде әле шунда!

Дәмдинов. Кызлар дигәннән, бер кызык нәрсә сөйлимме үзеңә?

Дәмин *(әйләнеп).* Сөйлә инде әйдә, сөйләп күңелне юатсаң гына!

Дәмдинов *(тамак кырып).* Шулай бервакыт... бер авылга концерт белән баргач, концерттан соң миңа бер яшь кенә...

Дәмин. Чибәр генә...

Дәмдинов. Әйе, чибәр генә бер артистка белән... Туктале, мин сиңа ул вакыйганы сөйләдеммени?!

Дәмин. Сөйләгән дә кебек инде, сөйләмәгән дә... Белмим... Әйдә, сөйлә инде!

Дәмдинов. Менә шул чибәр генә, яшь кенә артистка белән миңа бер йортка кунарга керергә туры килде...

Дәмин. Ә ничек керттеләр?

Дәмдинов. Кая?

Дәмин. Кунарга.

Дәмдинов. Хуҗа хатынына мин аны үземнең хатыным дип таныттым.

Дәмин. Ә ул синең хатының түгел идеме?

Дәмдинов *(кызып).* Карале, бүлдермә әле мине! Сөйләгәнне тыңла! *(Пауза.)* Төнлә теге кыз белән бергә ятып, ышын-мышын гына килә башлаган идек, чаршау артыннан килделәр дә чыктылар бит хуҗа хатынының балалары...

Дәмин. Кит аннан!

Дәмдинов. Әйе. Караңгыда күзләре генә ялтырап тора тегеләрнең. Чаршау кырыен ачып, күзәтеп торалар болар безне...

Дәмин. Ә син нәрсә?

Дәмдинов. Мин куарга тотындым. Куа гына башлаган идем, шундук әниләре дә килеп чыкты...
Дәмин. Хуҗа хатынымы?
Дәмдинов. Әйе. Үләрсең көлеп! Беләсеңме нәрсә ди?
Дәмин. Нәрсә ди?
Дәмдинов *(хатын-кыз тавышы белән).* Кума, ник куасың, баксыннар, үрәнсеннәр, ди! *(Көлешәләр.)* Менә шулай... *(Кашынып.)* Әллә бетләдем инде! Карале, таракан күп икән монда! *(Дезодорант алып сиптерә.)* Мур кыргырлары! Бу кунакханәдә шул булыр инде: йә бет, йә таракан ияртеп кайтасың. *(Тараканны куып тотып.)* Бусы безнең Казан тараканына охшаган, син ияртеп килмәгәнсеңдер ич?!
Дәмин. Юк ла... *(Иснәнеп.)* Карале, малай, син нинди ис чыгардың, ә?
Дәмдинов. Дезодорант.
Дәмин. Дезодорант белән кем таракан үтерә инде, ә?! Уф, тончыктырасың!
Дәмдинов. Аптыраганнан инде, дустым, аптыраганнан. Юрганың селке, тик ятма!
Дәмин *(кул селкеп).* Әй! Таракан бетми инде ул! Тараканcыз җир юк инде ул, бездә бит хәзер «хризис». Миңа калса, мин аларга ияләштем дә инде. Минем хәтта ул тараканны ашаганым да бар.
Дәмдинов. Синнән булыр! Син бит дуңгыз күкәе кыздырып ашаган кеше!

Дәмин чөйдә эленеп торган сушкины кулына ала. Сындырып карый.

Дәмин. Бу безнең күк мескен артистлардан калган сувенирдыр инде... *(Кимерә.)* Ай... ай... ай...
Дәмдинов. Ни булды?
Дәмин *(тешен тотып).* Шуш-кины капкан идем...
Дәмдинов. Нәрсә, нәрсә?
Дәмин. Менә шушы шушкины... әй, сушкины капкан идем, тешем төште дип торам. *(Аңкавын капшап.)* Төшмәгән, исән икән әле!
Дәмдинов. Куй урынына, йә тондыр!
Дәмин *(чөйгә элеп).* Торсын әле, киргә чыгар. *(Эчен тотып.)* Килгәннән бирле эчем быгырдап тора. Шушы гастрольгә чыксаң, гел ашыйсы гына килеп тора.
Дәмдинов. Әзрәк сабыр ит, дустым, тиздән ужин кертерләр.
Дәмин. Нинди ужин?
Дәмдинов. Легкий.
Дәмин. Ә?!
Дәмдинов. Әйе. Мин кулларны «зю-зю-кать» итеп алыйм әле.

Ванна бүлмәсенә кереп китә.

Дәмин *(киерелеп)*. И-их! Ни әйтсәң дә, гастрольдә йөрү авылда тирес эчендә казынып яту түгел шул инде. Гармун күреген генә дә тартып, үзеңә яшәрлек кенә эшләргә була икән бу дөньяда.

Поднос күтәреп калын күкрәкле, Официантка керә.

Официантка. Хәерле кич! Сигезенче бүлмәме?
Дәмин *(русчага күчеп).* Да.
Официантка. Кичке ашка заказ биргән идегезме?
Дәмин. Да.
Официантка *(подносны өстәлгә куеп).* Рәхим итегез! Ашыгыз тәмле булсын! *(Китәргә җыена.)*
Дәмин. Одну минутку...
Официантка. Тыңлыйм.
Дәмин. Гафу итегез, сезне бүген чакырырга буламы?
Официантка. Кая? Ресторангамы? Килегез, мин үзем шунда эшлим. *(Кесәсеннән лотерея билеты чыгарып.)* Лотерея алырга теләмисезме?
Дәмин *(ни әйтергә дә белмичә).* Алам. *(Акча биреп.)* Сдачи не надо!
Официантка. Хушыгыз!

Лотерея билетын Дәминнең кесәсенә тыгып чыгып китә.

Дәмин *(сокланып).* Их, шайтан алгыры! *(Котырып.)* И-хи-хи!

Пауза.

*(Дәмдиновка.)* Чык әйдә, малай, әзрәк капкалап алырга кирәк. *(Поднос өстендәге салфетканы күтәреп.)* У! Ни генә юк монда! *(Счет квитанциясен кулына алып.)* А-а-а-алты мең... алты... Менә сиңа мә! *(Подносны салфетка белән каплап, тиз генә кырыйга китеп утыра.)*

Дәмдинов керә.

Дәмдинов *(подносны күреп).* Керттеләрме? Әйбәт. Син нишләп шулкадәр моңсу утырасың?
Дәмин. Счет кәгазен укып кара, син дә моңаерсың.

Дәмдинов счет кәгазен кулына ала, күпсенеп, кашларын уйнатып тора.
Йөзеннән шатлык качса да, иптәшенә сиздермәскә тырыша.

Дәмдинов. Алты мең кыйбатрак, билгеле.
Дәмин. Кыйбат кынамы соң?
Дәмдинов. Нишләмәк кирәк, дустым, китергән әйберне кире биреп булмый, дөрес аңламаулары бар.
Дәмин. Үзең заказ бирдең, үзең аша да инде. Ә мин аның бер кисәгенә дә орыначак түгел.
Дәмдинов *(коньяк шешәсен алып).* Моның бер коньягы гына да фәлән хәтле тора!
Дәмин. Буфетка гына кереп, кәтлит ашаган булсам.
Дәмдинов. Салкын котлетмы?! Салкын котлет синең авыру ашказаныңа ярамый.
Дәмин. Ярый, бик ярый. Кыздырып ашасаң.
Дәмдинов. Борчылма, дустым, борчылырлык берни дә күрмим. Алты меңне урталайга бүлсәк, өч кенә мең туры килә бит.
Дәмин. Бер тиен дә бирмим!
Дәмдинов. Кемгә?
Дәмин. Сиңа да, дәүләткә дә.
Дәмдинов. Кызмале, кызма. Тынычлан. Сиңа бит моны бүген үк ашап бетерергә кушмыйлар. Бу ужин легкий гына булса да, безгә бер өч көнгә җитә әле ул.
Дәмин. Күрәсем дә, ишетәсем дә килми.
Дәмдинов. Дәмин, син буйдак кеше. Син инде әзрәк гаилә кешесенең хәленә керә бел. Мине өйдә хатын белән өч бала көтеп тора. Сиңа җиңел, синең, әйбер ташып, бала үстерәсең юк. *(Кесәсеннән өчкә бөкләнгән кәгазь чыгара.)* Син менә моны күрәсеңме? Син менә монда кара!
Дәмин. Күрәсем дә, ишетәсем дә килми. *(Кырын күзе белән генә кәгазьгә карый.)*
Дәмдинов. Бу кәгазьдә унбиш төрле әйбергә заказ язылган. Көзге сапожкидан башлап үкчәле галуш белән тәмамланган. Имеш, эшләгән акчамны җилгә очырмыйм, хатынга әйберләтә алып кайтам...
Дәмин. Ә алып кайтмасаң?
Дәмдинов. Алып кайтмый гына кара, җаныңа төшәчәк! *(Йөренә.)* Әле аның анысы пүчтәк, ул әле көнләшеп җанны ашый.
Дәмин. Ничек?
Дәмдинов. Менә шулай.
Дәмин. Нәрсә ди?
Дәмдинов. Син анда гастрольдә кызлар белән бик чуалып йөрмә, ди.
Дәмин. Ә син нәрсә дисең?
Дәмдинов. Мәйтәм, хатын, син юкка борчыласың, дим, мин бик тыйнак ир, дим. Хыянәт иткән очракта да син аны беләчәк түгелсең, дим!
Дәмин. Ә ул нәрсә ди?
Дәмдинов. Көлә. Кайтып кына кара, ди, кайтуга ук мин сине, ваннага салып, тикшереп карыйм, ди.
Дәмин *(шаккатып).* Кит аннан! Карале, малай, аны шулай да тикшереп карап була димени?
Дәмдинов. Була икән шул. Менә шундый зәһәр хатын белән яшим инде мин! Зәһәрнең дә зәһәре! Ә син, ашамыйм, дисең — ашарга кирәк!
Дәмин *(чыраен сытып).* Рәхмәт.
Дәмдинов *(кәефле).* Әйдә, дустым, мин сиңа «Әлфинур» җырын җырлыйм, ә?! Бәлкем, кәефең күтәрелеп китәр!
Дәмин. Җырла инде әйдә, җырлап күңел юатсаң гына.
Дәмдинов *(җырлап).*

Гөлдән алмыйм күзләремне,
Миңа ни булды икән?
Кайда соң син, мәхәббәтем,

Кайлардан эзлим икән?
Әлфинур, Әлфинур,
Чынлап әйтәм, көлмәле.
Сагынам, сагынам
Син утырткан гөлләрне.
Айный алмыйм хисләремнән,
Күзем йомып уйланам.
Сулкылдама, түз, йөрәгем,
Хәзер... хәзер уянам.
Кайда соң син, мәхәббәтем,
Кайлардан эзлим икән?
Гөлдән алмыйм күзләремне,
Әллә шул гөлдә микән?
Әлфинур, Әлфинур,
Чынлап әйтәм, көлмәле.
Сагынам, сагынам
Син утырткан гөлләрне...*

Дәмин *(кул чабып).* Маладис! *(Дәмдинов баш ия.)* Карале, малай, синең хатының Маһруй түгелме соң?

Дәмдинов. Әлфинур — минем яшьлек мәхәббәтем. Их, шуңар өйләнмичә ялгыш иттем... Әлфинур, Әлфинур дигәннән...Карале, дустым, әллә мәйтәм, номерга кызлар чакырыйкмы?

Дәмин. Без чакырдык бит инде.

Дәмдинов. Кемнәрне?

Дәмин. Теге... турист кызларны!

Дәмдинов. Ә... теге буфетта танышкан кызларны әйтәсеңме?!

Дәмин. Әйбәт кызлар.

Дәмдинов *(киная белән).* Әйбәт. Кияү эзләп йөрүче кызлар.

Дәмин. Бер төнгә ярамаган тагын.

Дәмдинов. Керерләр дип уйлыйсыңмы?

Дәмин. Керерләр инде. Чакырдык бит.

Дәмдинов. Көтәсеңме?

Дәмин. Көтәм. Тугызынчы яртыда керербез, диделәр бит.

Дәмдинов. Керми инде алар, үзең кереп чакырмасаң. Анда да әле мин кереп чакырсам гына!

Дәмин. Нигә?

Дәмдинов. Кызлар белән сөйләшә белмисең син, сөйләшә. Кызларны аларны алдый белеп алдарга кирәк. Үпкәләмә дөресен әйткәнгә. Болай булсаң, син гомердә дә өйләнәчәк түгелсең.

Дәмин. Булсын. Миңа өйләнмичә дә бик әйбәт әле.

Дәмдинов. Алай димә. Өйләнергә кирәк. Өйләнмәсәң дә, балаң булуы кирәк.

Дәмин. Алимент түләргәме?

Дәмдинов. Картлык көнеңдә балаң булуы шарт.

Дәмин. Мин әле яшь, картаймаган. Бала үстерү түгел, үземә җитәрлек акча да эшләгән юк әле. *(Пауза.)* Без синең белән юкка баш ватып утырабыз бугай. Иртәгәге концерт программасын карап чыгасы иде бит.

Дәмдинов. Нинди программа?! Миңа бернинди дә программа бирмәделәр. Аның турында сүз чыккач, безнең оешмада, беләсеңме, миңа нәрсә диделәр?!

Дәмин. Нәрсә?

Дәмдинов. Мәскәүдә булдыгыз, Питерда булдыгыз. Анда шәп кенә чыгыш ясадыгыз, инде хәзер берочтан Архангельскига да барып кайтыгыз, диделәр. Мәйтәм, Архангелда анда руслар гына яши, алар безнең сәнгатьне аңларлар микән, дигәч, алар миңа, беләсеңме, нәрсә дип җавап бирделәр?

Дәмин. Нәрсә дип?

Дәмдинов. Анда сезгә зур гына мәйдан бирерләр... Шул мәйданга җырлап керерсез, җырлап чыгарсыз, диделәр.

Дәмин *(уйланып).* Мине бернәрсә бик тә борчый әле, малай!

Дәмдинов. Нәрсә?

Дәмин. Нишләп безне монда беркем дә каршы алмады?

Дәмдинов. Каршыларлар, тот капчыгың! Син нәрсә, безне ипи-тоз белән каршы алырлар дип уйладың мәллә?! Менә шушы номерга бронь, ягъни «борын» биргәннәре өчен дә рәхмәт әйт инде син!
Дәмин. Әллә керергә инде?
Дәмдинов. Кая?
Дәмин. Кызлар янына. Алар йөз дә беренче бүлмәдә яшиләр бугай.
Дәмдинов. Кер, бар!

Телефон шалтырый.

Дәмин *(трубканы алып).* Да, алло! Роддом?! Нет, это не роддом! Карале, товарищ, это гостиница, а не роддом! Да, роддом... нет, гостиница... роддом... нет... не гостиница... род... *(Буталганын аңлап.)* Тфү! Алло...

Ишек шакыйлар.

Дәмдинов. Куй трубкаңны! Ишек шакыйлар!

Зәвык белән киенгән Дәрья керә.

Дәрья. Мөмкинме?
Дәмдинов. Мөмкин. Керегез.
Дәмин *(трубканы куеп).* Мөмкин! Бик мөмкин!
Дәрья. Хәерле кич!
Дәмдинов. Хәерле кич! Утырыгыз!

Дәмин урындык бирә. Дәрья утыра.

Дәрья. Рәхмәт. Минем болай тиктомалдан гына килеп керүемә исегез китмәсен...
Дәмдинов *(елмаеп).* Юк, без бик шат.
Дәмин. Без шундый шат.
Дәмдинов. Без сезне үзебез үк кереп чакырмакчы идек. Бигрәк тә дустым бик зарыкты, сезне көтеп... *(Дәрьяның каршысына килеп утыра.)*
Дәрья. Без иптәш кызым белән, көне буе кибетләрдә йөреп арыгач, кайттык та яттык. Иптәш кызым шундук йокыга китте, ә мине нигәдер йокы алмый. Утырдым-утырдым да, нишләргә белмәгәч, туктале, яңа танышларымны күреп чыгыйм әле дип, сезнең янга кердем.
Дәмдинов *(Дәминне Дәрьядан каплап).* Әйбәт, бик әйбәт.
Дәмин *(бер алга, бер артка чыгып).* Әйбәт кенәме соң, шә-ә-әп!
Дәрья *(кинәт).* Сигарет юктыр?
Дәмдинов. Сигарет юк, без тартмыйбыз.
Дәмин. Юк, без тартмыйбыз. *(Пауза.)* Хәзер табып керәм!

Дәмин ашыгып чыгып китә.

Дәмдинов. Сезнең өчен кечкенә генә өстәл әзерләткән идек. *(Салфетканы алып ыргыта.)*
Дәрья *(табынны ошатып).* О!
Дәмдинов. Коньяк! Телисезме?
Дәрья. Рәхмәт. Каршы килү уңайсыз булыр инде, салыгыз әз генә...
Дәмдинов *(коньяк салып).* Әз генә... *(Чәкештереп эчәләр.)* Шоколад...
Дәрья *(шоколад алып).* Мерси.
Дәмдинов. Димәк, сез Дәрья буласыз... Нижгардан... Ә монда ял итәргә килдегезме?
Дәрья. Әйе. Туристик путевка белән.
Дәмдинов. Димәк... таш карарга!
Дәрья. Нинди таш?
Дәмдинов. Э... э... Борынгы тарихи ташлар... музейлар, димәкче идем...
Дәрья. Юк. Бәхеткә каршы, мине музейлар, ташлар кызыксындырмый. Монда килгәннән бирле әле безнең кибетләрдән бушый алганыбыз юк.
Дәмдинов. Туристлар шулай инде ул, барган җирләреннән әйбер җыеп кайтмасалар, күңелләре булмый.
Дәрья. Ә сез гастрольдә инде?
Дәмдинов. Әйе, без — артистлар.
Дәрья. Гафу итегез, исемегезне онытым.

Дәмдинов. Дәмдиныч. Дустымныкы — Дәмин.
Дәрья. Сәер исем.
Дәмдинов. Исем түгел, псевдоним ул.
Дәрья. Аха! Артист буларак нәрсә башкарасыз инде?
Дәмдинов. Халык җырлары. Мин — җырчы, дустым — гармунчы. Тик без халык җырлары, ягъни фольклор белән генә чикләнмибез. Без бөтен төр сәнгатьне дә башкарабыз. Телисезме танго биергә?

Музыка яңгырый. Дәмдинов, Дәрья, хисләнеп, танго бииләр.

Дәрья. Сез өйләнгәнме?
Дәмдинов *(уйланып).* Әлегә юк... юк... әлегә...
Дәрья. Ә дустыгыз?
Дәмдинов. Белмим. Анысын инде үзеннән сорагыз.

Дәрьяны кочаклый. Битеннән үбә.
Дәмин керә. Кулында бер пачка «Беломорканал».

Дәмин *(Дәрьяга папирос сузып).* Таптым. Рәхим итегез!
Дәмдинов. Тапкансың инде! Ахмак. Кызлар папирос тарталар димени инде!
Дәрья *(папиросны алып).* Рәхмәт.
Дәмин. Сигарет юк. Коридорда мужиклар гына иде.
Дәрья. Борчылмагыз. Төтене чыккач барыбер түгелмени! Беләсегез килсә, патша заманында аристократлар сигаретка караганда папирос тартуны кулайрак күргәннәр.

Дәрья папирос тарта. Дәмдинов рюмкаларга коньяк сала. Дәмин
кырлы стакан китереп куя.

Дәмдинов *(Дәмингә).* Сиңа да салыргамы?
Дәмин. Сал!
Дәмдинов. Ярамас булмасын.
Дәмин. Сал, үлмәм әле! *(Коньяк эчеп җибәрә.)* Үтүкли... язвене...
Дәрья *(көлеп).* Күңелле сезнең белән!
Дәмдинов. Безнең белән һәрвакытта да күңелле.
Дәмин *(тончыгып).* Мөмкинме... сезгә бер сорау...
Дәрья. Мөмкин.
Дәмин. Сезгә ничә яшь?
Дәмдинов. Ахмак. Кем инде кызларның яшен сорый ди, ә?!
Дәрья. Зарар юк. Мин яшемне, гомумән, беркайчан да яшергәнем булмады. Егерме алты.
Дәмдинов. О! Вакыт инде.
Дәрья. Нәрсәгә вакыт?
Дәмдинов. Кияүгә чыгарга.
Дәрья. Әйе... вакыт... бик вакыт.
Дәмин. Ә нишләп чыкмыйсыз?
Дәрья. Аласызмы соң?
Дәмин. Алам. Бүген үк.

Шәрык стилендәге көй яңгырый.

Дәрья *(җырлап).*

Мин кияүгә чыкканым юк,
Кияүсез торганым юк.
Чөнки миңа болай рәхәт,
Өстем бөтен, тамак тук.
Аласыгызмы соң?

Дәмин *(җырлап).*

Чыгасыгызмы соң?
Кияү табалмаган кызлар
Ташкентка дип китәләр.
Шунда шул як халкы белән
Кияүләшеп бетәләр.

Дәрья.

Аласыгызмы соң?

Дәмин.

Чыгасыгызмы соң?

Дәрья.

Анда кияүгә чыкмаган
Бер үзбәк тә калмады.
Инде монда килгән идем,
Бер урыс та алмады.
Аласыгызмы соң?

Дәмин.

Чыгасыгызмы соң?
Пожалуй, мин сезне бүген
Берәр кичкә алырмын.
Караңгылар төшсен әле,
Берәр җаен табармын.

Дәрья.

Аласыгызмы соң?

Дәмин.

Чыгасыгызмы соң? *(Кочаклашып торалар.)*

Дәмдинов. Кыхым! Беләсегез килсә, Дәрья, без бит универсаллар! Без бөтен төр сәнгатьне дә башкарабыз!

Дәрья. Ничек?

Дәмдинов. Телисезме — театр! Телисезме — цирк!

Дәрья. Ой! Мин цирк трюкларын бик яратам!

Дәмдинов *(кызып).* Мөмкин ул, мөмкин! Дәмин! Сал ыштаның!

Дәмин. Нәрсә?!

Дәмдинов *(ыштанын салып).* Ыштаның сал!

Дәмин. Нигә?

Дәмдинов. Сал, диләр сиңа! *(Коньяк эчеп.)* Дәрьяга цирк күрсәтәбез! Ламбада!

«Ламбада» көе яңгырый. Дәмин, Дәмдинов, ыштаннарын салып, ламбада бииләр.

Дәрья *(кул чабып).* Ой!

Дәмдинов. Архангельскида беренче вә соңгы мәртәбә «смертельный» номер! Дәмин, сикер!

Дәмдинов Дәминне, ковбой үгезне котырткан кебек, кызыл яулык белән котырта. Дәмин Дәмдиновның кул өстенә сикерә. Дәмдинов кулын тартып ала, Дәмин идәнгә барып төшә. Жуков керә. Шаккатып карап тора.

Дәрья. Ой, үләм! *(Кул чабып көлә.)*

Дәмдинов. Алле-хоп!

Дәмин, Дәмдинов тамашачылар алдында баш ияләр. Тагын куышып китәләр. Чак кына Жуковны бәреп екмыйлар.

Жуков. Исәнмесез!

Дәмдинов *(айнып).* Исәнмесез!

Жуков. Сез Казан артистларымы?

Дәмдинов. Әйе. Без — Казан артистлары.

Жуков. Яхшы. Репетиция ясыйсызмы?

Дәмин. Юк... без... ни...

Дәмдинов. Әйе, без репетиция ясыйбыз.

Жуков. Бик әйбәт. Таныш булыйк: Андрей Николаевич Жуков. Тамашалар режиссеры булам.

Дәмдинов *(ыштанын киеп).* Дәмдинов.

Дәмин. Дәмин. *(Кул биреп.)* Нихәл, брат...

Жуков. Бер генә минут. *(Дипломаттан кәгазь белән ручка чыгарып.)* Менә шушы исемлеккә кул куегыз әле!

Дәмдинов

Дәмин } *(шикләнеп).* Нигә? Юк, куймыбыз! Кул куеп күп яндык инде!

Жуков. Иртәгә тамашада катнашачак һәрбер артистка кечкенә генә сувенир бирелә. Матрешкалар!

Дәмин. О! Моңа куйсаң ярый!

Жуков Дәмин белән Дәмдиновка ике кечкенә матрешка бирә.

Жуков *(Дәрьяга).* Ә бусы сезгә! *(Матрешканың иң зурысын бирә.)*

Дәрья *(матрешканы алып).* Рәхмәт.

Жуков *(пафос белән).* Иртәгә Үзәк мәйданда булачак тамашаның режиссеры буларак, мин сезгә менә нәрсә әйтмәкче идем...

Дәмин. Гафу итегез!

Жуков. Әйе.

Дәмин. Бер генә сорау бирергә мөмкинме?

Жуков. Әйе, тыңлыйм.

Дәмин. Гафу итегез, сез Жуковның туганы түгелме?

Жуков. Нинди Жуков?

Дәмин *(үрә катып).* Маршал Жуков!

Жуков. Юк, ялгышасыз. Мин, гомумән, хәрбиләр нәселеннән чыккан шәхес түгелмен, мин — мәдәният хезмәткәре.

Дәмдинов *(Дәмингә).* Ыштаның ки, ахмак!

Дәмин, ашыга-ашыга, ыштанын кия. Дәрья көлә.

Жуков. Мин ике генә артист чакырган идем. Чибәр ханым да сезнең беләнме?

Дәмдинов. Юк, ул безнең кунагыбыз. Дәрья.

Жуков. Кунак кызы... Әйе, әйе, аңлыйм... Гафу итегез... *(Дәрьяның матрешкасын, кире алып, дипломатына ташлый.)*

Дәмдинов. Ул безгә кунакка дип керде.

Жуков. Күрәм, күрәм... *(Өстәлгә күзе төшә.)*

Дәмдинов. Рәхим итегез! Сез киләсен белгәч, кечкенә генә табын көйләп җибәргән идек.

Жуков *(сәгатенә карап).* Юк, юк, минем вакытым тар. Әйдәгез, эшкә керешик!

Дәрья. Миңа вакыт. *(Китәргә кузгала.)*

Дәмдинов. Сез кая?

Дәрья. Номерга. Йокларга вакыт җитте.

Дәмдинов. Йокларга?

Дәрья *(йомшак кына елмаеп).* Әйе. Бай-бай!

Жуков *(кесәсеннән блокнот чыгарып).* Менә бу блокнотта язылган берничә мөһим пунктка тукталып киткәнче, минем сезгә берничә сорау бирәсем килә...

Дәмдинов. Гафу итегез, биш кенә минут!

Жуков. Аңламадым?

Дәмдинов. Биш кенә минут сабыр итсәгез иде, мин кунак кызны гына озатып керим.

Жуков *(чыраен сытып).* Яхшы...Ну, биш кенә минут, озак йөрмәгез! Вакыт тар. Иртәгә тамаша. Минем әле сездән башка да берничә кешене күрәсем бар.

Дәмдинов. Мин хәзер. *(Дәрьяга.)* Киттек әйдә!

Дәмин *(араларына кереп).* Әллә мин генә озатыйммы?

Дәмдинов. Т-с-с! Мин исерек, аңлыйсыңмы?! Минем хәзер режиссерга әллә нәрсә сөйләп атуым бар... Мин хәзер...

Кесәсенә коньяк тыгып, Дәрья артыннан чыгып китә.

Жуков. Биш минут, биш минут...

Дәмин. Әйе... биш минут. Биш минуттан чыгар ул...

Жуков. Чыгар микән?

Дәмин. Чыгар... әйткәч чыгар...

Жуков, өстәл артына утырып, капкалап ала. Дәмин дә кушыла. Гомер ашамаган сымак ашый.

Жуков. Миңа хәзер вакыт алтын белән бер. Сезнең программагыз белән танышып аласы иде.

Дәмин. Ә безнең программабыз юк.

Жуков *(исе китеп).* Юк?!

Дәмин. Әйе, безнең җыр программабыз юк.

Жуков. Миңа җыр кирәкми, миңа клоунада кирәк.

Дәмин. Без бит клоуннар түгел сезгә, клоунада ясарга.

Жуков. Ә кем соң сез?

Дәмин. Мин — гармунчы, дустым — җырчы.

Жуков *(ашавыннан туктап).* Аңламадым. Сез клоуннар түгелмени?

Дәмин. Юк.

Жуков *(торып).* Сәер. *(Кашыгын кесәсенә сала.)* Мин бит сезне клоуннар дип аңладым. Мин кергәндә, сез клоунада ясыйдыр идегез түгелме?!

Дәмин. Юк ла... Без бит юләрләндек кенә...

Жуков *(каушап).* Берни дә аңламыйм. Мин бит, тамаша уздыру өчен, Казаннан клоуннар сорадым. Яңалык булсын өчен. Ә алар миңа ниндидер җырчылар, гармунчылар җибәргәннәр. Сез каян соң? Цирктан түгелмени?

Дәмин. Юк. Без җыр оешмасыннан.

Жуков. Бетте баш! Сез мине астыгыз, сез мине кистегез, сез мине пычаксыз суйдыгыз! Бүгенге көннән башлап минем карьерам, минем шулкадәр тырышып яулаган карьерам җилгә очты, җил-гә! *(Җырлый.)*

Хыяллар буа буарлык,
Гомереңә җитәрлек.
Тормышка ашыра калсаң,
Колымага китәрлек.
Ни пычагыма тотындым,
Ник алындым бу эшкә?
Мең утыз сум алып була,
Эшләмәгән килеш тә.
Нигә кирәк соң ул миңа
Төньяк коэффициентлары?
Чукынып китсен иде лә
Бәйрәме, концертлары!
Сау бул, карьерам, сау бул,
Гаепләмә, бәхил бул!
Иртәгә соңгы һөҗүмгә —
Жуков булсаң Жуков бул!
Ни пычагыма тотындым,
Ник алындым бу эшкә?
Мең утыз сум алып була,
Эшләмәгән килеш тә...

Дәмин *(боегып).* Борчылмагыз... без — универсаллар... без ясарбыз... тамаша...

Жуков *(кызып).* Мин ышанмыйм, сез нәрсә дә булса башкара алырсыз дип. Миңа клоуннар кирәк, миңа халыкны көлдерергә кирәк!

Дәмин. Без... көлдерербез...

Жуков. Рәхмәт, көлдердегез инде! Сезнең оешмагызда нинди ахмаклар утыра соң анда?! Нишләп соң алар сезне җибәргәннәр? Ахмаклар! Бетте! Бетте баш! Бетте карьера! Шуның белән минем карьерам тәмам! Әгәр дә иртәгә тамаша өзелсә, мин бөтен халык алдында көлкегә калачак. Халык ерунда, ә менә начальство ни әйтер?! Тамаша өзелсә, баштан сыйпамаслар, билгеле! Эштән куарлар, хатыным ташлар! Ә балаларым, балаларым миннән, бармак төртеп, «тамаша корбаны» дип көләрләр...

Дәмин. Борчылмагыз... Бар да әйбәт булыр... Без күрсәтербез...

Жуков. Нәрсә? Мин әле монда бернәрсә дә күрмим!

Дәмин. Мин үзем генә күрсәтә алмыйм, дустым кирәк.

Жуков. Ә кая соң ул синең дустың? Тәмугка олактымы әллә?

Дәмин. Кызлар күрсә, шулай инде ул, бөтен дөньясын оныта.

Жуков. Их, артыгызга тибеп, Казаныгызга гына кайтарып җибәрергә! *(Пауза.)* Йа Хода! Нишләп кенә мин бу эшкә алындым икән?! Акча кирәк булдымы? Үземне күрсәтергә уйладыммы? Дан кирәк булды-

мы? Аңламыйм, ни кирәк булды миңа? Аллаһы Тәгаләнең хәерсез сәгатенә туры килгән икән теләгем! Прости меня, о Боже! *(Чукына.)*

Официантка керә.

Официантка. Хәерле кич!
Жуков. Хәерле кич!
Официантка *(Дәмингә).* Ашап бетердегезме?
Дәмин *(сагышланып).* Да вруде...
Официантка *(подностан счет кәгазен алып).* Сездән алты мең дә биш сум. Хәзер үк түләгез!
Дәмин. Не...ту...
Официантка. Нәрсә не...ту?
Дәмин. Денег... не...ту...
Официантка. Ничек не...ту? Акчагыз булмагач, нишләп соң заказ бирдегез?
Дәмин *(кызып).* Әй, кардәш, не я заказывал, другой татарин заказывал! *(Ишек ягына күрсәтә.)*
Официантка. Аха! Кем ул «другой татарин»? *(Жуковка.)* Сезме? Сездән алты мең дә биш тәңкә!
Жуков. Извините, я не татарин! Татарин там, ушел на пять минут. Сейчас вернется! Мин... кунак... эш белән килдем... Кирәк икән, менә документымны... *(Кесәләрен актара.)* Менә... *(Кесәдән кашык килеп чыга.)*
Официантка *(кашыкны тартып алып).* Аха! Кашыкларга кадәр урлыйлар!

Кашык белән Жуковның башына бәрә.
Жуков коридорга чыгып кача.

Официантка. Сез нәрсә, миннән көләсез мәллә?! *(Дәмингә.)* Түлә хәзер үк!
Дәмин. Подождем.
Официантка. Кемне?
Дәмин. Сейчас... другой татарин придет...
Официантка *(чыгырыннан чыгып).* Сез нәрсә, миннән көләргә уйладыгыз мәллә?! Юк, мин моны болай гына калдырмыйм, күрсәтәм мин сезгә кирәгегезне! *(Телефон трубкасын ала.)* Алло! Милиция!
Дәмин *(куркып).* Түте, не надо, түте, не надо... түте... *(Телефонга ябыша.)* Не надо! Мә, чукынып кит! *(Чалбар ерымын чишеп җибәрә. Чалбар төбенә тегелгән яшерен кесәсеннән акча чыгара башлый. Официантка, башка нәрсә уйлап, урын өстенә ава. Куркып, сыбызгысын сызгырта.)* Мә, түте, мә! Ал, мә! Алты меңне ал...Тик биш тәңкәсе юк... *(Акчаны суза. Чалбарын төймәли.)*
Официантка *(җиңел сулап).* Ух! Тәмам котны алдың! *(Акчаны алып.)* Кара аны, поднос белән биш тәңкәне төшерергә онытма!

Зарланып, тиз-тиз атлап чыгып китә.

Дәмин *(моңсу).* Уф... Үләселәрем бар икән... Аллага шөкер, китте!

Сыбызгы сызгыртып, Официантка керә.

Официантка. Кая минем туфлиләрем?! *(Табып.)* Уф, монда икән! Кара син аларны, ә!

Туфлиләрен киеп чыгып китә. Жуков керә.

Жуков. Ярар, миңа китәргә вакыт. *(Дәмингә.)* Менә нәрсә, иптәш, мин сезне тыңладым, инде хәзер сез мине тыңлагыз. Билгеле, эшнең болай килеп чыгуына сез гаепле дә түгелдер, сезне җибәрүчеләр гаепледер. Сезнең миңа кирәгегез булмаса да, мин сездән бөтенләйгә баш тарта алмыйм. Кирәк булуыгыз бар. Тамаша иртән-иртүк сәгать җидедә башлана. Билгеле, сезнең нәрсә дә булса башкара алачагыгызга мин инде ышанмыйм, шулай да сезнең анда булуыгыз кирәк. Һич югында, начальство күрер үзегезне! *(Сәгатенә карап.)* Хушыгыз! Иртән сәгать җидедә Үзәк мәйданда!

Дипломатын күтәреп чыгып китә.

Дәмин. Таладылар, кычкыртып таладылар. *(Гармунын алып җырлый.)* Сагындым, сагындым, би-и-ик сагындым... *(Елый.)*

Дәмдинов керә.

Дәмдинов. Кемне шулкадәр сагындың? Мине түгелдер ич? *(Пауза.)* Нигә дәшмисең? Ни булды? Үпкәләдеңме?
Дәмин. Авыр чакта дусларны ташлап китмиләр.

Дәмдинов. Ә ни булган? Мин бит сине чүлдә йә булмаса ачык диңгездә ташлап калдырмадым, син бит номерда калдың.

Дәмин. Официантка алты меңемне алып чыгып китте! Инде акча да калмады...

Дәмдинов. Аптырама, миндә акча бар, бирермен.

Дәмин. Ә иң кызыгы, беләсеңме, нәрсә?!

Дәмдинов. Нәрсә?

Дәмин. Архангелга без бөтенләй килергә тиеш булмаганбыз. Аларга клоуннар кирәк, ә клоуннар урынына тотканнар да безне җибәргәннәр.

Дәмдинов. Шулаймыни?! Ә режиссер нәрсә ди?

Дәмин. Сүкте. Иртәгә иртүк Үзәк мәйданга чакырды. *(Пауза.)* Җәзаларгадыр инде! *(Пауза.)* Нишлибез?

Дәмдинов. Кайгырма. Күрсәтербез без аларга тамаша! Дәмдинов махы бирмәс! Дәмдинов күрсәтер аларга кәмит! Моңсуланып утырма. Бар, Дәрьяларга кереп чык.

Дәмин. Син анда булдың бит инде.

Дәмдинов. Булса ни. Мин булган җирдә сиңа булырга ярамыймыни?! Ул сине чакырды.

Дәмин *(дәртләнеп).* Чынлапмы?

Дәмдинов. Чынлап.

Дәмин. Ә син кермисеңме?

Дәмдинов. Юк. Минем инде кызлар куып йөри торган чакларым үтте. Кызыгын тапмыйм. Бар, бар, ул сине чакырды.

Дәмин. Әллә барырга инде?! *(Тамашачыларга.)* Барыйм микән?

Дәмдинов. Бар, бар. Кызлар кочагына кергәч, әзрәк тормыш мәшәкатьләрен онытып торырсың.

Дәмин. Ярар, мин киттем! *(Китәргә кузгала.)*

Дәмдинов. Бар әйдә, бар. Уйлаган уең Аллаһы Тәгаләнең хәерле сәгатенә туры килсен! *(Дәминне чыгарып җибәрә. Телефон шалтырый, трубканы алып.)* Алло! Әйе, роддом, роддом! Кем туган? Коммунизм! Карале, иптәш, коммунизмның туганы һәм туачагы да юк! *(Трубканы ташлый.)*

Дәмин керә.

Дәмин. Ярар, мин киттем инде...

Дәмдинов. Әле син китмәдеңмени?!

Дәмин. Озаграк торсам, борчылма, мин үз вакытым белән кайтып җитәрмен. Исән-сау гына кайтырга насыйп иләсен иде инде...

Дәмдинов. Бар инде, бар! *(Дәминне чыгарып җибәрә.)* Ахмак! *(Уйланып.)* Бик тә уңышсыз сәфәр булып чыкты әле бу! Каһәр төшкән сәфәр! Артистларны болай да кешегә санамыйлар инде безнең илдә, бигрәк тә яшьләрне! Этеп-төртеп йөртәләр бер урыннан икенче урынга! *(Пауза.)* Яшьтән үк өйләнеп ялгыштым, ахрысы! Чын мәгънәсендә сәнгать белән шөгыльләнәсе урынга, үземне көчләп гаилә баткаклыгына батырдым. Артист буларак мин үземне югалтып барам кебек, роботка әйләнеп барам... *(Пауза.)* Их, калага кайтып, дусларны җыярга да яңа бер театр ачып җибәрергә иде! Бөтен сәнгать дөньясының астын өскә китерергә иде! *(Урындыкка менеп баса.)* Юк! Әле мин сәнгать өчен үлмәгән, артист буларак соңгы сүземне әйтмәгән! Иртәгә тамаша! Ә тамаша юмордан башлана...

«Сыерчык» керә. Чапан кигән. Кулында раскладушка. Сәлам дә бирмичә, раскладушкасын җәеп йокларга ята.

Дәмдинов *(пафос белән).* Әй син, кеше! Кем син?! Нишләп йөрисең? Кем син?! *(«Сыерчык»ны якасыннан тартып торгыза.)*

«Сыерчык» *(буылып).* У...у...у...

Дәмдинов *(йолкып алып).* А ну-ка матай отсюда!

«Сыерчык». Кума... бу минем урын...

Дәмдинов. Нишләп синең урының булсын ул! Бу — ике кешелек номер. Ә син өченчегә тыгыласың. А ну-ка, матай, матай отсюда!

«Сыерчык». Кума... админстрат кушты...

Дәмдинов. А ну матай! Нишләп әле мин сине кертергә тиеш?! Бәлкем, син карактыр! А ну матай отсюда! *(«Сыерчык»ны куып чыгара. Телефон шалтырый, трубканы алып.)* Алло! Ниткән коммунизм тусын! Әйттем бит инде, аңа аборт ясаганнар, аборт! *(Трубканы ата.)*

«Сыерчык» керә.

Дәмдинов. Тагын кердеңме?!

«Сыерчык». Зинһар, кума. Мин җылы яктан килдем... Эш эзләп йөрим. Кума. Ятим балаларым хакына кума!

Дәмдинов. Кем кертте сине монда?

«Сыерчык». Админстрат.

Дәмдинов. Администратор? Акча төрттеңмени?!

«Сыерчык». Нәрсә?

Дәмдинов. Акча бирдеңмени? Сәмән төрттеңме, сәмән?!

«Сыерчык». Ие... төрткән идем шул.

Дәмдинов. Акча дигәндә чукына да китә халык. Ярар, кал инде алайса. Тик кара аны, кеше әйберсенә тиясе булма!

«Сыерчык». Тиямме соң инде, Аллам сакласын! Кеше әйберенә тию Ходай каршында зур гөнаһ.

Дәмдинов. Анысын белгәч әйбәт инде. Алайса, бөтенләйгә кал.

«Сыерчык». Рәхмәт инде... Аяк-кулларың сызлаусыз булсын... *(Тезләнә.)*

Дәмдинов *(кагылып)*. Булсын, булсын... Ярар, ят инде, бик күп сөйлисең...

«Сыерчык». Карале, сиңа да төртимме?

Дәмдинов. Төртмә, кирәкми. Ярар, ят, күп сөйләнмә, алайса куып чыгарам хәзер!

«Сыерчык» раскладушканы җәеп куя да шундук йокыга китә.

Арыган... мескен... Ярар, миңа да йокларга кирәк... Иртәгә тамаша, ә тамашадан күзләр камаша... *(Йокларга ята.)*

Ут тоныклана. Җырлый-җырлый Дәмин керә.

Дәмин *(җырлап).*

Менә, малай, шул эчүнең
Тәме бар бит, нәгеләт.
Йөз грамм каплап куйгач та,
Кузгала начар гадәт:
Иң элек аласы килә.
Алгач саласы килә.
Алгач-салгач, Соняларда
Кунып каласы килә.
Әйтсәм әйтим сезгә дөресен:
Эчеп ачыла күңел.
Эчеп ачылмаган күңел
Мәңге ачылачак түгел...
Иң элек аласы килә.
Алгач саласы килә.
Алгач-салгач, Соняларда
Кунып каласы килә...

*(Сөйләнеп.)* Не везет мне, вәт не везет! Пачему мне не везет?!

Дәмдинов *(уянып).* Ни булды?

Дәмин. Карале, малай, синең сәгатең ничә?

Дәмдинов. Минем сәгатем берәү генә.

Дәмин. Шаярмале, сәгатең ничә?

Дәмдинов *(сәгатенә карап).* Төнге бер.

Дәмин. Минеке дә төнге бердә...

Дәмдинов. Котлыйм.

Дәмин. Ә нишләп алай соң ул?

Дәмдинов. Нәрсә алай?

Дәмин. Сәгать төнге бер!

Дәмдинов. Ә ничә булырга тиеш соң ул?

Дәмин. Сәгать төнге бер. Ә төн яп-якты. *(Пауза.)* Ә нишләп соң төн якты? Нишләп караңгы төшми?

Дәмдинов. Нигә соң сиңа караңгы?

Дәмин. Соң, мин бит кызлар янына кергән идем, ә бүлмәләре яп-якты. Бүлмәдә ике кыз. Берсе янына барып ятар идең, икенчесе карап тора. Икенчесенә барыр идең, тегесе күзен акайта.

Дәмдинов. Йә, йә!

Дәмин. Караңгы төшкәнне юләр кебек көттем-көттем дә, төшмәгәч, чыктым да киттем... Нишләп караңгы төшми соң, ә?!

Дәмдинов *(көлеп).* Син үзеңнең Архангелда икәнеңне оныттыңмыни?!

Дәмин. Ә нәрсә?

Дәмдинов. Архангел шәһәре төньяк ярымшарда урнашкан. Шуңа күрә дә монда җәй көннәрендә караңгы төшми, ак төннәр була.

Дәмин. Ак төннәр?

Дәмдинов. Әйе, дустым, ак төннәр.

Дәмин *(ачудан).* Кадалып кына китсен бу ак төннәре! Не везет мне, вәт не везет! Авылга гына кайтып, берәр сыер савучыга, берәр гертрудага гына өйләнгән булсам, хәзер май белән каймак кына ашап яткан булыр идем. Бәлки, бу ашказанымдагы язвеләрем дә булмаган булыр иде... *(«Сыерчык»ны күреп.)* Ә бу кем тагын?

Дәмдинов. Кунак... Җылы яктан килгән... сыерчык...

Дәмин. Ни пычагыма безгә сыерчык?

Дәмдинов. Урнаштырганнар. Нигәдер бик шикле күренә ул.

Дәмин. Миңа да шулай тоела. Акчаны яшерергә кирәк. Синең акчаң кая?

Дәмдинов. Чалбар кесәсендә. Уң ягында.

Дәмин. Ә кая яшерәбез?

Дәмдинов. Кая яшерсәң дә табар ул аны. Син ишекне биклә дә ачкычны яшер. Акчаны алса да, чыгып кача алмас.

Дәмин. Ну баш та инде синдә, Дәмдиныч! *(Ишекне бикли. Ачкычын трусик кесәсенә сала. Салкын тимер ачкычтан җиңелчә генә калтыранып ала.)* И-хи-хи! Тыныч йокы!

Дәмдинов. Тыныч йокы!

Дәмин йокыга китә. Тынлык урнаша. «Сыерчык», торып, бүлмә буенча йөренә. Әйтерсең ул кече йомышын үтәргә йөри. Туктап, Дәмди-
новның чалбарын күтәрә, кесәләрен капшый.

«Сыерчык». Кая соң моның уң ягы? Ә, менә икән! *(Кесәдән янчык алып, ишеккә ташлана.)* Ябык... Бикле... Ачкыч...

Дәмин янына килә. Матрас, карават асларын тикшерә.
Дәмин төшендә кычкырып җибәрә. «Сыерчык», куркып, ишек ягына сикерә. Ишекне тарта. Шыңшый. Ишек ачылмый. Тезләнеп йокыга тала.

Дәмин *(төшендә).* Дәрья! Дәрья! Якты хыялым минем, сөеклем, Дәрья! Син булганда, караңгылык миңа куркыныч түгел, яктылык өстә минем караңгы төнемә, Дәрья!

Музыка агыла. Бүлмәдә Дәрья, фәрештә кыяфәтендә — озын ак күлмәктән пәйда була. Ул биеп ала. Дәмин, торып, биюгә кушыла.

Дәрья *(дәртле).* Дәмин!

Дәмин. Дәрья! Син — изге! Син минем ялваруларымны ишеттең, Дәрья! Мин сине егетләр эзләп йөрүче кыз гына дип уйлаган идем, ә син изге икәнсең, фәрештәм син минем, Дәрья!

Дәрья югала. Официантка пәйда була.

Дәмин *(сискәнеп).* Син кем? Сиңа ни кирәк?!

Официантка *(Дәминнең башына кашык белән бәреп).* Биш сум да биш сум — була ун сум! *(Кычкырып.)* Подносны төшерергә онытма! *(Югала.)*

Дәмин *(кычкырып)*. А-а! *(«Сыерчык»ның якасыннан каптырып ала.)*

«Сыерчык» *(тыпырчынып).* Җибәр! Җибәр! Миңа берни дә кирәкми! Ишекне ач! Ишекне! *(Янчыкны атып бәрә.)*

Дәмин ачкыч белән ишекне ача. «Сыерчык» чыгып кача.

Дәмдинов *(уянып).* Ни бар анда?

Дәмин. Сыерчыкны чыгарып җибәрдем. Җылы яктагы туганнарын сагынган. *(Урынга барып ава.)*

Дәмин, Дәмдинов тагын йокыга китәләр.

Дәмдинов *(төшләнеп).* Маһруй! Маһруй!

Бүлмәдә Маһруй пәйда була. Кулына саберке тоткан.

Маһруй *(Дәмдиновка).* Ә! Кайттыңмы?!

Дәмдинов *(дәшеп).* Маһруй... кил... ят яныма...

Маһруй *(борынын җыерып).* Фу! Эт! Архангел марҗалары кырында йөреп сасып беткәнсең! Синең шул булыр инде, гастрольдән кайтасың да ятасың, кайтасың да ятасың. Биш балага өч жвачка алып кайткансың!

Дәмдинов. Биш?! Каян килеп биш? Мин киткәндә өчәү генә иде ич алар! *(Маһруй каршына килә.)*

Маһруй *(чәчрәп).* И! Синең шул булыр инде! Көнләшеп теңкәмә тиясең! Менә мин сине үзеңне ваннага салып карыйм әле, суга салып! *(Дәмдиновның җилкәсенә менеп кунаклый.)* Давай, давай! *(Дәмдиновны себерке белән кыйный. Куалый.)*

Дәмдинов. А-а! *(Ишеккә чаба. Маһруй югала. Дәмдинов уяна.)* Уф! Аллага шөкер! Төш кенә икән! *(Утны сүндереп ята. Йокыга тала.)*

Бүлмәдә Жуков пәйда була. Трусиктан. Култык астында дипломат.

Жуков. Иптәшләр! Бүген сез күрергә теләгән артистлар тамаша кылырга килмәде! Алар урынына мин калдым. Телисезме, мин үзем сезгә цирк күрсәтәм! Алле-хоп! Алле-хоп! *(Сикереп-сикереп ала.)* Алле-хоп! *(Пауза.)* Бүгенге тамашаны өзүчеләр менә шушы җылы номерда тыныч кына йоклап яталар. Нинди җәза бирергә аларга, ә?! Ә?! *(Аягы белән каты итеп идәнгә тибә.)*

Дәмдинов, Дәмин сикереп торалар. Жуков югала. Икесе дә Жуковны эзлиләр. Бер-беренә килеп бәрелгәч, кисәк кенә уянып китәләр. Ут
кабына.

Дәмин. Дәмдиныч... Мин шундый төш күрдем, малай, шундый төш... Төшемә фәрештә керде... Ап-ак фәрештә... Мин аны кочып алмакчы гына идем, ниндидер кара көчләр аны җәһәннәмгә олактырдылар...

Дәмдинов *(күзләрен уып).* Мин дә күрдем...

Дәмин. Нәрсә күрдең?

Дәмдинов *(ялганлап).* Мин үземне сәхнәдә күрдем. Рәхәтләнеп җырладым. Көчле алкышлар астында. Минем кабат сәхнәгә менүемне сорадылар. *(Як-ягына карап.)* Ә «Сыерчык» кая соң?

Дәмин. Мин аны чыгарып җибәрдем!

Дәмдинов. Ахмак! Ә бәлки, ул безнең акчаларны урлап качкандыр, ә?! *(Ашыгып.)* Карыйк әле кесәне! *(Чалбар кесәсен карый.)* Юк! Акча юк!

Дәмин *(кычкырып).* Акча! Акча! Акча! *(Чабып йөри башлый.)*

Дәмдинов *(елардай булып).* Юк... акча... акчадан җилләр исте...

Дәмин. Кайтырга да акча калмады. Беттек, Дәмдиныч!

Дәмдинов *(идәнгә авып).* Беттек, дустым!

Дәмин *(йодрыгын төйнәп).* Ну, «Сыерчык», ну, «Сыерчык»! Тотсам — изәр идем бер!

Дәмдинов. Сыерчыктамыни эш!

Дәмин. Ә нидә?

Дәмдинов. Системасы шундый... Дәмин, син коммунизмга ышанасыңмы?

Дәмин. Ышанам. Кесәдә акча булганда.

Дәмдинов. Ә теге дөньяның, ахирәтнең барлыгына ышанасыңмы?

Дәмин. Алдан ышанмый идем. Хәзер ышана башладым. Ышандырдылар.

Дәмдинов. Ә беләсеңме, коммунизм белән ахирәт арасында бернинди дә аерма юк бит. Алар икесе дә бер үк матур ялган. Максатлары бер үк. Аерма бары тик шунда: дин кешегә бәхетне, җәннәтне теге дөньяда, ахирәттә вәгъдә итсә, коммунизм тарафдарлары аның бу тигезсез дөньяда булуына өмет салалар. *(Пауза.)* Ә син кая яшәр идең: коммунизмдамы, әллә ахирәттәме?

Дәмин *(уйланып).* Коммунизмда. Коммунизмда җеннәр юк. Мин җеннәрдән куркам. *(Пауза.)* Кара-ле, нишләп син шулкадәр моңсуландың, ә? Үлмисеңдер ич? Төсең дә ап-ак...

Дәмдинов. Йөрәк кыса... Син менә миңа карап торасың инде, бөек артистка караган кебек. Ялгышасың, мин бөек түгел. Үземне чын артист дип йөрсәм дә, мин карьера турында уйлыйм. Оешмабызга кайтып, нәчәлник булып утырасым килә минем. Трай тибеп, гастрольдә эшерелеп йөргәнче, җылы кабинетта нәчәлник булып утыруга ни җитә. Әгәр мин җитәкче булсам, бу артистларны эт типкесендә йөртмәс идем.

Дәмин. Нәчәлник булсаң, син дә бозыласың. Үзең турында гына уйлый башлыйсың. Дәмдиныч, безгә ул турыда уйларга кирәк түгел, безгә акча турында уйларга кирәк.

Дәмдинов. Акча! Ай... *(Йөрәген тотып.)* Искә төшермәле...
Дәмин. Ни булды сиңа? Төсең бик киткән!
Дәмдинов. Эчәргә ярамый миңа, йөрәк кыса башлый. Дәмин... үләм... ахрысы! *(Башын ия.)*
Дәмин *(куркып).* Үлмә, малай, үлмә!
Дәмдинов. Дәмин! Валидол!
Дәмин. Вәлидул! Ә нәрсә ул Вәлидул? Кем ул?
Дәмдинов *(тыны кысылып).* Кори... дор... да...
Дәмин. Коридорда... Хәзер... хәзер табып керәм мин ул кешене... Тик үлә генә күрмә... Вәлидул абый! Вәлидул абый!

Чыгып китә.

Дәмдинов. Нәрсә соң бу? Ни булды минем белән?

Ут сүнә. Тонык яктылыкта Кара кеше пәйда була. Сәер генә елмаеп, урындыкка килеп утыра.

Син кем? Кара... кеше... А-а... архангел... Га-а-авриил... *(Егыла.)*

Кара кеше шаркылдап көлә. Матәм көе яңгырый. Күк күкрәп ала.

Пәрдә.

**ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ**

Шул ук кунакханә номеры. Бүлмәнең дивары кара бәрхет белән ябылган. Бүлмә уртасында яшел сукнолы канцелярия өстәле һәм кәнәфи. Өстәл янында, мәрткә киткән хәлдә, Дәмдинов утыра. Өстендә кара фрак, цилиндр. Аягында ак тапочкалар. Күк күкрәп ала. Ялтырап яшен яшьни. Җир тетри. Дәмдинов уяна.

Дәмдинов *(йокы аралаш).* Тә...ә...әк... *(Баса.)* Иптәшләр! Оешмабызның ачык җыелышын ябык дип белдерергә рөхсәт итегез... Ә, юк, гафу итәсез, оешмабызның ябык җыелышын ачык дип белдерергә рөхсәт итегез. *(Пауза.)* Көн тәртибе түбәндәгечә... Сораулар юкмы? *(Секретарьга эндәшкән сыман.)* Юк... Яз!

Бибигөлҗамал керә. Кулына сулы чиләк, чүпрәк тоткан. Диварның бер кырыен сөртә башлый.

Дәмдинов *(югары тонда).* Апа! Эшкә вакытында килергә кирәк! Сезгә соңгы кисәтү ясыйм! Яз!
Бибигөлҗамал. Аллаһы Тәгалә үзенең хозурына тагын бер тинтәкнең җанын алган икән инде. Берсеннән әле яңа гына котылган иде, җәһәннәмгә озатып.
Дәмдинов. Приказ шундый... Яз... *(Пауза.)* Син, апа, эшеңне кара! Безнең эшкә тыгылма, безнең монда бик мөһим киңәшмә бара. Иптәшләр, минем сезгә шундый бер соравым бар...
Бибигөлҗамал. Монда сорау бирмиләр. Монда сорауга җавап кына бирәләр.
Дәмдинов. Молчать, швабра!
Бибигөлҗамал. Алла, диген! Тинтәк. *(Чиләген идәнгә куеп.)* Аллаһы каршына килгән адәмнәр барысы да бертөсле икән — сорау бирергә яраталар. *(Чүпрәген суга манып, диварның бер генә урынын сөртә.)*
Дәмдинов. Эшлисең! Ну, эшлә! Миңа да эшләргә кирәк. Шалтыратып аласым бар... *(Телефон номерын җыя.)* Алло! Министрлык!

Күк гүли. Югарыда илаһи тавыш ишетелә.

Тавыш. Сиңа ни кирәк?
Дәмдинов. Миңа дотация кирәк.
Тавыш. Нигә ул сиңа?
Дәмдинов. Телеграмма килеп төште. Минем ике артистым Архангельскидан кайталмыйча ята, акчалары беткән. Акча сорыйлар. Ә мин каян бирим, үз кесәмнән чыгарып бирә алмыйм бит инде.
Тавыш. Уйлашырбыз. *(Югала.)*
Дәмдинов. Менә бит! Минем белән исәпләшәләр югарыда! *(Мактанып.)* Әйбәт утырам бит, ә!
Бибигөлҗамал. Монда озак утырмыйлар. Җиде көн срок.
Дәмдинов. Җиде көн? Ә нишләп җиде генә?
Бибигөлҗамал. Җидесе дә күп әле аның.

Дәмдинов. Җиде көндә дә күп нәрсә майтарырга була анысы. Җиде көндә яңа клуб салдырырга була. *(Киерелеп.)* Ардырды, әзрәк ял итеп алырга кирәк. *(Кулына гәҗит ала.)* Нәрсә бу?

Бибигөлҗамал. Нәрсә булсын — гәҗит.

Дәмдинов. Гәҗит икәнен күрәм. Нишләп соң ул тоташ некрологлардан гына тора.

Бибигөлҗамал. Үлгән кешеләрнең санын алып бара торган гәҗит ул.

Дәмдинов. Ел саен шулкадәр кеше үләме?

Бибигөлҗамал. Көн саен.

Дәмдинов. Көн саен?! Тәк... укып карыйк әле берәрсен... тәк... профком... цехком... Дәмдинов Дәмдин Дәмдинычның кинәт кенә үлүе турында хәбәр итә. Хатынының, туганнарының авыр кайгысын уртаклаша... Туктале! Дәмдинов мин бит ул! *(Пауза.)* Йа Хода! Мин үлгәнмени?

Бибигөлҗамал. Аңладыңмыни инде! Әйе, җаным, син ахирәттә. Тик әлегә җәннәттә дә, тәмугта да түгелсең. Сират күперен кичәсең бар. Аллаһы каршында җавап тотар өчен, синең җиде көн вакытың бар. Шушы җиде көн эчендә син, бар булган гөнаһларыңны искә төшереп, Аллаһы каршында җавап тотарга әзер булырга тиешсең. Аңладыңмы?

Дәмдинов *(моңсуланып).* Аңладым. *(Пауза.)* Карале, апа, ә нишләп син диварның бер генә җиреннән сөртәсең?

Бибигөлҗамал. Башка җирен сөртсәм, миңа эш кенә арта.

Дәмдинов. Ә син үзең кем соң?

Бибигөлҗамал. Ахирәттә җыештыручы.

Дәмдинов. Син дә минем кук дөнья куйган кешеме?

Бибигөлҗамал. Әйе. Мин грыжадан үлдем. Авыр күтәреп. Аллаһы Тәгалә, мине жәлләп, мәңгелеккә җыештыручы итеп калдырды. Өч балам калды. Яшәгәндә акылсыз булдым. Хәзер генә акыл керде... Ярар, минем эшем бүгенгә тәмам. Хушып тор! *(Китә башлый.)*

Дәмдинов. Апа, ә Аллаһы хәзер ни белән шөгыльләнә?

Бибигөлҗамал. Аллаһының эше күп. Ахырзаманга әзерләнә.

Дәмдинов. Ахырзаман җитә димени?

Бибигөлҗамал. Җитә, ди шул. Халык бозылды, дөньяның рәте китте. Ярар, киттем, миңа күп сөйләшергә ярамый.

Дәмдинов. Апа, тукта инде!

Бибигөлҗамал. Нәрсә, җаным?

Дәмдинов. Китмә инде. Мин ялгызлыктан бик куркам.

Бибигөлҗамал. Син дә кешечә сөйләшә башладың. Артист! Артистларны бик тә ярата идем мин. Мин сиңа әзрәк ярдәм итәргә телим, энем!

Дәмдинов. Ничек?

Бибигөлҗамал. Мин сиңа тылсымлы көзге калдырам.

Дәмдинов. Аның белән нишләп була?

Бибигөлҗамал. Бу — тылсымлы көзге. Моның белән сиңа күңелсез булмас. Җирдәге теләсә нәрсәне, теләсә кемне күрер өчен, сиңа бары тик көзгене өч мәртәбә ышкып алу җитә. *(Көзге бирә.)*

Дәмдинов. Рәхмәт.

Бибигөлҗамал. Аның бер шарты да бар. Әйтик, син көзгедән күренгән кешене бары тик күрә генә аласың, аның белән аралаша алмыйсың. (*Күк күкри.)* Ярар, китим. Ходай алдында гөнаһлы булмыйм тагын!

Бибигөлҗамал китә.

Дәмдинов *(ялгызы).* Димәк, мин үлгән. Димәк, миңа нindидер сират күперен кичәргә кирәк. Нинди була соң ул сират күпере? Әбекәй үзе исән чагында сөйли торган иде ахирәт галәмәтләре турында. Ә без аны игътибар белән тыңламый идек. Әби намаз укырга тотынса, шаркылдап көлә торган идек... *(Көйләп.)*

Ай күрдем иман белән,
Авызым тулсын аман белән.
Шушы айларда үлә калсам,
Каберем тулсын нур белән...

*(Елап.)* Әбекәй шулай дип җырлый торгание. Денле карчык иде. Урыны җәннәттәдер инде җаныкаемның. *(Пауза.)* Әбекәйдән башка тагын кемнәрем бар соң әле минем?

Тагын кемнәр? *(Исенә төшереп.)* Хатыным бар бит! Маһруй! Ул... исән... Нишләп ята икән инде ул анда? Көн-төн елый торгандыр инде, бичара, мине кызганып. Тизрәк күрәсе иде сөекле хатынымны! *(Көзгене ышкый.)*

Маһруй пәйда була. Ул телефоннан кем беләндер сөйләшеп утыра.

Маһруй. Нишлисең инде, кодача, үлгән артыннан үлеп булмый... Ничек тә яшәргә кирәк! Өч баламны үстерәсем бар. Олы кызымны кияүгә биргәннән бирле расхут чыгып кына тора. Ә аңардан нәрсә калсын инде! Тапкан акчасын эчеп бетерә барды.

Дәмдинов. Син нәрсә, хатын?! Ни сөйлисең?! Мин бит кассада утыз мең сум акча калдырдым.

Маһруй. Утыз меңебез бар иде. Анысы да кызыбызның туена кереп бетте. Бәхет күрмәдем инде мин аңардан, уңмадым.

Дәмдинов. Сеңелкәшне кара син, ә! Миңа туган кеше бит ул. Юк, сеңелкәш, ялгышасың, минем хатын андый иләс-миләсләргә бирешә торган кеше түгел ул, миңа һәрчак тугры булды.

Маһруй. Сүзең дөрес, кодача. Балалар өчен, ир өчен күп яшәдем инде мин. Хәзер инде үзем өчен яшәр вакыт җитте.

Дәмдинов *(маңгаен кашып).* Тел төбеңне аңламадым, хатын?

Маһруй. Әллә берәрсе белән таныштырырга уйлыйсыңмы?

Дәмдинов. Юләр! Кемгә кирәк син өч балаң белән?

Маһруй. Чыгар идем, билләһи!

Дәмдинов *(аяк тибеп).* Син, хатын, миннән көләсең инде әллә?

Маһруй. Фатирлы булса тагын да әйбәтрәк. Фатирымны балаларга калдырыр идем.

Дәмдинов. Акылың алтын икән! Юкка гына мин сине юләр дип йөргәнмен икән бит.

Маһруй. Пеләше бармы?

Дәмдинов. Ә! Нигә аның сиңа пеләше?

Маһруй. Нигә дисеңме? Пеләшле ирләр темпераментлы булалар.

Дәмдинов. Каян беләсең?

Маһруй. «Бурда» журналыннан укып белдем... Бар! Ой! Әйбәт!

Дәмдинов *(күрсәтеп).* Хатын! Менә минем дә пеләшем бар иде бит!

Маһруй. Нәрсә дисең? Аңламадым... Импотент?!

Дәмдинов. Ха! Менә шул кирәк сиңа!

Маһруй. Ярар инде, импотент булмагае шайтаным булсын, тик кеше генә булсын. Нәрсә? Сөяркәм бар! Әй, аның исеме генә инде, бер мәхлук шунда! Көндезләрен килергә ярата, балалар өйдә булмаганда.

Ишектә кыңгырау тавышы.

Әнә! Килеп тә җитте! Әй, үз күләгәсеннән үзе куркып йөри торган бер бәндә инде шунда. Ярар, кодача, тагын шалтырат, яме! *(Трубканы куя.)* Хәзер, хәзер... Әй, бигрәк тә түземсез инде! Газиз иремнең дусты булып йөргән кеше бит әле, җитмәсә!

Ишек ачарга бара.

Дәмдинов *(башын кашып).* Дус! Минем дус! Кем икән инде ул?

Дәмин керә. Кулында чәчәк.

Дәмин. Бәйрәм белән сезне! Ягъни сине диюем... Мә! *(Чәчәк бирә.)*

Маһруй. Рәхмәт. Ә нинди бәйрәм соң бүген?

Дәмин. Матбугат көне белән.

Маһруй. Матбугат көне? Андый бәйрәм дә бармыни?

Дәмин. Белмим тагын. Син өйдә үзең генәме соң?

Маһруй. Кем белән булыйм инде, Дәмин?

Дәмдинов *(шаккатып).* Дәмин! Шушы да булдымы сөяркә! Тфү!

Дәмин *(Маһруйны кочып).* Концерттан качып кайттым, җаным... Сине сагынып беттем... Еллар буена...

Маһруй. Гармуныңны асып һаман да шул авылдан авылга йөрисеңме?

Дәмин. Тиздән Берләшкән Гарәпләр Эмиратына барабыз!

Маһруй. Нәрсәгә?

Дәмин. Дуслык концерты белән.
Маһруй. Ә кая соң ул?
Дәмин. Эмиратмы? Монда гына... Казанны чыккач кына... Африка тирәсендә...
Маһруй. О! Ә миңа нәрсә алып кайтырсың икән?
Дәмин *(назланып).* Җаның ни тели, җаным, шуны алып кайтырмын.
Маһруй. Шулаймы?! Мин сиңа исемлек язып бирермен.
Дәмин. Беләм инде, җаным, көзге сапожкидан башланган синең...
Маһруй. Әйе... үкчәле галуш белән тәмамланган...
Дәмин. Мин яратам сине, Маһруй!
Дәмдинов. Их! Кем уйлаган, ә! Шушы чирләшкә кайчан да булса минем хатынымның сөяркәсе булыр дип! *(Кычкырып тибенә.)* А-а! Мә сиңа, мә!

Дәмин як-ягына карана.

Маһруй. Ни булды? Нигә як-ягыңа каранасың?
Дәмин. Күңелем тыныч түгел. Ни әйтсәң дә, мәет чыккан йорт бит.
Маһруй. Әйдә, чәй эчеп алыйк, бәлкем, күңелең тынычланыр.
Дәмин. Мәең юктыр бит?
Маһруй. Мәем дә бар, чәем дә бар. Әйдә утыр! *(Аракы сала.)*
Дәмин. Ирең әйбәт кеше иде, урыны җәннәттә булсын инде.
Дәмдинов. Ә син тәмугта янсаң иде!
Дәмин. Карале, җаным, чәй белән мәй эчкәнче, караватта тәгәрәшеп алсак ничегрәк булыр икән?..
Маһруй. Яхшы булыр, яхшы. Бик тә әйбәт булыр. Син чишенә тор, ә мин өстемне генә алыштырып алыйм.
Дәмин. Бар, җаным, бар. *(Ятып.)* Их, рәхәт, Маһруй, синең белән!
Дәмдинов *(чыгырыннан чыгып).* Хатын, ку син аны, ку!
Дәмин. Минем кочакка керергә ашык, Маһруй, тизрәк бул!
Маһруй. Киләм, киләм! *(Икенче бүлмәгә кереп китә.)*
Дәмдинов. Дәмин!

Дәмин торып баса. Йөренә. Эчке күлмәктән Маһруй чыга.

Маһруй. Ни булды тагын? Нәрсә уйга баттың?
Дәмин. Карале, җаным, син ireңнең киемнәрен яккан идеңме?
Маһруй. Юк. Ә нигә?
Дәмин. Әгәр дә үлгән кешенең киемнәрен якмасаң, өрәге кайта, диләр.
Маһруй. Шулай микәнни?!
Дәмин. Ие. Тотып ягарга кирәк.
Маһруй *(назланып).* Ягарбыз, ягарбыз... *(Дәминне кочаклый.)*
Дәмин *(эреп).* Җаным, кил миңа, җаным... *(Яталар.)*
Дәмдинов. Юк, мин моңа карый алмыйм. Нигә миңа мондый җәза?! *(Йөзен каплый.)*
Маһруй *(хисләнеп).* Дәмин, син шундый да назлы... Ирем андый назлы түгел иде...
Дәмдинов. Юк, минем түзәр хәлем калмады! Мин моңа түзеп тора алмыйм! *(Тибенә.)* Мә сиңа, мә!
Дәмин *(торып)*. Карале! Кемдер бар кебек өеңдә!
Маһруй. Кем булсын инде, юләр!
Дәмин. Йортыңа җен ияләшмәгәндер ич?
Дәмдинов *(сөенеп).* Әһә! Шүрләдеңме?!
Маһруй. Син нәрсә инде!
Дәмин. Синең ireң шушы караватта ята идеме?
Маһруй. Шушында, кая булсын!
Дәмин. Карале, җаным, әйдә, башка караватка күчеп ятыйк әле.
Маһруй. Әйдә инде, әйдә! *(Дәминне башка бүлмәгә алып кереп китә.)*
Дәмдинов. Вәт хатын! Хур итте мине хатын! Бетерде мине хатын! *(Кулына көзгене алып.)* Мине яклый алырлык бер генә кешегез дә юкмыни соң шул якты дөньягызда?! *(Көзгене ышкый.)*

Ишектә кыңгырау тавышы. Маһруй, Дәмин атылып чыгалар.

Маһруй. Ходаем! Кем булыр икән бу?
Дәмин. Дәмдиныч кайтмагандыр ич?

Маһруй. Алла, диген!

Дәмин. Үлгән кешенең өрәге кайта, диләр. Өрәге кайта, үзе кайтмаса да...

Маһруй *(карап).* Кызым килгән!

Дәмин *(күңеле төшеп).* Әй, ул гына җитмәгән иде! Нишләргә инде? Ярар, мин балкон ягына чыгып торыйм, ул киткәч чыгармын.

Чыгып китә. Маһруй ишекне ача. Ләлә керә.

Ләлә. Нишләп шулкадәр озак ачмыйча торасың?

Маһруй. Кызым!

Дәмдинов *(сөенеп).* Кызым! Бердәнберем! Бар ышанычым синдә!

Ләлә. Кеше бармы әллә?

Маһруй. Юк, беркем дә юк. Утыр әле, хәлләрең ничек?!

Ләлә. Ярый инде шунда. *(Утыра. Сигарет кабыза.)*

Маһруй. Кәефең юкмы әллә? Кияү нихәл?

Ләлә. Нәрсә булсын аңа! Мин озак сөйләшеп утырырга дип килмәдем, әни. Миңа акча кирәк.

Маһруй. Нинди акча?

Ләлә. Акча нинди була соң! Әтидән калган акча!

Маһруй. Юк акча.

Ләлә. Ничек юк? Ә кая соң ул?

Маһруй. Соң, кызым, синең туеңа кереп бетте бит инде ул акчалар. Аз гына калды.

Ләлә. Калганын бир!

Маһруй. Кызым, үпкәләмә, биралмыйм! Әле ике энеңне башлы-күзле итәсебез бар.

Ләлә. Кешеләрнең әтиләре әти төсле, ичмасам! *(Торып баса.)* Ә безнең әти нәрсә инде?! Нәрсә калдырды безгә шулкадәр?!

Дәмдинов *(рәнҗеп).* Әй кызым, кызым!

Ләлә. Җиде юл чатында утыртты да калдырды.

Дәмдинов. Шул шул. Сезгә әти кирәк булмаган, әтиегезнең акчасы кирәк булган. Их, балалар, балалар!

Ләлә. Мин фатир бүләргә дип килдем. Йә фатир, йә акча. Минем коммуналкада, комод кадәр бүлмәдә череп ятасым килми! Кияүгә бирдем дә шуның белән котылдым димә!

Маһруй. Тынычлан, кызым!

Ләлә. Юк инде!

Маһруй. Ә син энеләрең турында уйладыңмы, юкмы?

Ләлә. Ой, һаман да шул бер балык башы! Энекәшләр дә энекәшләр! Минем дә башкалар кебек яхшы фатирда яшисем килә!

Маһруй. Тынычлан!

Ләлә. Йә акча, йә фатир!

Маһруй. Акчам юк!

Дәмин *(балкон ягыннан).* Җаным, бирмә акчаңны, бирмә! *(Югала.)*

Ләлә *(каранып)*. Кем бар анда?

Маһруй. Кунак.

Ләлә. Ха-ха! Сөяркәңме?!

Маһруй. Син нәрсә инде!

Ләлә. Беләм мин аның кем икәнен!

Маһруй. Кем?

Ләлә. Әтинең элеккеге дусты. Теге бер мескен инде шунда, тишек чемодан күтәреп йөрүче. Их, әни! Нервым чыдамый! Ну хәзер кызык итәм мин аны!

Маһруй *(ялварып).* Кызым!

Ләлә. Кызык итәм! Әтинең менә шушы тунын киеп алам да! Куркудан йөрәге шартласын әле! *(Тун кия.)*

Дәмдинов *(чиксез шатланып).* Алга, кызым, алга!

Маһруй. Кызым, шаярма!

Ләлә. Ух! *(Балконга чыгып китә.)*

Дәминнең ачыргаланып кычкырган тавышы ишетелә. Ләлә кире керә. Кулында Дәминнең кепкасы. Елый.

Әни!

Маһруй. Ни булды?

Ләлә. Ул егылды. Җиденче каттан егылды...

Караңгылык. Ләлә, Маһруй югалалар.
Дәмдинов җитди кыяфәт ала. Гармун уйнап Дәмин керә.

Дәмин *(җырлап).*

Их, алмагачлары,
Сайрый сандугачлары.
Юк дисәң дә бардыр әле
Күңел юаткычлары...
Их, алмагачлары!..

Дәмдинов. Дәмин, син дә мондамыни?

Дәмин. Нихәл, Дәмдиныч!

Дәмдинов. Әйбәт. Кая барасың?

Дәмин. Гайсә пәйгамбәр янына барам әле.

Дәмдинов. Әйдә соң, бергә барыйк! Син уйнарсың, мин җырлармын.

Дәмин. Әйдә. Менә хәзер аның күңелен ачып алабыз да, ул безне танышлык буенча җәннәткә урнаштырып куяр.

Дәмдинов. Дәмин, бу алдашу булмасмы соң? Без бит җирдә дә күп алдаштык, ә мин монда алдашырга теләмим.

Дәмин. Үзең кара инде! Миңа җирдә никогда не везло, ә монда повезет, понял!

Дәмдинов. Дәмин, син нишләп минем хатыным белән шаярдың, ә? Туктале, Дәмин... җавап бир...

Давыл җиле исә. Күк күкри.

Дәмин. Карале... малай... бетәбез... Бәхил бул... Җәһәннәм җиле... Җәһәннәм...

Караңгылык. Дәмин, Дәмдинов югала. Кара кеше пәйда булып ала. Югала. Ут яна. Элеккеге кунакханә номеры. Дәмдинов йөрәген
тоткан, ята. Дәмин керә. Таблетка тоткан.

Дәмин. Дәмдиныч, таптым! Менә, мә! *(Таблетка суза.)*

Дәмдинов. Нәрсә бу?

Дәмин. Вәлидул. Мин аны кеше дип торам, коридор буенча пыр туздырып эзләп йөрдем. Ә ул тәблитке икән! Мә! Кап!

Дәмдинов *(йотып).* Дәмин, ә нишләп син минем хатыным белән шаярдың, ә?

Дәмин. Кайчан?

Дәмдинов. Соң, әле генә.

Дәмин. Туктале! Син үзеңнең кая икәнлегеңне беләсеңме соң?

Дәмдинов. Нишләп белмәскә! *(Пауза.)* Ахирәттә.

Дәмин. Нинди ахирәттә! Без Архангельскида... кунакханәдә... номерда... Соң, шулай булгач, мин синең хатының белән ничек шаяра алыйм ди инде?!

Дәмдинов *(торып).* Ә мин исәнме? Мин үлмәгәнме?

Дәмин. Исән. Үлмәгән.

Дәмдинов. Карале, Дәмин, ахирәткә эләгәсе бар бит әле!

Дәмин. Саташмале! Безгә хәзер, билет алып, Казаныбызга кайтып китәргә кирәк! Әйдә җыеныйк! Кайда минем чумадан? *(Караватастыннан чемоданын чыгарганда, акча янчыгын табып ала.)* Дәмдиныч! Карале, безнең акча! Акча! *(Дәмдиновка бирә.)*

Дәмдинов *(алып).* Акча! Безнең акча!

Дәмин. Дәмдиныч, хәзер үк Казанга кайтабыз! Миңа швейцар ниндидер кәгазь дә бирде әле монда! Мә, укы әле, укы! *(Кесәсеннән телеграмма кәгазе чыгарып бирә.)* Их! Казанга кайтсам, ташлар идем бу артист тормышын! Берәр гертрудага өйләнеп, каймак-катык кына ашап ятар идем...

Дәмдинов *(карап).* Дәмин, бу бит телеграмма!

Дәмин. Телеграмма шул. Укы әйдә, укы!

Дәмдинов *(укып).* «Гастрольләрегезнең уңышлы баруын искә алып... зпт... җыр оешмасы сезне туптуры Нарьян-Марга, Нарьян-Мардан Салехардка җибәрә...»

Дәмин. Тчк...

Дәмдинов *(чак кына еламыйча).* Программа шул ук: җырлап керәсез, җырлап чыгасыз... И... Мазутов... Тчк! *(Катып калалар.)*

Музыка яңгырый. Быргы кычкырта. Дәмин, Дәмдинов басып җырлыйлар:

Дустың белән юлга чыксаң әгәр,
Юлдаш итеп ал син җырыңны,
Юлдаш итеп ал син хыялыңны,
Хисләреңне, йөрәк җырыңны.
Әйдә, дустым, иркен мәйданнарга,
Җырлап торсын безнең шат йөрәк.
Якты нурдай балкып тирә-якка,
Татар җыры яңгырый, дисеннәр,
Татар җыры яңгырый, дисеннәр!
Юлга чыксаң, күктә, баш очында
Балкып торсын якты бер йолдыз.
Сак-Сокларның йолдыз галәменә
Илтер безне якты юлыбыз...

Дәмдинов, Дәмин: «Даешь Нарьян-Мар! Даешь Салехард!» — дип җырлый-җырлый, сәхнәдән чыгып китәләр.

Пәрдә.

## ХАТЫНЫМ-АЛТЫНЫМ

*Ике пәрдәле комедия*

**КАТНАШАЛАР:**

Мингазиз.
Мәдинә — аның хатыны.
Рәбига — Мәдинәнең анасы.
Хәбибулла (Хабл).
Геннадий Бакирович — отставкадагы старшина, Одессадан килгән кунак.
Өмәмә.

Вакыйга авылда бара.

### БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

#### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Гади авыл өе. Гади декорация. Ә уртада бик матурлап, бик зур зәвык белән ясалган агач сәгать. Бу — кияүнең кәләшкә бүләк иткән туй бүләге. Гомерләр узган, сулар әз-мәз аккан, бу бүләк-сәгать тә инде күптәннән йөрми, аның тарихын белүче дә юк. Сәгать янында балалар фоторәсемнәре. Алар — өчәү. Тик очраган берсен элгәнгә күрә, алар күзгә күп булып күренәләр. Мәдинә өйдә үзе генә. Ул журнал карап утыра. Тышта ире Мингазизнең тавышы ишетелә. Ул, ачып керәсе урынга, өй ишеген дүрт-биш тапкыр каты итеп тарта.

Мингазиз *(тыштан).* Ха-тын! Мәдинә, ач әле!

Мәдинә *(журналын куеп).* Әй Алла, бер генә дә тынычлык юк шушы өйдә! Әзрәк ял итәрмен, ичмасам, яраткан журналымны укырмын дигән идем дә... Кая ул?!

Мингазиз *(тыштан).* Ха-тын! Ач! Үлдең мәллә?!

Мәдинә. Мунчага киткән иде! Башына ис тимәгәндер ич?! Ач! Тартма! Этеп кер! Үз ишегеңне дә ачып кералма инде, ә?! *(Ача.)*

Мингазиз атылып өйгә килеп керә. Трусиктан, муенына сөлге чорнаган. Егыла.

Мингазиз *(туңып).* У-у! Кат-тым!

Мәдинә. Җүләр сатма инде, кем инде мунчадан туңып чыга?!

Мингазиз. Мунча, менча, монча! Ләүкә астында яткан мунча бакасы дип уйладың мәллә мине?! Син нинди мунча яктың соң бүген, ә?! У-у-у!

Мәдинә. Кызу мунча яктым! Миченә дә биш-алты кочак кына утын ташладым...

Мингазиз. Иреңне, газиз ярыңны сап-салкын мунчага кертмәсәң, күңелең булмаган булыр идеме-ни? Воспаление легких алдырта яздың бит! Ка-а-атып беттем! Зәңгәрләнеп чыктым! Баштарак сизмәдем, кәнишне, чөнки үземдә градус бар ие... Соңыннан мандрашка тотып алмасынмы? Эчке органнарга тиклем салкын үтте... У-у! Айныткычта да бу кадәр салкын түгел! Син мине нәрсә, тундрада яшәгән кар белән юынучы чукча дип уйладың мәллә? У-у! Нинди мунча яктың соң син, ә?!

Мәдинә. Кызу мунча. Эссесе күбрәк чыксын дип, морҗасын да иртәрәк япкан идем әле...

Мингазиз. Нинди эссе ди анда! *(Кулына чүмеч тотып, су салган кебек кылана.)* Эссе сала-сала җан чыкты! Әнкәң шулай кысып кына яга иде мунчаны, син әнкәңнән дә кысмыр!

Мәдинә. Туктале... Син кемнәр мунчасына кердең соң? Әниләр мунчасына кермәдеңмени?!

Мингазиз *(төшенә башлап).* Ә нишләп әле мин әниләрең мунчасына керергә тиеш, үзебезнең мунча булганда!

Мәдинә көлә.

Нәрсә ыржаясың?!

Мәдинә. Хи-хи! Мин бүген әниләр мунчасына яккан идем, безнең мунчаның миче ишелгән! Соң, җаным, син, әниләр мунчасына бармыйча, безнең салкын мунчага кердеңмени?!

Мәдинә тагын көлә.

Мингазиз. Шай-тан!

Мәдинә. Их! Бер көләсе дә елыйсы гына килә! Менә эчү кешене нишләтә?!

Мингазиз. Нәрсә ыржаеп торасың әле, ә?! Югал күземнән! Тиз! Чыгарам хәзер эссеңне! *(Кизәнә.)*

Мәдинә үпкәләп чыгып китә. Мингазиз өстенә җиңел тун, сырган чалбар киеп куя. Шул килеш урындыкка килеп утыра. Салкыннан куырылып, җыерылып китә. Кышын салкын җил, буран сызгырган тавышлар чыгып ала.

Тәрәзә ачыла. Хаблның башы күренә. Өстенә «Ну, погоди!» дип язылган футболка кигән.

Хабл. Сәлам!

Мингазиз. Ә! Хабл! Мультфильм!

Хабл. Син нәрсә, Кыш бабай булдың мәллә? Яңа ел җитмәгәндер бит?!

Мингазиз. Иманыңны киясе бар әле синең! Син нишләп, карамыйча-нитмичә, мине салкын мунчага илтеп тыктың?

Хабл. Да так, для хохмы!

Мингазиз. У-у! Юктыр бит?! Әзрәк җылыныр идем!

Хабл. Бар... башлаган...

Мингазиз. Каян?!

Хабл. «Прилетит вдруг волшебник...»

Мингазиз. Аңлашылды... Кер әйдә, сикер тәрәзәдән! Син, мәктәптә укыганда, бишлегә сикерә идең бугай биеклеккә?! Әле дә фурмыңны югалтмаган булса кирәк?!

Хабл. Да! Я самый лучший летун в мире! Я мужчина в самом расцвете лет! Малыш, держи меня!

Хабл тәрәзәгә сикереп менә дә шуып аска төшә башлый. Маңгае белән идәнгә терәлә. Ыштан төбе кадакка эләгеп кала.

Малыш, помоги!

Мингазиз. Ни булды?

Хабл. Түгелә! Ал яртыны! *(Кесәсендәге бер шешә яртыны Мингазизгә суза.)*

Мингазиз. Чү, чү, әкрен... түгә күрмә зәмзәм суын.

Мингазиз тунына чуалып егыла. Аракы шешәсе Хаблның кулыннан ычкынып китә. Түгелә. Мингазиз шешәне кулына ала. Исни. Бала назлаган кебек назлый. Шыңшый.

Мингазиз. Бетердең... Соң, тамчысын да калдырмадың... Фашист син, Хабл... Пиначет... Мао-цзедун... Иван Грозный син... Сталин... Бен Ладен, билләһи!!!

Хабл. Спокойствие, только спокойствие... Пятачок... Ай-я... *(Очып төшә.)*

Мингазиз күзен шешәгә төбәгән. Хабл сикереп тора да Мингазизнең аркасыннан кагып куя.

Хабл. Хәлең ничек, Винни-Пух?

Мингазиз. Хәлләр начар, Пятачок. Ыштан туздды, акча юк.

Хабл. Күптән мультфильм караган юк. *(Пауза.)* Телевизорны куй әле!

Мингазиз *(шешәне куеп).* Ничек карыйсың син ул мультфильмнарны, ә?! Шул мультфильм карый-карый, мультфильмга әйләнеп беттең бит инде! Син бит әле Казанга киткән идең, эшкә урнашам дип. Ник кайттың соң?

Хабл. Авылдашлар замучили. Дус-егетләр. Авылдан киләләр дә кыз табып бир, диләр. Кыз табып биргәч, бүлмәдән чыгып тор, диләр. Иртәрәк әйләнеп керсәң, ник иртә кердең, диләр. Эшләре барып чыкмаса, нинди кыз табып бирдең син безгә, дип сүгәләр. Просто замучили!

Мингазиз. «Время» кара син, гражданин булсаң... Анда ни генә күрсәтмиләр... төрле донҗә хәлләре...

Хабл. Куеп карале!

Мингазиз. Куйдым бит инде... *(Телевизор кабыза.)*

Хабл. Башка каналны куй! Донҗә хәлләрең үзеңә булсын!

Мингазиз. Ә анда ни бар?

Хабл. Чип и Дейл. Ә бәлкем, Черный Плащ!

Мингазиз. Хет көл монда, хет плач. Әнә анда Әфганстанны бомбага тоталар. Аягын бәреп сындырырга бу Бушның! Харап итә мөселманнарны! Буш булмады бу Буш! Әллә китәсе инде?!

Хабл. Кая?..

Мингазиз. Сугышка... Мин бит танкист...

Хабл. Әһә! Башланды у-па! Ух! *(Көйләп.)* Кто приходит в помощь к нам?! Черный Плащ, Черный Плащ! Ух! *(Музыка тавышына боргалана.)*

Мингазиз. Сиңа әйтәм, Мультик! Танкист булып сугышка китсәм ничек булыр иде икән дим?!

Хабл. Ничек бомбить иткәннәрен карап торыргамы? Синнән башка да күп анда, кулларын маңгайларына тидереп, күккә карап торучылар!

Мингазиз. Акча бирәләр, ди бит анда, учлап доллар тоттыралар, ди... дөрес булса...

Хабл. Син белән мин кирәк түгел инде анда, син барып йөрмә инде анда, Мингазиз, долларны да тәккә генә тоттырмыйлар... Әйбәт кеше син, Мингазиз, Чип и Дейл син, мистер Макдак...

Мингазиз. Кадак?

Хабл. Космостагы кеше син... тик син барып йөрмә инде анда... Космонавт син! Синең йөрәгең бөтен дөнья буенча сызлый...

Мингазиз. Косманав?

Хабл. Хуже.

Мингазиз. Нинди косманав? Куркак косманав бит мин!

Хабл. Хатыныңнан курыкканыңны беләм...

Мингазиз. Юк, ялгышасың. Әле хатын белән килешеп була. Минем иң курыккан кешем беләсеңме кем?!

Хабл. Кем? Баба Яга?

Мингазиз. Ие... Каенана! Түще!

Хабл. Ә кем инде ул?

Мингазиз. Кем булсын инде, хатынның әнкәсе!

Хабл. Ә! Рәбига апай!

Мингазиз. Нәкъ үзе!

Хабл. Старуха... Шепокляк...

Мингазиз. Ие... ие... шапы... шопы... Шуның аяк тавышын гына ишетсәм дә, йөрәккәем калтырап куя, малай! Аңа берәр йомыш белән барырга туры килсә, бөтенләй калтырап төшәм. Армиягә алганда да бу кадәр калтырамаган ием... Ниндидер заговор оештырырга йөри сыман ул, Кариб кризисын китереп чыгармаса ярый инде. 11 сентябрь кабатланмаса ярый...

Хабл. Анысы нәрсә тагын?

Мингазиз. Хатыннан аерттырмаса ярый инде, дим... Шуңа да йөрәгем выжт итеп тора!

Хабл. Не сый, Пятачок! Притворись, что ты маленькая черная тучка! *(Пультны боргалый.)*

Мингазиз. Карале, зинһар, уенга бормале! Хатын бик тә канәгать түгел миннән, ә түще тагын да! Авылда хатыннан аерылу бер дә күңелле нәрсә түгел бит инде ул...

Хабл. Анысына да түзәргә була! Аракыдан дәваланырга җибәрмәсеннәр... наркологическийга!

Мингазиз. Түще анысын да оештырырга мөмкин. Алай-болай җибәрә калсалар, минем урынга син генә барырсың инде, Хабл!

Хабл. А я че, Чебурашка что ли?!

Мингазиз. Ә сиңа нәрсә! Син — буйдак, рәхәтләнеп ашап ятарсың казенный акчага, көн-төн мультфильм карарсың!

Хабл. Как ежик в тумане...

Мингазиз. Именны... как ежик...

Мәдинә керә.

Мәдинә. Мингазиз... Мин тагын әни белән сөйләштем...

Мингазиз. Миңа димәгәе... Хет шунда министр белән сүләш... хет президент белән!

Мәдинә. Безгә аерылышырга кирәк... Хәзер әни килә...

Мингазиз. Юллар аерыла, димәк. Ә балалар?

Мәдинә. Сиңа балалар кирәкмени соң? Алар бит, синең исерек чагыңны, синең затсыз кыланышларыңны күрмәс, ишетмәс өчен, инде икенче ай трудлагерьда яталар. *(Пауза.)* Ни булды сиңа, Мингазиз, син кайчандыр андый түгел идең?!

Мингазиз. Ни булсын инде... Ә нигә беркөннәре... эткә талаттыгыз? Аякны эт тешләде...

Мәдинә. Кем талатсын сине?! Сине безнең этебез Томан талады.

Мингазиз. Томан?! Кит аннан, булмас! Ничек инде эт үзенең хуҗасының аягын тешләсен?! Җүнле эт түгел ул, алайса чыгам да атам мин аны хәзер!

Хабл. Аттың бит инде син аны!

Мингазиз. Ә! Кайчан? *(Сикереп тора.)*

Хабл. Кичә. Ау мылтыгыннан!

Мингазиз. Томаннымы? *(Тәрәзәдән башын тыгып.)* Соң әле бүген иртә белән генә чинап йөри иде түгелме соң? Борынны да килеп җалады... Ә... Әнә бит! *(Сызгырып.)* Ыш... ыш... ыч... *(Йомшак тавыш белән.)* То... ман... кил... кил... *(Кулы белән этне иркәли.)* Әй, әй, матурым... Анасы... бер ит кисәге бирсәнә шуңа... ыч... ыч... ыш... *(Хаблга.)* Ялганчы син, Мультфильм! Куркыттың бит... Котны алдың... Болай да йөрәгем выжт итеп тора!

Хабл *(телевизордан күзен алмыйча).* Тра-ля-ля, обманули короля!

Мингазиз *(аягын тотып).* Иртәдән бирле аяк авыртып торале нигәдер?! Кичә районнан кайтышлый өч пирожки алып ашаган идем дә, шуңа менә аяк сызлап тора...

Мәдинә. Күпме җүләр сатарга була, Мингазиз?! Кайчан син игә килерсең икән?!

Мингазиз. Йөрәк әрни, хатын, йөрәк. Кая карама бардак, кая карама тәртипсезлек. Ач, ятим балаларны күреп, ничек тере кешенең җаны сызламасын ди... Гондураста холера башланган, Казанга кадәр килеп җиткән... Никарагуада әнә өченче ел ачлык дәвам итә... Ачлар бит мескеннәр, күзләрен дымландырып, миңа телевизор аша карап торалар... Ничек моңа йөрәк түзсен?! Ничек выжт итмәсен?! *(Кулын күкрәгенә куя.)*

Мәдинә. Әллә кая ерактагын күргәнче, син борын төбендәген күрер идең! Капкаң янтайган, мунчаң ишелгән!

Мингазиз *(ишетмәскә теләп).* Җарар, җарар. Аерылыштык та ди... Әнә чехлар белән словакларны аерып куйдылар бит әле... Һаман шуларны хоккейда җиңә алмыйбыз... Җарар... аерылыштык та ди... Кәнишне, мин хатынсыз калмам... Көтеп торучылар бар минем аерылганны... Мин югалмам анысы! Ә менә кем сиңа өйләнер икән, ә? Балаң белән кемгә кирәк соң син?! Кем алыр? Менә Хабл безнең буйдак җегет, кирәкме икән син, пример, Хаблга?! *(Хаблга.)* Хабл... Хабл! Слушай, Хабл, җитте сиңа мультфильм карарга! *(Телевизорны сүндерә.)* Монда донҗә җарылырга тора, кырыкмаса кырык җиргә! Монда минем язмышым хәл ителергә тора... Әйт, Хабл, кирәкме ул сиңа, юкмы?

Хабл. Не понял... Пятачок?!

Мингазиз. Син менә минем хатынга өйләнер идеңме?

Хабл. Юк, мин синең хатынга өйләнмәс идем!

Мингазиз. Юк... хәзер син мине аңламадың... Әгәр дә менә мин хатын белән аерылышсам, ул автоматически минем хатын булудан туктый. Ул — иректә... Менә шул чагында син минем хатынга... ягъни... Мәдинәгә *(елаган булып),* минем сөекле Мәдинәмә өйләнер идеңме?

Хабл. Ә?!

Мингазиз. Күрәм, харап иткән сине бу мультфильмнар... Мәйтәм, менә шушы өч балалы хатынга өйләнер идеңме, дим?!

Хабл. Юк. Мин әле үзем дә бала гына...

Мингазиз. Менә шул шул, бөтен хикмәт тә шунда. *(Мәдинәгә.)* Менә күрдеңме инде! Сине алырга торучы да юк бит, хатын!

Мәдинә. Минем өчен кайгырырга кирәкми. Аптырагансың икән, өйләнүче табылмаса, мин ялгызым гына яшәргә дә әзер. Балалар өчен, балалар хакына...

Мингазиз. Масайдың, хатын, әй масайдың. Борын күтәрә башладың. Ни өчен икәнен дә беләм, беләм! Теге Сөембикәләр, Сөенбикәләр, Ханбикәләр журналында сурәтең чыкканнан бирле бик тә үзгәрдең син, үзгәрдең, тәмам кеше танымый башладың...

Мәдинә. Мин үзем сорамадым бит, төшерделәр дә киттеләр!

Мингазиз. Алар төшерерләр — төшерттерсәң! *(Журналны алып.)* Адәм мәсхәрәсе бит бу! Бөтен донҗәгә даныңны сатканнар! Мә сиңа! Мә! Шул кирәк сиңа! *(Журналны ерткалап ата.)*

Хабл *(журнал кисәкләрен җыеп).* Пятачок, ну ты че?! Какую красоту губишь...

Мәдинә. Мингазиз... ни булды сиңа, нишлисең?! *(Елый.)*

Мингазиз. Мә, мә! Нәрсә, кызганычмы?

Мәдинә. Көнләшәсең әллә?

Мингазиз. Көнләшәм, ие! Исем китте!

Мәдинә. Әйе. Кадерле, бәхетле минутлар тиз онытыла икән шул ул. Кайчандыр син дә башка идең бит, Мингазиз, матур идең, акыллы идең... назлы идең... игътибарлы идең... Өйләнешкән чакларда, нәрсә бүләк итим сиңа, дип сорагачтын, шаярып кына, сәгать бүләк ит миңа, дигәч, син чынлап та миңа агач сәгать бүләк иткән идең... Бөтен җире агачтан... Бөтен кеше шаккаткан иде шуңа, бик күпләр көнләшкәннәр иде! Мин дә шатланган идем, сөенгән идем чын күңелдән... Ярата идем...

Мингазиз. Мәдинә... җитәр...

Мәдинә. Ни булды безгә? Хисләр сүнгән, сәгать йөрмәс хәлгә килгән.

Мингазиз *(айнып).* Ә! Ничек алай?

Мәдинә. Ничек алай?! Менә шулай! Тәүге кабат авызыңа аракы алып, исереп кайтып тавыш чыгарганнан бирле туктады ул сәгать. Сәгать телләре әнә төннең берендә туктаганнар...

Хабл *(карап).* Да, верно, Пятачок!

Мәдинә. Туктаган сәгать, сәгать белән безнең бәхетебез дә туктаган, тынычлыгыбыз да югалган...

Мингазиз. Йөрми дисең инде, ә?! Йөрер... Хәзер җибәрәм мин аны... *(Сәгать янына килә.)* Хәзер... Мингазиз оста ул, мастер... Макдак, әй, тфү! Мингазиз тотынса... йөрмәгән филне дә йөртер... *(Сәгатьнең эчен ачып актара.)* Каһәр... ник йөрми соң ул?! Ник йөрми... *(Кыза.)* Куллар тыңламый, куллар... Йөрми бит, каһәр! Их! Бетерәм! Җимерәм хәзер! Тормасын күз карасы булып...

Мингазиз, балта эләктереп, сәгатьне ватмакчы була. Хабл аның юлына аркылы төшә.

Хабл. Ты че, старик, шундый матурлыкны ватарга ничек кулың бара?! Ташла балтаңны!

Мингазиз. Кит юлдан! Ватам! Болай да йөрәк ватык... донҗәсе ватык... Кит юлдан! Ва-там! Чүртымамы ул матурлык?! Матурлыкны ашап та, эчеп тә булмый! Кит! (*Балта күтәреп, өй буенча чаба-чаба йөри.)* Ва-там!!!

Рәбига керә. Ул усал күзләрен Мингазизгә төби.

Мингазиз *(туктап).* Менә шуны әйтмәкче идем шул! Утын вата торган балтаны артык кайрарга ярамый, дип... *(Аягын тотып.)* Ай... аяк сызлап тора әле нигәдер...

Хабл. Наверное, чего-нибудь поел?!

Мингазиз. Менә мин дә шуны баядан бирле сүләп торам бит инде... Кичә районнан кайтканда өч пирожки алып ашаган идем... шуңар сызлыйдыр инде... Җарар, мин утын ватып керим әле, әзрәк буыннар да җазылып китәр... *(Буыннарын яза.)* Бүтән шул пирожки сатканнарын күрсәм, якын да бармас идем, билләһи!

Балтасын култык астына кыстырып чыга башлый. Эт өреп каршы ала.

*(Томанга.)* Өрмәле, зинһар, ә! *(Усал.)* Өрмә, дим! Нинди хатын соң син... әй... Томанчик... җитәр инде. Өрмә! Кирәк кешегә өрә белмисең, хуҗаңа өрәсең!.. Атам мин сине тиздән... Билләһи, атам!

Чыгып китә. Рәбига усал күзләрен Хаблга төби.

Хабл *(каушап).* Булышмыйча булмас инде, бер ай элек утын ватарга дип чакырган ие... дус бит, иптәш...

Хабл чыга. Эт өреп каршы ала.

*(Эткә.)* Ну ты! Ежик в тумане! Исчезни в темпе вальса! *(Югала.)*

Рәбига. Нәрсә?! Кул уйната башладымыни?!

Мәдинә. Сәгатьне хутка җибәрмәкче иде дә...

Рәбига. Сәгатьне, сәгатьне! Сине аңламассың, канга батырып кыйнаса, минем янга йөгереп киләсең, кайвакытта, шуны яклап туялмыйсың! Җүнле ир, балта күтәреп, өйдә чабып, тузынып йөрми! Кара аны, суга-нитә калса, яшереп калма, шундук утыртабыз! Яклама, ишеттеңме?! Азынды, азынуның ахырына җитте ирең...

Мәдинә. Чәй куйыйммы?

Рәбига. Нинди чәй? Чәй күзгә күренми әле монда! Утырту безнең максат! Карале, алар чынлап та утын ваталармы?

Мәдинә *(тәрәзәдән карап).* Яралар...

Рәбига. Киттем, ярар. Камыр куйган идем, ташып ятмасын, берәр сәгатьтән кабат әйләнеп керермен... Киттем! *(Китә.)*

Мәдинә елмаеп-көлеп кала. Уйланып утыра. «Яшәүмени бу?» дигән җырның бер куплет көе яңгырый. Мәдинә тыныч кына елап ала.
Машина килеп туктаган тавыш ишетелә. Мәдинә ишетми. Сәгатьтән
күзен алмыйча, тын гына көйли.

**ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Геннадий Бакирович керә. Кулында саквояж, чәчәкләр. Гражданский киемнән. Ул дөньяда ике нәрсәгә гашыйк: хатын-кызга һәм тәртипкә. Ул Мәдинәнең моңсу җырын бик бирелеп тыңлап тора да, озаккарак киткәч, тамак кырып куя. Мәдинә сискәнеп китә.

Геннадий. Искиткеч! Матур! Гаҗәп! *(Пауза.)* Исәнмесез! Рөхсәт итегез сезгә мөрәҗәгать итәргә!

Мәдинә. Әйе...

Геннадий *(укып).* Мәдинә Гали кызы Халикова сез буласызмы?

Мәдинә. Мин... мин...

Геннадий. Узарга рөхсәтме?

Мәдинә. Билгеле... Узыгыз! Чәй?

Геннадий. Чәйдән баш тартмас идем. Ерак юлдан килдем. Килгәч, чәй эчерәчәгегезне белдем, шуңа күрә чәйгә тәмле ризыклар да алып килдем. *(Саквояждан нигъмәтләр чыгара.)* Ике кило конфет... «Орбита»... өч кило печенье... «Крекет», повидло «Ароматное»... ширбәт кило ярым... ананас, апельсин, хөрмә... Ә менә бусы махсус сезнең өчен: шо-ко-лад! С орехами! Мәгез! *(Бирә, калганнарын өстәлгә тезә.)*

Мәдинә *(алып).* Рәхмәт... Сез кем буласыз соң?

Геннадий. Соңыннан. Әлегә сер булып калсын, хәрби сер. *(Мәдинәгә карап.)* Туры сүзем өчен мине кичерегез, сез әзрәк кенә үзгәргәнсез!

Мәдинә. Ә сезнең мине күргәнегез бармыни? Минем сезне күргәнем юк!

Геннадий. Сезне инде миллионнар күреп соклангандыр дип уйлыйм! Сезнең чигәгезгә төшеп торган көдрәгез югалган...

Мәдинә. Аңламадым...

Геннадий. Хәзер аңлатам. *(Геннадий саквояждан Мәдинәнең журнал тышында чыккан фоторәсемен ала. Рәсем — рамкада.)* Сез монда шулкадәр чибәр, матур чыккансыз!

Мәдинә. Рәсемдә, әйе, тик тормышта, үзегез күрәсез, мин үземне артык чибәр хатын дип әйтә алмыйм.

Геннадий. Ә мин, сезне рәсемдә күрүгә үк, шундук гашыйк булдым!

Мәдинә. Әй! Ниемә генә дип шул журналга төшәргә дип ризалык биргәнмендер инде! Авылга алдынгы сыер савучы төшерергә дип килгән фотограф тотты да мине — китапханәчене төшереп китте! Кай җирем ошагандыр, белмим?! «Сөембикә»нең иң алгы битендә үземне күргәч егылыплар китәрдәй булдым!

Геннадий. Киресенчә, сез, журналга чыгып, күпме кешене бәхетле иткәнсез!

Мәдинә. Әй, исемем телдән төшмәде. Хатлар да алдым әле...

Геннадий. Хатлар? Кемнәрдән инде? Әгәр сер булмаса...

Мәдинә. Кемнәрдән?.. Егетләрдән... ирләрдән...

Геннадий. Ә эчтәлеге нинди иде?

Мәдинә. Эчтәлеге бер инде аларның: яратам, сөям, дигәннәр... Ой, үләрсең! *(Көлеп җибәрә.)*

Геннадий *(күңелсез).* Кешенең хисләреннән, мәхәббәтеннән көлү...

Мәдинә. Юк. Юк, сез мине аңламадыгыз. Мин килгән хатларның бары тик икесен генә саклап калдым. Ни өчен көлдем? Чөнки аның берсе бик тә көлкеле, икенчесенә охшамаган... Анысы, киресенчә, җитди, тирән мәгънәле... Телисезме, мин сезгә беренчесен, ягъни көлкелесен укыйм?!

Геннадий. Кеше хатын уку хәрби серне ачу белән бер, билгеле. Ләкин бу очракта мин сезнең теләгегезгә каршы килә алмыйм. Укыгыз!

Мәдинә. Менә ул, монда гына ята... *(Өстәл тартмасыннан хат алып.)* Моны миңа бер өйләнмәгән, буйдак кеше язган...

Геннадий тамак кырып куя. Өй эчен күзәтә. Балаларның фотоларын
күреп моңсулана.

Мәдинә *(тамак кырып).* «Хөрмәтле Мәдинә! Менә мин сиңа хат язарга булдым әле! Синең рәсемең чыкканнан бирле, «Сөембикә»нең һәрбер санын калдырмыйча укып барам. Мин сиңа беренче карауда ук гашыйк булдым, малай! Мин үзем әллә кем түгел, гади тракторчы, трактор йөртәм... йөргәндә... сине оныта алмыйм! Тракторга утырсам, анда син, малай, өйгә кайтсам, анда да син, малай! Бөтен җирдә дә син, малай!»

Геннадий *(кашын җыерып).* Что за «малай»?!

Мәдинә. «Синең рәсемең төшкән журналны йөз штук сатып алып, бөтен җиргә ябыштырып бетердем, малай!»

Геннадий. Ну и малай!

Мәдинә. «Син, малай, мине онытма инде, малай, син дә миңа хат яз инде, малай, син җавап язсаң, минем күңелемә май булып ятар иде».

Геннадий *(ирония белән).* Малай?!

Мәдинә. Ие, малай! *(Мәдинә, Геннадийның көлмәгәнен күреп, укудан туктый.)* Сезгә кызык түгел, шулаймы?

Геннадий. Мин сирәк көләм. *(Пауза.)* Сер булмаса әйтегез әле, ә икенчесе кемнән иде?

Мәдинә. Ә анысы еракта... Одессадан... Хат җибәргән кешенең исеме... Геннадий... Бакирович иде булса кирәк...

Геннадий. Булса түгел, ә нәкъ шулай.

Мәдинә. Хәрби кеше бугай.

Геннадий. Бугай түгел, ә чынлап та хәрби кеше.

Мәдинә. Сержант... бу...

Геннадий. Ялгышасыз.

Мәдинә. Мин ул званиеләрне бөтенләй начар беләм...

Геннадий. Отставкадагы старшина.

Мәдинә. Ә сез каян беләсез?

Геннадий *(төз басып).* Чөнки ул хатның авторы менә сезнең каршыгызда басып тора! Отставкадагы старшина Геннадий Бакирович Әфләтунов!

Мәдинә. Сез?!

Геннадий. Нәкъ үзе.

Мәдинә. Кичерегез... мин сезнең хатыгызга җавап яза алмадым.

Геннадий. Көттем. Бик көттем. Мин — хәрби кеше, мин иң элек төгәллек, тәртип яратам. Хатны җавапсыз калдыруыгыз, шулай ук сезне күрү теләге мине әнә шундый ерак сәфәргә этәрде.

Мәдинә. Одессадан... Ә анда татарлар бармыни соң?

Геннадий. Татарлар кая гына юк ул, мадам! Мин дә бит сибелгән татарның бер газиз баласыдыр...

Мәдинә. Ә журнал, «Сөембикә»?!

Геннадий. Хатын алдырта иде.

Мәдинә. Сезнең хатыныгыз бармы?

Геннадий. Хатыным мәрхүм... Моннан бер ел элек йөрәк авыруыннан үлеп китте. Мин инде күптәннән иректә кош. Ләкин иректә кош та бертуктаусыз һавада очып йөри алмый. Ул да кайчан да булса бер килеп кунакларга, җан-җанашы белән оя, гаилә корырга тиеш. Тәртипне югалтырга ярамый. Шуңа күрә дә минем бар өметем сездә генә, Мәдинә ханым!

Мәдинә. Ә мин сезнең өметегезне кисәргә мәҗбүрмен, кызганычка каршы...

Геннадий. Әйе. Аңладым. Сәфәргә чыгар алдыннан мин бу турыда уйлап җиткермәгәнмен. Әйе, ирегез, балаларыгыз эшне катлауландыра, билгеле. Ирегез белән ничек торасыз?

Мәдинә. Начар. Эчә, туктаусыз тавыш чыгара, беркая да эшләми. Аерылырга йөрибез...

Геннадий. Андый тәртипсез ирдән иртәме-соңмы котылырга кирәк булачак, Мәдинә ханым. Балаларыгыз ничәү?!

Мәдинә. Өчәү.

Геннадий. Өч — яхшы сан. Шулай да дүрт-биш түгел бит әле. Нишлисең, хәл шактый ук катлаулы булса да, мин сездән өметемне өзмим, Мәдинә ханым. Сезгә карата мин бик нык ихтирам хисе кичерәм! Сез ничектер минем беренче хатыныма да охшагансыз! Мин, гомумән, авыл кызларын яратам! Алар — эшчән, сабыр, түземле. Беренче хатынымны авылдан урлап алып киттем, частьта өйләндем. Әти-әниләре дә эшне соңыннан гына сизделәр... Әгәр дә менә без дә сезнең белән шундый серле рәвештә кавыша алсак, мин үземне чиксез бәхетле һәм шат тояр идем. Үтенеп сорыйм, минеке булыгыз! Бергә булыйк! *(Кулыннан үбә.)*

Рәбига керә. Усал карап тора.

Рәбига. Әстәгы... Бу кем?

Мәдинә *(кулын алып).* Кунак... Одессадан...

Рәбига. Ә! Теге фотографмы?! Командировкага килгәнме? Эш белән.

Мәдинә. Әйе... эш белән...

Рәбига. Күрәм нинди эш белән килгәнен, күрәм...

Мәдинә. Әнкәй...

Рәбига. Ярый. Ярый, әйттем исә кайттым. Хатыны бармы?

Мәдинә. Юк. Үлгән хатыны...

Рәбига. Анысы ярый икән... Исеме?

Мәдинә. Нишләп үзеннән сорамыйсың?

Рәбига. Синең белән сүләшәм бит, ул, телен йоткан сыман, сүзсез тора.

Геннадий. Геннадий...

Рәбига. Урыс икән! Әйтәм җирле... дәшми. Хәер, урыс булмагае, чуртым булсын, кеше генә булсын! *(Геннадийга.)* Ученны приятны! Я — мама, это — дучка! Мадинучкы! Ты, дарагуй, зрә через нас не прошел, я бы стулом пуставил, чәйкум бу угостил! Ә уних никогда ничу нет, здес ничу не дождүсся!

Мәдинә. Әнкәй, тукта инде...

Рәбига *(Мәдинәгә).* Тукта, кысылмале! *(Геннадийга.)* Урыский плух знам, алдан ук әйтәм, вчутаки алдан безгә зуходит надо был! У нас бит увсе ес! И баны ес, и погреф ес! Ә погрефтә чава тулке нет! И огурцыйлар һәм кыярлар, и помидорлар, һәм, хреннар... бар да бар, увсе ес!

Мәдинә көлә.

Рәбига *(Мәдинәгә)*. Нәрсә ыржаясың?! Мин монда, барлы-юклы урысчамны такылдап, синең язмышыңны хәл итәргә тырышам, ә син ыржайган буласың! Җүнләп кияүгә чыгалмыйсыз, җүнләп яши алмыйсыз! Аннан әнкәгез кирәк була! Җитте! *(Геннадийга.)* Значит, син, Знакум, женится субрался, да?!

Геннадий *(аптырап).* Да вот...

Мәдинә көлә.

Рәбига. Кара, җиттеме сиңа, юкмы?! Бик көләсең килсә, әнә бар, исерегең янына утын ватарга чык! Торма монда каршымда ыржаеп! *(Геннадийга.)* И-хи-хи! Дучка муя шибке умная, шибке матур! Ты мне туже шибке пунравился... Мужет әле и киявем станешь! Как знат, как знат! Хурушиу будеш кияү! Ә теге кияүне без аны прогунем, ул плахуй кияү! Алкаш, дебошир, пьянчук! Нам он не нужен, нам нужен ты! Мы его убурем с дуруги... са... са... са... стулбовой... Әстәгы! Әллә ниләр сүли башладым бугай! Ну шушы урысча белмәүләрем, шуның аркасында гына да авылда калдым! *(Мәдинәгә.)* Ярдәм итәр идең, ыржаеп торганчы, син бит русский хуруш знаш, а?!

Мәдинә. Әнкәй...

Рәбига. Әү?!

Мәдинә. Нишләп син аның белән урысча сөйләшәсең?

Рәбига. Ә ничек сүләшим, башка тел белмәгәч...

Мәдинә. Ул татар бит...

Рәбига. Ә?!

Мәдинә. Ул Бакирович, фамилиясе Әфләтунов...

Рәбига *(исе китеп).* Әй... вәт бит әй! *(Геннадийга.)* Татармыни соң син?! Әй кардәш, милләттәш! *(Кочаклый.)* Җитмеш чакрым җирне якын итеп килгән бит әле ул, бер күрешер, бер очрашыр өчен...

Рәбига, Геннадий кул биреп күрешәләр. Алар буталышканда, Мингазиз, Хабл килеп керәләр дә боларны күреп посалар. Мингазизнең
кулында балта. Эт өрә.

Мингазиз. Бу эт нигә безгә генә өрә соң бу, ә?!

Хабл. Аракы исен яратмый ул...

Мингазиз. Менә күрдеңме инде, түще нишли? Кем ул теге? Кемне кочаклый ул?!

Хабл *(Геннадийны күреп).* О-па, Нежданчик! Неждан, Неждан... Нишлибез?

Мингазиз. Түщенең чыгып киткәнен көтәбез дә тегенең башына җитәбез! Ә хәзергә качып торабыз! *(Качалар.)*

Геннадий *(күңеле булып).* Рәхмәт сезгә, рәхмәт җылы сүзләрегез өчен, рәхмәт! *(Түземсезләнеп.)* Булды, җитәр!

Рәбига. Җарар, мин кайтып өстәл әзерли торыйм әле, бераздан соң безгә килерсез! Мәдинә, ишеттеңме?

Мәдинә. Ишеттем, әнкәй!

Рәбига. Киттем, көтәм сезне, көтәм...

Ашыга-ашыга чыгып китә.

Мәдинә. Ай кызык кеше дә инде минем әнкәй, зинһар, аның сүзләрен чынга алмагыз!

Геннадий. Ә аның сүзләрендә дөреслек бар. Әгәр дә ул мине кияве итеп күрергә тели икән, монда аның ни гаебе бар?!

Мингазиз атылып чыга. Аңа Хабл ияргән.

Мингазиз. Кияү? Нинди кияү?!

Мәдинә, Геннадий сискәнеп китәләр.

Мәдинә. Мингазиз?! Син...

Мингазиз. Мин! Нәрсә субственный иреңне дә танымый башладың мәллә инде?!

Мәдинә. Ташла балтаңны! Әле ярый әни күрмәде! Чакырта иде бит ул милиция, утырта иде үзеңне!

Мингазиз. Утыртсын, чакыртсын! *(Мәдинә каршында балта уйнатып.)* Син бар әле, югалып тор моннан, мин менә бу кунак белән бер сөйләшеп алыйм әле!

Мәдинә. Мингазиз, кешедән оял!

Мингазиз. Бар әле, бар! *(Мәдинәне чыгарып җибәрә.)* Хабл, якынрак кил!

Хабл. Иду, Пятачок!

Мингазиз. Сәлам...

Геннадий *(сабыр).* Сәлам!

Мингазиз. Йә, ничек, ирләрчә сүләшеп алабызмы?

Геннадий. Әйдә сөйләшик.

Мингазиз. ...күбәләк, бергәләп...

Хабл *(Геннадийга).* Абый, сез Мамадыштан түгелдер бит?

Геннадий. Юк. Мин Одессадан.

Хабл. О! Одесса! Джентельмен-шоу! Бабан Иваныч! Лучшая в мире десятка анекдотов... Итак, муж возвращается с командировки...

Мингазиз. Тәк. *(Геннадийга.)* Димәк, син кияү буласың инде?!

Геннадий. Аңламадым...

Мингазиз. Ну ярый, сине монда кияү урынына чакырганнар, түще оештырган инде моны, ярый, син кияү ди, ә мин кем инде бу очракта?! Әйе, кем мин? Киләчәктә мин кем булып калырмын?!

Хабл *(борынын кысып).* Ты будешь как великий Не-хо-чуха!

Пауза.

Мингазиз *(Геннадийга).* Димәк ки, син Мәдинәнең кияүдә икәнен белмәдең?

Геннадий. Юк. Күрешергә, танышырга кайттым.

Мингазиз. Син кайтуын кайткансың да бит, бик үк дөрес кайтмагансың. Мин исән бит әле, мин — Мәдинәнең закунный, штампованный ире!

Хабл. Сиңа, абый, бу яктан тизрәк таю ягын карарга кирәк, диңгез ягына, кипарислар иленә! Тем более Мамадыштан да түгел икән әле син!

Геннадий. Бу нәрсә, мине куркытырга маташумы, әллә...

Хабл. Безгә каршы чыгуның мәгънәсе юк. Безнең күк асыл егетләргә! Мингазиз, например, ул сабантуй батыры... татарча көрәш буенча...

Геннадий. Кайсы елда?

Хабл. Ничек кайсы елда?

Геннадий. Кайсы елда сабантуй батыры булып калды, дим?! Төгәл датасын әйтә аласызмы?

Хабл *(каушап).* Әйтик... ну... 99 да... 99 килограмлы үлчәүдә... Ә мин үзем чабышчы... 100 метрны име... 7 минутта киләм... Так что...

Геннадий. Мине берни дә куркытмый! Сез генә түгел, Төньяк полюсның салкын җилләре дә ала алмады мине!

Мингазиз. Ә мин, беләсең килсә... аю тоткан кеше.

Геннадий. Нинди аю?

Мингазиз. Урман аюы инде. Мари урманыннан килеп чыккан да безнең Теләнче авылы аркылы Оренбург өлкәсенә китеп барышы булган...

Геннадий. Ну?!

Мингазиз. Унлап кеше урамда аю куып йөри. Шарт-шорт мылтыктан аталар, тидерә алмыйлар. Аю да авылдан чыкмый. Нишләргә? Өч мәртәбә атып карадым — тимәде... Тоттым да Сәгыйть абзыйга киңәшкә киттем...

Геннадий. Кем ул Сәгыйть абый?

Хабл. Посторонний В... осел... иа... *(Ишәк булып кычкыра.)*

Мингазиз. Тайгаларда урман кискән, аюларны күп очраткан. «Закун тайга, — ди бу безгә, — мидбит хузяин, а в районах черноземья один хузяин галава! «Хикмәти адәм булып чыкты бит бу! «Аюны, егетләр, аны болай тоталар, — ди бу, — ике метрлы фанер аласыз, тазараклары шуны тотып торсыннар». Таза булгач, фанерны үзем тотып тордым. Аю йөгереп килеп теге фанерны сикереп кенә чыкмакчы иде дә, булдыра алмады, тырнагы белән фанерга эләгеп калды. Аю, бәгырь, миңа карый, ә мин — аңа. Нәкъ менә син миңа карап торган күк. Ул миңа күз кыса, ә мин — аңа. Сәгыйть абзый килде дә болай ди: «Аюның койрыгын күтәрергә кирәк. Койрыгын күтәрүгә үк, арт ягына атарга кирәк». Шулай иттек тә. Колхозның баш агрономы, йөгереп килеп, аюның муенын кытыклый. Аю койрыгын күтәрә. Баш зоотехник аның арт ягына ата. Теге мескен үлә. Сварочный аппарат белән тиресен өтеп, итен колхоз базарына илтеп саталар. Саткан акча дүрт ел буена хезмәт хакы алмаган колхозчыларга түләргә җитә. Хәзер бар халык, эш ташлап, урманда аю эзләп йөри. Берсе булмаса, икенчесе булыр, янәсе.

Геннадий. Белмим, белмим, ялгышмыйсың микән?..

Мингазиз. Нидән?

Геннадий. Аюның койрыгы юк бит.

Мингазиз *(балтасын уйнатып).* Таярга вакыт җитмәде микән, дим мин сиңа! Минем фикер шундыйрак иде...

Геннадий. Сезнең фикерегез мине кызыксындырмый. Мәдинә ничек әйтә, шулай булыр.

Хабл. Ир белән хатын арасына керү зур гөнаһ. Ә алар бик тә тату, матур яшиләр. Ну, мәсәлән, как Гена с Чебурашкой!

Геннадий. Ничек яшәгәннәрен миңа сөйләделәр. *(Мингазизгә.)* Мәдинә сезне яратмый, ул сездән туйган, гарык булган. Мәдинә ханым белән безнең мөнәсәбәтләр киләчәктә ничек бәйләнәчәген тәгаен генә әйталмасам да, мин олы җанлы, гүзәл ханымны сез исеректән, дөнья хәсрәтеннән коткаруга бөтен көчемне дә куячакмын!

Мәдинә кереп, тыңлап тора.

Хабл. Кру-то! Берет на мушку!

Мингазиз *(Хаблга).* Әйттем бит, түще чакырткан, дип... *(Геннадийга.)* Эх, брат, әгәр дә син безнең як кешесе генә булсаң, мин инде күптәннән синең башыңны кулыңа тоттырып җибәргән булыр идем җибәрүен. Тик әлегә монда кайбер аңлашылмаган нәрсәләр бар... Әйт әле, дөресен генә, сиңа Мәдинә алай-болай кияүгә чыгарга дип сүз бирмәгәндер ич, ә?!

Мәдинә *(алга чыгып).* Бирдем...

Мингазиз *(сискәнеп).* Ә?!

Мәдинә. Геннадий миңа тәкъдим ясады, ә мин аны кабул иттем. Күңелең булдымы инде?!

Хабл. Ну Гена, ну крокодил!

Геннадий нидер әйтмәкче була. Мәдинә аңа, ишарә ясап, дәшми торырга куша. Мингазиз бермәлгә телсез кала.

Мингазиз. Менә... бит ничек икән?! Хана килгән икән бит миңа...

Хабл *(көйләп).* Хана приходит незаметно, когда его никто не ждет...

Мингазиз. Хатынсыз калдыммыни мин шулай итеп?! Ә?! *(Пауза.)* Карале, Хабл, нишләп соң безгә бу вакыйганы юмаска, ә?!

Хабл. Правильно мыслишь, Пятачок!

Мингазиз. Хабл, бар әле идән астындагы чүпрә суын алып мен! Беткән дөньясы беткән, эх, бер эчеп калыйк әле синең белән! Бар, тиз!

Хабл. Очам, Пятачок! *(Китә.)*

Мәдинә. Мингазиз, инде күпме эчәргә була, туктарга вакыт...

Мингазиз. Җитте! Син тыгылма, син миңа хатын түгел хәзер, талак, талак сиңа!

Мәдинә. Акылыңа кил, Мингазиз, хурлама мине кеше алдында, әле соң түгел, тукта...

Мингазиз. Соң инде, җаным, соң. Син мине саттың, чыгарып аттың, ил тарткалады, сугышлар башланды, ахырзаман! Ничек монда эчмичә түзәсең ди! Ничек моңа минем нечкә күңелем сызланмасын ди!

Геннадий. Авылда яшәп тәмам чудакка әйләнеп барасыз димме! Ниндидер дөньяви проблемалар турында сөйләгән буласыз, ә диңгез тубыктан гына юкса үзегезгә!

Мингазиз. Шулай инде... без бит Одессада яшәмибез! Безнең баткак инештә, батам дисәң дә, батып үлеп булмый шул. *(Көйләп.)* Ай йөрәгем, вай йөрәгем, нигә яна йөрәгем, потушите... зинһар...

Мәдинә. Мингазиз, син...

Мингазиз *(дәшмәскә ишарә ясап).* Чү, чү, зинһар, дәшмәгез, бик каты дәшеп йөрәк өянәгемне кузгатмагыз... Йөрәк болай да слабый... *(Юри кыланып.)* Ай, менә башланды... йөрәк... Ха...бл... Мультфильм... кая китеп олактың?.. Юк, юк, мин сезне гаепләмим, мин сезгә бәхет кенә телим... Барыр юлларыгыз тигез, киләчәгегез якты булсын... Ай... йөрәк...

Хабл күренә. Чүпрә суы тутырылган бик зур пыяла савыт күтәреп керә. Савытның башында озын шланг чыгып тора. Тигезлеген югалткан Хабл чайкалып китә. Савыт чак кына килеп төшми. Йөрәген тоткан Мингазиз тиз генә ярдәмгә ташлана. Геннадий да булыша.

Алар өчәүләп аны өстәлгә утыртып куялар.

Хабл. Җен авырлыгы бардыр монда! Эчемлекнең яртысы гына калса да...

Мәдинә. Аның яртысын Мингазиз чөмереп бетергәндер шул инде, юкка гына шланг тыгып куймаган. Ничек сыйган диген син?!

Мингазиз. Миңамы? Миңа сыя ул! *(Кәефле генә корсагын кашып.)* Бу корсакта җитмеш пот сырадыр яки бер вагон аракыдыр...

Мәдинә *(рәнҗеп).* Дивана... сәрхуш... Юк, ни генә булмасын, мин монда сиңа эчеп ятарга ирек бирмәм! Геннадий Бакирович!

Геннадий. Тыңлыйм, Мәдинә ханым!

Мәдинә. Сез хәрби кеше, отставкадагы старшина! Сез миңа ярдәм итәрсездер дип уйлыйм?!

Геннадий. Мин сезгә һәрчак ярдәм итәргә әзермен!

Мәдинә. Менә бу әтрәк-әләмнәрне, кулларына чүпрә суларын тоттырып, өйдән чыгарып җибәрергә кирәк булыр!

Геннадий. Нет проблем! *(Якынлаша.)*

Мингазиз. Хабл, ярдәмгә!

Хабл, Мингазиз Геннадийның юлына каршы төшәләр.

Якын килмә, старшина! Бу минем йорт, мин салган йорт, мин монда ни теләсәм, шуны эшли алам! Старшина, кит!

Хабл. Старшина?! Почему не имеет ордена?!

Мингазиз. Нинди ордена?! Отставкада, диде бит!

Хабл. Шундый яшь, ә инде отставкада! Ничек алай була соң ул?!

Геннадий. Мин мәҗбүри отставкада. Илдә ни барганын күреп торасыз! Армиягә караш үзгәрде, кыскартулар бара...

Мингазиз. Әһә! Кыскартканнар моны! Әйбәт кыскартканнар! Менә әйтәм бит! Ничек йөрәк янмасын?! Мондый кыскарган җүнсез армия белән без хәзер кемне генә җиңә алырбыз икән?! Без немец фашистларын җиңүчеләр! Теге утрауда яшәүче мескен кыргый папуасларны җиңсәк кенә инде! Ә?! Ничек моңа күңел сызламасын?! Хабл, күтәр шлангыны! Ал чүмечне! Бу хәлдән эчмичә мөмкин дә түгел...

Хабл. Чүмеч аларда, Хафизәләм-иркәм!

Мингазиз *(чүмечне Мәдинә кулында күреп).* Карале, бир әле чүмечне тизрәк, йөрәк яна бит, йөрәк!

Мингазиз Мәдинә кулыннан чүмечне тартып алмакчы була. Мәдинә тегенең башына чүмеч белән кундыра. Мингазиз миңгерәп китә. Аңга килеп, икенче кулы белән чүмечкә сузыла. Геннадий аның кулыннан каерып ала.

Мингазиз. Ай... кулым... җибәр... старшина...

Геннадий. Тәртипкә кертергә вакыт җитте сине, егет!

Мингазиз. Хабл, помоги!

Хабл. Хәзер, Пятачок! *(Сикеренә-сикеренә Геннадийга килә.)*

Геннадий. Әгәр бу җегетеңне туктатмасаң, кулыңны каерып сындырам, дустым!

Мингазиз. Ай... кулым... Хабл... отойди...

Хабл *(кире чигенеп).* Понял, Пятачок... Ребята, давайте жить дружно!

Геннадий *(Мингазизгә).* Ә бәлки, гафу үтенерсең?

Мингазиз. Җарар, җарар, гафу...

Геннадий *(көлеп).* Наряд вне очереди! *(Җибәрә.)*

Мингазиз. Ай кулым, бетте кулым... Менә күрәсеңме моны? *(Янган кулбашын күрсәтә.)*

Геннадий. Ни бу?! Кайда яндың шулкадәр?

Мингазиз. Кайда, кайда?! Танкта.

Геннадий. Ничек танкта?

Мәдинә. Уф! Тыңламагыз әле шуны, әкият сөйли бит ул.

Мингазиз *(Мәдинәгә).* Китеп тор әле, ирләр эшенә тыгылма. *(Геннадийга.)* Әфганчы мин.

Геннадий. Ә! Әфганчы! Гафу ит, брат, белмәдем. Белгән булсам...

Мингазиз. Зарар юк, зарар юк... Әфган сугышының башыннан ахырына кадәр булырга туры килде! Үзегез беләсез, интернациональ бурычны үтәмичә булмый.

Мәдинә. Уф!

Мингазиз *(Мәдинәгә).* Китеп тор әле, ә! *(Күзләрен акайта.)*

Мәдинә, кулын селтәп, кырыйга китә.

Геннадий. Кызык, кызык. Ә ничек булды ул?

Хабл. Пятачок, расскажи.

Мингазиз *(күзен дә йоммыйча).* Авыр, бик тә авыр сугыш булды ул. Безнең Т-34 танкы камалышта калды. Ә мин танк командиры. Алдан да, арттан да аталар. Һавадан бомба ташлыйлар, астан мина шартлаталар, чыдар хәл юк. Рәхәтләнеп чәй эчәргә дә бирмиләр. Беттек, минәйтәм. Нишләргә? Үлгәч-үлгәч, геройларча үләргә кирәк инде, мәйтәм. Танк башнясыннан башымны чыгардым да барам, мин сиңайтим, честь биреп. Аталар, һич кенә дә тидерә алмыйлар, чөнки сугышчан рух көчле. Шуннан бер дошман йөгереп чыкты да пулный хут килгән танкның башмагын бәреп чыгарды...

Геннадий *(шаккатып).* Ничек?

Хабл белән Мәдинә бер-берсенә карап көлешәләр.

Мингазиз. Ни беләнме? Чүкеч белән. Корал юк бит инде аларда. Алар аны бездән алып торалар. Бирмичә дә булмый: үзебезнең мөселманнар бит. Ярар. Туктады танк. Теге дошман дигәннәре чын мөселман булып чыкты. Кичер, кардәш, диде дә куак арасына кереп югалды. Менә, малай, шулчак тотындылар бит безнең танкка «катюша»лары белән сиптерергә. Кая анда чәй эчәргә?! *(Сулы чүмечкә карап куя.)* Сулатмыйлар да. Бер снаряд, сызгырып килеп, танкның башнясын алып атты. Очты бу. Ничек муен сынмаган, слушай?! Яна танк, танк белән бергә мин янам. Акырып янам.

Геннадий *(ышанып).* Кит аннан!

Мингазиз. Чын, билләһи! Әгәр дә борт-инженер шулчак каяндыр огнетушитель табып өстемә күбек сиптермәсә, миннән көл дә каласы түгел иде. Шул күбек исе *(чүпрә суын иснәп)* әле дә менә бетмәгән, киемгә сеңгән. Шуннан соң ачу чыкты бит, малай. Танкны 180 градуска борып алдык и һөҗүмгә ташландык. Ну чәен түктек инде дошманнарның, түктек.

Геннадий. Искиткеч! Ничек исән кала алдың соң син?

Мингазиз *(чүмечтән су эчеп).* Ах, рәхәт булып китте... Йөрәкләрем җазылып китте!

Геннадий *(Хаблга, Мәдинәгә).* Нинди герой яши икән бит авылыгызда, ә сез аны яшереп ятасыз! Гер-рой!

Мәдинә. Уф Аллам. Нинди герой булсын ул. Әкият сүли бит. Аның сугышта булганы юк. Бала чакта самавырга абынып егылган ул, самавыр суына пешкән.

Геннадий. Ә?! Ул шулай ялганчы дамыни әле?!

Мәдинә. Җә... күңелең булдымы инде?!

Мингазиз. Ә нәрсә? Мин синең бәхетле чыраеңа аек килеш карап торырга тиешмени соң? Син монда кияүгә чыгасың дип, сельсовет каршында бармак суырып утыра алмыйм бит инде! Монда старшиналар җыйнап кул каертмасаң, күңелең булмас идемени?!

Мәдинә. Ул сиңа тимәде. Сине тәртипкә генә кертте. Рәхмәт аңа. Ә мин китәм. Мин синең белән тора алмыйм!

Мингазиз. Китәсеңме?

Мәдинә. Китәм.

Мингазиз. Шуңа чыгасың дамы?

Мәдинә. Шуңа чыгам да!

Мингазиз. Соңгы сүзеңме бу?

Мәдинә. Бу минем соңгы сүзем. Балалар өчен борчылма. Аларны сиңа калдырмыйм. Алып китәм...

Мингазиз. Кая? Урмангамы?

Мәдинә. Әйе, урманга.

Мингазиз. Чыршылар арасынамы?

Мәдинә. Әйе, чыршылар арасына...

Хабл *(көйләп).*

В лесу родилась елочка,
И кто его родил?
Мария Лопес дурочка,
А Виктор крокодил!

Геннадий *(кызып).* Нәрсә бу? Мин моны үземнән көлү итеп кабул итәм. *(Хаблга.)* Әй син, җегет, кил әле монда!

Мәдинә. Геннадий Бакирович, кирәкми, вакланмагыз! Йорты да, байлыгы да Мингазизнең үзенә калсын! Ятсын шунда дусты белән чүпрә суын чөмереп, бер акылга килер әле, тик соңыннан соң булыр. Вакланмыйк... Киттек! Геннадий Бакирович *(күз кысып),* сез минем белән язмышыгызны бәйләргә әзерме?

Геннадий. Әзер, Мәдинә ханым, инде күптәннән әзер! *(Кулыннан үбә.)*

Мәдинә. Алып китегез мине үзегез белән!

Геннадий. Рәхәтләнеп! Киттек, Мәдинә ханым! Безне Одесса көтә! Кара диңгез көтә! Яхта, пляж көтә!

Мәдинә, Геннадий демонстратив рәвештә култыклашып чыгып китәләр.

Хабл *(тәрәзәдән).* Гена! Помаши маме ручкой! Пока! Ха-ха!

Мингазиз *(елап).* Менә мин дә хатынсыз калдым... Хабл, сал инде, йөрәк җана бит, йөрәк... Кайгы өстенә кайгы...

Хабл *(көйләп).* Шаланда полная кефали... А вся Одесса очень велика... *(Чүмеч белән чүпрә суы китерә.)*

Мингазиз *(алып).* Эх, баланда! *(Чөмерә.)* Мә, син дә чөмер! *(Хаблга тоттыра.)* Эх! Менә хәзер кәефләр әйбәтләнде, менә хәзер гармун күреген тартып алсаң да ярый! *(Кулына тальян гармун ала.)* Их-х! Чукынып китегез! Ник шунда яхтагыз белән капланып үлмисез! Китегез, китегез... юлыгызга ак җәймә! Их! *(Тартып.)* «Исем китми читтә үскән әфлисунга, бананга, үз илемдә җәмле миңа бәрәңге бакчасы да *(акырып),* бәрәңге бакчасы да!»

Хабл. Пятачок, акырмыйча гына булмыймы, ә?!

Мингазиз. Юк, булмый... Их, үтте гомерләр, үтте, акты гомерләр су кебек! *(Җырлап.)*

Ага-га су-лар, ай-яй-яй,
Ага-га сулар... ай-яй-яй.
Аг-га сулар... ай-яй-яй, ай...

*(Тамагын кыра.)* Ага-га...

Хабл. Ну, малай, син точно Рәхимкул!

Мингазиз *(көйләп).* Ага-га сулар...

Хабл *(үртәп).* Ага-га-вага-га! Син башка җыр белмисең мәллә?

Мингазиз. Мин белмәгән көй юк бу дөньяда, брат. Мин бу гармунда бөтен төрле көйне дә уйный алам. Әйдә, мин уйныйм, син җырла.

Хабл. Мин сиңа кушылып җырлый алмам шул, син дөрес уйнамыйсың!

Мингазиз. Уйныйм. Әйт, синең тональность нинди соң?

Хабл. Әле анысын да беләсеңмени?! Чамалыйсың икән... Ну фа-диез.

Мингазиз. Фадеев?

Хабл. Фадеев түгел, «Яшь гвардия» түгел. Фа-диез.

Мингазиз. Әһә! Фадиев... Таптым... *(Бармакларын гармун телләре өстендә йөрткәләп ала.)* Җә, нинди җыр, әйдә башла!

Хабл *(җырлап).*

Керим әле урманнарга,
Урманнар арасына...

Мингазиз гармунда «Керим әле урманнарга» көен уйнап җибәрә. Тик бер куплет уйнаганнан соң, «Ага сулар» көенә кайтып төшә.

Хабл. Сүлим әле серләремне...

Мингазиз. Ага-га... су-лар... ай-яй... ага-га...

Хабл. ... сандугач... Тфү! Тагын ага-га! Син чынлап та ага-гадан башка бүтән көй белмисең икән... Башка көйне генә башлыйсың, һаман шул ага-га кайтып төшәсең...

Мингазиз. Ага-га...

Хабл *(колагын томалап).* У-ла-ма, җитәр!

Мингазиз. Ничек уламыйсың?! Влад дусны да аттылар бит!

Хабл. Нинди Влад тагын?

Мингазиз. Теге «Час пик»ны алып баручы!

Хабл. Ә! Тапкансың дус! Нинди дус булсын ди ул сиңа! Менә мин синең дустың, син минем колакны җәллә әзрәк!

Эт улап куя.

Мингазиз *(хискә бирелеп).* Шигырь! Тыңла...

Урамда томан...
Ә безнең Томан
улый да улый...
Сәгать телләре
Туктап калганнар...
Ә көтә мине
Якты аланнар...
Ә мескен Томан
Улый да улый...
Йөрәгем шуңа
Сильно сулкылдый.
Язгы ташуда
Акты хатларым...
Кайда син ирек,
Кайда хатыным?

Хабл *(көлеп).* Я поэт, зовусь я Светик, от меня ко всем приветик! *(Пауза.)* Есенин... Мәхмүт Хөсәен...

Мингазиз. Хуже! *(Эт өрә.)* Тагын өрә. Карале, кеше юкмы анда?!

Хабл тәрәзәгә килә.

Хабл. Ха! «Ө-ө» кереп килә!

Мингазиз. Нинди «Ө-ө» тагын?

Хабл. Күршең Өмәмә!

Мингазиз. Шул гына җитмәгән иде! Җап ишекне!

Хабл ишекне ябарга өлгерә алмый кала. Өмәмә килеп керә. Алдагы ике теше юк. Эшчән, тырыш, ялгыз хатын, тик әз генә ычкынган.
Кара халат астыннан яхшы колготки кигән.

Хабл. О! Голден-Лейди! Лучшая в мире колготки!

Өмәмә. Ө-ө! Исәннәрмесез?!

Хабл. Исәннәр әле... Сез нихәл?

Мингазиз *(тупас).* Ни кирәк?

Өмәмә. Ө-ө! Ишеттем! Хатының ташлап киткән...

Мингазиз. Кайчан? Кайдан белдең?

Өмәмә. Инде бөтен авыл белә, җаным! Бөтен авыл сүли... Мингазизне хатыны Мәдинә ташлап киткән, диләр... Ө-ө! Әйбәт иткән! Мин әле аны мәми авыз дип йөри идем...

Мингазиз. Каян барысын да ишетеп өлгерә бу авыл халкы?! Син тараткансыңдыр әле?!

Хабл. Да! Как ежик в тумане!

Өмәмә *(чәчрәп).* Нәрсә, нәрсә? *(Хаблга.)* Әй син, эшсез керәшен, халык авыз иҗатын үрәнергә тотындың мәллә? Китеп тор! Олылар белән сүләшкәндә, читкә китеп тор! *(Мингазизгә.)* Җарар, әйбәт булган. Китсен әйдә, ул кайтканчы миндә торырсың!

Мингазиз. Ә?! Кем булып?

Өмәмә. Ир булып. Анысы бер. Түбәне ябасы бар. Синнән дә кулай кеше табалмыйм. Хатының юк, кулың алтын, колхозда эшләмисең...

Мингазиз. Түбә башыңны былтырлары гына яптырган идең бит әле?

Хабл. Чего, крыша поехала, да?!

Өмәмә. Ө-ө! Быел оцинкованный калайдан ябарга исәп. Бөтен кеше шаккатсын әле!

Хабл. Ө-ө!

Мингазиз. Бөтен кешене шаккатыра-шаккатыра, ирләреңне теге дөньяга олактырып бетердең инде, Өмәмә. Инде хәзер минмени чиратта?

Өмәмә. Ө-ө! Беркем дә олактырмады аларны, алар үз үлемнәре белән үлделәр.

Хабл. Ө-ө! Берсе, урманнан агач ташыганда, агач астында калды, икенчесе түбә башыннан егылып төште, түбә башы япканда...

Өмәмә. Синнән сорамыйлар. Тик кенә тор! Эшләмәгән, көч түкмәгән ирне асрый алмыйм. Әнә Мәдинә кебек йомшаклар асрасын! Мин бик гадел кеше! Мин иремнең хезмәте өчен түләмичә калганым юк! *(Мингазизгә.)* Әйдә утырма, киттек, яңгырлар җитә, түбәне яңадан ябасы бар. Киттек!

Мингазиз. Кая? Түбә ябаргамы?

Өмәмә. Карарбыз. *(Көлеп.)* Түбә җабарсыңмы анда, юрган җабарсыңмы! Әйдә җыен тизрәк! Миңа син бик тә кирәк, мин дә сиңа кирәк. Аракыны жәлләмәм, күпме хошь! *(Мингазизне өстери.)*

Мингазиз *(пышылдап).* Хабл, коткар!

Хабл *(чәчрәп).* Өмәмә апай, син нәрсә?! Дюймовочка что ли? Нет, Пятачок на это не пойдет!

Өмәмә. Син нәрсә белер-белмәс урысча сүләп торган буласың әле?! Чатан Гариф малае! Нинди Думывычка булыйм мин сиңа, нинди Пәтәчук! А-ну пшул отсуды! *(Этеп җибәрә.)*

Хабл *(чигенеп).* Ты че, соседка, игнорируешь тенденции парадоксальных эмоций?!

Өмәмә *(аңламыйча).* Нәрсә ди ул? Ә?!

Мингазиз. Түбә ябарга дисең инде?

Өмәмә. Ө-ө!

Мингазиз. Җарар, җарар, ябарбыз. Тик... бернәрсә бар... Әнкәйдән, ягъни түщедән үч аласы иде! Чөнки ул гына китереп чыгарды бит бу 11 сентябрьне! Хатынны да ул гына котыртты, балалардан да ул гына аерды, теге погонсыз, штатсыз старшинаны да ул гына кайтартты минем башка, ул гына!

Өмәмә. Ө-ө! Рәбига гомере буена миннән көнләште. Йорт салдырдым, йорттан көнләште, түбә яптырдым, түбәдән... Ирем үлгәчтен бәк шатланып йөргән иде, инде синең миңа авышканыңны күргәч, бәк тә көенер инде! Ха-ха!

Мингазиз. Ие. Сиңа авышканчы шуңардан бер үч алып каласы иде. Монда, күршем-бәгърем, синең дә булышлыгың кирәк булыр!

Өмәмә. Нинди ярдәм кирәк?

Мингазиз. Минем план бар. Соңыннан аңлатырмын. Ә син әлегә өеңә чыгып тор! Яме?!

Өмәмә. Җарар, чыгып пилмән куя торырмын! Ашыйсың килгәндер инде, ачыккансыңдыр! И җаным, бәгърем! *(Мингазизне үбә.)*

Хабл. Ие... Туй пилмәне... Дуй...

Өмәмә *(Хаблга күрсәтеп).* Моны да, чатан Гариф малаен да калдырма, алып кер, түбә җапканда, булышчы кирәк булыр... Ха-ха! Ө-ө! Җарар, киттем! Көтәм! *(Китә.)*

Мингазиз. Башлар бетте, Хабл. Бу җен хатыныннан котылам димә! Бер тагылса...

Хабл. Каян ирләре үлеп тора диген син аның?!

Мингазиз. Әйтмә дә инде... Хабл... алай-болай түбәдән очып төшсәм, мине кешечә җирләргә онытма инде, яме... Бар ышаныч синдә генә, Хабл. *(Пауза.)* Тик үлгәнче теге Рәбигадан үч алып каласы иде бит, әй!

Хабл. Ә ничек?

Мингазиз. Ничекме? *(Торып баса.)* Киттек! Мунчага табан... Шунда барын да аңлатырмын...

Хабл. Куда идет наш Винни-Пух, большой, большой секрет!

Мингазиз. Секреты менә аның! *(Кулына бау ала.)* Киттек, Мультфильм!
Хабл. Киттек, Пятачок! *(Авыз эченнән көйләп.)* Я тучка, тучка, тучка, я вовсе не медведь... *(Китәләр.)*

Сәгать суга. Музыка.

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук декорация. Бер генә үзгәреш: сул якта — мунча алды. Шуның тирәсендә төрле савыт-сабалар, чиләк-ләгәннәр, утын пү-лән-
нәре аунап ята. Хабл күренә. Аңа Рәбига ияргән.

Хабл. Рәбига апай, Рәбига апай!
Рәбига. Җә, җә, нәрсә?
Хабл. Тизрәк, Рәбига апай, болай әкрен кыймылдасаң, киявеңнән колак кагуың да бар.
Рәбига. Нәрсә, асылынам, диме?
Хабл. Болай озак селкенсәк, асылыныр да!
Рәбига *(кул селтәп).* Миңа димәгәе, ник катмый шунда!
Хабл. Соңыннан үкенечле булмасын!
Рәбига *(аягы таеп).* Ай Аллам! Шушы утынны да җыеп куя белмәде бит әй! Ай-яй! Әллә сындырдым инде, шушы кияү тәресен үлемнән коткарам дип! *(Аягын тота.)* Җә, кая соң ул?
Хабл *(мунчага күрсәтеп).* Менә шушында инде ул, шушы фигвамда!
Рәбига. Ә?! Син нәрсә минем алда сүгенеп торасың әле?!
Хабл. Сүгенмим мин, фигвам, дим бит! Индеецлар өйләрен шулай атыйлар... Фигвам!
Рәбига. Нинди фиквам булсын бу, мунча ич бу, бахыр, мунча! *(Пауза.)* Җә, җарар, исән микән инде бу?
Хабл. Исән булырга тиеш. Әнкәй белән хушлашмыйча бу якты дөньядан китү юк, дип әйтте ул!
Рәбига. Алла! Әллә мине дә үзе белән алып китәргә уйладымы? Кешечә генә асылына белмәде инде ул да!

Гырлап йоклаган тавыш килә.

Рәбига. Ни бу?
Хабл. Ни... Тончыга бу... бу... буыла... тизрәк...
Рәбига. Нишли тончыгып?
Хабл. Үлә... *(Күз яшьләрен сөртеп.)* Пятачок, бәхил бул...
Рәбига. Ай Алла! Күрәселәр бар икән! Үзең сакла! *(Укына-укына, мунчага кереп китә.)* Мингазиз... кияү...
Хабл *(кул изәп).* Галина-бланка, буль-буль, буль-буль...

Мунча эчендә тавыш-гауга. Мунчадан Мингазиз атылып чыга.
Ишекне тиз генә йозакка бикләп ала.

Мингазиз. Ха-ха! Капты! Моннан чыгу юк аңа!
Хабл. Галина-бланка *(көлеп),* буль-буль...
Рәбига *(тәрәзәдән башын тыгып).* Ачыгыз! Оятсызлар! Мунчага ябып үтерергә җыендыгыз мәллә?! *(Мингазизгә.)* Нәрсә ыржаясың, алдаганга шатланасыңмы?!
Мингазиз. Әнкәй! Син мине бик күп утырттың инде... унбиш суткыга, инде менә хәзер үзең утырып кара!
Рәбига. Ни өчен? Җә! Ни гаебем бар соң минем?
Мингазиз. Конституцияне бозганың өчен, безнең эчке эшләргә тыгылганың өчен!
Рәбига. Нәстә-нәстә?
Мингазиз. Хатын белән араны бозган өчен, хатын белән аерттырыр өчен, ниндидер погонсыз старшинаны кайтартканың өчен!
Рәбига. Мин беркемне дә кайтартмадым, ул старшинаны беренче тапкыр күрәм!

Мингазиз. Ә нишләп, алайса, аның янында биеп кенә йөрисең? Кош тоткан кебек! Кая китте алар? Кая хәзер минем хатын?

Рәбига. Каян белим, миңа ул караңгы.

Мингазиз. Ялганлама. Беләсең. Әйтмисең икән, ут төртеп яндырам хәзер мунчаны!

Рәбига. Соң, чукынмыш, мунчада мин ич!

Мингазиз. Тагы да әйбәт. Көлең генә калыр... Күмәсе дә булмас...

Рәбига. Алла! Караул! Үтерәләр! Күршеләр! Авылдашлар, кияү үтерә, кияү! Коткарыгыз! Кияү...

Мингазиз. Нинди кияү булыйм мин сиңа? Кияү түгел мин сиңа, мин тиздән башкага өйләнәчәкмен!

Рәбига. Кайчан?

Мингазиз. Хет бүген, хет иртәгә.

Рәбига. Ай Алла, кем генә чыгар икән сиңа? Нинди Ходай бәндәсе?!

Мингазиз. Чыгарлар. Бу дөнья бер синең кызыңа гына терәлеп калмаган. Әлегә сайланам әле мин, бик сайланам...

Рәбига. Сиңа чыккан кешедән бәхетсез кеше булмас инде бу дөньяда! Хәер, мин сиңа ышанып та беталмыйм әле! *(Хаблга.)* Хәбибулла энем, дөрес сөйлиме ул?

Хабл. Все в ажуре, мадам!

Мингазиз. Хе! Миңа ышанмаган була, ә! *(Хаблга.)* Ну-ка, Хабл, бар әле, миңа кәләш тап. Бар, бар, әнә халык арасыннан эзлә, әнә анда күпме хатын-кыз!

Импровизация: Хабл залдан кәләш алып чыга. Киендерә. Башына фата яба.

Мингазиз. Хабл, ярар, җитәр, Өмәмәне кертергә вакыт җитте!

Хабл. Өмәмә әзер, Пятачок!

Рәбига. Хәбибулла! Нәрсә, ишетмисеңмени?

Хабл. Ишетәм, нәрсә?

Рәбига. Дөрес сөйлиме ул?

Хабл. Дөрес, дөп-дөрес. Кәләше бар инде аның, туй күлмәгенә тиклем алынган.

Рәбига. Кем алды? Нинди акчага?

Хабл. Кем алсын?! Кияү! Синең акчага! Син үстергән теге ике тананы сатып җибәрдек тә...

Рәбига. Ә?! *(Сулышын кысып.)* Минем акчага? Таналарымны... Кире кайтар! Судка бирәм, ишетәсеңме?! Кышын бер тонна ташкүмер урлап алып кайтканыңны да язып бирәм, берсен дә яшермим.

Мингазиз. Ә кем якты соң ул ташкүмерне? Син якмадыңмыни? Бәлкем, якканыңны да язарсың, ә?!

Рәбига. Паразит!

Мингазиз. Шуңардан ук ишетәм!

Рәбига. Өйләнә, имеш! Кем чыксын сиңа?! Эчкече! Карак!

Мингазиз. Миңамы? Урамга чыгып бер сызгыру гына җитә, берсеннән-берсе чибәрләр җыелачак! *(Сызгырып куя.)* Хабл, син кая?

Хабл *(күренеп)*. Монда... Стою на шухере!

Мингазиз *(пышылдап)*. Әйдә, шухер-мухер итәргә вакыт җитте, алып кил чибәр тутыйны!

Хабл Өмәмәне алып чыга. Өмәмә матур киенгән. Актан.

Рәбига. Чыгар мине моннан! Чыгар тизрәк!

Өмәмә туктап кала.

Мингазиз *(танымыйча).* Кем бу?

Хабл. Кем, кем?! Принцесса на горошине! Сөйләшкән идек бит инде, онытыңмыни?!

Мингазиз. Өмәмәмени бу?! *(Өмәмәгә.)* Э... э... ээ... килдекме? Төкле аягың белән!

Өмәмә. Ө-ө! *(Пауза.)* Нәрсә ыржаясыз?! Нишләргә миңа? Уф, ояла башладым инде!

Хабл. Оялма, апакай! Сиңа хәзер яның белән генә булса да Рәбига апакайга күренеп алырга кирәк булыр! Безнең максат — түщене шаккатыру! Аны инфарктка, стенокардиягә, церебраль... церебраль параличка тиклем җиткерү! Шылдымы?!

Өмәмә. Ө-ө!

Хабл. Димәк, шылды. Шул чагында Мингазиз мәңгегә синеке булыр!

Өмәмә. Мәңгегә?

Хабл. Ие... үлгәнчегә ягъни.

Өмәмә. Ө-ө!

Хабл. Пятачок, түщегә әйт, кәләш килде инде, диген!
Мингазиз. Әнкәй, әнкәй, дим...
Рәбига *(сөенеп).* Нәрсә, чыгарырга уйладың мәллә? Тавышың бик матур!
Мингазиз. Юк... ни... Кәләш килде бит әле!
Рәбига. Ә?!
Мингазиз. Карап кал, димәкче идем!
Рәбига *(каранып).* Кая ул, күрмим?
Хабл *(Өмәмәгә).* Якынрак атла, ләкин бик якын да барма, танымасын! *(Этә.)* Бар, бар! Менә кәләш үзе! Килде. Килде... Ах, нинди кәләш! Ах, какая красавица! Активистка, понимаете ли, комсомолка!

Өмәмә Хаблның эченә төртә. Тегесе сыгылып төшә.

Рәбига *(яртылаш күреп).* Әстәгы... бу кем?
Хабл. Киндер-сюрприз...
Рәбига. Ке-е-ем?!
Хабл. Звезда китайского мультфильма!
Мингазиз. Минем булачак хатыным инде бу, хатыным-алтыным! Саҗидә... Егерме яшь... Әлдер-мештән...
Рәбига. Каян таптың моны? Бөкре димме?! Мөчәсе күршегез Өмәмәгә охшаган димме?!

Хабл тиз генә Өмәмәне икенче ягы белән әйләндерә.

Рәбига. Холкы ничегрәк, холкы?!
Мингазиз. Әйбәт! Мәдинә түгел инде! Бик тә күндәм, аның һәр сүзе йөрәккә май булып ята...
Рәбига. Азгын нәрсәдер әле!
Мингазиз. Урам чыраен да күргән кыз түгел әле ул! Синең кызың сыман хыянәтче түгел!
Рәбига. Алай бик яшь булгач, ялкаудыр ул!
Мингазиз. Булыр ялкау! Бер олау салам көчен ун минутта өеп ыргыта!
Өмәмә. Ө-ө! Өеп күрсәтимме?

Өмәмә, онытылып, кулына сәнәк ала да салам актарырга тотына. Хабл
аны туктатырга өлгерми.

Рәбига *(танып).* Әстәгы! Өмәмә ич бу! Нинди кәмит куясыз сез, ә?!
Өмәмә *(каушап)*. Ө-ө! *(Чыгып кача.)*
Мингазиз *(артыннан үртәп).* Ө-ө!
Хабл. Качты, Аллага шөкер! Әби белән нишләргә?
Мингазиз. Ятсын шунда! Әйдә, без өйгә керик. Бик тә көйрәдем, чүпрә суын сагындым! Ә син, Хабл, мунча ишеген дә, өйнекен дә бик шәпләп бикләп куй: ни түще, ни Өмәмә кералмасын! Ха-ха-ха!

Караңгылык.

**ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Сәхнәдә Мингазиз, Хабл. Уртада бушап калган чүпрә мичкәсе.

Мингазиз. Бу нәрсә бу... бушаганмыни?
Хабл. Бу... бу... бушаган шул!
Мингазиз. Идән астында тагын берәү булырга тиеш, бар әле, алып мен!
Хабл. Бая күрдем мин аны, күрдем, тик күтәрерлек түгел шул аны!
Мингазиз. Әй, аптырагансың икән, бар, шлангыны суз! *(Шланг бирә.)* Мә! Тарт тизрәк! Тарт!

Хабл, шлангны өстерәп, идән астына төшеп китә.

Тарттыңмы?
Хабл *(астан).* Тарттым!
Мингазиз. Тык хәзер шул шлангы башын! Тыктыңмы?
Хабл. Тыктым, Пятачок! Файдалана аласың!
Мингазиз *(көлеп).* Рәхәтләнеп! Шә-ә-әп!

Шлангтан су бәрә, Мингазизнең өсте чүпрә суы белән тула.

Хабл! Җап тизрәк! Агып бетә бит! Җап! Нинди хатын син... әй... җап!.. Имән тактаңны!

Хабл. Ябып булмый, кыс шуннан гына! Кыстыңмы?!

Мингазиз *(чыбык белән шланг башын кысып).* Уф! Котлар калмады!

Хабл күренә.

Хабл. Ничек?

Мингазиз. Кружка китер! Шуңар тамызып кына эчәрбез!

Хабл зур кружка китерә. Чүпрә суын агызырга торганда гына каты итеп ишеккә китереп тибәләр. Ишек ачылып китә. Ишектә — Өмәмә.

Өмәмә *(боларны күреп).* Ө-ө! *(Пауза.)* Мине мыскыл иттегез дә үзегез өйгә кереп качтыгызмыни?!

Хабл. Ө-ө!

Өмәмә. Сезне күпме көтәргә була?! Алып куйган түбә калаем күгәреп бетә бит инде! Тиздән яңгырлар башлана, өемә су төшәчәк! Ә болар!

Мингазиз *(пышылдап).* Хабл, бетерә бу безне, тап бирәр җаен! Каян гына бәйләндек шушы тулыр-тулмаска?! Тыныч кына эчәргә дә бирмиләр бит, әй!

Хабл *(йөрәген тотып).* Карале, Өмәмә апай, син әзрәк безнең хәлгә дә керә бел инде! Иманым камил, Мингазиз синеке булыр, сиңа түбә калаен да ябар. Тик аңла, аңа бик тә кыен хәзер!

Өмәмә. Ни булган аңа?

Хабл. Аңамы? Аңа хәзер бик зур кайгы килгән, ул хатыны белән аерыла. Ул хәзер яшьлеге, балачагы белән саубуллаша...

Өмәмә. Балачагы белән?

Хабл. Ие! Детсадка йөргән чаклары белән...

Өмәмә. Без үскәндә, авылда детсад юк иде! Ө-ө!

Хабл. Ни генә булмасын, сагындыра бит ул балачак дигән нәрсә. Әле менә дустым Мингазиз белән, гармунда уйнап, балачакта уйнаган көйләрне, җырлаган җырларны искә төшереп утыра идек. Әгәр син кермәгән булсаң, без балачакта яратып уйнаган уенны да уйнарга җыенган идек, тик менә син генә кереп комачауладың, әллә, мәйтәм, чыгып торасыңмы?!

Өмәмә. Чыкты ди бар? Нинди уен ул, өйрәтегез миңа да, минем уйнап карыйсым килә!

Хабл *(каушап).* Ай, нишләргә?

Мингазиз *(аптырап).* Ну өйрәт инде, өйрәт!

Хабл. Вәт бәла, ә! *(Пауза.)* Җарар, әйтсәм әйтим, «Күз бәйләш» дип атала ул уен!

Өмәмә. Ө-ө!

Хабл. Яшь чакта «Күз бәйләш» уены уйнаганың булдымы, Өмәмә апай?!

Өмәмә. Ө-ө!

Хабл. Ө-ө! Алайса, башлыйбыз!

Мингазиз *(Хаблның чабуыннан тартып).* Син нәрсә, Мультфильм, тагын нәрсә уйлап таптың?!

Хабл. Шаулама! Соңыннан күрерсең!

Мингазиз. Ә бәлкем, кирәкмәс тә, ә?!

Хабл. Ә кем миңа җаен табарга кушты?! Башка юл күрмим, шушы бер генә юл бар! Әгәр ошамаса...

Мингазиз. Бетте! Дәшмим!

Хабл. Шулай диген! Тәк! Башлыйбыз! Өмәмә апай!

Өмәмә. Әү, җаным!

Хабл. Яшь чакта уенга кем соңга калып килә, башта шуның күзен бәйли иделәр. Син бүген уенга соңга калып килдең, синекен бәйләргә туры килә инде. Каршы түгелдерсең бит?!

Өмәмә. Әйдә бәйлә, түлке тиз бәйлә! Бүген үк эшкә тотынасы иде, күктә болытлар куерып тора... Әйдә, тиз! Манчы!

Хабл, яулык алып, Өмәмәнең күзен бәйли. Хәйләне аңлап алган Мингазиз шатланып уч төпләрен уып ала. Хабл, керләр элә торган җепне тартып, аның һәр башына берәр кечкенә кыңгырау асып куя. Җепнең бер ягына Мингазиз, икенче ягына Хабл утыра.

Өмәмә. Абау! Караңгы! Берни дә күрмим!

Хабл. Болытлар куера. Өмәмә апай, куера! Болай!

Өмәмә. Ө-ө!

Хабл. Уенның шарты болай, Өмәмә апай! Хәзер җиз кыңгырау чыңлар, син, кыңгырау чыңлауга ук: «Раз, два, пять, я иду искать!» — дисең дә...

Өмәмә. Ничек? Ничек?

Хабл. Раз, два, пять, я иду искать! Аңладыңмы?!
Өмәмә. Ө-ө!
Хабл. Кабатла әле!
Өмәмә. Рәз, двә, пәт, я иду искәт!
Хабл. Вот маладис! Әйдә башлыйк! В кошки-мышки! Том и Джерри! *(Кыңгырауга суга.)*
Өмәмә. ...рәз, двә, пәт, я иду искәт!..

Өмәмә кулларын җәеп чабып йөри. Кыңгырау бертуктаусыз әле бер, әле икенче башта яңгырый. Өмәмә тегендә-монда йөгергән арада, Мингазиз, Хабл чүпрә суы чөмерәләр. Өмәмә эзли. Табалмый. Хабл, Өмәмәнең яулыгын салып атарга теләгәнен күреп, тиз генә ишекне ачып куя. Өмәмә ишектән чыгып китә. Хабл тиз генә ишекне бикләп ала. Тышта шап итеп егылган тавыш ишетелә. Эт өреп куя. Көлешәләр. Моңа бик күңеле булган Мингазиз кулына гармун ала да калын тавыш белән җырлап җибәрә.

Мингазиз. Ага-га-га су-лар... аг-га... су...лар... лай...
Хабл *(чын күңелдән Мингазизгә кушылып).* Ага-га-га су-лар... кайларга ла...
Икесе бергә. Кайлар-га... га...

**ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Бакча ягыннан Мәдинә, Геннадий керәләр.

Мәдинә. Әнкәй кая?
Мингазиз. Ага-га... ха! Мин кемнәрне күрәм!
Мәдинә. Әнкәй кая, дип сорыйм мин синнән?
Хабл. Ау-у! Әнкәй, кая син?!
Мәдинә *(тыңланып).* Мунчада әнкәй тавышын ишетәм, син аны бикләп куймагансыңдыр ич?!
Мингазиз. Ие!
Мәдинә. Нигә?
Мингазиз. Сезгә үч итеп...
Мәдинә. Оятсыз! *(Ишектән чыгып китә.)*
Мингазиз. Ә нәрсә?! Сез кайтмыйсыз да кайтмыйсыз! Одессага, диясез дә чыгасыз да китәсез, Одессага, диясез дә югаласыз...
Геннадий. Иптәш, без Одессага бармадык.
Хабл. А куда? На кудыкины горы?!
Геннадий. Сорочига! Ярминкәгә бардык.
Мингазиз. Ниемә?
Геннадий. Мәдинә үзенә, балаларына кирәк-яраклар алды.
Мингазиз. Нәрсәсенә? Каян шулай бик тиз баеп китте соң әле ул? Ю-ук! Ярминкәдә булмаган сез, каядыр бүтән җирдә! Шулаймы, иптәш старшина?
Геннадий. Әйе, нәкъ шулай.
Мингазиз. Сиңа үпкәм бик зур, ә, старшина! Әле аерылып бетмәгән хатынны алдың да каядыр качтың! Ни хакың бар?
Хабл. Ие! За это у нас бьют!
Геннадий. Где это у вас?!
Хабл. У нас... в деревне... в Просто-ква-шино! *(Күкрәк киереп.)* Беләсең килсә, мин бөтен авылны кулда тотып торган кеше!
Геннадий. Первый парень в деревне, а в деревне один дом! Так что ли?!
Хабл. Пятачок! Бездән көләләр! Әгәр дә без көлә башласак, ә?!
Геннадий. Көләргә түгел, еларга кирәк сезгә! Кемнән үч аласыз? Ялгыз, көчсез карчыктанмы?! Мин сезнең кебекләрне армиядә дә, тыныч тормышта да хөрмәт итмәдем! Һәм хөрмәт тә итмәячәкмен!
Хабл *(Мингазизгә).* Сизәсеңме, ул безне кабат кыйнарга җыена!
Мингазиз. Җитте! *(Торып.)* Бу килмешәкнең башын кулына тоттырып җибәрергә вакыт җитте! Хабл, эләктер!
Геннадий. Кем кемнекен тоттырыр бит әле!

Хабл Геннадийга сикерә. Геннадий бик тиз Хаблны очыра.

Хабл. Пятачок, помоги!

Мингазиз. Ну, старшина, хана сиңа!

Мингазиз Геннадийга ташлана. Геннадий Мингазизнең кулыннан
каерып ала. Мингазиз авыртуга түзалмыйча егыла.

Ай! Кул! Җибәр!

Геннадий. Кая хезмәт иттең?

Мингазиз. Танковыйда.

Геннадий. Кайчандыр син яхшы танкист та булгансыңдыр, ә хәзер син бернигә дә ярамыйсың. Менә шуннан нәтиҗә яса инде! *(Мингазизнең кулын ычкындыра.)*

Мингазиз. Врешь! Не возьмешь! *(Күтәрелә.)*

Мингазиз китә башлаган Геннадийга ташлана. Геннадий бик каты итеп Мингазизнең күкрәгенә суга. Мингазиз сыгылып төшә. Хабл аны
селкетә. Мәдинә керә.

Мәдинә *(куркып).* Ой, кирәкми, тимәгез аңа! Мингазиз, син исәнме? Мингазиз... ник тормыйсың?

Хабл. У-мер!

Мәдинә. Ә?! Юк, ышанмыйм...

Хабл. Үл-де!

Мингазиз *(аңга килеп).* Үләр, бар, үтерерсең Мингазизне! Ә син, хатын, бар әле, ирләр арасына тыгылып йөрмә! Китеп тор, мин аны хәзер үзем әтмәлләп алам!

Мингазиз тора, Геннадийга карый.

Әнкәйне чыгардыңмы?

Мәдинә. Чыгардым...

Мингазиз. Нәрсә ди? Кая китте?

Мәдинә. Милициягә йөгерде...

Мингазиз. Башка йөгерә торган урынын белмим мин аның, йөгерсә, шунда гына йөгерә инде ул! Да-а! Укыттылар минем арт сабакны, хәер, миңа шул кирәк тә булган инде! Калдырыгыз мине, ялгызым гына калдырыгыз, минем башка яшәрлек әмәлем калмады... Зинһар өчен, калдырыгыз!

Мәдинә. Юләр син, Мингазиз. Без бит сиңа яхшылык кына телибез! Айнырга вакыт җиткән сиңа бу түбәнчелектән, бу аяныч хәлдән!

Мингазиз. Ә айнып ни файда? Әгәр Гондураста... Ни кызыгы бар бу дөньяда яшәүнең. Калхуз бетте, таркалды. Эшлисең, акча түләмиләр. Ирләрнең пачуты бармыни суң хәзер?! Хатыннар бездән күбрәк акча ала. Ә безгә нишләргә кала? Иле белән бардак, яшәү әмәле калмады... Мин, менә мин, кемгә кирәк хәзер?!

Мәдинә. Юләр! Син миңа кирәк, син балаларыңа кирәк!

Мингазиз. Мин кирәк түгел сиңа, сиңа старшина кирәк!

Мәдинә *(иркәләп).* Ялгышасың... Миңа синнән башка беркем дә кирәкми, яратам мин син юләрне! Яратам! Бөтен барлыгың белән...

Мингазиз. Яратасың? Хе! Ә яратырлыкмы соң мин? Ничек итеп мине яратырга була? Дуңгыз бит мин! Дуңгыз!

Мәдинә. Үзеңне битәрли алгач, төзәлергә өмет бар икән әле!

Мингазиз. Яратам, дисең инде... Син әйттеңме соң бу сүзләрне?! Синме?!

Мәдинә. Мин инде, кем булсын, хатының!

Хабл. Яхшылап кара, Пятачок!

Мингазиз. Хатыным-алтыным... Син бит инде бу?!

Мингазиз Мәдинәне башаяк күздән кичерә. Киенгән-ясанган Мәдинәне танымыйча тора.

Юк! Бу син түгел! Хатыным түгел...

Мәдинә. Кем булсын соң инде, юләрем, хатының булмыйча! Йә, кил, кочакла, бүтән сиңа беркем дә тимәс!

Мингазиз. Син икән шул! Чит хатын булса, кочаклатып тормас иде! Ай-яй! Яңа киемнәр кигәчтен, сине хәзер танырлык та түгел. Нәрсә, әллә кунак киендердеме шулкадәр?

Мәдинә. Көнләшәсеңме?

Мингазиз. Әлегә кадәр көнләшми идем, менә бу старшина килеп чыкканнан бирле тынычлыгым качты. Их, җүләр мин, ә, тинтәк мин! Кая караган мин?! Никарагуа, Гондурас, имеш! Әфган... Чукынып

китсеннәр! Читләр өчен баш ватарга?! Гаиләңне, хатыныңны кара икән! Балаларыңны ярат! Иң элек өеңдә, гаиләңдә тәртип булырга тиеш икән ул! Гаиләңдә тәртип булса, илеңдә дә тәртип булыр!

Хабл. Ие! «Главнее всего погода в доме...»

Мингазиз *(Мәдинәне кочаклап).* Кичер мине, Мәдинә! Белмәгән, белмәгән мин синең кадереңне! Синең сабырлыгыңа, гүзәллегеңә соклана белмәгәнмен икән бит! Барлыгың, булганың өчен мең-мең рәхмәт сиңа! Хатыным минем, алтыным минем! *(Геннадийга.)* Старшина, сиңа да бик зур рәхмәт! *(Кулын кыса.)*

Геннадий. Ә миңа ни өчен?

Мингазиз. Әгәр дә син кайтып төшмәгән булсаң, минем күзләрне ачмаган булсаң, мин мәңгелек ушсыз, ваемсыз йөргән булыр идем. Түбән тәгәрәп, үземне дә, гаиләмне дә, хатынымны да харап иткән булыр идем... Мәдинәм, бәгърем! *(Кулыннан тотып.)* Яратам мин сине, яшьлек юләрлегем белән яратам! Синсез яшәү миңа юк, малай...

Мәдинә. Малай? Ниндидер таныш сүзләр ишетәм түгелме?

Мингазиз. Ие... Теге син көлеп укыган кызык хатны мин язган идем бит...

Мәдинә. Син? Ничек син?

Мингазиз. Башка авыл почтасына төшереп салдым...

Мәдинә. Ә нишләп алай эшләдең? Әйтергә, аңлатырга телең юкмы әллә?!

Мингазиз. Тел бар анысы... Аллага шөкер! Ә нишлим? Бөтен ил буйлап сиңа хат агыла, понимаешь, көнләштерә, понимаешь, тоттым да яздым инде, нишлим, ну чиләндем мин ул хатны язып...

Мәдинә. Син хәзер тракторист түгел бит!

Мингазиз. Әй! Башыңа төшкәч тракторист та, гармонист та буласың икән аны! *(Кулына гармун алып.)* Их, бар иде яшь чаклар, Мәдинә, бар иде! Җыенга чыгар алдыннан, гармун уйнап, тәрәз каршыңнан узган чаклар! *(Көйләп.)*

Мин утырып хатлар язам,
Синең исеңдә дә юк,
Мәдинәм-гөлкәем,
Синең исеңдә дә юк, бәгырькәем!

Их, тиле яшьлек, юләр яшьлек! Кая киттең син, кая калдың?! Нәрсә таптык без, нәрсә югалттык?! Табуга караганда, югалтулар күбрәк булган, күрәсең! Кеше гомере бер кыска җыр сыман гына ул, балкып ала да сүнә. Ә бит аны сүндермәс өчен бу дөньяда мәхәббәт бар, сөю бар, матур тормыш бар... *(Җырлый.)*

Яратышып таныштык без,
Сөеп кавыштык.
Аралардан җилләр үтте,
Читкә авыштык.
Кай җиһанга, кай тарафка
Качты ярату?
Ялынып, сорап ярату ул —
Күңел юату.
Кушымта:
Сиздермичә ага гомер,
Гүя агымсу.
Син бер ярда, мин бер ярда,
Яшәүмени бу?!
Нишлим инде, нихәл итим,
Син — бердәнберем.
Берьялгызым сөеп назлыйм
Мәхәббәт гөлен.
Яшьлек ямен кайтарыйк, дип
Кабат ялварам.
Бердәнберем, сөю җырын
Башлыйк яңадан.
Кушымта.

Күрәм, син миңа әле ышанмыйсың, төзәлеремә ышанмыйсың...

Мәдинә. Мин өметемне өзәргә җыенмыйм, Мингазиз. Әгәр үзеңне үзең ышандыра алсаң, мине дә матур киләчәккә инандыра алырсың дип ышанам...

Зур агач сәгать сугып куя. Сәгать телләре йөреп китәләр.

Мингазиз. Сәгать... мин ясаган сәгать йөри башлады... Менә хикмәт! Мәдинәм! Сиңа бүләк иткән сәгатем йөри башлады, безнең яшьлек сәгате... Әнә, ишетәсеңме, келт-келт... келт-келт... Юкка гына әйтмиләр икән шул, әйбернең дә җаны бар, дип... Китте, йөри бит, бәгырькәем, йөри...

Хабл *(башын чайкап).* «Старинные часы еще идут...»

Мингазиз. Бу бит гади генә сәгать түгел, Мәдинә, бу — безнең мәхәббәтне берләштергән сәгать. *(Сәгатьне сыйпап.)* Туктама, җаным, йөр, безгә кабат бәхет алып кил... Их, дуслар, сезгә әйтәсе бер сүзем бар, тормыш ваклыкларына вакланып, кеше сүзенә карап кына дөньяда иң якын кешеңне, газиз хатыныңны беркайчан да җәберләмә икән, юк, беркайчан да җәберләмә! Моны сезгә барыгызга да атап әйтәм, атап! Һаман хатыннарны сүккән булабыз, ә бит аларсыз бер көн дә яши алмыйбыз. Бергә чакта кадерен белмибез икән шул бәхетнең...

Хабл *(көйләп).* «Ялгыз калып кара, ялгыз калып, ялгыз калып кара, ялгыз калып...»

Рәбига керә.

Рәбига. Әһә! Җинаятьче әле дә иректә икән! Башы беткере! Әкият сүләп утыра икән әле. Менә, мә, мин сиңа милициядән повестка алып килдем, мә, менә кулыңа ук тоттырам! Ярты көн ирегемнән мәхрүм иткәнең өчен ярты гына ел булса да төрмәдә черетәм әле мин сине! Мә! *(Мингазизгә повестка бирә.)*

Мингазиз. Ни бу?

Рәбига. Ни булсын, повестка!

Хабл. Киндер-сюрприз!

Геннадий *(күз төшереп).* Мондый повестка белән элек безнең егетләрне армиягә чакыралар иде.

Мингазиз. Ие! *(Иснәп.)* Нафталин исе килә димме?! Сандык эчендә бер йөз ел яткандыр бу синең, әнкәй! Бу повестка белән синең ирең сугышка китмәгәнме дип тә уйлыйм әле мин...

Рәбига. Тагын телеңә салынасыңмы? Телеңне дә, кулыңны да тиздән кыскартам әле мин!

Мингазиз. Ә бәлки, кире уйларсың, ә?! Әле менә мин синнән гафу үтенергә дип тора идем.

Рәбига. Ничек итеп?

Мингазиз. «Кичер мине, әнкәй, гафу ит...»

Рәбига. Ә?!

Мингазиз. Чын күңелдән, билләһи!

Рәбига *(йомшап).* Мин кичерермен дә бит! Тик менә хатының, балаларың?!

Мингазиз. Төзәлергә сүз бирәм, әнкәй! Эчмәм, тартмам, «Новости» карамам! Сине башка «түще» дип атамам! Хатыныма «алтыным» гына диярмен, балаларымны яратырмын, хөрмәт итәрмен! Чын! Сез миңа ышанасызмы, әллә...

Мәдинә. Тормыш күрсәтер, Мингазиз! Шулай да сиңа ышанасы килә!

Мингазиз. Карале, хатын, мин тиздән нәчәлник тә булырмын, бәлкем, предколхоз!

Геннадий. Предколхоз? Синең белемең бармыни соң предколхоз булырга?

Мингазиз. Ничек булмасын. Училище бетердем бит — тракторист-моторист.

Геннадий. Колхоз кадәр колхозны җитәкли алыр идеңме?

Мингазиз. Алам — запрысты!

Геннадий *(елмаеп).* Алсаң, әйдә, гариза яз!

Мингазиз. Нинди гариза? Кемгә?

Геннадий. Менә минем исемгә. Әйтик, мин хакимият башлыгы ди. Әгәр син гариза яза алсаң, сине предколхоз итеп алырлар. Язаласыңмы?

Мингазиз. Язам, ник язмаска! Хабл, кәгазь белән ручка китер әле!

Хабл *(китереп).* Яз, Пятачок, от души яз!

Геннадий. Формасын беләсеңме?

Мингазиз. Беләм, ник белмәскә. Формага ипи салып пешергән кеше бит мин пекарняда. *(Яза.)*

Мәдинә. Мингазиз, ташла инде, кеше көлдермә, нинди синнән предколхоз, нинди нәчәлник!

Мингазиз. Кит, комачаулама. Нәчәлник булам мин, предколхоз. Мә! Яздым! Укы!

Геннадий *(укып).* Абау! «Килбәтле вә гыйззәтле, олуг вә кодрәтле, бәрхет камзуллы, сафьян читекле Бакир улы Геннадий хәзрәтләре! Гариза. Мине «Кызыл Байрак» колхозына предколхоз итеп куегыз. От души эшләрмен, чәчем белән җир себерермен... Сезгә иҗат уңышлары теләп, Илгазиз ибне Мингазиз». Вәт бу гариза! *(Көлә.)*

Мингазиз *(Мәдинәне кочаклап).* Их! Хатыным минем, алтыным! Әгәр көчемнән килсә, мин сиңа бөтен дөньяны бүләк итәр идем.

Геннадий. Әйе, менә нәкъ шул уңайдан минем бер тәкъдимем бар. Мәдинә аны белә...
Мингазиз. Нәрсәне белә?
Геннадий. Мин сезне барыгызны да үземә кунакка чакырам. Одессага, диңгездә ял итәргә!
Мингазиз. Мин дәме?
Геннадий. Сине дә, Мәдинәне дә, Рәбига апайны да, балаларны да!
Рәбига. Менә бит, акыллы кешедән акыллы сүз чыга инде!
Мингазиз. Мин бармам, ахры! Анда киеп барырга җүнле кием дә юк ич минем! Анда барып хур буласы килми!
Мәдинә. Ә нишләп булмасын! Мин сине дә онытмадым! Мин сиңа өр-яңа костюм-чалбар алып кайттым! Бар! Сал бу телогрейкаңны! Мә, менә бусын ки! *(Бирә.)*
Мингазиз. Әй, кирәкми иде бу кадәр расхутланырга, кирәкми иде!
Мәдинә. Ки, ки, бер генә тапкыр яшибез! Киеп кал! Тормышның ямен татып кал!

Мингазиз тиз генә киенеп ала.

Мингазиз. Карале, Хабл, бар әле теге чүпрә суын алып мен. Бу обновканы юарга кирәк!
Мәдинә *(усал).* Мингазиз!
Мингазиз *(акылына килеп).* Бетте, бетте, ялгыштым, Мәдинә, ялгыштым...
Рәбига. Алла! Җүнле киенгәч, безнең кияү дә хәч икән!
Мәдинә. Инде хәзер матур итеп бер кырынасың гына калды!
Мингазиз. Мунчага кереп кырынырмын инде!
Мәдинә. Кара аны, салкын мунчага керә күрмә!
Мингазиз. Кермәбез, Алла боерса, кермәбез!
Геннадий. Җыенырга кирәк булыр!
Мингазиз. Белмим, ничек барып җитәрбез инде без ул диңгезгә!
Хабл. Пятачок, мине дә калдырма!
Мингазиз. Синсез бару юк, Хабл дус! *(Геннадийга.)* Син, брат, кыланышларым өчен миңа ачуланма инде, яме!
Геннадий. Ә мин кешегә үпкәли белмим, кешегә үпкәләү — соңгы нәрсә ул.
Мингазиз *(җилкәсеннән кагып).* Менә маладис! Хәер, борын җимереп дуслашкан дуслар киләчәктә чын дуслар була, ди, бит алар.
Геннадий. Анысы шулай! *(Кул бирешәләр.)*
Мингазиз. Их! Кайда әле минем гармун? *(Гармунын ала.)*
Хабл. Тагын... ага сулармы?!
Мингазиз. Нинди ага сулар?! Аккан сулар агып бетте инде алар! *(Мәдинәгә.)* Әйдә, матурым, җырла әле бер безнең өчен, җырла!
Мәдинә *(җырлый).*

Синең куллар назлы җилдер,
Иреннәрең шәрә төн.
Ничек алай килеп чыкты,
Ничек алай булды бу?

Кушымта:

Син мине канатландырдың,
Аннары харап иттең.
Үзеңә гашыйк иттердең,
Яшьлегемне бетердең.

Мин җирдән күккә очам, дип
Хыялланып яшәдем.
Ләкин кояш юкка чыкты,
Яңгырлар да башланды.

Кушымта.

Зәңгәр күктә кош булып мин
Башка җырлар җырламам.
Йолдызлар балкып торса да,
Аларга оча алмам.

Кушымта: *(Мәдинә, Мингазиз бергә.)*

Син мине канатландырдың,
Аннары харап иттең.
Үзеңә гашыйк иттердең,
Яшьлегемне бетердең.

Өмәмә керә.

Өмәмә. Ө-ө! *(Пауза.)* Көтәм, көтәм, көтәм. Көз җитте бит инде, яңгырлар башлана. Түбәне черетәсез бит! Күрәм, күрәм, шатлыгыгыз бик тә зур! Ир белән хатын тагын кушылганнар! Күрәм! *(Хаблны эләктереп ала.)* Яле, кил әле монда! Әлегә миңа син дә ярап торасың! Синнән эш чыкмаса да, бәлкем, төш чыгар!

Хабл *(тартылып).* Мингазиз, коткар!

Өмәмә. И-хи-хи! Мин синнән менә дигән ир ясаячакмын әле! Җә, үп мине бер, үп!

Хабл. Юк, юк!

Өмәмә. Үп, дим!

Хабл *(тартынып, шул ук вакытта мутланып)*. М... м... му-кис-мукис-су-кис... *(Авызын сөртеп куя.)*

Өмәмә. Син нәрсә миннән читләшкән буласың әле, чирләшкә! Салып торып бер җибәрермен яңак төбеңә!

Хабл *(чарасыз).* «Зайка моя... я твой тазик...»

Өмәмә. Ө-ө! *(Хаблны өстерәп алып чыгып китә.)*

Рәбига. И-хи-хи! Ә-кә-мәт! *(Геннадийга.)* Әйдәле, знакум, Одессага киткәнче, бер безнең өйне дә карап кайт! Пушли ко мне! Я кыстыбый сварил... наш татарский... әйдәле!

Геннадий. Ярый, апай. Ярый, барып килик, тик, зинһар, урысча гына сөйләшмә!

Рәбига. Җарар, җарар! Әйдә, пушли, у нас у все ес: и огурцыйлар, и кыярлар...

Геннадий, Рәбига көлә-көлә китәләр.
Музыка.

Мәдинә.

Синең куллар назлы җилдер,
Иреннәрең шәрә төн.
Ничек алай килеп чыкты,
Ничек алай булды бу?

Мингазиз
Мәдинә } *(икесе бергә).*

Син мине канатландырдың,
Аннары харап иттең.
Үзеңә гашыйк иттердең,
Яшьлегемне бетердең.

Сәгать тавышы яңгырый.

Пәрдә.

## НӘФИГА ХАНЫМ

*Ике пәрдәле сатирик комедия*

**КАТНАШАЛАР:**

Нәфига — урта яшьләрдәге ханым, үҗәт, шул ук вакытта кеше сүзенә ышанучан.
Хасият — аның ире, шофер, хатынын кулда тота алмый.
Гүзәл — аларның кызлары, дөньяны «йокы аралаш» күзаллый.
Зөбәрҗәт — Нәфиганың дусты, матур елмаеп, катыга утырта торган зат.
Вальс Валерьянович — «Өмет» оешмасы хезмәткәре, болай начар кеше түгел, ләкин тормыш аны алдашырга мәҗбүр иткән.
Әнисә — авылда кибетләр тота, горур, мәзәкчән, үзен бер дә юкка алдата торганнардан түгел.

Марс — аның малае, дөньяда яшеннән башка бернигә дә исе китми. Сөйләшкәндә «ш» белән «с»ны һәм «ч» белән «з»ны бутый.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ике бүлмәле «хрущевка». Түрдә дәү иске комод. Балыксыз аквариум. Ишек катында попугай читлеге эленеп тора. Бер якта — иске «Свияга» суыткычы (терәтеп куелган), икенче якта (уртада) — борынгы совет телевизоры. Аның өстенә зур итеп «Инвентарь №...» дип язылган. Бер якта — хан заманындагы шыксыз кара телефон. Нәфига (аягына киез итек кигән) таушалган кәнәфидә оекбаш бәйләп утыра. Ара-тирә дивардагы сәгатькә карап ала. Ул ирен көтә. Оеп, йокыга талып ала.

Попугай *(кеше тавышы белән).* А Чика гер-рой! А Чика гер-рой! А Вика дур-ра! Дур-ра!

Нәфига *(уянып).* Әстәгы... Гарык шушы попугайдан! *(Тора.)*

Попугай. А Вика дур-ра! Дур-ра!

Нәфига. Ходаем! Да заткнись ты, а! Дур-рак!

Попугай *(үртәгән кук).* Дур-рак! Дур-рак! Дур-ра...

Нәфига. Мә! Олак! *(Читлекне калын тастымал белән каплап куя. Попугай тына. Читлек эченнән еламсыраган тавыш килә. Бүлмәдә илаһи тынлык урнаша. Шул чакны, дөбер-дөбер килеп, совет суыткычы эшләп китә. Ул трамвай яисә поезд үтеп киткәндә чыккан тавышлар чыгарып ала да тына.)* Әй Аллам! *(Йөрәген тота.)*

Ишектә кыңгырау тавышы. Нәфига ишекне ача. Хасият керә.
Шактый кызмача.

Хасият *(шат).* Нәфига!

Нәфига *(куштанланып).* Әү, әү!

Хасият. Шатлан!

Нәфига. Әй, әй, нәрсә?!

Хасият. Шоферлар бәйгесендә беренче урынны алдым. Иң яхшы автобус — минеке! Иң яхшы йөртүче — мин! Ас! Ас! Ас! Асса! *(Биеп ала.)*

Нәфига. Күрдем инде, күрдем!

Хасият. Каян күрдең?

Нәфига. Телевизордан. «Хәбәрләр»дән...

Хасият. Күршеләргә кереп карадыңмы?

Нәфига. Нишләп күршеләргә керим ди, үзебезнеке булганда!

Хасият *(чыраен сытып)*. Телевизормыни инде ул безнең телевизор! Тфү, адәм көлкесе! Көйсез... Синең кук көйсез... Җае килсә генә күрсәтә... Нәзберек кыз кеби... Хи-хи... Борчылма... Яңасын алырбыз... *(Киемнәрен сала.)* Япон телевизорын! «Саньо»!

Нәфига. Сания? Нинди Сания?

Хасият. Сания димим, «Саньо» дим! 80 диаметрлысын! *(Беләген сузып.)* Менә мондыен! Кадрда кадр! Бөтен өйне тутырып торачак. Дөньяны аклы-каралы итеп кенә түгел, төсле итеп карарга да вакыт җитте!

Нәфига. Кыйбаттыр инде ул, төсле булгач?

Хасият. Кыйбат, карчык, кыйбат... *(Нәфига иңен җыера.)* Борчылма... Уч тутырып премия бирделәр...

Нәфига. Күпме?

Хасият *(елмаеп)*. Күп!

Нәфига. Соң... күпме соң инде?

Хасият *(кесә турын капшап)*. Утыз мең.

Нәфига *(сулышы кысылып)*. Кит аннан!

Хасият. Министр бирде. Министр бирсә, аз бирми инде ул. Аркадан сөеп, мактап әйтеп бирде.

Нәфига. Ай-яй! *(Хасияткә карап тора.)* Ә минем турында берни дә әйтмәдеме?

Хасият. Әйтте.

Нәфига *(каушап).* Кит... Ни диде?

Пауза.

Хасият. Хатыныңны алыштыр, диде.

Нәфига *(үпкәләп)*. Әй, синең гел шул булыр инде!

Хасият (*исенә төшереп*). Туктале! Сәгать ничә? *(Карый.)* Әһә! Бу вакытта «Хәбәрләр»не кабатлап күрсәтәләр. Яле! *(Телевизорны кабыза. Тавышы бар. Сурәте юк.)* Җә, җә! *(Телевизорга суга. Телевизор күрсәтә башлый.)* Чебаксар күрсәтә, Казан юк... Нинди телевизор соң син! *(Тагын суга.)* Хатын, хатын, кара, мине күрсәтәләр, мине...

Нәфига. Кая, кая? *(Йөгереп килә.)*

Хасият. Әнә, әнә! Министр премия бирә... Бар да кул чаба... *(Сурәт югала. Тавыш кына кала.)*

Диктор тавышы. Ә хәзер һава торышын тыңлагыз!

Хасият. Шайтан! *(Суга — телевизор сүнә.)* Аллага шөкер! Котылам икән синнән!

Нәфига *(аңламыйча)*. Кемнән? Миннәнме?! *(Хасият аңа карап тора.)* Баедыңмыни... Шулай шул... Татар, баегач, хатын алыштыра башлый... *(Елый.)*

Хасият. Синнән түгел инде! Син нәрсә?! Телевизордан!

Нәфига. Ә соң, шулай диген! Нәрсә кызасың?! Берәр нәрсә булса, йә мине сугәсең, йә телевизорга суга башлыйсың...

Хасият. Мә! Акчаны тыгып куй! *(Акча бирә.)* Бер йөзлеген эчтем инде, ачуланма, юдык премияне!

Нәфига *(алып).* Урлатсаң шунда?!

Хасият. Кем урласын — үзебезнең парк егетләре бит!

Нәфига. Ышан аларга! *(Уйланып.)* Карале, Хасият!

Хасият. Нәрсә? Бар инде, акчаны яшереп куй! Ышанычлы урынга!

Нәфига. Мин бит синең зур акча алачагыңны моннан бер-ике атна элек үк белдем.

Хасият. Кемнән?

Нәфига. Начты әйтте.

Хасият. Нинди Начты?

Нәфига. Соң... Теге Начты инде... Настя... Күрәзәче...

Хасият. Ничек күргән?

Нәфига. Бер зур агач янында басып торасың икән. Агачның яфраклары яшел. Коела да коела икән шул яшел яфраклар...

Хасият. Юкны сөйләмә! Яшел яфраклар коелмый, сары яфраклар гына коела.

Нәфига. Ә монықы коелган... Яшел яфрак — яшел долларлар икән инде ул... Начты шулай дип юрады... Бу акчаны долларга әйләндерсәң, күпме булыр икән?

Хасият. Әйләндерермен мин сиңа, тот капчыгың!

Нәфига. Артмас микән, дим инде...

Хасият. Артыр, бар... Арттырам дип, бер әйләндереп караган идең инде син... Арттымы соң? Кәстрүл алырга да җитмәде акчаң... Инфляция... Куй, бар! Иртәгә телевизор чыгып алырбыз...

Нәфига. Ярар, ярар! *(Кечкенә савытка сала. Акчалар сыймый. Өч литрлы банка эченә тыгып куя.)*

Хасият. Кая салдың инде?

Нәфига. Ә кая салыйм соң? Элеккесенә сыймый.

Хасият. Күренеп тора бит акчаң. Кыз күреп алмасын.

Нәфига. Күрмәс. Аның әле үз-үзен дә күргәне юк. Йоклый да йоклый...

Ишектә кыңгырау тавышы.

Кем икән?

Хасият. Кем булса да, яшер акчаңны! Банкыңны!

Нәфига (*банканы читлектәге тастымал белән каплап*). Телевизор алганчы, суыткыч кына алыйк мәллә? Тавышына түзәр хәл юк бит моның... *(Тыңлаланалар. Суыткыч калтыранып ала да тына.)*

Хасият. Бәлкем, акча икесенә дә җитәр әле... Карарбыз... Бу йорттагы бөтен хламны алыштыра башласаң, ашамыйча-эчмичә, ачка гына үләргә кирәк...

Кыңгырау тавышы кабатлана.

Нәфига. Хәзер, хәзер, ачам! Әй Аллам, кем йөри инде анда, кирәкмәгән вакытта?!

**ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Зөбәрҗәт керә. Ул, бай хатыннарыдай, затлы киенгән. Балкып тора.
Нәфига аның янында чебеш кебек күренә.

Нәфига *(шаккатып)*. Ай, ахири! Синме соң бу?

Зөбәрҗәт. Мин, мин!

Нәфига. Сине танырлык та түгел, әй! Ничек шулай тиктомалдан гына үзгәреп китә алдың... Баеп димме... Эшләмисең дә бугай...

Зөбәрҗәт. Юк. Җүләрләр эшләсен, дур-раклар!

Нәфига. Ай! *(Коты очып читлеккә карап куя. Попугай тын гына тора.)* Ә мин әле менә һаман да эшләп йөрим.

Зөбәрҗәт. Һаман да шул валяльно...

Нәфига. Ә?

Зөбәрҗәт. Войлочныйдамы?

Нәфига. Шунда, шунда. Һаман да шул итек басабыз...

Зөбәрҗәт *(онытылып)*. Нәрсәне басасыз?

Нәфига. Итек басабыз, дим, итек! *(Итеккә күрсәтә.)*

Зөбәрҗәт. Ә! Мин тагын...

Нәфига. Сөйлә... Фабрикадан киткәнеңә әллә кайчан. Кая югалдың? Ни белән шөгыльләнәсең?

Зөбәрҗәт. Сораулар соңыннан! Җә, бер үзеңне пәп итим әле! Сагындым үзеңне! У-ух! *(Кочаклап үбә.)*

Нәфига. Матурлангансың, чибәрләнгәнсең!

Зөбәрҗәт *(Хасиятне күреп)*. Исәнме, Хасият! Хәлләрең ничек? *(Күрешә.)*

Хасият. Ярыйсы...

Нәфига. Әйдә утыр, сөйлә, ничек итеп безгә килеп чыгарга булдың? Ничекләр яшисең?

Зөбәрҗәт *(көйләп)*. «Әйт әле, күбәләк, яшисең син ничек... табасыңмы азык...» *(Утыра.)* Бизнеста мин хәзер.

Нәфига. Ә?!

Зөбәрҗәт. Әле дә ярый шул фабрикадан кудылар. Шуңарга сөенеп, шатланып туя алмыйм. Бер эштә генә чукынып яту дөрес нәрсә түгел икән лә ул!

Нәфига. Кем инде син хәзер?

Зөбәрҗәт. Төзүче.

Нәфига. Ә?! Әле генә үзеңне эшмәкәр дидең түгелме соң?

Зөбәрҗәт. Пирамида төзибез.

Нәфига. Нинди пирамида?

Зөбәрҗәт. Пирамида! Мисыр пирамидасы түгел, билгеле. Шундый фирма инде ул. «Өмет» дип атала. Акча күктән ява торган урын ул, бердәнбер шундый урын...

Нәфига. Явамы?

Зөбәрҗәт. Ява. Яудыра белсәң.

Нәфига. Яхшы явамы?

Зөбәрҗәт. Ишеп ява.

Нәфига. Менә бит! Күктән акча яумый, дигән булалар тагын! Ява икән бит!

Хасият *(кулына газета алып)*. Ява... болыты куерса...

Зөбәрҗәт. Дөрес. Мин кайда гына хезмәт итмәдем. Яшәргә кирәк бит. Теге дә...

Нәфига. Кем инде ул?

Зөбәрҗәт. Теге инде... *(Нәфиганың колагына пышылдый. Көлешәләр.)* Ташлаган иде, хәзер ул да кире кайтты. Ә ник кайтмасын?! Байлыгым бар! Чалбар сатып баемакчы идем, барып чыкмады... Ә менә монда... яңасында... анда инде, ичмасам!

Нәфига. Ничек соң ул?

Зөбәрҗәт. Менә болай, башта күпмедер акча кертәсең...

Нәфига. Җә, җә...

Зөбәрҗәт. Аннан...

Хасият *(газетаны атып)*. Аңлашылды. Афера.

Нәфига. Туктале! Тыңлап бетер! *( Зөбәрҗәткә.)* Җә, җә...

Зөбәрҗәт. Акча кертәсең...

Нәфига. Күпме?

Зөбәрҗәт. Күпме?! Бер утыз меңнәр тирәсе инде... Күпме кертә аласың...

Хасият сискәнеп китә, чыраен сыта.

Нәфига. Җә, җә...

Зөбәрҗәт. Менә шул керткән утыз меңең бер өч айда өч йөз меңгә әйләнә дә куя.

Нәфига *(шаклар катып)*. А!

Зөбәрҗәт. Менә шулай баедым да инде мин!

Нәфига. Баер өчен нишләргә кирәк инде?

Зөбәрҗәт. Әйттем бит, инде, утыз мең сум кертергә дә...

Хасият *(коры)*. Анысын ишеттек.

Нәфига. Шулай ансат кынамы?

Зөбәрҗәт. Ну бер келтифүне бар инде аның... Үзең өч кеше табасың.

Хасият. Нинди өч кеше?

Зөбәрҗәт. Кеше кебек кеше инде.

Хасият. Нигә?

Зөбәрҗәт. Алар син тапкан кешеләр булып исәпләнәләр. Менә шулар синең исемең астында акчаларын гомуми кассага кертәләр. Бу синең өчен актив була инде.

Хасият. Ә кертмәсәң?

Зөбәрҗәт. Кертмәсәң, пассив була. Алар кертеп бетергәч, син рәхәтләнеп дивидендлар ала башлыйсың. Шулай итеп, син керткән акча өчләтә, аннан йөзләтә арта.

Нәфига. Ансат кына икән.

Зөбәрҗәт. Ансат, бик тә ансат.

Хасият. Ансат, имеш. Ә син тап әле шул өч кешене башта!

Зөбәрҗәт. Теләүчеләр мо... ре... Сорап, интектереп бетерәләр...

Хасият. Ә син үзең таптыңмы соң?

Зөбәрҗәт *(кабынып)*. Хе! Тапмасам, сезнең янда утырган булыр идеммени! Өчне генә түгел, алтыны таптым... Минем хәзер дүрт бүлмәле фатирым бар, елга ярында дачам...

Нәфига. Берүзеңә?

Зөбәрҗәт. Юк, үземә генә түгел, тегенең белән бергә... *(Көлә.)*

Нәфига *(кызыгып)*. Җә, җә...

Зөбәрҗәт. Шуңар күрә сезгә дә киңәш итәм...

Нәфига
Хасият } *(икесе бергә)*. Нәрсә?!

Зөбәрҗәт. Пирамидада катнашырга.

Хасият. Бу ниндидер уенга охшаган... Оттырсак? Буш калсак?

Зөбәрҗәт. Оттыру мөмкин түгел. Анда оттыру юк, анда фәкать оталар гына

Хасият. Белмим. Мин әле откан кешене ишеткәнем юк.

Зөбәрҗәт *(үзгәреп)*. Менә мин оттым. *(Пауза.)* Хәер... шунысы да бар... Кешенең үзеннән дә тора... Кайсы айда, кайсы елда туган булуың да бик мөһим. Бу тормыштагы гамәлләрнең күпчелеге гороскоп, ягъни йолдызнамә аша хәл ителә. *(Нәфигага.)* Менә син йолдызнамә буенча кем әле?

Нәфига. Балык.

Зөбәрҗәт. Әллә ни түгел инде!

Нәфига. Ничек әллә ни түгел?

Зөбәрҗәт. Ну Балык Балык инде ул. Тотрыксыз элемент. Бер аска, бер өскә калка. Бер уңга, бер сулга йөзә. Үз башы юк аның. Арыслан түгел бит инде ул...

Хасият. Менә мин Арыслан!

Зөбәрҗәт. О! Арыслан! Менә бу билге, ичмасам! (*Пауза*.) Ну бик нәзберек инде! Карьерист!

Хасият. Нинди карьерист инде мин! Авылдан килгәннән бирле һаман шул баранка артында... Автобуста.

Зөбәрҗәт. Алдан нинди автобуста идең?

Хасият. «Пазик»та.

Зөбәрҗәт. Ә хәзер?

Хасият. Хәзер «Мерседес-бенц»ка утырттылар.

Зөбәрҗәт. Менә бит карьера ясагансың! «Мерседес»та гына йөрисең!

Хасият. Үземнеке түгел шул ул, дәүләтнеке.

Пауза.

Зөбәрҗәт. Мин бернәрсәгә бик нык аптырыйм: ничек бергә яшисез сез, ә?!

Хасият

Нәфига } *(икесе бергә).* Ничек, ничек?

Зөбәрҗәт. Балык белән Арыслан бөтенләй капма-каршы билгеләр!

Хасият. Карале, син безне аерырга дип килмәгәнсеңдер ич, ә?!

Зөбәрҗәт. Юк, мин сезгә якты тормыш алып килергә дип килдем.

Хасият. Якты тормышны без аны үзебез дә төзибез, мадам, сездән башка да!

Зөбәрҗәт *(өй эченә күз салып)*. Күренә, яхшы күренә якты тормышыгыз! Хәзерге заманда мондый хәерчелектә яшәү — хурлык!

Хасият. Әйе, без бай яшәмибез, зато безнең күңелебез саф! Без тыныч йоклыйбыз! Тыныч йоклый алмаучылар да шактый!

Нәфига *(ирен куәтләп)*. Ие, ие, бик күп андыйлар да!

Зөбәрҗәт *(үзгәреп)*. Менә шуңар күрә дә яратам да инде мин сезне, саф күңелле, ышанычлы кешеләр булганга күрә. Ләкин тормыш бер генә килә. Яхшы яшәүнең юлларын эзләргә кирәк барыбер. Тик ятып кына булмый. Тик ятып кына беркем дә бернәрсә дә китереп бирми. Әгәр сез мине тыңласагыз, безнең оешмага әгъза булып керсәгез, сез дә минем кук байый алырсыз. Бу таракан оясын детдомга бүләк итәрсез, ә үзегезгә ташпулат салдырырсыз!

Нәфига *(кызыгып)*. Җә, җә!

Хасият. Юк, без анда керә алмыйбыз, чөнки без хәерче! Безнең бер тиен дә акчабыз юк. Ипилеккәтозлыкка гына!

Зөбәрҗәт. Ай-яй, алдамагыз! Эшем чиктән тыш артык булса да, ара-тирә телевизор караштыргалыйм, бигрәк тә «Хәбәрләр»не...

Хасият. Аңладым. Министр биргән премия акчасын әйтәсең инде...

Зөбәрҗәт. Министр учлап тоттырды түгелме соң үзеңә!

Хасият. Гомергә бер кергән зур акчаны җилгә очырасым килми әле! Мин аңа өр-яңа телевизор һәм өр-яңа суыткыч алам!

Нәфига. Ие, ие...

Зөбәрҗәт. Алдың да ди. Шуннан... акчаң бетә дә китә. Алган әйберләрең тагын искерә... берничә елдан... Тагын банкрот, тагын хәерчелек... Син салган утыз мең ике-өч айдан өч йөз меңгә әйләнә дә куя. Тагын кушыласың, тагын өч йөз мең... Акчаң арта да арта, арта да арта... Кая куярга белмәссең әле бервакыт! Ел саен Канарга йөрерсең!

Нәфига. Канар? Нинди авыл ул?

Зөбәрҗәт. Авыл түгел, утрау, ял итә торган урын!

Нәфига *(белмәгәнлегеннән оялып).* Җә, җә?!

Зөбәрҗәт. Җә, җә түгел, кәҗә! *(Тора.)* Уйлагыз! Сезгә киләчәктә менә дигән перспектива ачыла. Әгәр дә шуны ычкындырсагыз, гомер буе үкенәчәксез! Безнең оешма әгъзасы булырга теләсәгез, миңа шалтыратыгыз! Минсез бармагыз — минем белән бару шарт. (*Визит карточкасын бирә.)* Мәгез!

Нәфига. Ни бу?

Зөбәрҗәт. Сез нинди чорда яшисез соң, ә?! Таш чорында түгелдер ич! Тәмам тормыштан артта калгансыз бит! Сез һаман да ат арбасында барасыз, ә чын тормыш инде күптән «Боинг»та оча, җаннарым! Бу визит карточкасы дип атала. Монда минем адресым, телефоным. Аңладыңмы?

Нәфига. Җә, җә?!

Зөбәрҗәт. Киттем! (*Хасиятнең чәченнән сыйпап.)* Баер өчен сезгә соңгы шанс бирелә. Шунысын онытмагыз! *(Залга карап.)* Сезгә генә атап әйтәм, иманым камил, шушылар иртәгүк безгә йөгереп киләчәкләр! Уф! Ике кеше таптым, өченчесен тагын каян табарга инде?! *(Күлмәген тартып.)* Әнисәнең күлмәге әзрәк таррак булды, кайткач әйтәм, башкасын тапсын! *(Чыгып китә.*)

**ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Нәфига. Минемчә, Зөбәрҗәт дөрес сүли, Зөбәрҗәт хаклы.

Хасият. Нәрсәсе белән хаклы соң инде ул?

Нәфига. Безгә акчаны салырга кирәк.

Хасият. Кая?

Нәфига. Шунда.

Хасият. Кая шунда?

Нәфига. Шунда инде... Сала торган төшкә.

Хасият киерелеп ала. Күлмәген сала.

Хасият *(битараф)*. Ярар. Йокларга вакыт. Иртәгә эшкә.
Нәфига. Җә...
Хасият. Нәрсә җә?
Нәфига. Әйт инде соңгы сүзеңне!
Хасият. Син нәрсә, судья мәллә миңа соңгы сүз бирергә?! *(Пауза.)* Оныттыңмыни?
Нәфига. Нәрсәне?
Хасият. Ниндидер бер торгашка уч тутырып акча биреп чыгарганыңны?! Шуннан бирле ни акча, ни дубленка!
Нәфига. Нишлим инде, аферист булып чыкты бит!
Хасият. Ә монда аферистлар утырмый дип уйлыйсыңмы?!
Нәфига. Кайда?
Хасият. Шул акча сала торган төштә.
Нәфига. Ничек инде... Ул бит оешма... Тикшерү астында тора. Аннан... Зөбәрҗәт тә үзебезнең кеше бит... Алдамас инде безне... Дусларын...
Хасият. Чын дуслар юк ул дөньяда. Ышанма беркемгә дә. Синең дус хатыныңа да ышанып бетмим.
Нәфига. Нишләп?
Хасият. Күзләре туры карамый. Нидер яшерә бездән, әйтеп бетерми... Ә син бик тә ышанучан. Җүнсез син! Бөтен аферист синең тирәңдә чуала!
Нәфига *(үпкәләп)*. Ә синең янда җүләрләр, дур-раклар! *(Читлеккә карап куя.)* Үзеңне дә бел инде, яме! Әле кайчан гына ике айлык хезмәт хакыңны казинога салып кайттың. Ике ай каты-котыда яшәдек.
Хасият *(кызып)*. Шуннан бирле казинога барган да юк бит инде! Һаман да шуны сүлисең, һаман да шуны кичерә алмыйсың! Бер җүләр котыртканга! Җиттеме сиңа, юкмы?! Тәмам канымны эчтең бит инде! Башсыз!
Нәфига *(чәрелдәп)*. Ә син!
Хасият *(кычкырып)*. Ә син!!!

**ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Гүзәл чыга. Эчке күлмәктән. Күзләре йомык. Йокы халәтендә.
Өйдәгеләр, аны күргәч, тынып калалар.

Гүзәл. Ани...

Пауза.

Ани!
Нәфига. Әү, кызым, әү?!
Гүзәл (*акцент белән).* Бездя катик бармы?
Хасият *(җене котырып).* Катик түгел, ка-тык!
Гүзәл. Катик, димим бит...
Хасият. Катик түгел, катык, дип әйт! Кайчан син дөрес итеп татарча сөйләшергә өйрәнерсең икән, ә?! Суверен Татарстан җирендә!
Нәфига. Атасы, ярар инде!
Хасият *(ярсып).* Нәрсә ярар, нәрсә ярар?! *(Гүзәл өстәл каршына килеп баса. Һаман да күзен ачалмый.)* Ни кирәк сиңа?!
Гүзәл. Ка-тик!

Пауза.

Нәфига. Суыткычта, кызым, суыткычта ка... тик...

Хасият аңа сәер генә карап куя.

Катык...
Гүзәл. Ә нәрсә ул?
Нәфига. Нәрсә, кызым?
Гүзәл. Суиткич?! *(Хасият дәшми.)*
Нәфига. Холодильник ул, кызым, холодильник. Катык та шунда.

Гүзәл суыткыч янына килеп баса. Ача. Суыткыч янтая. Дөбердәп ала.
Гүзәл дер калтырый.

Хасият. Ачмале шуны, ә! Нәрсә дип ачасың аны?!

Гүзәл. Катик кирәк.

Хасият. Ачмыйча гына ал!

Гүзәл. Как?

Нәфига. Кызым, чәй генә эч. Катык юк бугай анда. Эч чәй генә!

Гүзәл *(авырлык белән ябып).* А чайны ни белән эчим? Сыт бармы сон бездә?

Хасият. Нинди сыт? *(Сикереп тора.)*

Нәфига. Тынычлан әле! Сыт, дими, сөт, ди!

Хасият. Үтерәсез сез мине, билләһи! Эчне пошырасыз! *(Бер кызына, бер хатынына усал карап йөренә.)* Хет бүген генә бер кешечә яшәп калырмын дип хыялланып кайткан идем! Булмады!

Гүзәл. Бармы сыт?

Нәфига. Бар! Холодильникта!

Гүзәл *(суыткычка карап-карап тора да).* Да ну вас, нафиг! *(Чайкала-чайкала, бүлмәсенә кереп китә.)*

**БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Хасият *(артыннан үчекләп).* Ай-яй, ай-яй! Принцесса Диана диярсең...

Нәфига. Көлмә инде шул кызыңнан! Бердәнбер яраткан кызың бит!

Хасият. Ә мин нишләргә тиеш? Нинди кыз таптың миңа? Йоклый да йоклый, йоклый да... Тәмам йокыга талган гүзәлгә әйләнеп бетте бит бу! Син боздың аны, син! *(Пауза.)* Түтелдәп!

Нәфига. Имтиханнар бирә бит. Аспирантурада укый.

Хасият. Ниемә кирәк соң аңа анда уку?! Диплом алды — эшләсен! Нәрсә, гомер буе шулай укырга, гомер буе атасы җилкәсендә утырырга уйлый микәнни ул?! Менә мин эшлим, син дә эшлисең! Аның кебек чагында инде мин... Унөч яшемдә сука... әй, сука артына бастым!

Нәфига. Үзең белән чагыштырма баланы. Болар бит башка буын, гыйлемле.

Хасият. Үзе өчен куркам. Йокы капчыгына әйләнеп бара бит инде. Тиздән аны йокы чиреннән дәваларга кирәк булачак. Нәрсә һаман өйдә ята?! Хет әзрәк урамга чыгып керсен иде инде, җилләнеп керсен!

Нәфига. Баланы хәзер урамга чыгарырга да куркыныч. Кругом наркомания, кругом СПИД... Өйдә ятуы әйбәт тә әле аның. Борчылма...

Хасият. Борчылам мин, бик борчылам!

Нәфига. Аспирантурасын бетергәч, кияүгә бирербез.

Хасият. Белмим, нинди егет өйләнер икән аңа! Нинди җүләре! Аңа өйләнгәне дә йокы чүлмәгенә әйләнмәсә ярый инде! Бер катик урынына икенче катик пәйда булмаса ярый инде!

Нәфига. Көлмә. Егете бар инде аның. Менә дигән! Төшеңә дә кермәслек!

Хасият. Кем ул?

Нәфига. Али исемле!

Хасият. Нинди Али? Каян ул? Кайсы районнан?

Нәфига. Аклахомадан!

Хасият. Нинди район соң ул?

Нәфига. Район түгел ул, җаным, штат.

Хасият. Ә?!

Нәфига. Америка Кушма Штатларында ул, җаным!

Хасият *(шаккатып).* Ычкынасың мәллә инде?!

Нәфига. Дөресен сүлим, дөресен!

Хасият. Башка сыймаслык хәл бит! Йокыдан күзен дә ачалмаган кызның каядыр Америкада, ниндидер Аклахомада кияве бардыр дип кем уйлаган?!

Нәфига. Ә син көлгән буласың!

Хасият *(уйланып).* Туктале... Ә ул ничек анда барып җитә алган соң?

Нәфига. Кая?

Хасият. Ну шул Аклахомага!

Нәфига. Ничек инде?
Хасият. Соң... аптырыйм инде үзем дә! Кайчан карама йоклый да йоклый! Ничек танышканнар, дим?
Нәфига. Танышыр өчен Америкага кадәр барырга кирәкми.
Хасият. Монда танышканнар мәллә?
Нәфига. Монда ул башка егет белән танышкан булган. Укыганда. Америкадан килгән. Татар егете. Дуслар булганнар. Аннан ул Америкага, Аклахомасына кайтып киткән. Гүзәл аңа фотосын бүләк иткән булган. Ул аны үзенең иптәш егетенә күрсәткән. Алига. Алар туганнар да икән. Али бер күрүдә үк кызыбызга гашыйк булган.
Хасият *(аңламыйча).* Каян, ничек күргән соң ул аны?
Нәфига. Соң, сүләп торам лабаса инде! Фотосын күреп гашыйк булган! Фотосын!
Хасият. Ә! Менә ничек! Хәзер шулай фотога карап кына гашыйк булалар микәнни?!
Нәфига. Алиның карары нык. Ул өйләнергә теләк белдергән.
Хасият. Ничек? Ул бит әле аны күрмәгән дә!
Нәфига. Нишләп аңламыйсың син? Соң... көн-төн безгә телефоннан шалтыратып ята бит инде.
Хасият. Каян?
Нәфига. Аклахомадан.
Хасият. Телефонлы мәхәббәт, значит! Аңлашылды. Әй бичара Али! Белсәң иде дә, күрсәң иде син булачак кәләшеңне!
Нәфига. Али Гүзәлне Америкага чакыра.
Хасият. Гүзәл барам диме соң?
Нәфига. Барам, ди.
Хасият. Син шушыңа ышанасыңмы?
Нәфига. Ышанам. Начты әйтте...
Хасият. Нинди Начты?
Нәфига. Күрәзәче... Кызыңны Америкада күрәм, бер-ике айдан Америкага китәр. Паспортына пичәт суктырып кайтыр... Ягъни кияүгә чыгар, ди...
Хасият. Кемгә?
Нәфига. Алига.
Хасият. Сине дә күрмәгәнме соң?
Нәфига. Кем?
Хасият. Начты!
Нәфига. Күргән. Пляжлы варианттан. Гавай тирәсендә күргән ул мине. Яр буенда кызынып ятам икән... Начтыдан сорадым: аңлат әле, минәйтәм... Өч елдан син дә Аклахомага очарсың, ди. Кызың бала табар, бала карарга китәрсең, ди... Матур тормышта яшиселәр бар икән әле!
Хасият. Мине дә күргәнме?
Нәфига. Юк. Сине күрмәгән.
Хасият. Ә ничек күрә соң ул?
Нәфига. Алдына берничә фундук чикләвеге тезеп куя. Шуларны болгаткалап ала да чем итеп күзләрен йома...
Хасият. Ничек итеп?
Нәфига. Менә болай итеп! *(Күзләрен йомып күрсәтә.)*
Хасият. Шулай итеп күрәме?
Нәфига. Күрә. Шундук нәрсә буласын әйтеп тә бирә.
Хасият. Син шуңа ышанасыңмы?
Нәфига. Ник ышанмыйм, аның бөтен әйткәннәре туры килеп кенә тора. Бер генә дә ялгышмый.
Хасият. Берәр әйткән сүзенең сиңа туры килгәне булдымы соң?
Нәфига. Булды.
Хасият. Нәрсә?
Нәфига. Әй, хәтерләмим дә инде.
Хасият. Акча аламы?
Нәфига. Кем?
Хасият. Күрәзәче Начтыңны әйтәм!
Нәфига. Ала.
Хасият. Аферистка!

Телефон шалтырый. Нәфига телефонга йөгерә.

Теләсә нәрсә әйт, Нәфига, ну мин Гүзәлнең Америкада кияве барлыгына һич кенә ышана алмыйм!

Нәфига *(трубканы алып).* Алү... Ә?! Америка... Аклахома? Әйе, әйе, Нәфига апаң булам... Али, синме? Ә... Әйе... Хелло, хелло! Исәнме, җаным, исәнме!

Хасият *(тагын бер кат шаккатып).* Улмы?

Нәфига. Бик ашыгычмы?! Хәзер, хәзер чакырам! *(Трубканы читкә куеп.)* Америка! Ху! *(Тыны кысыла.)*

Хасият. Кайсы шәһәрдән шалтырата?

Нәфига. Фифти-фифтидән!

Хасият. Каян, каян?

Нәфига *(кул селтәп).* Әй, башымны катырмасана! Бик ашыгыч, ди... Кызым, кызым! *(Гүзәл бүлмәсенең ишеген ачып кычкыра.)* Кызым, телефонга! Америка! Али!

Гүзәл бүлмәдән атылып чыга. Башы-күзе акайган.

Хасият *(исе китеп).* Хикмәт! Минем кызны да уятыр адәмнәр бар икән бу дөньяда!

Гүзәл *(трубканы алып).* Алло! О! Хелло! Али! Салют, Америка! Да, да, сөйлә, тыңлыйм! *(Тыңлый.)* Аһа! Аһа! Да, да... Гуд бай! Гуд бай! *(Трубканы куя. Көйләп.)* «Гуд бай, Америка, гуд бай!»

Нәфига. Ни диде, кызым?

Гүзәл. Ани... ул мине Америкага чакера! *(Хасияткә карап тора. Хасият бер сүз дә дәшми.)*

Нәфига. Шулаймы?! Бик әйбәт, бик әйбәт, бик...

Хасият *(кырыс).* Алай ярамый. Әгәр дә ул чын джентльмен икән, ул сине үзе кайтып алырга тиеш.

Гүзәл. Ул биш айдан соң гына кайта.

Нәфига. Кайтам дидеме? Кайтсын, кайтсын. Кайтса, әле кышка гына кайтып җитә ала икән.

Гүзәл. Ани... мин Америкага хочу! Али янына...

Нәфига. Юк, кызым, мин сине җибәрә алмыйм андый ерак юлга. Әле имтиханнарыңны да тапшырасың бар. Иң элек аны сынап карарга кирәк?

Гүзәл. Нәрсәгә?

Нәфига. Сиңа булган мәхәббәтен сынап карарга кирәк. Әгәр ул сине ярата икән, көтәр, кайтыр!

Гүзәл *(аяк тибеп).* Ани! Мин иртәгә үк китәм!

Хасият. Кая йокласаң да бер түгелмени: әллә Америка, әллә Рәсәй?!

Гүзәл. Китмәсәм — гуд бай, Америка! Ул анда икенче кешене табачак!

Нәфига. Кызым, син миңа ышан. Ул кайтачак. Ул сине ярата. Яратмаса, көн-төн шалтыратып ятмас иде.

Гүзәл. Да ну вас, нафиг! *(Йокы халәтенә күчә.)* Бай-бай! *(Бүлмәсенә кереп китә.)*

Хасият *(киная белән).* Бай-бай... Шулай шул, бу илдә эшләгәнче, йоклавың әйбәтрәк.

Нәфига. Әйбәт егет ул Али — сүзендә торачак.

Хасият. Каян беләсең?

Нәфига. Начты әйтте.

Хасият *(сүгенеп).* Тфү!

Нәфига *(күз төшереп).* Кайтып төшәр. Безнең хәерчелекне күреп шаклар катар инде!

Хасият. Телевизор алабыз бит инде, суыткыч...

Нәфига. Шаккатырдың ди аны телевизорың белән! Андый телевизор аларда бүлмә саен! Ташпулатта каршы алсаң иде икән аны, ташпулатта!

Хасият. Ә каян аласың аны?

Нәфига. Сатып!

Хасият. Ә каян бездә ул кадәр акча?

Нәфига. Тегендә салабыз да, акчабыз арта...

Хасият. Син ул уеңнан әле һаман да кайтмадыңмыни?! *(Кычкырып.)* Сиңа күпме аңлатырга була?! Афера ул, афера!

Нәфига. Кычкырма! Минем дә кеше күк яшисе килә. Синең белән яшәгәннән бирле нинди рәхәт күргән бар соң минем?! Нәрсә күргәнем бар? Бер мәртәбә урманга алып чыккан идең ял итәргә дип, анда да шашлыгың янган иде. Ә минем дөнья күрәсем килә! Диңгез ярында аягымны салындырып утырасым килә! Дөньяга бер генә киләбез, бер генә! *(Елап ала.)* Әле бүген төштә дә диңгездә йөзеп йөрдем...

Хасият. Төштә генә йөзүең яхшы булган.

Нәфига. Нишләп?

Хасият. Расхуды әзрәк.

Нәфига. Әй, синең гомер шул булыр инде, гомерең буе миннән көлдең. Гомер буе миннән издеваться иттең... *(Елый.)* Гомерең буе минем өстән йөрдең...

Хасият. Кайчан?

Нәфига. Сөйлимме кемнәр белән типтергәнеңне? Хәзер генә син тәүфыйклы мәчегә әйләндең... Комың коела башлагач...

Хасият. Җитте! Тимә миңа! Нервымны чыгарма! Теләсәң нишлә! Мин сиңа акча кайтарып бирдем, теләсә нишлә! Тик миңа тимә, орынма миңа! Уф, гел кычкырыш, гел кычкырыш! Татарның театры да кычкырыштан башлана!

Нәфига *(елаудан туктап).* Күптән шулай диләр аны... *(Акча салынган банка янына бара. Бер банканы карый, икенчесен, тапмый.)* Акча! Акча!

Хасият. Ни булды? Нәрсә акырасың?

Нәфига. Акча... *(Таба.)* Уф, монда икән! Икенче банкада икән! *(Акчаларны күкрәгенә кысып.)* Югалттым дип торам... Йөрәгем выжт итте!

Хасият. Аллага тапшырдык инде!

Нәфига. Тапшырдык...

Попугай *(ачыргаланып).* Вика дур-ра! Вика дур-ра!

Нәфига *(сискәнеп).* Ә?! *(Сыгылып төшә.)*

Попугай. А Чика гер-рой! А Чика гер-рой! *(Хасият башын югары күтәрә.)* А у Чики фиски, фиски!

Караңгылык.

**АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ**

«Өмет» оешмасында. Өстәл артында Вальс Валерьянович утырган. Зәвыклы киенгән, кыяфәт горур. Астан яшереп нидер ашап утыра, ни ашаганы билгесез. Нәфига керә. Арзанлы туфли кигән. Чатанлап килә. Туктап, ял итеп ала. Ниһаять, Вальс Валерьянович өстә
ле каршына килеп баса. Вальсаңа урын күрсәтә.

Нәфига *(кыюсыз, як-ягына каранып).* Исәнмесез!

Вальс. Салют!

Нәфига. Дөрес килдемме икән инде?

Вальс. Дөрес. Фирмада клиентлар белән мин эшлим. Таныш булыйк: Вальс Валерьянович. Өлкән хезмәткәр. *(Тора. Биеп ала.)*

Нәфига. Абау! Монда биеп үк каршы алалар икән!

Вальс *(сискәнеп).* Ни телисез, чәйме, кофемы?

Нәфига. Икесен дә!

Вальс *(куырылып).* Ни йомыш?

Нәфига. Мин Зөбәрҗәт Сабирова әйтүе буенча килдем.

Вальс. Ә кем соң ул?

Нәфига. Сез аны белмисезмени? Ул бит сездә член булып тора.

Вальс. Юк... Бәлкем, бәлкем, беләм дәдер... Безнең фирмада меңәрләгән әгъза.

Нәфига. Очрашырга дип сөйләшкән идек, юллар аерылды.

Вальс. Зыян юк. Мин сезне тыңлыйм.

Нәфига. Минем дә аның кебек член буласым килә.

Вальс *(сөенеп).* Без проблем! *(Нәфигага кызыксынып карап тора.)*

Нәфига *(пышылдап*). Ни... мин алып килдем.

Вальс. Нәрсә?

Нәфига. Акчаны. Член булыр өчен иң элек акча кертергә кирәк түгелме соң?!

Вальс. Безнеңчә взнос дип атала ул. Менә укыгыз, монда бөтен шартлары да язылган. *(Кәгазь бирә.)*

Нәфига. Укып тормыйм. Рәхмәт. Барысын да беләм. Ахирәт аңлаткан иде инде. Кемгә бирергә соң взнусны?

Вальс. Миңа. Ә мин аны кассага салам.

Нәфига. Хәзер, энем, тукта, акчамны гына чыгарыйм. *(Акчасын оекбаш эченнән чыгара. Тирләп пешә. Ала алмый интегә. Вальс, оялып, йөзен читкә ала.)*

Вальс *(көйләп).* «Любовь приходит незаметно, когда ее никто не ждет...»

Нәфига. Ай Аллам! Алдым, ниһаять! Мә, энекәш, санап ал! *(Акча төргәген бирә.)*

Вальс. Күпме кертергә булдыгыз?

Нәфига. Нәрсәне?

Вальс. Взносны?

Нәфига. Утыз мең.

Вальс. О! *(Тиз генә санап ала.)* Тәк. Взнос акчасы саналды. Ә хәзер, әйдәгез, сезгә регистрация ясап алыйк.

Нәфига. Квитанция бирерсез инде, яме!

Вальс. Билгеле. Сүз дә юк. Квитанция генә түгел, мин әле сезгә таныклык та бирәчәкмен. Сертификат. Таныклык бөтен Россия буенча хәрәкәт итә.

Нәфига. Кит аннан!

Вальс. Язабыз. Исемегез? Русча әйтегез!

Нәфига. Нафига.

Вальс *(тотлыгып).* Апа, зинһар, сүгенмәгез! Сез бик тә әдәпле оешмада находитесь.

Нәфига. Энем, мин сүгенмим, әйтәм генә.

Вальс. Сүгенәсез шул, апа, сүгенәсез. Тәк. Исемегез?

Нәфига. Нафига!

Вальс. Кирәк. Исемегезне язмыйча ярамый. Сезнең исемгә таныклык ачарга кирәк.

Нәфига. Ач, энем, ач, миннән рөхсәт.

Вальс *(сәерсенеп).* Исемегез?

Нәфига. Нафига...

Вальс. Апа, соңгы мәртәбә кисәтәм. Взнос керткәнегезгә карап тормыйм, чыгарам да җибәрәм. Сүген-мәгез!

Нәфига *(аптырап).* Ә кем сүгенә соң әле?

Вальс. Исе... *(Төртелеп кала.)* Исе... ме... гез...

Нәфига *(озак кына дәшмичә торганнан соң).* На-фи-га!

Вальс *(тирләп-пешеп, үз-үзенә).* Тынычлан, Вальс, тынычлан, әгәр дә эшсез каласың килмәсә, түз ничек тә!

Нәфига. Әйе... Нафига!

Вальс *(тактиканы үзгәртеп).* Ярар, кадалып китсен! Фамилиягез?!

Нәфига. Нафикова!

Вальс *(шок дәрәҗәсендә).* Ә?! (*Торып йөренә. Дару эчә.)* Апа, сезгә оят түгелме?!

Нәфига. Ә нәрсәсе оят булсын ди инде аның?!

Вальс. Мин сездән исем-фамилиягезне сорыйм, ә сез сүгенәсез!

Нәфига. Соң мин бит җавап бирәм...

Вальс *(кычкырып).* Нәрсә?! *(Нәфига җавапсыз кала.)* Тәк... Вальс... кулыңа ал үзеңне, кулыңа... Бу хатынны конкурент фирма җибәргән булырга мөмкин... Конкурент...

Нәфига. Энекәш, әйдә инде тизрәк! Акчаны алдың, таныклыгы һаман да юк. Тутыр инде әйдә, тутыр!

Вальс. Апа, мин шеф белән сөйләшеп алыйм инде! *(Акчага кулын суза.)*

Нәфига *(акчага ябышып).* Юк, таныклык бирмичә, акча юк! Юк!

Вальс. Мин сезгә таныклык төзи алмыйм!

Нәфига. Нигә?

Вальс. Чөнки сез... сез... сүгенәсез!

Нәфига. Сүгенмим мин! Әйдә, тагын сора! *(Пауза.)*

Вальс. Исемегез?

Нәфига. Нафига!

Вальс. Фамилиягез?

Нәфига. Нафикова!

Вальс. Исемегез?

Нәфига. На-фи-га!

Вальс (кара янып). Хушыгыз... *(Егыла.)*

Нәфига. Әллә үлде инде?! *(Бармагын авызына тыгып сызгырмакчы була. Сызгыра алмый.)*

**ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Зөбәрҗәт керә.

Зөбәрҗәт. Син мондамыни? Ни булды?
Нәфига. Хезмәткәрегез үлеп ята!
Зөбәрҗәт. Кая?
Нәфига. Әнә! Идәндә!
Зөбәрҗәт. Ни булды аңа?
Нәфига. Белмим. Исем-фамилиямне әйткән идем, егылды.
Зөбәрҗәт. Ярар, тавышланма! Әйдә, күтәрик инде! Кеше күрмәсен тагын! *(Күтәрәләр.)* Син нишләп мине көтмәдең соң, без бит бергә барырга тиеш идек.
Нәфига. Мин сине кече мәйданда көттем.
Зөбәрҗәт. Олы мәйданда очрашабыз дип сөйләштек бит.
Нәфига. Мин сине аңламаган инде алайса.
Зөбәрҗәт. Ә ничек таптың?
Нәфига. Бик тә җиңел. Бөтен кеше белә. Бөтен шәһәр халкы бу оешманың члены булып беткән икән бит.
Зөбәрҗәт. Ахмаклар җитәрлек...
Нәфига. Нәрсә дидең?
Зөбәрҗәт. Җен авырлыгы икән бу зәхмәттә! Сип йөзенә су! *(Нәфига су сибә. Вальс аңына килә.)* Аңына килде...
Нәфига. Уф, Аллага шөкер!
Зөбәрҗәт. Бик тә нечкә күңелле хезмәткәр бу. Музейда экскурсовод булып эшләгән. Бар, син күренмә әлегә! Чыгып тор! Таныклыгыңны ясатып чыгармын!
Нәфига. Ярар, ярар! *(Чыга.)*
Зөбәрҗәт *(Вальска).* Әй, уян әйдә! *(Пауза.)* Уян, татар, уян!
Вальс. Ух! *(Каранып.)* Кая ул?
Зөбәрҗәт. Чыгарып җибәрдем. Ул — мин тапкан кеше. Минем файдага яз аны!
Вальс *(акчаларны җыеп).* Мин мондый тупас хатынны үз гомеремдә беренче мәртәбә күрәм. Мин аңардан исем-фамилиясен сорыйм, ә ул миңа сүгенеп җавап бирә.
Зөбәрҗәт. Нәрсә ди?
Вальс. Әйтергә дә оят.
Зөбәрҗәт. Ну шулай да!
Вальс. Нафига, ди!
Зөбәрҗәт. Дөрес әйтә!
Вальс. Нәрсә, син дә аны яклыйсыңмы?! Куам оешмадан!
Зөбәрҗәт. Мин синең үзеңне кудырам! Син үзең надан. Аның исеме шундый бит. Нә-фи-га! Фамилиясе — Нафикова! Аңладыңмы?!
Вальс *(шаккатып).* Кит аннан! Кем уйлаган?!

Зөбәрҗәт көлә башлый. Аңа кушылып Вальс та көлә. Икесе дә шаркылдап көләләр.

**СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Нәфигалар фатиры. Телефон шалтырый.

Попугай *(кычкырып куя).* Вика дур-ра!

Ванна ягыннан Нәфиганың тавышы ишетелә.

Нәфига. Кызым! Кызым! Ал әле телефонны! Кызым!

Икенче бүлмәдән Гүзәл чыга. Ярым йокы халәтендә. Телефон трубкасын кулы белән капшап таба. Ала.

Гүзәл. Алло! А... Али! *(Бер күзе ачыла.)* Салют! Салют! Ничек анда... Америка?! Айбат... да! Бездә һава торишы?! Азрәк яңгыр сибәли кебек... Ну... төгәл айталмыйм... Өйдән чыкканым юк... Сездә дә яңгыр ява?! Интересно! Да... Көтәсең?! Али... Бик теләп... Ну... ни... Ани... җибарми...

Ванна ягыннан Нәфига чыга. Аны танырлык түгел. Бай хатыннары
кебек киенгән. Башына (чәченә) прибамбас куйган.

Нәфига *(аның хәтта сөйләшүе дә үзгәргән).* Кем җибәрми?! Кем телефонда?!

Гүзәл. Ну... пока... Гуд бай... Звони! *(Трубканы куя.)*

Нәфига. Кем?

Гүзәл. Америка!

Нәфига *(көзгедән каранып)*. Нәрсә ди Америка?

Гүзәл. Көтәм, ди.

Нәфига. Көтсен. Әйттем бит, без аны сынап карыйбыз, дип...

Гүзәл. На что? На прочность любви?

Нәфига *(көлеп).* Нет, на вшивость.

Гүзәл. Күпме сынарга була?! Шалтыратыр-шалтыратыр да туктар. Ки-тәм!

Нәфига. Син анда барып җитә аласыңмы соң? Син бит көн-төн өйдә ятасың!

Гүзәл. Самолетлар очадыр бит?

Нәфига. Очалар...

Гүзәл. Ки-тәм! Хочу в Америку!

Нәфига. Китәрсең. *(Пауза.)* Акча җибәрсә?

Гүзәл. Нинди акча?

Нәфига. Юлга акчасыз чыгып китеп булмый, акча кирәк. Ә безнең акчабыз юк, без акчаны бер төшемле урынга салдык. Тиздән зур акчалар булыр, Алла боерса!

Гүзәл. Безнең беркайчан да акча булмаячак. Ничек хәерче булсак, шулай хәерче булып калырбыз да.

Нәфига. Җитәр, не каркай! Алиеңә әйт, юлыңа акча җибәрсен, шуннан соң китәрсең. Ишеттеңме?!

Гүзәл. Ишеттем. *(Ике күзе дә ачыла. Әнисенә аптырап карап тора.)*

Нәфига *(аның ягына борылып)*. Нәрсә лупаларыңны акайттың?!

Гүзәл. Ани... Синме бу?

Нәфига (*як-ягына каранып*). Мин. Ә кем булсын тагын?

Гүзәл. Ну и прикид!

Нәфига *(аңламыйча)*. Брикет?

Гүзәл. Прикид, дим, прикид! Мин сине мондый итеп беренче мәртәбә күрәм!

Нәфига. Ничек?

Гүзәл. Модный итеп!

Нәфига. Син әниеңне хәзер гел шундый итеп кенә күрә башларсың. Мин хәзер фирма, бик зур фирма әгъзасы. Миңа кешеләр алдында матур булып күренергә кирәк. Ә аның өчен матур итеп киенергә, төз итеп атларга кирәк... Зөбәрҗәт апаң кебек! Менә болай...

Нәфига, төз басып, күкрәген киереп, элегантно йөренә. Гүзәл кул чаба.
Хасият керә. Шаккатып Нәфигага карап тора.

Хасият *(танымыйча, Нәфигага)*. Исәнмесез...

Нәфига. Син нәрсә, ычкындың мәллә?!

Хасият. Ә нәрсә?

Нәфига. Хатыныңа сез дип эндәшмәсәң!

Хасият *(танып алып)*. Нәфига... Бу синмени?!

Нәфига. Мин шул.

Гүзәл. Ани... безнең... того! *(Кереп китә.)*

Хасият. Кара карт юләрне, ә, мин бит сине танымадым, билләһи! Кем йөри инде, мин әйтәм, безнең өйдә?! Дус хатының килгән дип торам...

Нәфига *(күкрәк киереп)*. Җә?!

Хасият. Нәрсә?

Нәфига. Прокатка алдым. Обкатка үткәрәм. Матурмы?!

Хасият. Матур... ха-ха-ха!

Нәфига. Нәрсә көләсең?

Хасият *(прибамбасына күрсәтеп)*. Бусы нәрсә инде тагын? Ниемә дип тактың аны?!

Нәфига *(кул селтәп)*. Әй, син ни аңлыйсың соң модада?! Калхузник!

Хасият. Ай, ай! Үзеңнең каян чыкканыңны онытма! Акчаны каядыр илттең дә салдың, и вәссәлам!

Нәфига. Ничек вәссәлам?!

Хасият. Кая дивидендлар?!

Нәфига. Булыр. Ашыкма. Эшләр әйбәт бара. Бер кеше табылды да инде.

Хасият. Кем?

Нәфига. Үзебезнең авылдан. Әнисә исемле. Ике авылда икешәр кибет тота. Акчасын кая куярга белми.

Хасият. Кая соң ул?

Нәфига. Фирмага акча салырга дип китте. Минем исәпкә.

Хасият. Нишләп син дә аңа ияреп бармадың?

Нәфига. Язу язып җибәрдем. Әйтер, аңлатыр, ышанычлы хатын.

Хасият. Ничек риза булды соң?

Нәфига. Малаен бер айга бездә калдырып тора.

Хасият. Нинди малаен?

Нәфига. Бер малае бар аның. Җәйгә бездә калдырып тора. Баш на баш. Ул — миңа, мин — аңа. Син каршы килмә тагын. Эшне бозма!

Хасият *(иңен җыерып)*. Мин нәрсә инде... Мин хәзер кечкенә кеше. Белмим, барып чыгар микән синең бу бизнесың, куаныч кына булырмы?!

Нәфига. Чыгачагына шигем юк.

Хасият *(киная белән)*. Начты ни ди соң?

Нәфига. Начты барысын да күреп тора. Ул безне хәзер яңа йортта күрә. Яңа йорт баю дигән сүз.

Хасият. Яңа йорт үлем булырга да мөмкин. Бик мөмкин.

Нәфига. Юкны сөйләмә. Яңа йортта — биш бүлмәле фатирда.

Хасият. Ә фатир нинди йортта?

Нәфига. Ничек инде нинди йортта?

Хасият. Панельныйдамы, әллә инде кирпичныйдамы?

Нәфига *(ачу белән)*. Анысын ук сорамадым инде, җаным! *(Ясана, бизәнә.)*

Хасият. Ә син сора, ничәнче этаж, нинди подъезд?! Урам исемен дә сора!

Нәфига *(ысылдап).* Җитте!

Ишектә кыңгырау тавышы.

Ач әле! Минем арттан килергә тиешләр иде бүген. Минем бүген культурный программа!

**ТУГЫЗЫНЧЫ КҮРЕНЕШ**

Хасият ишекне ача. Вальс Валерьянович керә.

Вальс. Исәнмесез!

Хасият *(бер хатынына, бер таныш булмаган иргә карап).* Исәнме... Безгәме?

Вальс. Сезгә. Нәфига ханым өйдәме?

Нәфига *(чәчрәп)*. Өйдә, өйдә! Исәнмесез, Вальс Валерьянович! Исән-сау гына килеп җиттегезме?! *(Кулын суза.)*

Вальс *(күрешеп).* Ой, сез бүген шундый гаҗәп булып күренәсез! Мин сезне танымадым хәтта!

Нәфига. Бу минем ирем. Хасият.

Вальс. Вальс... Валерьянович... Бик тә шатмын...

Хасият. Мин дә. Шатлыгымнан үкереп елыйсы килә...

Пауза.

Нәфига. Сез хәзер офиста утырмыйсызмыни?

Вальс. Юк... мине төшерде... юк... алай түгел... Мин хәзер мәдәният бүлеге мөдире... Шул ук оешмада инде, билгеле...

Нәфига. Күтәрделәрмени?

Вальс. Күтәрделәр, ие, күтәрделәр. Сез мине гафу итегез инде, теге вакыт мин сезне бик үк аңлап та җиткермәгәнмен. Мин сезне сүгенәсез дип торам. Әзрәк конфуз чыкты. Гафу итегез инде... Гаеп миндә...

Нәфига. Зарар юк.

Вальс. Нафига... Нафик... ова... Хи-хи...

Хасият. Әтисенең исемен дә сорадыгызмы соң?!

Вальс. Ә ничек?

Хасият. Нафиевна.

Вальс. Ба! *(Көлешәләр.)* Нәфига ханым, мин сезне алырга дип килдем. Мин сезгә бүген культурный чара тәкъдим итәм. Кая барырга телисез? Ресторангамы, театргамы?

Нәфига *(иренә)*. Кая барыйм?

Хасият. Ә нишләп аны миннән сорыйсың?

Нәфига *(якынрак килеп).* Син бит минем ирем!

Хасият. Ирең итеп санасаң, иң элек син миннән барырга рөхсәт сорар идең!

Нәфига. Миңа йөрмичә ярамый. Йөрү, аралашу — бизнесның төп шарты. Әнә күрәсең бит, миңа ничек зурлап эндәшәләр: Нәфига ханым! Күрдеңме?!

Хасият. Күрдем. Утыз мең акча илтеп түләсәм, миңа да Хасият әфәнде дип кенә эндәшерләр иде анысы.

Вальс. Әгәр дә теләге булса, ирегезне дә алып бара аласыз! Аның фикере ничегрәк соң?

Нәфига. Аның үз фикере юк. Ул хәзер минем фикер белән генә яши.

Вальс. Ни уйладыгыз инде? Уйлагыз, мин көтәм. Мин бүген сезнең карамакка тапшырылган.

Нәфига. Ә болай ярамыймы: башта театрга, аннан ресторанга?!

Вальс. Ярый, нишләп ярамасын. Кайсы театрга?

Нәфига. Камалга, билгеле. Мин Камалны яратам. Аның «Зәңгәр шәл»енә, «Казан сөлгесе»нә мөкиббәнмен. Ул Булат җырлый, ул Мәйсәрә... *(көйләп)* «Булат, Булат кайткан, бүләк алып кайткан...» *(Иренә төрттереп.)* Трам-тарам, трам-тарам...

Вальс. Сезне аста машина көтә... «Вольво»!

Нәфига. Рәхмәт сезгә. Хасият, мин киттем. Өйдә тәртип булсын. Авыл Әнисәсе килеп чыкса, әйбәтләп каршы ал. Чыраең сытма. Киттек, Вальс Валерьянович!

Вальс. Киттек, Нәфига Нафиевна!

Нәфиганы култыклап ала. Чыгып китәләр.

Хасият *(үртәп)*. Ой, ой, ой! Нәфига ханым! Тфү! Үзгәрсә дә кеше үзгәрә икән, әй! *(Тәрәзә янына килә, аска карый.)* Кара инде син аның йөрешләрен генә, кара сөйләшүләрен! Их, әйбәт булган икән элеккеге тормышлар, элеккеге Нәфигам да шәп булган. Әби иде бит, ә хәзер әнә яшь, чибәр кызлар төсе кереп китте үзенә! Нишләрсең, әгәр сөекле хатының мөгез куя башласа?! Түз, Хасият, ничек тә түз!

**УНЫНЧЫ КҮРЕНЕШ**

Ишектә кыңгырау тавышы. Хасият ишек ача. Әнисә керә. Аңа улы Марс ияргән. Чәче үрә торган, күзләре төрле якка карый. Матур
киенгән, ләкин аның тулы түгеллеге әллә каян күренеп тора.

Әнисә *(улын ишек катында калдырып)*. Ой, өлгералмый калдым, китеп барды Нәфига... Синең хатын идеме ул?!

Хасият *(аптырап)*. Минекедер инде, минекен күргән булсагыз...

Әнисә. Шул инде. Кара «Вольво»га утыртып алып киттеләр... И-хи-хи! Бик читкә җибәрмәгез инде хатыныгызны, хатынсыз каласыз бит! Ну үзгәргән хатыныгыз, үзгәргән! Каян шундый матур киемнәр алып кигән диген син?! *(Өйдәге җиһазларга күз төшереп.)* Тәмам искитәрлек! *(Борынын җыера.)*

Хасият. Прокатка алган ул аны.

Әнисә. Нәрсәне?

Хасият. Киемнәрне. Хәзер обкатка уткәрә.

Әнисә. Обкатка дигәннән... Миңа ачуланма инде син, мин шулай гел мәзәк сөйләргә яратам... Шундый инде мин... Обкатка дигәннән... Минем иремне беләсеңдер инде син...

Хасият. Юк. Күргән юк. Мин сезне беренче генә күрәм.

Әнисә. Ничек инде беренче?! Былтыр авылга сабантуйга кайткан идең бит! Мин ике авылда ике кибет тотам. Соңыннан бергә эчеп утырдык түгелме соң?!

Хасият. Хәтерләмим дә инде...

Әнисә. Син түгел идеңмени ул?!

Хасият. Белмим дә инде...

Әнисә. Ну ярый... Минем ирем бар... Бер авыл сантые инде шунда... Сөнтоймас! Менә шул бервакыт матай алды... «Юпитер»... Күптән булды инде бу хәл. Теге обкатка дигәннән әйтәм инде мин. Юл буенда басып торам. Теге, матайга утырып, авылга кайтып бара. Утыртмый гына бит мине бу. Хатынын

утыртмый. «Гафу ит, Әнисә, матайны яңа гына алган, обкатка уза, техника харап итәр хәл юк!» — дип, юл уртасында калдырды да китте бу мине! Ярар! Өйгә кайттым! Мин дә усал бит инде! Табак-савытларны ялтыратып юып куйдым, малай, ашарга берни дә пешермәдем мин моңа. Килеп утырды табынга. Ашарга кая, ди?! Ашарга юк, мәйтәм, пешермәдем. Нишләп юк, ди бу?! Ә нишләп мине юлда утыртмадың, дим?! Матай обкатка үтә, ярамый, ди. Мәйтәм, менә мин дә яңа табак-савытлар алган идем, алар да хәзер обкатка үтәләр, шуңар күрә сиңа ашарга пешермәдем, дим тегеңә... сантыйга... *(Шаркылдап көлә.)* Ике ай да йөрмәде матае... таралды... Мин хәзер үзем йөрим... машинам бар... «Нива»...

Хасият. Яхшы машина.

Әнисә. Каян беләсең?

Хасият. Мин — шофер.

Әнисә. Товар ташырга яхшы ул. Берзаман мондый хәл булды. Сантыйны беләсең бит инде син хәзер... Минем иремне...

Хасият. Белә башладым инде.

Әнисә. Кузгалып киттек машина белән. Юлдан барабыз, малай. Сөйлим дә сөйлим сантыйга. Мин бик сөйләргә яратам. Теге бер сүз дә дәшми бара. Мәйтәм, нишләп бер сүз дә дәшмисең, дим тегеңә... Ул утырган якка борылып карасам, юк теге машинада! Кара, мәйтәм, әллә төшеп калдымы икән, дим! Шаклар каттым инде! Курка да башладым шул сантыем өчен... Зрә! Соңыннан ачыкланды: ул ваще утырмаган булган машинага. Юл буенда басып калган... Хикмәт... Хи... хи!

Хасият. Нишләп шундый җүнсезмени соң ирегез?

Әнисә *(кул селтәп)*. Әй, сорама инде син! Әле бу кыш яңа гына шәһәргә үзенә мех бүрек алырга дип барган иде. Алган бу. Базардан алган инде. Алган да басып тора икән тукталыш чатында. Шуннан бер хулиган малай килеп чыккан. Карак булгандыр инде, сабакы малае! «Абый, синең башыңда бу нинди бүрек соң?» — дип сораган ул минем сантыйдан. «Ондатра!» — дип җавап биргән минеке. «Анда тормый ул, абый, монда тора!» — дигән дә бүреген салдырып алып киткән... Шулай итеп, ике мең сум акчадан колак кактык... Ну ярар! Яшәсен бизнес, ул яшәсә, без дә яшәрбез, Аллаһы боерса!

Хасият (*Марска күз төшереп*). Ә үзе кая соң әле ул?

Әнисә. Кем?

Хасият. Сантый... ягъни... ирегез...

Әнисә. Авылда, кая булсын. Ике авылда ике кибет тотабыз без. Байлар без, апаем! Мин үзем шәп хатын инде, дөньяның астын өскә китерәм! Менә сантыем гына «не-то.» Авызыннан бер сүз алырлык түгел. Берәр нәрсә сорасаң, бер елдан соң гына җавап кайтара. Ничек онытмый, искитәрлек! Яңа елда сораган идем, кибет йозагын кая куйдың, дип?! Җавап бирмәде. Икенче яңа ел җиткәч кенә әйтте: йозакны сарайга куйган икән... Ничек онытмый, искитәрлек!

Марс. Ишкитәрлек име, әнекәй! *(Шаркылдап көлә. Аптырашып Марска карап торалар.)*

Әнисә. Минем вакыт тыгыз. Бизнес. *(Марска күрсәтеп.)* Менә бу товарны сездә калдырып торам. Җәй беткәнче. Хатының әйткәндер бит?!

Хасият. Әйтте. Тик нигә калдырасыз соң аны монда?

Әнисә. Гел яшен бәрә мескенемне!

Хасият. Соң...

Әнисә. Авылда безнең грамота... гро... мото... отвод юк. Ә шәһәрдә бар. Шәһәрдә яшен бәрми...

Икенче бүлмәдән Гүзәл чыга. Эчке күлмәктән. Бер кулында китап, берсендә шифалы су. Су чөмерә-чөмерә, китап укый. Әнисә каршына килеп баса. Шифалы суны Әнисәгә тоттыра да китап битен ача. Шешәне кире алып, киерелә-сузыла, бүлмәсенә кереп китә.

Әнисә *(өнсез)*. Кем бу?!

Хасият. Кызым. Имтиханнарга әзерләнә.

Әнисә. Ай, тәмам котны алды! Сөяркәң дип торам! Ай! *(Йөрәген тотып.)* Ярар, киттем. *(Марска.)* Сау бул, улым, тәртипле бул! Бар, түргә уз, бар, улым! *(Үбеп чыгып китә.)*

Марс өстәл янына килеп утыра. Хасият тә утыра. Бер-берсенә сәер генә карашып алалар.

Хасият. Йә, сөлә!

Марс. Нәрсә сөлим соң, абый?!

Хасият. Сүлә... Как ты докатился до такой жизни?

Марс. Русча аңламыйм мин, абый!

Хасият. Сүлә... Ничек итеп сине яшен бәрде?!

Марс *(хисләнеп)*. Мине ясен өс мәртәбә бәрде, абый!

Хасият *(шаккатып)*. Өч мәртәбә?! Ә ничек исән калдың?

Марс. Значит, мин везучий... сундый...

Хасият. Җә... сүлә инде!

Марс. Беренсе мәртәбә көтү куарга чыккан җирдә бәрде. Сәйләүдә. Мин шәпидкә утырган идем. Шул шәпид аркылы бәрде.

Хасият. Нәрсә ул шәпид?

Марс. Ну шәпид. Йөри торган. Ике көпсәкле. Аны ут күрселәр уйлап тапканнар.

Хасият. Нинди ут күршеләр?

Марс. Баскортлар. Теге... терлим-терлим... *(Башкортча кубызда уйный.)* Ясен, бас осымнан кереп, аяк табанына тиклем төсте.

Хасият. Хикмәт. Исән калдыңмы?

Марс. Менә бит яныңда утырып торам... Ясен миннән штолбик яшады.

Хасият. Нәрсә ясады?

Марс. Штолбик. *(Баса. Багана кебек катып кала.)* «Чакрым шаен телеграм, чакрым шаен багана...»

Хасият. Аңлашылды...

Марс *(тантана белән)*. Ясен шандилының табанын каерып атты!

Хасият. Хикмәт!

Марс. Шуннан... басны калдырып, җиргә күмеп куйдылар. Җир миндәге токны үзенә алды. Менә мин сулай ишән калдым. Рәхмәт шиңа, Җир-ана! *(Баш ия.)*

Хасият. Ә аннан соң?

Марс. Кизләүгә шуга барганда бәрде. Көянтә-чиләк аша.

Хасият. Нишләп син суга барасың? Көянтә-чиләк күтәреп суга бару кызлар эше түгелме соң?!

Марс *(утырып)*. Безнең авылда кызлар юк. *(Пауза.)* Өшенше мәртәбә агас басында бәрде.

Хасият. Нишләдең агач башында?

Марс. Әтидән кастым. Шиңа шер итеп кенә әйтәм, абый, име...

Хасият *(көлеп)*. Нәрсә, Ленин ролен бирделәр мәллә?!

Марс. Мин авылдан ясеннән касып түгел, әтекәйдән касып килдем. Әтекәй бик ушал безнең... Айлар буе кайтмыйча каядыр йөри дә аннан шуң бер кайтып төсә. «Мин кайттым, тавыска әзерләнегез!» — дип, үзәкләрне өзә... Ушал, бик тә ушал... Ай туздыра өйне, ай туздыра, әнекәйне туздыра, мине... утын агасы белән кыйный иде, мин шиннән кесе ясыйм, дип... Әтидән касып килдем мин... абый, әтидән...

Пауза.

Хасият. Ә болай ни белән сөгы... тфү... шөгыльләнәсең инде?

Марс. Кайда?

Хасият. Авылда?

Марс. Кибет шаклыйм.

Хасият *(битараф)*. Алай икән...

Марс. Аннан сигырьләр дә язгалыйм. Әйдә, мин шиңа сигырь укыйм!

Хасият. Зинһар, теләсәң нәрсә укы, тик шигырь генә укыма.

Марс. Нисләп?

Хасият. Аллергия. *(Карашып торалар.)* Менә син си... шигырьләр язам, дидең, име! Ә син Тукайны беләсеңме соң?

Марс. Беләм. Безнең ахири ич ул.

Хасият *(мыскыл итеп)*. Ә син Тукайның «Моабит дәфтәрләре»н укыганың бармы?

Марс. Бар. Мин әле дә укыйм аны. Укыйммы бершен?

Хасият. Ә кая язган соң Тукай «Моабит дәфтәрләре»н?!

Марс. Кая... Суны да белмисеңме?! Төрмәдә утырганда язган. Аннан аның басын кишкәннәр!

Хасият. Әйе, алар елмаеп та үлгәннәр бугай әле...

Марс. Ие, аның әле дусты да булган... Абдулла Алис... тагын кемнәр... Зуя Космадемянская... Зурге...

Хасият. Аңлашылды. Шатлан, Хасият, в твоем полку прибыло!

Марс. Алар бергә елмаеп үлгәннәр дә әле...

Хасият. Кем белән?

Марс. Тукай белән... Кхый-кхый! *(Көлә.)*

Суыткыч дөбердәп ала.

*(Качып.)* Ясен! Ясен! Күк гөберди!

Хасият. Күк гөбердәми, безнең холодильник дөберди... «Свияга»... 304 нче модель... Инәсен корт чаккыры!

Гүзәл бүлмәсендә музыка уйный.

Марс. Теге бүлмәдә кем яси?

Хасият. Ул бүлмәдә эт яси.

Марс. Ул сулай музыка да тыңлыймы?

Хасият. Ул әле җырлый да! *(Музыка көчлерәк яңгырый.)*

Марс. О! Мин музыкадан балдею! Бу бит «рэп»!

Хасият. Нәрсә?

Марс. «Рэп». Клубта без хәзер гел суңа биеп ятабыз. Бетте ул хәзер «Әпипә»ләр... Менә болай... *(Такмаклый-такмаклый бии башлый.)* Әйдә бергә, абый... Бергә-бергә күңелле була ул! *(Хасият тә аңа кушылып бии.)*

Хасият. Да, җегетләр, күңелле яшибез!

Гүзәл чыга.

Гүзәл *(шаккатып)*. Ну ати... ты даешь!

Марс *(кычкырып)*. Даюс! Даюс!

Гүзәл, колагын томалап, бүлмәсенә кереп китә. Хасият ачудан чын-чынлап каты итеп бии.

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Нәфигалар фатиры. Ял көне. Радиодан татар җырлары яңгырый.
Нәфига, Хасият, Гүзәл өстәл янында чәй эчеп утыралар.

Хасият *(тынлыкны бозып)*. Соңгы вакыт никтер Америкадан шалтыратмый башладылар әле?! Кияү югалмагандыр бит?

Тавык ите ашап утырган Гүзәл кинәт кенә тыгыла. Йөткерә башлый.
Хасият, торып, аның аркасына суга. Гүзәл йөткерүдән туктый.

Нәфига. Ни булды?

Гүзәл. Ялгыш сөяк йоттым...

Нәфига *(коты очып)*. Ә?!

Гүзәл *(куркып)*. Чыгар микән инде ул?

Хасият. Чыгар.

Гүзәл. Нәрсә булып чыгар?

Хасият. Сөяк булып чыгар. *(Утыра.)*

Тынлык.

Америка...

Нәфига. Янды Америка!

Хасият. Ничек янды?

Нәфига. Алдадылар кызымны?

Хасият. Ничек алдадылар? Ул бит һаман да өйдә утыра.

Нәфига. Телефоннан. Гомәр исемле бер студент егет кызыбызны свиданиегә чакырган булган. Кызым бармаган. Менә шуңа үч итеп, Америкадан дигән булып, шаярып шалтыратып ятканнар... Сабакы малайлар!

Хасият. Соң, сине Начты Маямида купальниктан күргән иде түгелме соң?!

Нәфига. Күргән иде!

Хасият. Ну?!

Нәфига. Ә хәзер күрми!

Хасият. Ә ничек күрә соң ул?

Нәфига. Алдына фундук чикләвекләре сала. Шуларны тарата. Аннан соң... күзен йомып алга карый. Менә шулай итеп... күрә... *(Күрсәтә.)*

Хасият. Чепи күз! Алдакчы!

Пауза.

Нәфига. Марс кая соң әле?

Хасият. Иртән йөгерергә дип чыгып киткән иде.

Нәфига. Ул йөгерә дәмени әле?

Хасият. Мин куштым... Чыныксын дидем инде...

Нәфига. Нигә кирәк аңа йөгерү?

Хасият. Соң... гел яшен бәрә дә, яшен бәрә, ди ич!

Нәфига. Мескен бала! *(Пауза.)* Ул да туйдыра башлады. Кайчан алып китәр анасы...

Хасият. Мин чакырмадым бит.

Ишектән Марс йөгереп керә. Ертык трикодан. Ул, йөгерүдән туктамыйча, өстәл тирәли бер кат әйләнеш ясый. Туктамыйча, бер урында селкенгәләп тора. Гүзәл тагын тыгыла. Хасият, тормыйча гына, аның
аркасына суга. Гүзәл бүлмәсенә кереп китә.

Нәфига. Улым, ял ит аз гына...

Марс. Йөгерүне өзәргә ярамый, апа!

Нәфига. Нишләп?

Марс. Режим.

Хасият. Карале, Марс дус, нишләп син кулыңны өскә куеп йөгерәсең, ә?!

Марс. Алай шуларга җиңел, абый! *(Пауза.)* Киттем! Тагын бер круг биреп керим! *(Йөгереп чыгып китә.)*

Нәфига. Нишләргә җиңел ди ул?

Хасият. Кулны шул халәттә тоткач, суларга җиңел, ди.

Пауза.

Нәфига. Начты...

Хасият *(сискәнеп)*. Ә?!

Нәфига. Начты...

Хасият. Русский язык трудный... Начты — имя девушки... А плохая погода... неначты...

Нәфига. Күргән...

Хасият *(ачу белән)*. Нәстә күргән тагын?

Нәфига. Яшенле яңгыр астында күргән.

Хасият. Кемне?

Нәфига. Кызны инде!

Хасият. Сине дә күргәнме?

Нәфига. Күргән. Зонтик тотып йөрим икән. Затлы зонтик.

Хасият. Шуннан?!

Нәфига. Әллә, мәйтәм, шушы Марс белән кызыбызны бергә кушып куябызмы?!

Хасият. Ә?! Шул дивана беләнме? Хәер, безнең кыз да аңардан әллә ни артык түгел инде.

Нәфига. Ярар инде, гел шул кызыңнан көлеп утырмасана!

Хасият. Мин ул «яшен»нән менә болай туйган! *(Муенына сыза.)* Кайчан алып китәрләр инде үзен! Бизнес дип катырдың башымны!

Нәфига. Әнисе Әнисә шәһәрдә фатир алып бирергә йөри улына. Бай бит ул. Ике авылда ике кибет тота. Монда тормаслар, шул фатирга китәрләр.

Хасият. Шәп тормыш була инде бу! Берсе яшеннән качып йөрер, икенчесе йоклап ятар...

Нәфига. Кушылгач яшәрләр, беркая да китмәсләр! Әйдә, Гүзәл белән сөйләшеп карыйк әле. Мин аңа бер төрттергән идем инде.

Хасият. Нәрсә ди соң?

Нәфига. Миңа барыбер, ди.

Хасият. Гаҗәп! Хәер, гаҗәпләнер урын да юк, аның бит әле Марсны җүнләп күргәне дә юк, һаман йокы симертә...

Нәфига. Әйдә, керик әле!

Хасият. Юк ла!

Нәфига. Әйдә инде, кызыңның язмышы хәл ителергә тора бит! *(Өстерәп алып кереп китә.)*

Марс керә. Стаканнан чәй чөмерә. Баскан килеш кенә ашый. Радиодан яңгыраган җырга колак сала, аякларын чалыштырып кәнәфигә утыра. Диктор: «Татар радиосы! Татар радиосы! Сез туры эфирда... Җыр тапшырабыз... Кадерле әниебез...» Җыр яңгырый. Марс моң-
лана. Җыр беткәч, телефон янына бара.

Марс *(трубканы алып)*. Бис... бис... нуль, нуль... Алло! Алло! Бу «Татар радио»шымы?

Диктор. Әйе, тыңлыйбыз. Сез туры эфирда.

Марс. Апа, ишәнмешез!

Диктор. Исәнмесез! Исемегез?!

Марс. Ә?!

Диктор. Үзегез белән таныштырып китсәгезче!

Марс. Марш булам мин.

Диктор. Марш?!

Марс. Ие... Кукидән... Марш...

Диктор. Сәер... Әйе... Тыңлыйбыз сезне!

Марс. Әнкәйне шагындым, апа... Шез аңа багышлап Салават башкаруында «Таслама, әнкәй, таслама!» дигән җырны тапшыралмашшыз микән?!

Диктор. Гафу итегез, бездә андый җыр юк.

Марс. Ә Айдар Галимовның «Кызыл рожалар»ы бармы? *(Пауза.)* Нәрсә, юкмыни?! «Кызыл рожалар»... Ә Хәния апайның «Үпкәләмә»се дә юкмы?

Диктор. Нинди җыр ул?

Марс. Соң... «Үпкәләшәң, әйдә үпкәлә...» Юкмы?!

Диктор. Юк.

Марс. Алайса... Мәгъфур Хисмәтуллинның «Бәтәч» дигән җырын куегыз инде, яме! *(Трубканы ата. Тузынып сәхнә буенча йөри. Радионы сүндерә.)*

**ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Хасият чыга.

Хасият. Ни булды?

Марс. Авылны сагындым... Әнкәй дә килми... Зрә сердце булмаса ярый инде!

Хасият. Нәрсә булмасын?

Марс. Зрә сердце, дим! Йөрәк авыруыннан бик күп тәгәриләр хәзер. Үлеп китмим тагын... Сигырь яздым әле, абый!

Хасият. Нинди шигырь?

Марс. Туган авылга багышлап. Укыйммы?

Хасият *(коры гына)*. Укы.

Марс *(укып)*. Кайттым колхуз имени Лелина...

Хасият. Кая?

Марс. Колхузга. Безнең колхуз Лелин ишемен йөртә... Юлбасчы булган ул... Әле дә мавзалида ята... Авыр туфрагы җиңел булшын инде... Дәлсе... Укыйм... Кайттым колхуз имени Лелина, күрергә туганнарны, беростан Әбрарны...

Хасият. Кемне?

Марс. Әбрарны...

Хасият. Кем ул Әбрар?

Марс. Безнең авылныкы. Пипус Әбрары...

Хасият. Нишләп именны ул?

Марс. Кызык өчен яздым. Аңлап булмый аны. Шаика ул...

Хасият. Кем, кем?

Марс. Шаика... Тотлыга чашты...

Хасият. Синең үзеңне аңлап булмый, брат! *(Пауза.)* Карале, энекәш, син минем кызга ничек карыйсың?

Марс. Яхсы карыйм.

Хасият. Менә син минем кызыма өйләнер идеңме?

Марс. Мин сездән аның кулын шорар идем!

Хасият (*исе китеп*). Ә?!

Марс. Ул минем йөрәгемне әшир итте. Зрә сердце булмаса ярый инде!
Хасият. Нәрсәсе белән?
Марс. Бөтен нәршәше белән!
Хасият. Ә ул ризамы икән соң сиңа чыгарга?!
Марс. Риза.
Хасият. Нәрсә, сүз куешырга да өлгердегезмени?!
Марс. Ие... Коридорда бер очраткан идем мин аны... Шораган идем...
Хасият. Нәрсә сораган идең?
Марс. Кулын...
Хасият. Ә ул нәрсә диде?
Марс. Ярар, тынычлан, диде.
Хасият. Йоклаган чагына туры килгәнсеңдер инде. Ул сиңа: «Ярар, тыныч йокы!» — дип кенә әйткәндер...
Марс. Минем колак бик шлабый исетә, абый, ошобы ясен вакытында...
Хасият. Ярар, утыр әле. *(Марсны утырта.)* Менә синең минем кызга өйләнәсең килә инде, име! Минем кызым белемле, аспирантура бетерә. Ә синең ни белемең, ни профессияң. Син аңа тиң түгел! Һәрвакыт үзеңә тиң кешене эзләргә кирәк бу дөньяда. Без Нәфига апаң белән икебез дә югары белем алган кешеләр түгел, шулай да без бер-беребезне бик яхшы таптык. *(Үзалдына.)* Пирамида белән бәйләнгәнче, билгеле... *(Эченнән сүгенеп ала.)*
Марс. Ие, мин шигез клашш кына бетергән, абый. Минем югары белемем юк. Аттестатта гел өчле. Ә, оныттым. Бер бисле бар.
Хасият. Нәрсәдән.
Марс. Физкультурадан. Мин яхсы йөгерәм. Мин йөгершәм, мине сурт та тота алмый.
Хасият. Кемгә кирәк соң син?
Марс *(күкрәген киереп.)* Ну, мин телләрне яхсы беләм...
Хасият. Нинди телләрне?
Марс. Сит телләрне.
Хасият. Нинди чит тел беләсең соң син?
Марс. Немешсә яхсы беләм.
Хасият. Каян килеп?
Марс. Әшаф абый өйрәтте безне!
Хасият. Нинди Әсаф инде ул?
Марс. Разведшик. Шугыста разведчик булып хезмәт иткән. Суннан немешсә шөйләсергә өйрәнеп кайткан... Немеш әширләре янында... Суңа безне дә өйрәтте...
Хасият. Ничек итеп?
Марс. Менә болай итеп! *(Сикереп тора.)* «Гутен таг!» дип шәлам бирә безгә Әшаф абый.
Хасият. Әкрен!
Марс. «Гутен таг!» дип карсы алабыз без аны... Бөтен клашш белән...
Хасият. Шуннан?
Марс. Суннан... Ул әзрәк серем итеп ала... Арыган инде ул... гештапосылар арашында йөреп... Дәреш үтә... «Ауффедерзейн!» ди ул бешгә, клашштан чыкканда. «Ауффедерзейн!» дип озатып калабыз без аны бөтен клашш белән...
Хасият. Ике сүз генә беләсеңме?
Марс. Юк, барышын да.
Хасият. Ышанмыйм.
Марс. Валлаһи, абый!
Хасият. Ярар... «Бака сазда йөри» немецча ничек була?
Марс. Суны да белмишеңме?
Хасият. Юк, белмим.
Марс. Мин белмәгән тел юк ул, абый. «Бака сашда йөри» немешсә болай була... «Ундер квашен дер поболоту... де шап, де шап, де шап...» *(Бака сымак йөреп китә.)*
Хасият *(кычкырып)*. Җитте!
Марс. Ни булды, абый?
Хасият. Мин сине күралмыйм! Мин сине Пушкинга охшатам!
Марс. Пускинга?
Хасият. Әйе, А.С.Пус... ушкинга!

Марс. Мин ваще-то охсаган да аңа! Мәктәптә укыганда, минем чәч көдрә иде, чырай харашу иде. Мин коеп куйган Пускин идем. Сәп сигырьләр язам!

Хасият. Мин синнән шундый туйдым, име! Мин сине, Дантес сыман, атып үтерәсем килә, атып! *(Кычкыра.)*

**ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Нәфига йөгереп чыга.

Нәфига. Ни булды?

Хасият. Берни дә!

Нәфига. Ай Аллам, котымны алдыгыз! *(Хасияткә.)* Карале, кызым риза! Ани, сез нәрсә әйтсәгез, мин шуңа риза, ди. Тик әгәр дә егетнең фатиры булса, сез генә анда барыгыз инде, ди. Без монда гына калырбыз, ди. Үземнең бүлмәмне бик яратам, шуннан беркая да чыгып китәсем килми, ди.

Хасият. Америкага китәргә хыялланган иде бит әле! Ялкау!

Нәфига. Кияү белән таныштырырга куша.

Хасият. Ничек инде?! Менә бит ул, каршыда басып тора!

Нәфига. Ул аны бер тапкыр да күрмәгән икән.

Хасият *(шаккатып)*. Ничек?! *(Марска күрсәтеп.)* Бу адәм бер ай бездә яши бит инде!

Нәфига. Күрмәгән инде, нишлисең бит!

Хасият. Үтерәсез сез мине, билләһи! Соң... әле генә күрде түгелме соң?! Их! Үлгәнче бер эчәргә!

Нәфига. Кызың бит инде, ярар!

Хасият *(кычкырып)*. Азрак йокласын!

Гүзәл керә.

Нәфига. Кызым, син безгә, кияү белән таныштырыгыз, дигән идең! Менә киявебез килеп тә җитте инде...

Гүзәл *(исе китмичә генә)*. Да...

Нәфига. Акыллы гына егет. Анасы минем авылдаш. Исеме — Марс.

Марс. Ие... Марш...

Нәфига. Авылдан шәһәргә килергә уйлый.

Гүзәл. Ни белән шөгыльләнә? Хоббие?

Нәфига *(аптырап)*. Әйткән идем бит инде... Барысы белән дә...

Хасият *(мыскыллы)*. Телләрне яхшы белә.

Марс. Сынлап та... Немешсә беләм... Безне Әсаф абый өйрәтте...

Гүзәл. Нинди Әсаф?

Марс. Рәзведсик...

Хасият. «Яратам» ничек була?

Марс. Яратаммы?! Ни... әйләвью...

Гүзәл. Айлавью! У! Кого вы мне суюте?!

Хасият. Күзеңне ачыбрак кара!

Гүзәл. Да... *(Күзен ачып Марска карый. Чырылдап кычкырып җибәрә.)* А-а-а! Уберите его от меня! *(Кереп кача.)*

Марс. Штолбик! *(Йөгереп чыгып китә.)*

Хасият. Күрдеңме инде?!

Нәфига. Күрдем... Зыян юк... Ияләшерләр әле...

**ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Әнисә керә.

Әнисә. Ишегегезне дә япмагансыз! *(Кызу-кызу.)* Ха-ха! Тавышка әзерләнегез... мин килдем! *(Хасият белән Нәфига өнсез калалар.)* Ха-ха! Курыкмагыз! Шаярттым гына! Мин шундый инде... мәзәк кеше мин, мәзәксез торалмыйм! Ничек хәлләр?!

Нәфига. Ярыйсы. Әйдә, хуш килдең, без сине көттек!
Хасият. Сагынып!
Әнисә. Малай кая соң әле? Исәнме ул?!
Нәфига. Исән. Ни булсын аңа!
Әнисә. Яшен бәрмәдеме малаема!
Нәфига. Каян килеп! Башка нәрсә бәрде аңа!
Әнисә. Ни?
Нәфига. Мәхәббәт. Минем кызыма гашыйк булган ул.
Әнисә. Ә?!
Нәфига. Өйләнергә теләге бар малаеңның!
Әнисә. Өйләнсен. Мин каршы түгел. Тик синең кызың кайтырмы соң авылга?!
Хасият. Ә нишләп соң ул авылга кайтырга тиеш?
Әнисә. Минем Марсым авылда кибет саклый. Ул булмаса, кем минем кибетемне саклар?!
Нәфига. Син үзең шәһәрдән фатир алам, дип сөйләндең түгелме соң?! Баламны шәһәргә җибәрәм, дидең бугай...
Әнисә. Уйлаган идем. Инде алмыйм. Бер кибетне саттым. Товарга акча җитми! Аннан...
Нәфига. Нәрсә?
Әнисә. Күрдем кызыгызны! Андый кызга малаемны өйләндереп, аны бәхетсез итәсем юк әле. Ялкау сезнең кызыгыз! Иренә аш та пешереп ашатачак түгел ул. Ә минем улым аш ярата. Борчак ашын, кәбестә ашын...
Хасият. Күрдем.
Әнисә. Ни күрдең?!
Хасият. Малаеңны. Бер ай буе бездә ятты. Натуральный дебил. Хатын гына болгатты. Ул болгатмаган булса, кызымны синең малаеңа бирү уе башыма да кереп карамаган булыр иде. Кызым нинди генә начар булмасын, мин аны ул дебил янына якын да җибәрмәячәкмен!
Нәфига. Хасият, әкрен...
Хасият. Ә син дәшмә! Сине тыңлап, шундый хәлгә төштек тә инде! Гүзәл аны күрүгә үк кереп качты!
Әнисә. Минем балам алтын ул, андый бала беркайда, беркемдә дә юк.
Хасият. Алтын булса, ал да кит инде, бездә яткызма!
Әнисә. Кая соң минем алтыным?!

Шул чакны сәхнә артында ачыргаланып кычкырган тавыш ишетелә. Барысы да өнсез калалар. Марс йөгереп чыга. Күзләре акайган, чәч-
ләре керпе энәседәй үрә торган.

Әнисә *(коты очып)*. Улым! Ни булды?!
Марс. Ясен бәрде!

Пауза.

Әнисә. Әй Аллам, сезгә бала ышанып тапшырган мин җүләр! Харап иттегез баламны, харап иттегез!
Хасият. Тукта! Ничек инде яшен бәрде?! Өйдә торыпмы?! *(Марска барып орына. Ток сукканын сизеп, читкә сикерә.)*
Нәфига. Чынлап та... Өйдә ничек бәрсен соң инде ул?!
Әнисә. Карамагансыз баламны! Ай! *(Марсны кочаклый.)* Менә бит мине ток та бәрми, ана кеше ана кеше шул инде ул. Әй улым, җаным! *(Иркәли.)*
Марс *(күзләрен йомгалап)*. Ысанмыйсызмы?! Ваннага кергән идем... Битне, кулны юармын дип... Мин бит йөгердем дә бүген... Тирләдем... Тәннән иш килә башлады...
Әнисә. Нишләп йөгердең?
Марс. Йөгерттеләр.
Әнисә. Кем?
Марс *(Хасияткә күрсәтеп)*. Менә бу абый! Софер!
Әнисә. Имансыз!
Марс. Әти кебек акыл үрәтә баслады...
Хасият. Сиңа үрәтсәң дә таман гына килә ул... Җә, ничек бәрде соң сине яшен? Өйдә килеш?!
Марс. Астым шу кранын... Бик осак астым... Аннан... шуга кулны гына тыккан идем, ясен китерде дә бәрде!
Хасият. Хикмәт!
Нәфига. Булмас!

Әнисә. Булган инде, булган! Мин улыма ышанам! Су аркылы бәргән яшен, су!

Марс. Әнекәй, алып кит мине моннан! Минем авылга кайташым килә, бәршә сунда гына бәршен, үлшәм сунда гына үлим! *(Әнисәгә сырпалана.)*

Әнисә *(иркәләп).* Кайтырбыз, улым, кайтырбыз, сине алырга дип килдем бит инде, сине!

Хасият. Аллага шөкер! Котылабыз синнән!

Әнисә. Харап иттегез баламны!

Хасият. Җитте! *(Ачудан телевизорга китереп суга. Телевизор эшләп китә.)*

Диктор тавышы. Ә хәзер криминаль хроникага күчәбез. «Өмет» дип исемләнгән акционерлар оешмасының эшчәнлегенә җинаятьчелек эше кузгатылды. Аның эше прокуратурага тапшырылды...

Хасият. Хатын! Әнә оешмагызны япканнар!

Нәфига. Кая?! *(Телевизор каршына килеп баса.)* Чынлап та! Ай! Ай! *(Йөрәген тота.)*

Марс. Апа, акрын, зрә сердце булмасын!

Хасият. Очты акчалар!

Нәфига. Янды!

Әнисә *(көлеп)*. Шул кирәк сезгә! Күпме әйттем, минем улымны үпкәләтергә ярамый, дип!

Нәфига *(Әнисәгә)*. Ә нәрсә көләсең?! Син дә акча салдың бит анда! Минем активка... Димәк, син дә яндың...

Әнисә. Юк, җаным, синең активка мин бернинди дә акча салмадым. Мин бит җүләр түгел сезнең кебек теләсә кая акча салып йөрергә. Безнең күрше Гаяннар тавыгы гына шулай теләсә кемдә, теләсә кайда йомырка салып йөри. Ә мин Гаяннар тавыгы түгел! Ха-ха!

Хасият. Чыгып китегез!

Әнисә. Бик теләп. Әйдә, улым, киттек! *(Кычкырып.)* Киттек! Нәрсә каттың?

Марс. Кычкырма, әнекәй... Зрә сердце булмасын... Зрә сердце булса, бик начар...

Әнисә, Марс чыгып китәләр.

Хасият. Килеп терәлдек!

Нәфига. Әй Аллам! Ни генә дип шунда бардым икән?! Алдандым бит, алдандым! Нигә?!

Хасият. Нәфига ханым буласың килде ич! Менә булдың инде! Хатын-кызларга җитми шул инде ул, аларга ирләргә караганда да күбрәк кирәк. Мал кирәк, байлык кирәк. Пушкин әфәнде дөрес язган инде сезнең хакта... Бөтен дөньяны яулап алырга телисез... Колачыгызны бик тә киң итеп җәясез... Нәтиҗәдә ярык тагарак каршында утырып каласыз...

Нәфига. Ә бәлкем... Дөрес түгелдер ул...

Хасият. Нәрсә дөрес түгел?

Нәфига. Телевизорда күрсәткәннәр.

Хасият. Телевизор һәрвакытта да дөрес күрсәтә ул.

Нәфига. Ышан аларга!

Хасият *(ачу белән телевизорга сугып)*. Җитте! *(Пауза.)* Әнә сине телевизордан күрсәтәләр.

Нәфига. Кая, кая?!

Хасият. Әнә, әнә! *(Тәрәзә янына барып баса.)*

Нәфига *(телевизорга текәлеп)*. Кая?! Нишләп мине күрсәтсеннәр, бу бит маймыл!

Хасият. Соң син дә маймыл бит инде!

Нәфига. Синең шул булыр инде... Гел мыскыл итү...

Хасият. Әнә... Безнең йортка Зөбәрҗәт белән теге кем әле... Вальс...

Нәфига. Вальс Валерьянович!

Хасият. Әйе, кереп киләләр. Безгә керүләредер инде. Корабтан качкан күселәр шикелле йөгерешәләр, кара син аларны, ә! Керсеннәр, хәзер күрмәгәннәрен күрсәтәм әле мин аларга!

Нәфига. Бәлкем... тимәссең. Бәлкем, акчаны ала алырбыз, ә?! Җай белән генә...

Хасият. Алырсың бар алардан! Синең акчаларың күптәннән утю-тю инде, җаным!

Нәфига. «Ала каргадан аласың булсын» диләр бит!

Хасият. Болар инде ала каргалар гына түгел, болар инде кара козгыннар*! (Пауза.)* Син дәшмә дә, кушылма да, мин генә сөйләшәчәкмен, аңладыңмы?!

**БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Зөбәрҗәт йөгереп керә.

Зөбәрҗәт. Исәнмесез! *(Ясалма.)* Исәнме, ахирәт!
Хасият. Нишләп үзең генә кердең? Иптәшеңне кая калдырдың?
Зөбәрҗәт. Кемне?
Хасият. Вальсыңны!
Зөбәрҗәт. Ә! Вальс! *(Дәшеп.)* Вальс! Сине чакыралар!

Вальс керә.

Вальс *(кыюсыз)*. Исәнмесез...
Хасият. Исән әлегә! Ни йомыш?
Зөбәрҗәт. Йомышыбыз шул... э... э...
Хасият. Сезнең оешмагызга капут. Телевизордан күрдек. Эшегез судта. Кая безнең салган акчалар?
Зөбәрҗәт. Менә миндә. Алыгыз! *(Төргәк белән акча чыгара.)*
Нәфига *(сөенеп).* Дөрес хәлме бу?
Вальс. Дөрес. Оешмабыз вакытлыча гына ябылды. Киләчәктә әле без тагын оешабыз.
Хасият. Бездән башка гына, яме!
Нәфига *(Хасияткә).* Менә әйттем бит мин сиңа, Зөбәрҗәткә ышанырга була, дип. Рәхмәт! *(Акчага кулын суза.)*
Зөбәрҗәт. Ие... Акчагызны алып килдек. Тик безгә сезнең паспортларыгыз кирәк булыр. Икегезнеке дә. *(Төргәкне үзенә тарта.)*
Хасият. Анысы нигә?
Вальс. Сезне регистрациядән төшерергә кирәк.
Хасият. Төшмәсәк ни була?
Вальс. Сезне суд юлында йөртәчәкләр.
Нәфига. Әстәгы... Хасият, бирик, бирик тизрәк! Бар, алып чык!
Хасият. Һаман бирик тә бирик! Туйдым! *(Пауза.)* Ну ярар... *(Кереп китә.)*
Нәфига. Хәлләр шулхәтле дә начармыни соң, ахирәт?
Зөбәрҗәт. Юк, кем әйтте начар, дип. Мин менә кияүгә чыгам. Вальска. *(Вальс аның биленнән тота.)* Безнең аның белән йолдызнамәләр туры килә. Ул — Чаян, ә мин — Кыз. Без бер-беребезне ярты сүздән аңлыйбыз. Шулай бит, Вальсик! *(Вальс аның битеннән үбә.)*

Паспортлар тотып, Хасият чыга.

Хасият. Менә... таптым... *(Бирә.)*
Зөбәрҗәт *(алып).* Яхшы. Иртәгә иртүк кертербез. Мә, алыгыз акчагызны! Киттек, Вальс! Чао!
Вальс. Ауффедерзейн!

Чыгып китәләр.

Нәфига *(төргәкне актарып).* Нәрсә дип шулхәтле төргәннәр соң моны?!
Хасият. Кара, фәлшивке булмасын!
Нәфига *(ачып).* Менә. Акча бу! Безнең акчалар. Бер пачка акча.
Хасият. Сана.
Нәфига *(санап).* Йөз... *(Туктап кала.)* Әй... ни бу...
Хасият. Нәрсә?!
Нәфига. Кәгазь...
Хасият. Кәбестә! Алдаганнар!
Нәфига. Нинди кәбестә?
Хасият. Тышында — акча, эчендә — кәгазь.
Нәфига. Тагын алдандыкмыни?
Хасият. Менә ышан дусларга! Алар алдында ук санап аласы калган икән аны! Эх, баш! Син түтелдәгәнгә шулай булды ул. Әйттем бит, катышма, дип. *(Пауза.)* Әйе, бер алданган кабат алдана шул. *(Уйланып.)* Бер карасаң, алдамыйча, алданмыйча яшәп тә булмый, ахры, бу җәмгыятьтә. Алдау — җәмгыятьне хәрәкәткә китерүче көч. Гәҗиттә шулай дип язганнар иде хәтта. Дәүләт —безне, ә без дәүләтне алдыйбыз. Астагылар — бер төрле, өстәгеләр икенче төрле алдаша. Астагыларның алдашуы ул тиклем хәтәр түгел, алар өстәгеләрнең алдашуына түзә алмыйча алдашалар. Иң аянычы шунда: бер алдакчыга һәрвакыт йөз алданучы табыла... Ил! Нинди ил соң син?! Бер яхшы суыткыч алу өчен гомерең буе бил бөгәргә кирәк. Ил... Җирнең җелеген суыралар, нефть суырталар. Халык, гади халык һаман да хәерче. Безгә дигән байлык, нигъмәт влач кулында, аферистлар юлында ята...

Нәфига *(Хасиятнең җиңеннән тартып)*. Бәлкем, милициягә хәбәр итәргәдер, ә?!

Хасият. Ни файда?! Милиция көләчәк кенә бездән. Безнең милиция үзен дә яклый алмый бит ул, кая инде аңа безнең кебек гади гражданнарны якларга!

Нәфига. Аңламыйм, безнең паспортлар нигә кирәк булды икән аларга?!

Хасият. Безнең чын акчаларны алалар да чит илгә чыгып качалар...

Пауза.

Нәфига. Нишлибез инде хәзер? Ничек яшибез?

Хасият. Алдан ничек яшәсәк, хәзер дә шулай яшәрбез. Алданмыйча, юк-барга ымсынмыйча.

Нәфига. Син мине күралмыйсыңдыр инде, име?! Минем аркада хәләл акчаңнан коры калдың бит!

Хасият. Юк, син дөрес уйламыйсың. Син бит минем хатыным, яраткан, якын кешем, Нәфига. Исәнлек кирәк, исәнлек булса, Ходай бирер, өлешеннән калдырмас, шәт! (*Нәфиганы кочаклый.)* Борчылма, карчык... Кызга бер җүнле кияү табарбыз да үзебез авылга кайтып китәрбез. Туган нигез әле дә тора бит минем. Әзрәк йортны сипләп җибәрербез дә матур гына яшәп китәрбез. Анда без синең белән рәхәтләнеп яшибез инде: алданмыйча. Анда мондагы кебек аферистлар да, казинолар да, лохотроннар да юк... *(Кәнәфигә утыралар.)*

Нәфига *(назланып).* Рәхмәт инде сиңа, әле дә ярый син бар дөньяда, син бар — аңлаучы.

Хасият. Бу дөньяда өч кенә нәрсәдән куркам мин, Нәфига! Аферистлардан, американнардан һәм дә...

Нәфига. Нидән тагын?

Хасият. Яшеннән! Ә ясенне, әй... яшенне алдап булмый... Бәрсә, каты бәрә инде ул!

Гүзәл керә.

Гүзәл. Әни, холодильникны ачарга ярыймы?

Нәфига, куркып, Хасияткә карап куя.

Хасият. Ач, кызым, ач! Рәхәтләнеп ач! Чукынып китсен лә дөньясы! Ач! *(Нәфиганы кочаклый.)*

Телевизордан диктор тавышы ишетелә: «Бүген «Өмет» оешмасы хезмәткәрләрен кулга алдылар. Аларның эшләре судка тапшырылды...» Нәфига, Хасият аны ишетмиләр. Алар, арып, йокыга талганнар.

Гүзәл (*күзләрен ачып*). Ачасы юк — ул ачык икән инде!

Музыка.

Попугай. А Вика дур-ра! Вика дур-ра! А Чика гер-рой! Чика гер-рой! У Чики фиски... фиски... фишки... фишки!

Пәрдә.

## АТЫНДЫК БЕЗ ТАГАНДА

*Ике пәрдәле хәзерге көн вакыйгасы*

**КАТНАШАЛАР:**

Мидхәт — алыпсатар, 50 яшендә.
Энҗе — аның хатыны, ювелир кибете директоры, 53 яшендә.
Азат — аларның уллары, 16—17 яшендә.
Фәнис — Рәзинәнең улы, 21—22 яшендә.
Зарема.
Рәзинә.

Вакыйга шәһәр җирендә бара.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Сул якта шәһәрнең балалар мәйданчыгы. Комлык. Уртада зур таган. Арткы планда биек йортлар, шәһәр күренеше. Уң якта шәһәр ташпулатының зал ягы. Заманча затлы итеп җиһазланган өй кыйммәтле җиһаз, келәмнәр, бәллүр савытлар белән бизәлгән.

### БЕРЕНЧЕ ТАЛПЫНУ

Ләкин бүген хәл бөтенләй башкача төс алган. Түшәмгә эленгән затлы бәллүр люстра бер якка кыйшайган, гардероб, стенка эчләре актарылып ташланган, идәндә төрле кием-салымнар, савыт-сабалар, әйберләр чәчелеп ята. Шушы мәхшәр эчендә, кәнәфи чатына таянып, Энҗе басып тора. Кәефе кырылган, тавышы калтырап кына чыга.

Энҗе. Атасы ташлаган ятим бала кайчан да булса атасыннан үчен алмыйча калмый, дип юкка гына әйтмәгәннәр шул борынгылар. Тик нишләп соң әле бу безнең белән булды? *(Пауза.)* Гомерең буе җыйган изге малыңны ниндидер бер килмешәк килсен дә сәгать эчендә җыеп чыгып китсен әле, үләрсең хурланып! Гомердә булмаган, көтмәгән нәрсә бит бу! Оятсыз! *(Эченнән озак кына кемнедер каһәрли, тик кемне сүккәне аңларлык түгел.)*

Мидхәт керә. Ул өй алдында пәлтәсен элә башлый, тик элә алмый.

Мидхәт *(күз кырые белән генә зал ягына карап).* Кичә генә генераль уборка ясаган идек инде, тагын җыештырырга тотындыңмыни? Ничек иренмисең син, ә?!

Энҗе. Күзеңне ачыбрак кара!

Мидхәт. Ни бар? Булышырга кирәк мәллә? Ә мин шундый арыдым, ике машина товар гына озаттык бүген. Булыша алмыйм, язасы-исәплисе күп. Карале, бу пальто нишләп эленми соң, ә?! Элгече өзелгәнме соң моның? *(Пальтосын элә. Төшмәсен дип тотыбрак тора.)*

Энҗе. Күрмисеңмени?! Тизрәк кереп кара! Менә шушы инде ул — бәхетсез НЭП заманы!

Мидхәт. Аңламадым?!

Энҗе. Талаганнар безне.

Мидхәт *(пальтосын ташлап).* Ә! Кайчан? Кем? *(Залга йөгереп чыга.)*

Энҗе. Кем булсын? Кем булганы билгеле инде!

Мидхәт. Шулай да кем соң?!

Энҗе. Ә син үзең кем дип уйлыйсың?

Мидхәт. Мин каян белим. Әйт инде, сузма!

Пауза.

Энҗе. Синең улың. *(Ирония белән.)* Синең яраткан улың.

Мидхәт. Кем? Улым? Азатмы?

Энҗе. Һи! Ничек инде син улың турында шулай уйлый аласың?!

Мидхәт. Соң, үзең шулай дип торасың ич.
Энҗе. Үзе яшәгән өйне таларга башына тай типмәгәндер бит аның.
Мидхәт. Кем соң, алайса?!
Энҗе. Синең тагын кемең бар соң?! Оныттың дамыни?!
Мидхәт. Син нәрсә?! Фәнисне әйтмисеңдер ич?! Минем читтә башка балам юк, әле аны да мин чын-чынлап «улым» диеп әйтә алмыйм. Улмы әллә?
Энҗе. Шул! Дөмеккере! Нинди заманнар җитте бит, әй! Бертуган улы килеп атасын талый! Хурлык! Кешегә сөйләсәң, кеше ышанмас.
Мидхәт. Әйе. Көтмәгәндә-уйламаганда булды бит бу!
Энҗе. Ул хулиганыңнан, башкисәреңнән теләсә нәрсә көтәргә була!
Мидхәт. Нәрсәләрне алган соң?
Энҗе. Алган. Белгән нәрсә алырга кергән, башкасын белмәсә дә. Минем барлык алтын алкаларымны, көмеш беләзекләремне, бриллиант йөзекләремне урлаган, берсен дә калдырмаган. Гомуми сумма 7—8 мең долларга тарта. Белгән... юк-барга, чүп-чарга орынмаган. Ул алтын әйберләрнең берничәсе әле минеке дә түгел иде. Мин аны үзебезнең кибеттән алып кайтып куйган идем, соңрак югарырак бәягә сатып булмасмы дип уйлаган идем...

Энҗе елый.

Мидхәт. Тынычлан, борчылма, очына чыгарбыз әле...

Энҗе ава.

Энҗе! Хатын! Ни булды сиңа?! *(Энҗене күтәрә.)*
Энҗе. Су-у!
Мидхәт. Хәзер! Хәзер, әзрәк сабыр ит...

Мидхәт хатынын яткыза, аны тагын күтәрә, тагын яткыза, тагын йөгерә.

Энҗе. Су-у!!!

Мидхәт озак кына су табалмыйча интегә. Аптырагач, тере чәчәкләр куелган вазадан су салып бирә.

Энҗе *(укшып)*. У...у...у... Нинди су-у бирдең син миңа?
Мидхәт. Тынычлан. Берәр җаен табарбыз, тынычлан, ятып тор.

Мидхәт Энҗене кәнәфигә яткыза.

Менә шулай...

Пауза.

Фәнистән моны көтмәгән идем. Көтмәгән идем, билгеле. Менә ничек килеп чыга бит ул — көтмәгәндә-уйламаганда! *(Кинәт исенә төшкәндәй.)* Энҗе! Туктале! Ә син Фәнис урлаганын каян белдең соң? Бәлки, без аңа юкка гына гаеп тагабыздыр? Ә бәлкем...
Энҗе. У-ул! *(Пауза.)* Эштән кайтып кына килүем иде. Ишектә звонок бирә-бирә җан чыкты. Ачучы булмагач, үз ачкычым белән ачып кердем. Керсәм, ни күрим! Бандитың, Азатны урындыкка терәп, каеш ремень белән кулларын каерып бәйләп калдырган. Азат та куркып калмаган. Каршы торган. Теге бандит кыйнаган малаемны — күз төпләре кара янып чыккан... *(Елый.)* Бандит ул синең Фәнисең, чын бандит!
Мидхәт. Азат кая соң?
Энҗе. Милициягә хәбәр итәргә җибәрдем!
Мидхәт. Ә?! Ашыккансың, хатын, ашыккансың!
Энҗе. Ә мин нишләргә тиеш?! Көпә-көндез кереп таласыннар да, эндәшмичә калыйммы? Мин әле бөтен шәһәрне күтәрәчәкмен!
Мидхәт. Баланы чыгарып җибәрмәскә иде, аның өчен бит телефоннан шалтырату да җитә.
Энҗе. Телефонны өзеп, кисеп киткән. Сотовый синдә. Шалтырат.

Мидхәт кесә телефонын баскалап-баскалап ала да кире өзә.

Мидхәт. Әй хатын, хатын, уйлап бетермәгәнсең, хәбәр бирергә кирәкми иде.
Энҗе. Ә нигә?
Мидхәт. Ни әйтсәң дә, Фәнис — минем улым.

Энҗе. Сиңа, бәлкем, улдыр, ә миңа ул беркем дә түгел. Чит кеше. Синең белән кушылганнан соң, беренче күрүемдә үк ошатмаган идем мин аны. Мин аны башта ук яратмадым.

Мидхәт. Ул вакыт бала гына иде бит ул. Соңгы вакыт бик усалланып китте шул. Яшьрәк чагында ягымлырак, хыялыйрак иде.

Энҗе. Аның әнисе бар, әнисе тәрбияләсен.

Мидхәт. Әнисе чирле. Шулай дип ишеттерделәр.

Энҗе. Алиментын вакытында түләп килдең, тагын ни җитми инде аларга?!

Мидхәт. Шулай да ашыккансың, хатын. Үзара аңлаша алган булыр идек.

Энҗе. Аңлый торган бала түгел ул. Карале, нишләп әле син һаман шул бандит малаеңны яклыйсың, ә?! *(Торып утыра.)*

Мидхәт. Мин аны якламыйм. Ә менә милиция пычагыма да качмаган булыр иде. Файдасыннан бигрәк зыяны. Талаучыны да ачыклыйсы юк, кем икәне билгеле...

Энҗе. Синең Фәнисең, бик беләсең килсә, минем балама пычак күрсәткән, пычак белән куркыткан!

Мидхәт. Куркаграк шул безнең Азатыбыз!

Энҗе. Ай җаным! Бугазыңа пычак китереп терәсеннәр әле, нишләрсең икән?! Ул бит әле яшь, аңа уналты гына...

Мидхәт. Анысы шулай.

Энҗе. Безнең әйберләргә орынма, дигәчтен, теге бандит аңа сугып җибәргән. Баланың күз алдында барысын да җыеп чыгып киткән...

Мидхәт. Кемнән нәрсә, ә Фәнистән мин моны көтмәгән идем. Хәер, мин аны инде бер-ике ел юньләп күргәнем булмады. Начар юлда йөргәнен ишетеп белә идем. Тик менә шулай, икенче бер гаиләгә килеп, бертуган атасын талап чыгар дип башыма да китермәгән идем.

Энҗе *(торып).* Ул сиңа күптән бала түгел, ә син аңа ата түгел. Ул сине санга да сукмый. Фәнис кенә түгел монда, монда аның әнисенең, Рәзинәнең дә кулы уйнагандыр, баласын ул котырткандыр дип уйлыйм. Ух, юха елан!

Мидхәт. Тимә Рәзинәгә. Ул андый түгел. Сөйләмә аның турында...

Энҗе. Син әле аны бөтенләй белмисең. Баласын яшьтән үк урларга өйрәтә, дип, ничә кешедән ишеттем. Бөтен шәһәр белә...

Мидхәт. Җитәр, сайрама! *(Пауза.)* Көтмәгән идем. Малайдан моны көтмәгән идем!

Энҗе. Ул бандиттан хәзер барысын да көтәргә була, өеңне яндырып чыгарга да күп сорамас!

Әйберләр арасында актарынган Мидхәт язу кисәге табып ала.

Нәрсә бу? Язу... Фә... Фәнис язып калдырган...

Энҗе *(борынын җыерып).* Шантаж!

Мидхәт *(күзлек киеп).* Тәк... «Папа! Прошу меня простить, я просто надумал жениться. Твой сын Фанис».

Энҗе. Нәрсә?

Мидхәт. Нәрсә, нәрсә... өйләнергә җыена. Шул турыда хәбәр итә.

Энҗе. Ха-ха! Оригинально! Башта талый, аннан соң хәбәр итә!

Мидхәт. Тукта! Ничә яшь соң әле аңа?!

Энҗе. Инде биш ел алимент түләүдән туктадың.

Мидхәт. Егерме икеләр, димәк. Кая ашыга? Хәер, бер тапкыр әйткән иде шул очрашкач, ул чакта мин аның сүзләрен чынга алмаган идем.

Энҗе. Аны хәзер дә чынга алырга ярамый. Аның өйләнәм диюе чеп-чи ялган. Сәбәп табу, аклану гына ул. Син ышанма аңа!

Мидхәт. Өйләнер өчен акча кирәк булгандыр, күрәсең! Әнисенең инвалидлык пенсиясенә генә өйләнеп була димени хәзерге заманда?!

Энҗе. Ә мин башкача уйлыйм. *(Йөренә.)* Минем алтыннарымны акчага әйләндереп, чит илгә таюдыр әле уе. Анда ычкынса, байлыгыңны кире кайтарам димә инде. *(Башын тотып.)* Баш әйләнә... Азат милициягә барып җитте микән инде?

Мидхәт. Җитмәсә генә ярар иде. Юкка җибәргәнсең! Уйлап бетермәгәнсең! Милиция килер дә тикшерер, бу алтын әйберләрне нинди акчага, кайдан алдыгыз, дип сорый башлар. Көн кебек ачык бит: бу хан сарае да хәләл акчага салынмаган, бу байлык та хәләл акчага җыелмаган. Йөз процент үк булмаса да, туксан проценты урланган.

Энҗе. Нигә куркырга, син бит алыпсатар.

Мидхәт. Мин бит әле генә алыпсатар булдым, ә аңа кадәргесе барысы да синең кибет аркылы эшләнде. Төрмәгә тыгып куярга да күп сорамаслар, начар даның хәзер чыгар. Әйе, исен чыгармаска иде моның, кешегә белгертәсе түгел иде.

Энҗе. Дуслар аңлар...

Мидхәт. Дусларммы? Ха-ха! Дусларың шатланачак кына! Алар бит тыштан гына ихласлар, эчтән күралмыйлар алар безне, бай булганыбыз өчен күралмыйлар. Бу дөньяда, хатын, беркемгә дә ышанырга ярамый. Ярамый!

Энҗе *(каушап).* Менә... менә бусын уйлап бетермәгәнмен!

Мидхәт. Эшнең һәрчак ахырын уйлап эшләргә кирәк шул.

Энҗе. Соң, аңла, башым әйләнгән чак иде бит.

Мидхәт. Мин сине аңлыйм аңлавын...

Энҗе. Аннан, урлап җыйнаган мал, дисең, хәләл көч белән җыйганы да бардыр инде аның. Әнә гарнитурны гына ал...

Мидхәт. Моңа беркем дә ышанмаячак. Чөнки безнең илдә урлашмыйча байый алмыйсың, урлашмыйча затлы һәм кыйммәтле әйберләр алып булмый. Безнең бөтен җәмгыятебез, беләсең килсә, урлашуга, талауга корылган. Шуңа күрә дә без һаман мантый алмыйбыз инде. Ун проценты бай, туксан проценты хәерче. Аңладыңмы? *(Пауза.)* Ярар, мин Азатны эзләп кайтыйм әле! *(Кузгала.)*

**ИКЕНЧЕ ТАЛПЫНУ**

Азат керә. Күз төпләре кара янган.

Энҗе. Улым! Ай Аллам, харап кына иткәннәр үзеңне! *(Улын кочаклый.)*

Мидхәт. Улым, хәлең ничек?

Азат. Ярыйсы. Мам, мин милициягә бармадым, мам, беләсеңме?..

Мидхәт. Дөрес эшләгәнсең.

Энҗе. Әтиең дөрес әйтә...

Азат. Мам, минем кабат кыйналасым килми.

Энҗе. Милициягә бару кирәк түгел иде. Дөрес эшләгәнсең. Ә син аңардан курыкма, ул тагын бер кат кулын күтәрә калса, мин аны тиешле урынга озатачакмын...

Азат. Да, мам, мин курыкмыйм... зурга җибәрәсе килми... Ни әйтсәң дә, без бит аның белән бертуганнар, ул бит миңа брат тиешле... Фәнис Мидхатович! *(Әтисенә карап ала.)*

Энҗе. Табылды! Абый?!

Азат. Мин аның ачуын чыгардым. Әгәр мин тыгылмаган булсам, ул миңа сукмаган да булыр иде.

Энҗе. Аның сиңа орынырга хакы юк. Нинди абый булсын ди әле ул сиңа?!

Азат. Әйе, мам, безнең әтиләр бер булса да, әниләр бер түгел. Мин инде әзрәк чамалыйм ул нәрсәне, без быел мәктәптә анатомия дәресләрен үтә башладык... *(Пауза.)* Ә Фәнис монда гына йөри. Мин күрдем аны. Ул безнең йортны күзәтә...

Мидхәт. Тагын ниләр күрдең?

Азат. Аның белән тагын бер кыз да бар.

Энҗе. Шәйке!

Мидхәт. Кәләшедер инде!

Энҗе. Берәр төнге күбәләк булмаса тагын! *(Мидхәткә пышылдап.)* Бергә йоклыйлардыр әле!

Мидхәт. Син бик тирәнгә керәсең түгелме? Акрын. Бала бар. Бу бик, бик тә интим нәрсә!

Азат. Мам, мин киттем!

Энҗе. Кая?

Азат. Теге якка. «Боевик» карыйм.

Энҗе. Урамдамы?

Азат. Син нәрсә, мам, урамда түгел, видиктан...

Энҗе. Ә!

Азат икенче бүлмәгә кереп китә.

Мидхәт. Урамда «боевик», өйдә «боевик», телевизорда «боевик», кругом «боевик» — килеп терәлдек! Менә шуларның нәтиҗәсе инде бу!

Энҗе. Без, ул алтын әйберләрне сатып, яңа «Тойота» алырга тиеш идек бит.

Мидхәт. Борчылма. Без ул алтыннарны кире кайтара алырбыз. Тик тавышланып, гауга чыгарып түгел, ә җайлап кына, хәйлә белән. Мин әйләнеп керим әле, бәлкем, ул шушы йорт тирәсендә генә тулганып йөри торгандыр. *(Китәргә җыена.)*

Энҗе. Сак бул, коралланган булмасын!

Мидхәт. Борчылма, мин үз балам белән генә уртак тел таба алырмын. *(Пальтосын эләктереп, җәлт кенә ишеккә юнәлә.)* Вәт бит ничек, ә?! Көтмәгәндә-уйламаганда!

**ӨЧЕНЧЕ ТАЛПЫНУ**

Мидхәт ишекне ача. Ишек төбендә Фәнис басып тора, аның артында үк Зарема. Ул үзен бик тә иркен тота.

Мидхәт *(шаккатып).* Фәнис... у... уз әйдә!

Энҗе *(чәчрәп).* Кабахәт! Бандит! Карак!

Мидхәт. Әкрен, шаулама!

Зарема. Фәнис! Нишләптер синең әниең безне бик усал каршылый, без аңа бурычлы түгелбездер ич?! *(Ясалма.)* Исәнме, әни!

Энҗе *(шаклар катып).* Ә!

Зарема. Исәнме, әти!

Мидхәт. И... и... исәнме...

Энҗе кулын селтәп читкә кагыла. Икенче бүлмәдән Азат атылып чыга.

Зарема. Исәнме, егет!

Азат *(йөзен чытып).* Исән әле... *(Кире кереп китә.)*

Фәнис. Зарем, ялгышма, минем әнием түгел ул.

Зарема. Ничек? Син мине, әтием, әнием белән таныштырам, дип, үзең монда алып килдең түгелме соң?! *(Мидхәткә кулын сузып.)* Зарема.

Мидхәт. Мидхәт Вәлиевич... алыпсатар...

Зарема. О!

Мидхәт. Энҗе... хатыным... улымны күрдең инде... Азат...

Зарема. Сезнең белән танышуыма чиксез шатмын. Мин бик теләп сезнең белән туганлашыр идем.

Мидхәт. У... у... узыгыз! Сөйләшербез, хәл итәрбез, киңәшербез... Узыгыз өстәл янына... Энҗе...

Энҗе. Энҗе дә Энҗе. Нәрсә тыңлыйсың шуларны, ку да чыгар хәзер үк! Ничек кергән диген әле син, шундый хәлдән соң, оялмыйча! Җирбит! *(Пауза.)* Йә, нәрсә?

Мидхәт. Табын әзерлә. Чәй куй.

Энҗе. Нинди табын, нинди чәй?!

Мидхәт. Энҗе, эшлә инде әйткәнне.

Энҗе ашъягына кереп китә.

Узыгыз, утырыгыз!

Яшьләр түргә узалар. Фәнис өстәл янына килми, читкә китеп утыра. Зарема, берни дә булмагандай, өстәл янына түргә үк кереп утыра.

Мидхәт *(елмаеп).* Бүген өйдә тәртип юк, берүк кичерерсез дип уйлыйм.

Зарема. Бер юлга гына кичерербез! *(Көлеп җибәрә.)*

Фәнис *(тешен кысып).* Җитте сиңа!

Зарема. О! Мин ничек кунакка йөрергә яратканны белсәгез икән! Тик менә үзем генә кунаклар кабул итәргә яратмыйм. Чөнки кунак каршыларлык урыным юк. *(Пауза.)* Аннан соң мин әзерли, ягъни пешерә-төшерә белмим.

Мидхәт. Әйе, тормыш корып җибәргән чорда пешерә-төшерә белү дә бик мөһим.

Зарема. Нет проблем! Без ирем белән кафе, ресторannarда гына тукланачакбыз. *(Фәнискә карап.)* Шулай бит, әйеме? *(Фәниснең чырае бозыла.)*

Энҗе, йөзен чытып, поднос белән өч чынаяк чәй чыгара.

Зарема. Рәхмәт гафу итегез, ә кофе юктыр?

Энҗе. Кофены ресторанда эчәрсең инде, сеңлем, бу си- ңа ресторан түгел! Бәлки, сиңа шәраб та китерергәдер, ә?!

Зарема. Лимон китерсәгез яхшы булыр, мин чәйне лимонлап эчәргә яратам.

Энҗе *(хурланып).* Ү-ү-ләм!

Мидхәт *(аптырап).* Лимон бар бит бездә, алып кил инде, зинһар.

Энҗе. У-у-ф! *(Ашъягына кереп китә.)*

Мидхәт. Ә бәлки, ликер белән сыйларгадыр үзегезне?!

Зарема. Ликер? Смотря какой?

Фәнис. Җитте! Маймылланма!

Зарема. Яхшы. *(Пауза.)* Һинд чәеннән яхшы нәрсә юк бу дөньяда. Ух, яратам кунакка йөрергә! *(Чәй йотып куя, көлә.)*

Мидхәт. Сезне бүген артык зур кунак итеп булмас инде.

Зарема. Әйе, апайның да кәефе юк, шулай бит?!

Мидхәт. Киләсегезне алданрак белгән булсак, әзерләнеп торган булыр идек.

Фәнис. Ишегегезне дүрт йозакка бикләп куйган булыр идегез, милиция чакыртыр идегез, шулай-мы?!

Зарема. Ә сез бер дә борчылмагыз. Безнең, кияү һәм кәләш буларак, кунак буласыларыбыз алда әле. Әйтик, никах укытасы булачак, анда бәлеш ашыйсы булачак, әйтик, килен аягын, ягъни минем аякны юасы булачак... аннан инде бәби туйлары, төрле туган көннәр, тагын әллә ниләр... Кунак та кунак кына! *(Кулларын чәбәкләп.)* Как красиво!

Пауза.

Мидхәт *(ашыгыбрак).* Балалар... Ни диеп әйтергә инде?! Менә сез, яшь парлар, матур гаилә тормышы корып җибәрергә уйлагансыз...

Икенче бүлмәдән Азат атылып чыга.

Азат *(кычкырып).* Го-ол! *(Кулларын җәеп, өстәл тирәли әйләнеп чыга.)*

Мидхәт. Улым...

Азат. Пап, футбол! Италия—Югославия! Бесчастных кертте...

Мидхәт. Несчастный?!

Азат. Бесчастных, пап, Бесчастных! Наш лучший форвард! *(Кереп китә.)*

Мидхәт. Нәрсәдә тукталып калдым соң әле?.. Ә, әйе, сез бергәләп тормыш корып җибәрергә уйлагансыз икән...

Зарема. Уйлап кына калмадык, без аны тормышка да ашырдык инде.

Мидхәт. Ягъни?

Зарема. Без инде күптәннән бергә яшибез.

Мидхәт аптырап карап тора.

А это нормально. Хәзер барысы да шулай яшиләр...

Мидхәт. Әйе, яшәп карыйлар...

Зарема. Яшиләр, чын-чынлап яшиләр, ирекле яшиләр, между прочим, сездән күпкә яхшырак һәм күңеллерәк яшиләр.

Зарема торып баса.

Фәнис *(усал).* Утыр!

Зарема кире утыра.

Мидхәт. Мин бит сезне яратмыйча яшәмисез, димим, язылышып яшәргә дә кирәк, дип әйтмим.

Зарема. Язылышып, өйләнешеп кенә бәхетле була алмыйсың, кыз килеш чыгып та бәхетле була алмыйсың. Менә бит сез дә кайчандыр шулай өйләнгәнсез, аннан соң гомер буе алимент түләп торгансыз!

Энҗе *(ашъягыннан чыгып).* Ә син каян беләсең, өстерәлчек?!

Зарема. Между прочим, мин өстерәлчек түгел! Ә инде тыңлап тору — гадәтсезлек билгесе.

Энҗе. Абау, җаным! Каян килгән мулла кызы!!!

Мидхәт. Балалар! Тыныч кына сөйләшик әле, тавышсыз гына. Гомумән алганда, өйләнешү кеше тормышында олы, зур вакыйга булырга тиеш. Әгәр дә туйлар ясап, матур итеп үткәрсәк...

Зарема. Менә бу бик тә матур фикер. Сез миңа киңәш итсәгез иде.

Мидхәт. Нинди киңәш?

Зарема. Миңа туй күлмәген фата беләнме, әллә инде фатасыз гына кияргәме?

Энҗе. Туйлар буласы булган инде монда, инде аерыласы гына калган.

Фәнис. Туй була. Туй акчасына машина йә загран- путевка.

Зарема. Ә миңа тун кирәк, норка тун...

Азат атылып чыга. Барысы да сискәнеп китәләр.

Азат. Гол! Тагын керттеләр!

Мидхәт. Кем, кем кертте?!

Азат. Ананко!

Энҗе. Анаңны?!

Азат. Анаңны, димим, Ананко кертте, дим! Футболчы Ананко!

Энҗе. Ә! Мин тагын әллә нәрсә дип ишеттем!

Азат. Әй, сезне! *(Кире кереп китә.)*

Зарема. Минем таләбем шул: әгәр дә тун булмый икән... мин...

Фәнис *(Заремага).* Бар әле, син дә югалып тор әле! *(Зареманы, этеп диярлек, икенче бүлмәгә кертеп җибәрә.)*

Зарема. У-у сине! Мин сиңа чыкмыйм, бел шуны! *(Югала.)*

Фәнис Энҗегә карап куя. Энҗе ашъягына кереп китә.

Мидхәт. Утыр! Әйдәле, бер ирләрчә сөйләшеп алыйк әле!

Фәнис. Ну?! *(Утыра.)*

Мидхәт. Әгәр туй ясарга теләгең бар икән, мин сиңа бирермен.

Фәнис. Нәрсә?

Мидхәт. Акча.

Фәнис. Күпме?

Мидхәт. Күпме дип, күпме кирәк соң инде?!

Фәнис. Ә миңа күп кирәк.

Мидхәт. Ә шулай да күпме соң?

Фәнис. Акчаң җитмәс, хатының да ярдәм италмас. Нишләп әле син шулай юмартланырга булдың?

Мидхәт. Минем бурычым ул.

Фәнис. Син үзеңне авыр хәлгә куясың. Миңа бит бик күп кирәк.

Мидхәт. Хәлдән килгәнчә инде. Без синең белән килешә алырбыз дип уйлыйм.

Фәнис. Беләсең килсә, мин бит баедым инде, туй ясарга да, машина алырга да акчам бар минем хәзер.

Мидхәт. Кайчан шулай баерга өлгердең соң әле?

Фәнис. Бүген. Моннан бер өч сәгать элек кенә.

Мидхәт. Ә... аңладым. Ә нишләп урладың син ул алтыннарны, нишләп минем белән сөйләшмәдең? Алар бит хатынныкы!

Фәнис. Сине күреп, сөйләшергә теләгән идем. Тик син генә мине күрергә теләмәдең. Үзең гаепле...

Мидхәт. Без аерым яшибез. Күрешергә вакыт та тими. Ә алиментны мин вакытында түләп барырга тырыштым бугай...

Фәнис. Төкерәм мин синең алиментыңа. Миңа синең алиментың кирәк түгел, миңа әти кирәк иде, әнигә — син. Минем сиңа әти диясем килгән иде.

Мидхәт. Ә нишлим? Әйе, гаеп миндәдер, миндә. Тик мин инде әниең белән барыбер тора алмаган булыр идем. Менә бит син дә өйләнергә йөрисең, ә тормыш ул, улым, бик тә катлаулы нәрсә, әле белеп булмый...

Фәнис. Анысы минем эш. Син менә үзең өчен генә җавап бирсәң иде.

Мидхәт. Ә нәрсә?

Фәнис. Нишләп минем турында уйламадың?

Мидхәт. Син бик яшь идең әле. Әниең әйтте, бала турында уйлама, аны үзем тәрбияләрмен, диде. Кеше итәрмен, диде. *(Пауза.)* Иткән икән...

Фәнис *(торып).* Ә син?! Син бит әнинең кискән тырнагына да тора торган кеше түгел! Әнигә өйләнгәнче син бит бер беткән сәрхуш булгансың. Сине бит әни урамнан табып алган. Җылыткан, ашаткан, кеше иткән. Ә син аны авыр вакытында ташлап киткәнсең! Нәрсә, оныттыңмыни соң?!

Мидхәт. Авырды ул...

Фәнис. Авыру килеш, балалы килеш ташлагансың. Ә үзеңә җылы урын эзләп тапкансың. Безне оныткансың, безне күрергә дә теләмәгәнсең! Ә әни... *(Күз яшенә буылып.)* Ә әни минем чын кеше, чын... на самом деле...

Мидхәт. Син әле аны белеп бетермисең...

Фәнис. Әйтеп бетер! Әйт әнинең бер начар ягын! *(Пауза.)* Әйталмыйсың шул! *(Пауза.)* Әйтеп кенә кара! *(Пычак чыгара.)* Әйтеп кенә! *(Уйчан.)* Әни авырый, каты авырый, ә синең аның янына бер тапкыр да килеп караганың булмады.

Мидхәт. Килермен.

Фәнис. Ул сине көткән иде, бик тә көткән иде. Ә хәзер инде килеп тормасаң да була!

Мидхәт *(пычакка күрсәтеп).* Бу сиңа ниемә?

Фәнис. Икмәк кисәргә.

Мидхәт. Куй, яшер, кеше куркытма! Хатын куркыр...

Фәнис. Хатыныңнан бигрәк син үзең куркасың бугай әле.

Мидхәт. Ә нишләп әле мин синнән куркырга тиеш? Әтиеңә пычак күтәрергә җөрьәт итмәссең дип уйлыйм.

Фәнис *(ирония белән).* Ә-ти! Папаша! Нашелся! То же мне! *(Магнитофон төймәсенә баса.)* То же мне!

Магнитофоннан Виктор Цой тавышы яңгырый: «Отныне действовать будем мы!»

Менә ул минем әтием, минем кумир! Син түгел! Төкерәм мин сиңа!

Мидхәт. Фәнис, әкрен, тынычлан! Әйдә, ирләрчә сөйләшик. Син бит инде бала-чага түгел! Эшне шуннан башлыйбыз, син бүген үк урлаган әйберләрне кире кайтарып бирәсең!

Фәнис. Хәзер! Тот капчыгың!

Мидхәт. Әгәр мин әйткәнне тыңламасаң, мин сине милициягә тапшырырга мәҗбүр булачакмын! Мине килеп таларга синең хакың юк!

Ашъягыннан Энҗе атылып чыга.

Энҗе *(чәчрәп).* Күптән шулай диясе аны! Хәзер милиция чакыртам! Хулиган! Карак!

Энҗе кесә телефонына ташлана. Фәнис телефонны бәреп вата.

Энҗе. Ә?!

Мидхәт. Фәнис, шаярма! Әйт, алтыннар синдәме?

Фәнис. Миндә, өйдә...

Мидхәт. Алар синең кесәңдә булса кирәк.

Фәнис. Каян килеп?

Мидхәт. Бүлтәеп тора.

Фәнис. Әгәр шунда дип уйласаң, ал, мә!

Мидхәт Фәнис каршына килә.

Энҗе. Мидхәт, әкрен, сак бул!

Фәнис әтисенең күкрәгенә пычак тери.

Мидхәт. Кадар идеңме?

Фәнис. А запросто!

Азат атылып чыга.

Азат. Шайтан! Өченче голны санамадылар! Ну судья... *(Мондагы хәлне күреп, кире керә.)*

Зарема чыга.

Зарема. Яратмыйм шул футболны! *(Боларны күреп.)* Ой, монда да футбол!

Мидхәт. Син? Мине?

Энҗе. Мидхәт, сак бул, кадый күрмәсен, аңардан барысын да көтәргә була.

Мидхәт. Әниең дә үзенә күрә түгел: һаман горур кеше булып кыланды! Горур хәерче!

Фәнис. Әни турында бер начар сүз дә әйтмә, ишеттеңме! *(Сизгерлеген югалтып, читкә тайпыла.)* Әйтмә!

Мидхәт Фәнискә барып асылына. Аның кесәсенә керә.

Мидхәт. Чыгар! Хәзер үк!

Фәнис. Мә!!!

Фәнис, борылып, әтисенең җилкәсенә пычак белән кадап ала.

Зарема. Фәнис! Ты че?!

Энҗе *(төсе бетеп).* Ай! Үтерделәр! Каравыл!

Азат атылып чыга.

Улым! Әтиеңне үтерделәр!

Азат *(битараф).* Их, шул футболны да тыныч кына карап булмады!

Фәнис чыгып китә. Зарема аңа иярә.

Энҗе. Мидхәт, нишләтте ул сине, нишләтте сине ул бандит?!

Мидхәт. Кычкырма! Әле бик үк зыянлы кебек түгел!

Энҗе. Ничек инде? Ул бит сиңа кадады! Улым! Чакыр «скорый»!

Азатның бер күзе — әтисендә, бер күзе — телевизорда.

Тиз бул! Әй Аллам, кан ага бит, кан...

Азат. Ә кая телефон?!

Энҗе. Телефонның берсен өзде, икенчесен ватты. Бар, урамнан, автоматтан шалтырат.

Азат чыга башлый.

Мидхәт. Сабыр, сабыр. Берүк милиция генә чакыртмагыз, ишеттегезме?!

Энҗе. Аңладык, аңладык, әйдә, ят, менә шулай... *(Яткыра.)* Ят, кадерлем, хәзер мин бинт табып бәйләрмен... *(Чыга.)*

Азат *(икенче бүлмәгә күз салып).* Беренче тайм тәмам...

Энҗе *(чыгырыннан чыгып).* Бар! Чакыр!

Азат *(йөзен җыерып).* Хәзер! *(Чыга башлый.)*

Энҗе *(хәле китеп).* Ай Аллам, нинди көн булды соң бу, нинди көн?!

Энҗе, ялгышып, магнитофон төймәсенә баса. Аннан баягы «Отныне действовать будем мы!» көе яңгырый. Энҗе бар көченә төймәгә баса,
суга. Магнитофон туктамый, һаман уйный.

Азат. Видимо... заело...

Тынлык.

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ ТАЛПЫНУ

Берничә атна узган. Шул ук декорация. Зал ягы җыештырылган, чистартылган. Сәхнәнең сул ягындагы мәйданчыкта бер агач эскәмия, балалар уйный торган комлык, асылмалы таган. Зарема, авыз эченнән нидер көйли-көйли, таганда атына. Фәнис сигарет кабызган. Йөткереп куя. Бер Заремага, бер өй ягына карапторa. Җиһанда көзге моңсулык.

Фәнис. Туймадыңмы?

Зарема. Нидән?

Фәнис. Атынудан.

Зарема *(көйләп).*

Уйнадык җәй буе,
Таганда атынып.
Очтык без болытка,
Кошлардай талпынып.
Очтык без болытка
Кошлардай талпынып...
Күз җитте. Һәм очты
Күньякка кыр казы.
Ә таган моңаеп
Калды бит ялгызы.
Ә таган моңаеп
Калды бит ялгызы...
Таганда атынып,
Кошлардай талпынып
Очтык без болытка,
Очтык без болытка.
Таганда атынып,
Кошлардай талпынып...*

Фәнис, моңга бирелеп, Зареманы таганда атындыра. Кочаклый. Үбә.

Фәнис. Таганда атыну ул — талпыну. Әллә кая — чиксезлеккә, биеклеккә. Тормыш та бит таганда атыну кебек: ул сине бер күккә чөя, бер җиргә төшерә. Әнә шулчак сынатмаска, ныграк тотынырга, ныграк этелергә, мөмкин кадәр биеккәрәк очарга кирәк... бу тормышта...

Зарема. Философ, ей-богу! Ә мин менә туйдым бу тормыштан.

Фәнис. Нидән?

Зарема. Хәерчелектән.

Фәнис. Ә син хәерчемени?

Зарема. Ә кем соң мин? Әни алкаш, әти алкаш. Минем өйгә дә кайтасы килми. Кайтсаң, акча таләп итәләр. Мин аларны күралмыйм!

Фәнис. Синең бит аларны юньләп күргәнең дә юк. Танышканнан бирле миндә торасың!

Зарема. Күпсенәсеңме?

Фәнис. Юк. Сезгә бит бар да тиз генә булсын: акча, байлык, кияү, комфорт. Ә ул тиз генә тәтеми шул, малышка.

Зарема. Менә шуңа күрә дә мин илемне дә, халкымны да, гаиләмне дә сөймим.

Фәнис. Син бик матур сөйләргә өйрәнеп киттең әле! Әгәр дә безнең урамга бәйрәм килсә, нишләр идең?

Зарема. Безнең урамга беркайчан да бәйрәм килмәячәк.

Фәнис. Борчылма. Бар да о’кей булыр!

Зарема. О’кей? Кайчан?

Фәнис. Менә бүгеннән!

Зарема. Син алтыннарны саттың мәллә?

Фәнис. Юк.

Зарема. Ә нигә сатмыйсың?

Фәнис. Мин аларны сатмаячакмын.

Зарема. Кире аларга бирәсеңме?

Фәнис. Бирәм. Алар әтинекеләр. Дөресрәге, Энҗе апаныкы.

Зарема. Дөрес эшләмисең кире биреп. Алтыннарны долларларга әйләндерергә дә чит илгә таярга кирәк.

Фәнис. Каян килеп керде сиңа шундый хыял — чит ил дә чит ил. Минем анда булганым юк. Мине анда беркем дә көтеп тормый.

Зарема. Кулыңда акчаң булса, юкка чыкмыйсың, ди, анда.

Фәнис. Әнине авыр хәлдә калдырып, чит илгә кача алмыйм.

Зарема. Әниеңә озак яшәргә калмаган, йә бүген, йә иртәгә...

Фәнис. Ә син аның үлгәнен көтәсеңме?

Зарема. Көтмим. Тик язмыштан узып булмый. Яшәрлек түгел бит, өметсез.

Фәнис. Күпме әйткәнем бар... *(Зареманы йолкып ала.)* Минем әни турында авыр сүз әйтәсе булма, дип...

Зарема. Ә нәрсә әйттем соң?!

Фәнис Зареманың кулын борып ала.

Ай! Кулны сындырасың! Җибәр, придурок! *(Таганнан егылып төшә.)*

Фәнис таганга тибеп җибәрә. Зарема башын иеп кала.

*(Елап.)* Придурок...

Фәнис *(торгызып).* Кызу чакка туры килдең, кичер! Утыр! *(Эскәмиягә утырта.)* Бүген әткәй белән ачыктан-ачык сөйләшергә вакыт җитте! Ул безнең туйга акча бирәм, дип вәгъдә иткән иде. Аның байлыгында минем дә өлешем бар. Закон буенча, билгеле. Мин дә аның малае бит.

Зарема. Аның икенче малае — Азаты бар. Сиңа караганда, аның хокуклары күбрәк түгелме?!

Фәнис. Төкерәм! Шарт куям: йә акча, йә... Аңладың?! *(Пауза.)* Дөрес аңла, мин талап алмыйм, мин тиешлесен генә алам.

Зарема. План әйбәт. Болай булгач, безгә чит илгә юл ачыла инде!

Фәнис. Ниемә? Нәрсәң калган анда?

Зарема. Ул — минем хыялым! Чиксез зур хыялым! Минем дәү әнием бар иде, мин аны бик тә ярата идем. Күрәзәче иде ул, мәрхүмә инде, үлде. Ул миңа: «Синең илең хәзерге туган илең түгел, чит ил — синең туган илең», — дия торган иде. Минем «Уолт-Дисней»да буласым, Голливудны күрәсем килә, Канар утрауларында ял итәсем килә...

Фәнис. Нишләп сез шулай тиз алданасыз икән, ә?! Сезне бит сагыз белән дә алдарга була!

Зарема. Мине түгел. Ә син чит илгә китү турында уйламыйсыңмыни?

Фәнис. Юк, мин әни турында уйлыйм. Ул бик каты авырып калды. Озак йөрмәвемне сорады. Мин хәзер өйгә әни янына кереп чыгам. Аннан соң тагын монда килермен. Болар белән ныклап сөйләшергә кирәк булыр. Киттек!

Зарема. Юк!

Фәнис. Аңламадым?!

Зарема. Минем сезгә кайтасым килми. Әллә ничек кенә анда?

Фәнис. Авырудан курыктыңмы?

Зарема башын аска ия.

Син, алайса, беркая да китмә, мин тиз генә өйдән әйләнеп киләм. Әнине күреп... нишли икән?

Фәнис китә башлый.

Шунда гына утыр!

Зарема. Фәнис!

Фәнис. Ә?!

Зарема. Мин сине яратам, Фәнис! Фәнис! *(Фәнисне кочаклый.)* Мин сине беркемгә дә алыштырмам, тик син мине ташлый күрмә, яме?!

Фәнис. Зарем! Вакыты ул түгел, әнине күрергә кирәк. Пока! *(Китеп бара.)*

Зарема. Аннан соң, соң булырга мөмкин, придурок! Соң! Үзеңә үпкәлә! Без бит бүген дискотекага барырга тиеш идек! Эх! Һаман шул бер пластинка: әни, әни! Нинди әни булгандыр инде ул?! *(Көйләп.)* «Әле дә ярый син бар бәхетемә, әле дә ярый син бар дөньяда!» Ха-ха-ха!

**ИКЕНЧЕ ТАЛПЫНУ**

Азат чыга. Колагына наушник аскан, музыка тыңлап килә.

Зарема. Әй, җегет! Ишетмисең мәллә?! Музыка тыңлап, чукрак каласың бит инде!

Азат *(танып).* Ә! Таныш апайны күрәм. Ә кем кая?

Зарема. Кем?

Азат *(ирония белән).* Тип?

Зарема. Тип? Ул тип сиңа абый тиешле түгелме соң?

Азат. Тагын кем?

Зарема. Ну ярар. Ә тип юк, тип китте.

Азат. Китсә, бик әйбәт. Мин дә киттем...

Зарема. Тукта. Кая ашыгасың?

Азат. Монда гына...

Зарема. Кил әле минем яныма!

Азат *(янына килеп).* Килдем.

Зарема. Бала. Нишләп син шундый оялчан, ә?

Азат. Артык кыю булырга әти белән әни кушмый.

Зарема. «Әниең баласы» инде син. Ә нигә кушмый?

Азат. Кызлар белән йөрсәң, акча бик күп китә, ди. Алар бик тә талымсызлар икән... хәзерге кызлар...

Зарема. Ха-ха! Әниең сиңа бөтенләй акча бирмимени?

Азат. Бирә. Җитәрлек бирә. Тик мин «Сникерс»ларга тотып бетерәм. Видеокассеталар алам, хоккейга йөрим...

Зарема. Кызларга бүләк тә алганың юкмы?

Азат. Бүләк алып, бүләк итәрлек кыз очраткан булмады...

Зарема. Кызлар сиңа карамый дисең инде?! Нәрсә, үбешкәнең дә булмадымы?

Азат. Юк.

Зарема. Ә син ничё егет! Кил, үзем сине пәп итәм!

Зарема Азатны кочаклап үбә.

Азат. Тип нәрсә әйтер?

Зарема. Тип берни дә әйтмәс, чөнки берни дә белмәс.

Азат *(утырып).* Ну ярар... *(Музыка тавышын көчәйтә, музыка ритмына ияреп чайкала.)* На-на-на...

Зарема. Син кемне тыңлыйсың?

Азат. «Кисекбаш» төркеме.

Зарема. Ә нинди төркем ул? Нәрсә җырлый алар?

Азат. Татарча рок!

Зарема. Татарча рок була димени?! Бер дә ишеткән юк!

Азат. Соң, мә, тыңлап кара!

Азат наушникны Заремага кидерә. Музыка тавышы көчәя.

Төркем *(җырлый).*

Нигә без шундый хәлгә төштек,
Нигә без һаман артта?
Без — бәхетле илдә, дибез,
Хәерчеләр генә арта!
Язмыштан ачы каһәр төште,
Кушылды каннар канга,
Иман сатып, денен саттык,
Милләтне сукмый санга.
Нигә без шундый хәлгә төштек,
Нигә дөньясы шакшы?
Нигә соң без бәдрәф кошы,
Нигә чит илдә яхшы?!

Зарема. Шәп! Бигрәк тә менә монысы — «Нигә соң без бәдрәф кошы, нигә чит илдә яхшы?!» дигәне ошады. *(Пауза.)* Азат, ә синең чит илгә чыгасың киләме? Нью-Йоркны, Парижны, Луврны күрәсең киләме?

Азат. Килә. Әти алып барырга вәгъдә итте. Тиздән барырбыз да, мөгаен.

Зарема. Юк. Барып кайтырга гына түгел, ә анда яшәргә?

Азат. Килә, билгеле. Тик акча кирәк.

Зарема. Ә син таба аласыңмы?

Азат. Әнидән алсам гына!

Зарема. Сорап?

Азат. Сорап бирмәс! Урлап алырга кирәк!

Зарема. Урлап?! Ә син булдыра алмассың!

Азат *(егетләнеп).* Ә нишләп булдырмаска? Фәнис талап алды бит әле! Болай — баеды! Сораучы да юк хәзер! Ә миңа һаман шул шоколадка гына бирәләр. Мин акчаның кая ятканын беләм, әни үзе бер тапкыр күрсәткән иде. Хәзер керәм дә алам! *(Урыныннан кузгала.)*

Зарема *(туктатып).* Юк, юк, матурым, хәзер үк түгел, бераз соңрак! *(Як-ягына каранып ала.)*

Азат. Нигәдер синең өчен минем барысын да эшлисе килә!

Зарема. Андый егетләрне мин бик тә хөрмәт итәм, рәхмәт, үскәнем!

Азат. Син миңа ошыйсың! Йөр минем белән! Ә теге типтан ераграк бул!

Зарема. Фәнисне яратмыйсыңмы? Кыйнаган өченме?

Азат. Юк. Яшәгәне өчен! Сүз гел шуның турында гына! Гел шуны гына сөйлиләр, ә мин как будто бу дөньяда юк! Минем барысыннан да үч аласым килә! Ә Фәнис мине күралмый, миннән көнләшә! Мине, бай малае, ди... Тфү! Тип!

Зарема. Борчылма, вакыт җитәр. Фәнистән үчеңне алырсың. Әгәр дә синең минем өчен яхшылык эшлисең килсә, мине дискотекага алып бар. Рәхәтләнеп күңел ачарбыз! Шәраб эчәрбез... Пофлиртуем... Ризамы?

Азат. Билгеле.

Зарема. Әй, матурым! *(Азатны үбә.)* Киттек! *(Китәләр.)*

Фәнис керә.

Фәнис. Зарема! *(Пауза.)* Кая син? Әйттем бит инде беркая да китмә, дип, көтеп тор, дип! *(Эзләп китә.)* За-ре-ма! *(Уйланып тора.)* Әни, әни... Китәсең бит... җаным...

Караңгылык.

**ӨЧЕНЧЕ ТАЛПЫНУ**

Мидхәтләрнең өй эчендә ут яна. Җилкәсе бинт белән чорналган
Мидхәт, кәнәфигә ятып, газета-журналлар карап утыра.

Энҗе *(ашъягыннан).* Мидхәт! Кил чәй эчәргә!

Мидхәт. Хәзер. Бер бик тә кызыклы, гыйбрәтле язма укып утырам. Әйе, ни генә юк бу дөньяда! Бер ир бала әнисен кыйнап үтергән, таяк белән кулларына сугып...

Энҗе. Алла сакласын инде!

Мидхәт. Беләсеңме ни өчен үтергән?!

Энҗе. Беләсем дә, ишетәсем дә килми, бигрәк әшәке заманда яшибез!

Мидхәт. Әнисе баш төзәтергә акча бирмәгән.

Энҗе. Ерак китәсе юк, үзеңнең улың да нишләтте соң үзеңне?! *(Ашъягыннан чыгып.)* Мә, чәеңне монда алып чыктым, чәй эчеп ал!

Мидхәт. Мин исән бит әле, исән.

Энҗе. Исән инде, исән. Исән калган, имеш. Ой, шул бандитны яклап гомереңүзды инде!

Мидхәт. Син дә хаклы. Тик Фәнисне дә аңларга була. Ятим иттем мин аны. Атасыз үсүе җиңел түгел ул. Атасыз үсүнең нәрсә икәнен беләм мин. Үзем дә бик иртә әтисез калдым. Шуңа күрә исән килеш тә оныттым.

Энҗе. Жәлләп утырмале шуны!

Мидхәт. Бөтенләй үк тискәре егет дип әйтмәс идем мин аны, яхшы яклары да юк түгел үзенең! Әйтик...

Энҗе. Булды! Җитте! Кайсы ягы белән яхшы булсын ди ул?! Талап чыкты үзеңне, чак кына үтермәде.

Мидхәт. Артык кырысрак булдым. Мин бит аны үзем шундый хәтәр адымга этәрдем.

Энҗе. Малаемны кыйнады, теге фахишәсен алып кереп, бездән мыскыл иттерде! Шул бандитыңны «яхшы бала» диеп әйтергә ничек телең бара?!

Мидхәт. Анасы өчен гарьләнә, бимазалана. Анасы турында ялгыш авыр сүз ычкындырсаң, чыгырыннан чыгарга тора. Бичара...

Энҗе. Уф! Таптың бичара!

Мидхәт. Анасыннан да якын кешесе юк бит аның. Әле синең малаеңның да...

Энҗе. Ә нишләп минеке генә, синеке түгелмени?

Мидхәт. Әйе, безнеке. Аның да кем буласы билгеле түгел, укырга теләге юк, бар белгәне акча сорау!

Энҗе. Ул талап алмый, сорап кына ала. Сизәм, син Азатка караганда Фәнисеңне күбрәк яратасың бугай!

Мидхәт. Минем әле алай дип әйткәнем булмады.

Энҗе. Азат үзе дә шулай ди. Әти мине яратмый, гел Фәнисне генә уйлап йөри, ди. Рәзинәңне күбрәк яратасың, димәк, шуңа карап Фәнисеңне дә!

Мидхәт. Азатның проблемалары аз, ул җылы канат астында яши. Ә Фәниснең әле...

Энҗе. Мин берни дә белмим! Кайчаннан бирле безнең алтыннарыбызны кайтармый. Минем инде түземлегем калмады, шалтыратам...

Мидхәт. ...Милициягә, шулаймы? *(Пауза.)* Утырасың киләмени?

Энҗе. Утыртсыннар. Ә мин докажу...

Мидхәт. Ә нәрсә докажешь? *(Пауза.)* Көтәргә кирәк. Ул үзе китерәчәк.

Энҗе. Көт!

Мидхәт. Көтәргә кирәк. Мин аның китерәчәгенә ышанам.

Энҗе. Алган алтыннарымны кире кибеткә кайтарасым бар.

Мидхәт. Алтын урынына акча кертеп тор.

Энҗе *(кызып).* Карале! Син аның белән, уйнаштан туган улың белән, бер мафиядә түгелсеңдер ич, ә?! Сез, аталы-уллы, бергәләп таларга киңәшләштегез мәллә?!

Мидхәт. Әйе, нәкъ шулай!

Энҗенең күзләре шар була.

Ха-ха-ха! Тәки ышандың, ә! Ха-ха!

Энҗе. Ташлале шул юләрләрчә көлүләреңне! Сөймим!

Мидхәт. Син, Энҗебикә, гомерең буе акчага табынып яшәдең, син хәзер үз-үзеңне аңламаслык хәлгә җиткәнсең.

Энҗе. Син үзеңне белер идең. Миңа өйләнгәндә кем идең соң син? Син әле миңа рәхмәт әйтергә тиеш!

Мидхәт. Әйе, мин сиңа бик тә рәхмәтлемен. Син миннән менә дигән алыпсатар ясадың. Шул гына!

Энҗе. Өйләнгәнеңә үкенәсең мәллә инде?

Мидхәт. Юк, үкенмим, минем өчен кәҗә үкенсен!

Ишектә кыңгырау тавышы.

Улың Азат кайтты бугай, ач!

Энҗе. Әле генә киткән иде бит, шулай тиз кайттымыни соң?

Мидхәт. Берәр нәрсәсен онытып калдыргандыр, ач. Кара аны, сөйләшкәннәр безнең арада гына калсын! Безне аның белән дә сугыштырма тагын!

Кыңгырау тавышы кабатлана.

Энҗе. Хәзер! Хәзер, матурым! *(Ишекне ача.)* Ах!

Фәнис керә.

Син?! Нәрсә, тагын үтерергә килдеңме?

Фәнис. Миңа узарга ярыймы?

Энҗе. Юк, ярамый.

Мидхәт. Кем анда?

Фәнис. Апай, мин беркемне дә үтерергә дип килмәдем.

Энҗе. Нәрсә өчен килдең?

Фәнис. Гафу үтенергә дип.

Энҗе. Синең гафу үтенүең миңа ниемә! Син кайчан минем алтыннарымны китерәсең, ә?!

Фәнис. Миңа әти белән сөйләшеп алырга кирәк.

Энҗе. Синең әтиең юк монда, ул сиңа әти түгел!

Мидхәт *(Фәнисне күреп).* Ә! Керсен! Фәнис, кил монда, кер!

Фәнис түргә уза.

Безнең икебезне генә калдыр әле, Энҗе!

Энҗе. Юк. Мин икегезне генә калдыра алмыйм! Куркам!

Мидхәт *(Фәниска).* Утыр, мин тыңлыйм сине!

Фәнис. Мин өйләнәм, дип әйткән ием бит, өйләнгән очракта тиешлесен алырсың, дип вәгъдә биргән идең...

Мидхәт. Соң, әйе инде...

Фәнис. Әгәр дә өйләнмәсәм нәрсә?

Мидхәт. Өйләнмәскә булдыңмыни соң?

Фәнис. Әйтик, әгәр дә өйләнмәсәм?!

Энҗе. Өйләнсәң дә, өйләнмәсәң дә, берни юк сиңа!

Мидхәт. Энҗе, син безне калдырып тор әле!

Энҗе. Сөйләшегез, сөйләш, мин беркая да чыкмыйм, менә шунда гына утырып торам. *(Утыра.)*

Фәнис. Син миңа тиеш!

Энҗе. Ха! Каян килеп?!

Фәнис. Мин дә наследник.

Мидхәт. Ә, менә нәрсә! Наследник бер син генә түгел, минем тагын бер улым бар. Аннан соң без исән бит әле, без әлегә үлмәгән.

Фәнис. Сез үлгәнче, барысын да хәл итеп куярга кирәк. Аннан соң мин сезнең үлгәнегезне көтеп тора алмыйм, миңа тиешлесен хәзер үк бирсәгез иде.

Энҗе. Ай-яй! Акылың алтын икән! Алдың бит инде үзеңә кирәгеңне: алтыннар синдә. Инде тагын ни кирәк сиңа?!

Фәнис. Әйе, алдым. Тик мин аларны талап алдым. Ә миңа талап алынган байлык кирәкми. Мин аны кире кайтарырмын. Миңа ул акчаны сезнең үз кулыгыз белән бирү кирәк, аңлыйсызмы?

Мидхәт. Ә син акча белән нишләргә уйлыйсың?

Фәнис. Анысы минем эш.

Энҗе. Әгәр без хәерче булсак, син монда килеп йөрмәс идең, билгеле!

Фәнис. Ничек кенә! Бәлкем әле сезнең белән бергә яши дә алган булыр идем.

Энҗе. Инде шул гына җитмәгән, син кемгә кирәк соң? Уф, үләм!

Мидхәт *(торып).* Җитте! *(Фәнискә.)* Син бар кайт, мин аңладым сине. Бу мәсьәләне бер көндә, бер сәгатьтә генә хәл итеп булмый. Кайт, без уйлашырбыз!

Фәнис. Сузарга кирәкмәс иде, миңа бик тә кирәк.

Мидхәт. Ярар. Бүген хәл итәрбез. Иртәгә керерсең.

Фәнис, башын түбән иеп, ишеккә юнәлә.

Әниеңнең хәле ничек? *(Пауза.)* Нигә җавап бирмисең?

Фәнис. Хәле? *(Кәефсез.)* Ярый... әлегә... *(Еламсырап.)* Яши әле...

Мидхәт. Ни булды сиңа?

Фәнис. Юк, болай гына. Синең бит бервакытта да әнинең хәлен сораганың булмады.

Энҗе. Ә син әтиеңнең хәлен килеп сорадыңмы соң? Әтиеңне чак үтермәдең...

Фәнис. Хушыгыз... *(Чыгып китә.)*

Мидхәт. Нәрсә булган бу балага?

Энҗе. Белмим инде. Ни белән бетәр бу юлдан язган малаеңның кыланышлары?! Наследник, имеш. Авыз тутырып сөйләшкәнен күр әле син аның! Әле әнисе булсам бер хәл.

Мидхәт. Да-а. Син гомерең буе минем беренче хатыным Рәзинәдән көнләшеп яшәдең.

Энҗе. Әй! Нәрсәсеннән көнләшим инде аның, бетеннәнме?!

Мидхәт. Көнләштең. Ә бит мин сине көнләштерерлек бер генә яман эш, бер генә артык адым да ясамадым шикелле. Барып йөрмәдем, малайны монда ташымадым. Алар турында хәтта сүз дә кузгатмадым. Рәзинәнең барлыгы сине тыныч кына яшәтмәде. Син инде күптән аның үлемен телисең. Теләгеңә ирешәсең дә бугай. Рәзинә үлем хәлендә ята. Фәнис һаман нидер яшерә. Барып килергә кирәк миңа аның янына. Минем уйлавымча, ул авыр хәлдә. Бәлкем, берәр ярдәм кирәктер үзенә.

Энҗе. Каян беләсең?

Мидхәт. Сизенәм. Нидер яшерә Фәнис, әйтеп кенә бетерми. Артык горур. Нәкъ әнисе күк. Яшерә, артыгын сөйләми. Ул безне, ә без аны аңлап бетерә алмыйбыз.

Энҗе. Тагын берәр этлек эшләргә йөри торгандыр әле, аңардан көтәргә була. Ә ярдәмгә килгәндә, алтыннарны китерсен, китерми торып, ярдәм итмә... *(Пауза.)* Ай, арыдым. Йокларга вакыт. Сиңа кая җәйим?

Мидхәт. Тыныч йокы. Мин монда, залда гына...

Энҗе. Бик күп уйланма. Врачлар кушмый. Ишекне икенче йозакка бикләп тормыйм. Азатның ачкычы бар, үзе ачып керер. Тыныч йокы! *(Мидхәткә мендәр, юрган ташлап, икенче бүлмәгә кереп китә.)*

**ДҮРТЕНЧЕ ТАЛПЫНУ**

Караңгылык иңә. Мидхәт, абажур утын гына калдырып, кәнәфигә чүгә. Моңсу көй агыла. Шушы сәер, моңсу караңгылыкта Рәзинә пәйда була. Яшь чагы. Матур, пөхтә киенгән.

Рәзинә. Исәнме, Мидхәт. *(Пауза.)* Мин синең тавышыңны, аһәңеңне ишетеп килдем. Син миңа тартыласың, һаман мине чакырасың. Килдем мин, әйт сүзеңне!

Мидхәт *(саташыбрак).* «Әйтер сүзең әйтеп кал». Ие... Рәзинә, Рәзинә, син әле шундый яшь, чибәрсең... Ә мин инде менә картаеп киләм...

Рәзинә. Син ялгышасың. Син бит мине һаман да шулай яшь, чибәр килеш кенә хәтерлисең. Син бит мине һаман да шул килеш яратасың, Мидхәт! Юллар аерылышкачтын, син миннән читләштең, мине күрергә теләмәдең. Ялгыш кына очрашканда да, тиз генә исәнләшеп, читкә борылып китеп бара идең. Рәнҗесәм дә үпкәләми идем. Син Фәнисне яраттың, аны гына күрергә теләдең. Ләкин ул үсә башлагач, аңардан да йөз чөерә башладың...

Мидхәт. Мин Фәнисне ярата идем. Бала булганга ярата идем. Тик яратуымны аңа барыбер аңлата алмадым...

Рәзинә. Чөнки син аңардан һәрчак югары булырга тырыштың. Ә баладан югары булып булмый, ул бит безнең дәвамыбыз. Безнең мәхәббәтебезнең җимеше ул, без бит бер-беребезне бик тә ярата идек. Тик соңрак... син ул яратудан ояла башладың... Ә мин сине оныта алмадым, мин син бар дип яшәдем... Кил, кил бире! *(Кулларын суза.)* Кил... Танцплощадкада вальс биегәнне оныттыңмыни соң? Бергә вальс биегәнне?! Хәтерлисеңме?

Мидхәт. Юк, хәтерләмим... Көе хәтердә кебек... көе...

Рәзинә. Әйе, көе дә матур... *(Көйләп.)* «Бу тәүге сөю, тәүге мәхәббәт, миңа нишләргә, әйт, дускаем, әйт...»

Рәзинә, Мидхәт вальс ритмында бер-берсенә тартылалар. Куллар бергә тоташа. Бииләр. Арткы планда Азат күренә. Ул аларны күрми. Кача-кача керә дә, шүрлектән акчаларны алып, кесәсенә тутыра. Китмәкче була. Тик тукталып кала. Кулына кәгазь алып нидер сырлый да сумкасын күтәреп, җылы курткасын эләктереп чыгып чаба.

Мидхәт. Рәзинә, кичер мине, әгәр дә кичерә алсаң...

Рәзинә. Кеше иң элек үзен кичерә алырга тиеш, үзен кичерә алса гына ул кеше булып кала ала.

Мидхәт. Мин синең алда гаепле, Рәзинә.

Рәзинә *(читләшеп).* Әйе, син мине ташладың. Юкка сәбәп табып, корсаклы килеш, исерек баштан кыйнадың. Юк өчен генә дә баланы тотып кыйный идең. Беләм, мин барын да беләм: минем өстән йөрдең. Ләкин безнең хакка, балам хакына түзә килдем...

Мидхәт. Нинди кешене югалтканымны мин бит соңыннан гына аңладым. Кешегә акыл соңлап кына килә. Мин сине күрергә атлыгып тордым, мин сиңа тартылдым. Миңа хатын ирек бирмәде. Ә мин курыктым, мин икенче тормышымны җимерүдән курыктым...

Рәзинә. Димәк, синең икенче тормышың беренчесенә караганда җайлырак, синең өчен кулай булган. Хатыныңнан түгел, син аның байлыгыннан курыккансың. Бай яшәргә һәркемнең дә хакы бар. Тик бу очракта байлык сине сукырайткан, сине алдаган... Син алдангансың, сине алдаганнар. Бай хатынга өйләндең, бай хатынны югалтып, байлыгымнан колак кагармын дип курыктың. *(Көйләп.)* Кайда очты безнең хыяллар, кайда калды яшьлек җилкәне, ах, без бушка гомер үткәрдек, дөнья кудык, дөнья җитмәде...

Мидхәт *(көйләп).* Әйе, әйе, дөнья кудык, дөнья җитмәде. Дөрес... Менә монысы дөрес... Тик бәхет китердеме соң ул миңа? Байлык кына күңелне җылыта алмый. Салкын миңа, шыксыз... Күңелдә бушлык, бушлык... Нәрсә өчен яшибез? Кая барабыз? Бетәбез бит, бетәбез...

Рәзинә. Сынган канатларны ялгаучы, күңелгә көч бирүче бер генә нәрсә бар, ул да булса ярату, мәхәббәт...

Мидхәт. Миндә ул юк, миндә ул сүнгән инде.

Рәзинә. Ә мин аны саклыйм, ул — минем бердәнбер өметем, җан сулышым...

Мидхәт. Кичер... мин саклый алмадым... Мин синең алдыңда мең-мең бурычлы, Рәзинә. Әгәр син мине коткармасаң, сәрхуш хәлендә салкын карда аунап яткан җиремнән өеңә өстерәп алып кермәсәң, җылы сулышыңны өрмәгән булсаң, мин хәзер синең каршыңда басып тора алган булыр идемме соң?! Син мине коткардың, син! Советлар Союзының юлдан язган бер баласы идем бит мин. Ул режим мине

таптап изгән иде... Ә син үзеңнең зәгыйфь, назлы кулларың белән мине әнә шул упкыннан тартып алдың да җан сулышы өрдең... Рәхмәт сиңа, чиксез рәхмәт. *(Тезләнә.)* Син минем коткаручым, син! Энҗе дә, аның дуслары да түгел. Син! Тик менә кадереңне генә белә алмадым. Бай, рәхәт тормышка алданып, сиңа, безнең мәхәббәткә хыянәт иттем...

Рәзинә. Кичерүне миннән түгел, Ходайдан сорарга кирәк.

Пауза.

Мидхәт *(дога кылып).* Мин барын да аңлыйм. Тик бер генә нәрсәне аңлап җиткермим: ни өчен Фәнис синең яклы, ни өчен сине генә ярата?!

Рәзинә. Көнләшергә кирәкми. Ул мине, мин аны яратам. Көнләшмә. Мин аңа бар булган сәләтемне, көчемне бирергә тырыштым, ятим булып үсүен теләмәдем. Менә шул гына...

Мидхәт. Кичер, Рәзинә...

Рәзинә. Ходай кичерер, без барыбыз да иртәме-соңмы аның каршына барачакбыз... Хуш...

Мидхәт *(торып)*. Кая? *(Каранып.)* Рәзинә!

Рәзинә. Хуш... бәхил бул, Мидхәт... *(Тавыш ерагая, илаһи тавышка әверелә.)*

Мидхәт *(елап).* Рә... зи... нә...

Караңгылык. Ишектә кыңгырау тавышы.

**БИШЕНЧЕ ТАЛПЫНУ**

Кәнәфидә йокыга талган Мидхәт уяна. Икенче бүлмәдән Энҗе йөгереп чыга.

Энҗе. Кем?! Азат, синме?! *(Ишекне ача.)* Ай Аллам!

Фәнис керә.

Төнлә белән кеше борчып йөрмәсәң ярамагандыр.

Фәнис. Төн түгел, инде таң атып килә.

Мидхәт *(түшеннән арына алмыйча).* Кем? *(Танып.)* Ә! Берәр нәрсә булмагандыр ич, шултиклем иртән... дисәм... *(Саташып.)* Ятим бала булып үсүен теләмәдем... шул гына... Ни булды?

Фәнис. Әни үлде.

Энҗе читкәрәк тайпыла.

Мидхәт *(йөрәген тотып).* Рә... зи... нә... ки... чер... *(Пауза.)* Кайчан?

Фәнис. Таң алдыннан. Төнлә үләсе килмәде... «Таң атса иде, кояшны күреп үлсәм ярар иде» дип саташты... Беренче кояш нурлары күренгәч, аның ничек шатланганын күрсәгез икән...

Мидхәт. Изге җан иде, изге җан...

Фәнис. Ә ул көтте сине, әти, ахыр сулышына кадәр... *(Күз яшенә буылып.)* Сине чакырды, сине... Киләрсең дип көтте...

Мидхәт. Кичер, Рәзинә... Яныңа килә алмадым, син үзең килдең...

Энҗе *(Мидхәтнең маңгаеннан тотып).* Саташмыйсыңмы? Ничек ул синең янга килә алсын?!

Мидхәт. Күңелеңдә, теләгеңдә булса... барына да ирешергә була...

Энҗе. Тынычлан, Мидхәт, тынычлан.

Фәнис алтын әйберләрне өстәлгә китереп сала.

Энҗе. Нәрсә бу?

Мидхәт. Фәнис, ни бу?

Фәнис. Алтыннарны кире кайтарам. Кичерегез. Бүтән урламаска сүз бирәм. Алыгыз, миңа кирәк түгел алар... Хәзер...

Мидхәт. Хәзер? Алар хәзер сиңа, киресенчә, кирәк булырга мөмкин.

Фәнис. Юк, кирәкми.

Энҗе. Мидхәт, алып куй инде...

Мидхәт. Сиңа кирәк булды бит, син алып та куй. Әйбер, әйбер, дия-дия, тәмам кешелектән чыктык инде... *(Саташып.)* Җаныбызны, рухыбызны саттык шуңа...

Энҗе. Сүзеңдә тора беләсең икән, егет, көтмәгән идем. *(Алтыннарны җыеп куя.)*

Мидхәт *(Фәнискә).* Син миңа аңлат әле, хәзергә кадәр аңламыйм, сиңа бу алтыннарны урлау ниемә кирәк булды? *(Пауза.)* Нигә дәшмисең?

Фәнис. Әни бик каты авырды. Аны дәвалар өчен акча кирәк булды. Дару алырга акча юк. Ә мин эшләмим. Аптырагач, әнине шатландырырга теләп, алтыннарны урлап, акчага әйләндерергә иде исәбем. Әнигә акча алып кайтырга, кирәкле дарулар сатып алырга уйладым. Әнигә операция кирәк иде, ә аны ясатырга акча юк. Ә каян табасың?!

Мидхәт. Алдан ук әйткән булсаң, булышкан булыр идек, хәлеңә кергән булыр идек.

Фәнис. Бирмәссез дип уйладым.

Мидхәт. Хәер, үзем дә гаепле. Үзем үк аңларга тиеш идем. Димәк, акча сиңа өйләнер өчен түгел, ә әниеңә, әниеңне терелтер өчен кирәк булган. Ә без шуны аңламадык...

Фәнис. Алтынны урлаганымны, кемнән урлаганымны ялгыш әнигә тиштем, ул мине бик каты тиргәде. Әгәр хәзер үк кире илтеп бирмәсәң, мин сине бик каргыйм, диде. Мин аңа кире кайтарып бирергә вәгъдә иттем, соңгы көнгә кадәр тоттым. Тик әни генә...

Мидхәт. Аллаһы Тәгалә нигәдер гел яхшы кешеләрне үз янына алып тора. Хәер, яхшы кешеләр анда да кирәктер шул. *(Пауза.)* Син үзең генә килдеңме?

Фәнис. Әйе.

Мидхәт. Ә Зарема кая соң?

Фәнис. Югалттым мин аны. Азат белән иде ул. Таксига утырып киттеләр. Куып җитәргә өлгерә алмый калдым.

Мидхәт. Нәрсә, өйләнешмәскә булдыгызмы?

Фәнис. Өйләнешү сүз генә. Сәбәп чыгарырга гына. Әйе, ул бездә торды... барыр җире булмагач...

Мидхәт. Ярату юк, димәк?!

Фәнис. Юк, ул миңа ошый. Тик аны аңлап бетереп булмый. Кем кирәк? Ни кирәк аңа? Сәер кыз! Юк... хәтәр кыз ул... Ул теләсә кемне акылдан шаштырырга, харап итәргә мөмкин...

Энҗе. Харап итәргә... Туктагыз әле! Минем Азатым аның белән киттемени соң? Берүк баламны харап итеп куймасын тагын! Әле һаман да кайтмаган, кая соң ул?

Фәнис *(кузгалып).* Хушыгыз, мин киттем!

Мидхәт. Тукта, кая?

Фәнис. Миңа әни янында булырга кирәк. Аның янында утырырга дип, иртән-иртүк ике әбине кертеп калдырган идем. Туганнарга әйтергә кирәк. Бүген яисә иртәгә җирлисе булачак...

Мидхәт. Улым! Туктале! Энҗе!

Энҗе. Нәрсә?

Мидхәт. Егетнең чыгымнары күп булачак. Җитәрлек итеп акча бирергә кирәк.

Энҗе. Каян алып?

Мидхәт. Шүрлектән.

Фәнис. Рәхмәт. Мин акча сорарга дип кермәдем, хәбәр итәргә генә дип килдем...

Энҗе акча эзли башлый.

Энҗе. Мин монда акча табалмыйм әле!

Мидхәт. Шундадыр инде, кая булсын!

Энҗе. Кая соң әле алар?

Мидхәт. Яхшылап кара, биш йөзлекләр булырга тиеш.

Энҗе. Бишне түгел, өчне дә күрмим әле мин монда! Бу ни тагын? Язу!

Чыгып китәргә торган Фәнис язу турында сүз чыккач туктап кала.

Мә, укы, малаең язу язып калдырган, минем күзлегем юк! *(Мидхәткә бирә.)*

Мидхәт. «Пап! Мам! Без киттек еракка, чит илгә... Азат, Зарема... Акчасыз булмый... Аңлагыз...»

Энҗе. Чит илгә?! Теге җүнсез кыз беләнме? Тәки әрәм итә икән минем баламны! Чукынып китсен! Аяк чалды бит матур гына барган тормышыбызга!

Мидхәт. «Әти мине яратмый» дип тә язган... Әйе, саташкан бу бала, саташкан. Хәер, без бит барыбыз да саташканнар.

Энҗе. Фәнис! Тукта! Миндә тагын акча бар! Мә, менә ал! Тик син булыш миңа, булыш Азатны табарга! Булышасыңмы?

Фәнис. Булышырмын.

Мидхәт. Энҗе, син нәрсә, Фәниснең мәшәкате муеннан. Әнисен җирлисе бар. *(Кузгалып.)* Мин үзем дә аларга барырга торам...

Энҗе. Ә бала? Азат?! Мә, ал! Тап Азатны! *(Фәнискә бераз акча бирә.)* Мә!

Фәнис *(елый).* Юк, кирәкми. Ә Азатны табармын мин, табармын аларны, обещаю, сау булыгыз! *(Чыгып китә.)*

Мидхәт. Бир монда! *(Калган акчаларны тартып ала.)* Мин Рәзинәне озатышырга барам. Күмү эшләрен үз өстемә алам.

Энҗе. Ничек? Улың чит илгә качкандамы?

Мидхәт. Вакыт бар әле.

Энҗе. Самолеттадыр инде алар...

Мидхәт. Хыял ул! Алар бит балалар гына әле!

Энҗе. Алай димә, алай җиңел карама...

Мидхәт. Әйттем бит, алар беркая да оча алмаслар!

Энҗе. Нишләп?

Мидхәт. Аларның загранпаспортлары юк.

Мидхәт, киенеп, ишеккә бара.

Энҗе. Барасыңмы?

Мидхәт. Якын кешем белән соңгы тапкыр хушлашырга хакым бардыр бит?! *(Чыгып китә.)*

Энҗе утырып кала. Караңгылык.
«Бу тәүге сөю, тәүге мәхәббәт» көе яңгырап ала.

**АЛТЫНЧЫ ТАЛПЫНУ**

Ут яктыра. Мәйданчык янындагы эскәмиядә — Азат белән Зарема.

Азат. Ниндидер юк кына, кечкенә генә нәрсә аркасында китә алмыйбыз бит, кызганыч! Димәк, көтәргә кирәк. Загранпаспорт ясатырга кирәк.

Зарема. Юк, берни дә барып чыкмаячак. Алар синең акча алганыңны инде сизеп, күреп алганнар. Хәзер алар сине эзләтә башларлар. Табарлар. Әниең синең өчен үлеп тора бит.

Азат. Ә мин барыбер китәм. Әтине яратмыйм мин, барысыннан да качарга телим...

Зарема. Бала, бала әле син...

Азат. Көлмәле! Син бит үзең теләдең каядыр китәргә!

Зарема. Еракка, чит җирләргә китү зур хыялым гына булып калыр, ахрысы! Хәер, мин үзем дә бик үк ашкынып тормыйм инде китәргә.

Азат. Сине аңламассың! Нишләп алайса котырттың мине? Сүзеңнән кире кайтасың! Кая ашкынасың син? Кемгә тартыласың?

Зарема *(көйләп)*. «Кая шулай ашкынасың, йөрәк...» Минем Фәнисне күрәсем килә, минем аңа сүзем бар...

Азат. Ой! Һаман шул Фәнис тә Фәнис. Таптыгыз бер герой. Күралмыйм, күралмыйм мин аны хәзер!

Зарема. Ну ярар, кызма! Нишләп син шундый, ә?! Сиңа бер сүз дә ярамый.

Азат. Туйдым... бала-чага булып... Ә мин бит барысын да булдыра алам. Мин машина йөртә беләм, компьютерны от и до беләм. Минем менә дигән «Хонда» мотоциклым бар, ә Фәниснең юк. Фәнис әле ул машина да йөртә белми. Теләсә нинди бию башкара алам: «хип-хоп», «рэп», «брейк»! Телисеңме, күрсәтәм?!

Музыка. Азат «брейк» бии.

Зарема *(әкрен генә кул чабып).* Браво! Браво! *(Азатның башыннан сыйпап.)* Матурым... син миңа ошыйсың... Синнән менә дигән егет чыгачак. Ты будешь крутым! Фәнискә караганда синең перспективаң күпкә югарырак... Тик син... бала... бала шул әле...

Азат *(җилләнеп).* Ну ладно, җитәр! Заладила: бала, бала. Я сам знаю, что мин бала!

Зарема. Борчылма, әле син яшь. Синең тормышыңда әле күпләр очрар, миннән әйбәтрәкләр! Ә мин сине харап кына итәрмен...

Азат. Ә минем, киресенчә, харап буласым килә. Туйдым... барысыннан да... әнидән, әтидән... Качасым килә... От этой дурацкой морали... Минем үземчә яшисем килә, үземчә... Әйдә, тор, киттек!

Зарема. Кая?!

Азат. Барыбер өйгә кайтмыйм! Әгәр загранпаспорт юк икән, киттек әйдә Кырымга! Киттек!

Зарема. Нәрсәгә?

Азат. Нәрсәгә? Ял итәрсең! Син бит диңгез буенда ял итәргә хыялланган идең. Менә мин сине чакырам, тор әйдә... Ерак булыйк болардан, барысыннан...

Зарема *(торып).* Син акылыңдамы? Нишлисең?

Азат. Киттек! Турагентствога барып путевка алабыз да, и аллюр! Киттек! *(Зареманы тарта.)* Тизрәк әйдә, җебемә!

Азат әйберләрне ала. Зарема теләми генә аңа иярә.

**СОҢГЫ ТАЛПЫНУ**

Аларның каршыларына Фәнис килеп чыга. Фәнис Зареманы, кулыннан тартып алып, читкә ата. Зарема, чайкалып китеп, таганга ки-
леп утыра. Фәнис Азат каршына килеп баса.

Азат *(куркып).* Йә, сук, сук! *(Позага баса.)*

Фәнис. Тынычлан... Бир бишне! *(Кул бирә.)*

Азат шикләнеп кенә кулын суза.

Фәнис *(Азатны кочаклап).* Син бит миңа энекәш, брат... Ачуланма...

Азат. Мин?! Сиңа?!

Фәнис. Теге чакта кызурак кыланып ташладым. Мин бит сиңа сугарга теләмәгән идем... Әйдә, онытыйк үткәннәрне. Туган булыйк. Безнең тәндә бер кан ага, әти каны... Шулаймы, брат?

Азат. Шулай... брат. *(Сөенә.)*

Фәнис. Шулай булып калыйк та...

Азат *(юмартланып).* Брат... телисеңме мин сиңа мотоциклымны бүләк итәм.

Фәнис. Ә үзең нәрсә белән каласың?

Азат. Әти яңаны алыр.

Фәнис. Әти... әти... Әтиеңә генә ышанма, күбрәк үзеңә ышан. Миңа ышана аласың, чөнки син минем брат... энекәш...

Азат. Мотоцикл теләмәсәң, компьютер бүләк итә алам.

Фәнис *(җилкәсеннән кагып).* Энекәш... Азат... Аңла, миңа синнән берни дә кирәк түгел. Сиңа минем бер генә үтенечем бар.

Азат. Нинди?

Фәнис. Өеңә кайт. Сине анда көтәләр. Әниең көтә... борчылып...

Азат *(башын аска иеп).* Юк... кайтмыйм...

Фәнис. Курыкма... Әниең сине ачуланмас... Ә мин аңа сүз бирдем.

Азат. Нинди сүз?

Фәнис. Сине табарга, сине өйгә кайтарырга. Ә мин биргән сүземдә торырга яратам.

Азат. Мин...

Фәнис. Энекәш, брат... син мине аңла!

Азат *(елмаеп).* Понял... брат...

Фәнис. Брат!

Азат. Брат! *(Учка-уч, кулга-кул сугышып аерылалар.)*

Ритмик музыканы талгын көй алыштыра. Фәнис таганда чайкалган
Зарема янына килә. Салмак кына таганны этә.

Зарема. Фәнис... бу безнең соңгы атынумы? Соңгы талпыну?

Фәнис. Ә син ничек уйлыйсың?

Зарема. Мин синең алда гаепле... Качтым... Сине дә, әниеңне дә...

Фәнис. Әни вафат.

Зарема *(сискәнеп).* Вафат?! *(Пауза.)* Син... син мине ташларсыңмы?

Фәнис. Юк. Мин сине беркайчан да ташламам. *(Кочагына ала.)* Синең дә бит минем күк беркемең дә юк... Без бит икебез дә ялгызлар... Ике ялгыз һәрвакыт бер-беренә тартыла...

Зарема. Мин бит явыз, усал...

Фәнис. Мин бит сине ничек бар, шулай кабул итәм...

Зарема. Нигә?

Фәнис. Белмим... яратам, димәк.

Фәнис таганны тагын да катырак этеп җибәрә. Зарема һавага оча.
Җыр яңгырый:

Таганда атынып,
Кошлардай талпынып
Очтык без болытка,
Очтык без болытка...

...Тормыш ул, таганда атыну кебек, бер күккә чөя, бер җиргә төшерә...

Караңгылык. Зарема югала. Фәнис таган янында басып тора.

Фәнис *(тамашачыларга).* Ә хәзер сез атынып карагыз, ягез, килегез. Тик беркайчан да ялгыз гына атынмагыз...

Пәрдә.

## ЭЧТӘЛЕК

Газиз ярым ......................................................................................................
Ялгыз тәкәрлек ...............................................................................................
Артык гомер ....................................................................................................
Ялгыз каен күзе...............................................................................................
«Кызыма килер йөз кеше» ..............................................................................
Җырлап керәбез, җырлап чыгабыз ..................................................................
Хатыным-алтыным ...........................................................................................
Нәфига ханым ..................................................................................................
Атындык без таганда........................................................................................

Литературно-художественное издание

***Ибрагимов*** *Хабир Кабирович*

РОДНЕНЬКАЯ

(Пьесы)

Казань. Татарское книжное издательство. 2006

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

***Ибраһимов*** *Хәбир Кәбирович*

ГАЗИЗ ЯРЫМ

(Пьесалар)

Мөхәррире *Ф.М.Хафизов*
Рәссамы *В.В.Фомин*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *В.А.Савельева*
Корректорлары *С.Н.Галимуллина, Г.Г.Гарифуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 24.04.2006. Форматы 84×108 1/32.
Офсет кәгазе. «School Book» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 16,8. Шартлы буяу-оттиск 17,22.

Нәшер-хисап табагы 16,27. Тиражы 3000 д. Заказ З-261.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.